ISSN 0206–4189
Индекс 73210

# Казан утлары

9.2012




Казанда
«Мөхәммәдия»
мәдрәсәсе ачылуга
130 ел.

**Казан утлары**
**Qazan utlari**

2012

# 9
**(1079)**

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:
«ТАТМЕДИА»
ачык акционерлык җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Рәдиф Гаташ**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир, Камил Кәримов, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

✉✉: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир—562-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары—562-10-38.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—562-11-53.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—562-11-53.*
*Гамәли хезмәткәрләр—562-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге—222-09-80.*
✆: **Факс**—(843) 562-11-28.
💻: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Зиннур МАНСУРОВ. Сабыр холкым ерак каннан килә. *Шигырьләр.* ........ 5
Вахит ИМАМОВ. Утлы дала. *Тарихи роман* ........ 10
Рифә РАХМАН. Сан-зат тыйз-зи. *Бәян.* ........ 56
Асия ЮНЫСОВА. Иҗат көчен данлар алтын җитмәс. *Шигырьләр.* ........ 67
Таһир НУРМӨХӘММӘТОВ. Кабан күле, әй, алкын. *Бәян.* ........ 72
Нури АРСЛАНОВ. Азат җанлы булып туганмын мин... *Шигырьләр. (Р.Фәйзуллинның кереш сүзе белән)* ........ 105
Рүзәл МӨХӘММӘТША. Өч хикәя. *(М.Закирның кереш сүзе белән)* ........ 108

**КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫННАН**

Әсхәл ӘХМӘТ-ХУҖА. Тормыш тоташ әкияткә охшаш. *Шигырьләр* ........ 51
Василий ШУКШИН. Ана йөрәге. *Хикәя.* ........ 115

**ФӘН**

Флера ГАНИЕВА. Әдәби әсәр һәм тәнкыйть логикасы. ........ 126
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы ........ 149
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ........ 152

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Фәрит ЯХИН. «Оча торган кешеләр» яки ак тәс тантанасы. ........ 131
Фәрит ХАТИПОВ. Әсәрләребезгә ни җитми? ........ 134

**КӘРИМ ТИНЧУРИННЫҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ**

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. Вакытсыз сүнгән йолдыз. ........ 139

**ОЧРАКЛЫКЛАР ОЧРАКЛЫМЫ?**

Фәнзаман БАТТАЛ. Әҗәл миңа өч тапкыр янады. ........ 155

**ХӘТЕР**

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Карурман җанлы кеше. ........ 164

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Рәйсә ЮСУПОВА. Сәйдәш, Еники һәм... зәңгәр костюм кыйссасы. ........ 167

**АК ҖИЛКӘН**

Ләйсән ИСХАКОВА. Мин калам көзләрдә... *Шигырьләр.* ........ 173
Миңзифа ӘХМӘТШИНА. Сары яулык. *Хикәя* ........ 175

**ПЕЧӘН БАЗАРЫ**

Мөнир АБДУЛЛИН. Башлык килгәч. *Хикәя.* ........ 182
Халидин ӘХӘТОВ. Нигез көче. *Нәсер* ........ 185

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........ 190

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман В.ИМАМОВА «Огненная степь» (начало);
повесть Т.НУРМУХАМЕТОВА «Озеро моей юности»(окон.),
повесть Р.РАХМАН «Сан-зат тыйз-эи»; рассказы Р.МУХАМЕТШИНА, В.ШУКШИНА; стихи З.МАНСУРОВА, А.АХМЕТХУЖИНА, А.ЮНУСОВОЙ, Н.АРСЛАНОВА.
«Наука»: статья Ф.ГАНИЕВОЙ «Литературное произведение и логика критики»;
Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень».
«Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Литературная критика»: рецензия Ф.ЯХИНА на книгу Г.Гильманова «Летающие люди»; статья Ф.ХАТИПОВА о современной прозе; статья А.ЗАКИРЗЯНОВА, посвященная 125-летию К.ТИНЧУРИНА.
«Случайны ли случайности?»: Ф.БАТТАЛ. «Смерть трижды мне являлась».
«Память»: Р.ЗАЙДУЛЛА. «Он рано ушел...»
«Рассказы из жизни»: Р.ЮСУПОВА. «Сайдаш, Еники и история синего костюма».
«Белый парус»: стихи Л.ИСХАКОВОЙ;
рассказ М.АХМЕТШИНОЙ «Желтый платок».
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Памятник М.Джалилю в г. Москве; писатель Ахат ХАБИБУЛЛИН.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novel by V.IMAMOV «Fire prairie» (beginning);
story by T.NURMUHAMETOV «Lake of my youth» (ending),
story by R.RAHMAN «San tyyz sam-zi», stories by R.MUHAMMETSHIN, V.SHUKSHIN; poems by Z.MANSUROV, A.AHMETHUZHIN, A.YUNUSOVA, N.ARSLANOV.
«Science»: article by F.GANIEVA «Literary work and logic of critics'»;
F.GARIPOVA. «History of our villages».
«Pages of «Tatar Encyclopedia».
«Literary criticism»: book review by F.YAHIN on book by G.Gilmanov «Flying People», article by F.HATIPOV about modern prose; article by A.ZAKIRZYANOV devoted to the 125th anniversary of K.TINCHURINA.
«How random is random?»: F.BATTAL. «Death came three times to me».
«Memory»: R.ZAYDULLA. «He went away early...»
«Stories of life»: R.YUSUPOVA. «Saydash, Eniki and history of blue suit».
«White Sail»: poems by L.ISKHAKOVA;
story by M.AHMETSHINA «Yellow shawl».
From photo archives of magazine.
Diary of social and cultural life.
On our covers: M. Jalil monument in Moscow; Writer Akhat KHABIBULLIN.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция жавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә жыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 03.09.2012, график буенча 03.09.2012.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ М – 927. Тираж 4014.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ТУ 16-00337.
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААЖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2012 ел.



Зиннур
Мансуров

# САБЫР ХОЛКЫМ ЕРАК КАННАН КИЛӘ

## Хуҗалар тавына менү

*Алга — кояш чыгышына, уңга — көн уртасына, артка — көн батышына, сулга — төн уртасына кадәр сузылган җирдә яшәүче халыкны тупладым.*

Күлтәгин истәлегеннән

**Ялангач аяклы оландай,**
**яланнан никадәр җир бардым.**
**Җанымның узгынчы гамьнәрен**
**инешкә агызып җибәрдем.**

**Җырладым үзәнне яңратып,**
**әйтерсең илгизәр ашуг мин...**
**Хуҗалар тавына менгәндә**
**бушанып калырга ашыктым.**

**Ләйсәнле болытлар катыннан**
**бөркелеп исерткеч тын килде.**
**Биектә фәрештә канаты**
**кагылып киткәндәй тоелды.**

**Күптәнге теләккә ирештем —**
**шуңадыр күңелем көр менә.**
**О, моннан Болгарлар, Биләрләр,**
**Суварлар, Урдалар күренә!**

**Рәшәле тарафлар артында**
**ханлыклар шәйләнә күземә.**
**Таркалган каһанлык җирләре...**
**Аларның барсы да үз миңа.**

**Мәхрүмлек чикләрен ап-ачык**
**күрдем мин Хуҗалар тавында.**
**Кальбемә үзләшкән гамьнәрем**
**әйләнеп кайттылар тагын да.**

---

Зиннур МАНСУРОВ (1949) — *шагыйрь, публицист; «Кул бирам», «Ваем», «Күңел сәфәре», «Җәрәхәтле йөрәк җылырак», «Күңелдә фидаи яшәсә» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Бугазда кан-яшьтәй бөялде
ямьшәнле даланың бар исе.
Күченгән комнанмы сорарга:
«Без монда кемнәрнең варисы?»

Хәтердә чагылган манзара
томанга күмелер төш инде.
...Мәһабәт Хуҗалар тавыннан
әрнүле халәттә төшелде.

## Арканланган чалгычы

Төшкә кертеп, гамен салып, күзгә төртеп,
гарше әгъля ничә тапкыр искәртте.
...Ташкирмәннең бик-бик текә итәгендә
печән чаба Хозыр сыман ил карты.

Үзен-үзе чылбыр белән бәйләп куйгач,
аягында егылмыйча нык тора.
Тыныч кына сәйран кылып булмый монда,
шундый урын: йә кан, йә тир йоттыра.

Биеклектә ничек кенә бөекләнмә,
күкләр ала — Аллаһ шулай боерган.
Идел-йортка үлем чәчеп килгән яуның
күпме башы тәгәрәгән бу үрдән!

Шәрран ачып күрсәтелгән яра кебек,
янәшәдә шәрәләнгән ур кала.
Дивар буйлап печән чаба милләт карты,
чалгысына канлы үлән урала.

Тукранбашлар агып төшә авышлыктан,
гүя аста һаман көйрәп куз ята.
Янавычның чыңгылдатып җибәрүе
офыктагы яшен дәртен кузгата.

Чит-ят җиргә кулын сузар үчле чирү
урган-кискән — кылыч бәйдә булмаган.
Тирә-юньдә яшел үлән үстертмичә,
баскынчылар аны күпме буйлаган!

... Төшкә кертеп, гамен салып, күзгә төртеп,
гарше әгъля ничә тапкыр искәртте.
Ташкирмәннең бик-бик текә итәгендә,
үзен бәйләп, печән чаба ил карты.

## Дәкыйка

*Минем сәгать әкрен йөри бугай...*
Газинур Морат

Тәҗел бурыч алга килеп басса,
уфылдамыйм җегәр, дәрт юкка;
миңа бераз вакыт җитеп бетми,
җитеп бетми тик бер дәкыйка.

**Теге елда үлеп яткан бабам**
**тынгы бирми миндәй чал иргә, —**
**азга гына соңлый төштем аңа**
**«Мин тудым!» дип аваз салырга...**

**Гөрләвекләр белән йөгерештем —**
**бала чакта барсы тиз кирәк.**
**Әмма йөрәк баштук типте бугай**
**артка калган сәгать төслерәк.**

**Кайчак миңа тик бер мизгел җитми,**
**теләмимен өстәп күп көн дә.**
**Күрә алмый калдым — Илаһ сүзе**
**пәйда булгач авыл күгендә...**

**Тешләк мәлем тулы гасыр сыман**
**тоелгандыр газиз әнкәмә.**
**Гафу сорар өчен вакыт тапмау**
**ачысыннан саркып... кан тама.**

**Ил-җиремне яклап, өлгерлекләр**
**күрсәтергә күпме җай килде!..**
**Кулдан киткән иллә мөһим минут**
**Инде хәзер байтак җыелды.**

**Вакыт җитмәү тышау кебек кыса,**
**җанда яшьлек дәрте кабынса.**
**Гомер буе юкса артык көнен**
**бүләк итә барды кабисә.**

**Сабыр холкым ерак каннан килә,**
**инде үзгәрергә көч тукмәм.**
**Минем сәгать аз-маз артка калды,**
**Хөкем мәйданына кичекмәм.**

**Мондый фигыль, белмим, күпме торыр —**
**барсы өчен җавап бирермен.**
**Хәзер исә, мырлап, көен сузам**
**бакыйлыктай озын бер җырның.**

## Искәртү

**Каләм әһле әүвәл тәкрар кыла:**
**«Сәләт иңә гарше әгъләдән!»**
**Соңра үзен гайре хәлгә кертә**
**әллә тәкәбберлек, әллә дан.**

**Бәгъзе затлар зурдан кубып раслый:**
**«Язар каурый бирде фәрештә...»**
**Күкләр насыйп кылган илһам белән**
**башкарылса икән бар эш тә.**

**Каләм әһле кайчак артык горур,**
**йөртә, имеш, Ходай тамгасын.**
**Хәйран булып сорар кебек һатиф[1]:**
**«Ничек менден Парнас-тауга син?»**

[1] һатиф – күктән иңгән тавыш.

**Сиңа сөаль биреп кенә калмас,**
**искәрткәндәй итеп кычкырыр:**
**«Тулып ашкан вәкарь сүзгә күчсә,**
**гамәл дәфтәреңә көч килер!»**

**Каләм әһле башта тәкрар кыла:**
**«Иҗат могҗизасы Алладан!..»**
**Рәхмәт укыр иде — тыеп тора**
**әллә тәкәбберлек, әллә дан.**

## Учак җырлый...

**Качкын төсле ялгыз башым учак ягып,**
**кара урман аланында төн кундым.**
**Таңга хәтле дәһшәт утын хөкем иттем,**
**таңга хәтле изге утка тукындым[2].**

**Шундый тирән моң-зар белән җырлый учак,**
**күзләремә ирексездән яшь килә.**
**Минем алда манаралар тетрәп ава,**
**өскә таба янар таулар ишелә...**

**Шушы сихри учак аша уза сыман**
**җирдә гомер сөрүнең бер үткеле.**
**Төнге төтен нинди генә рәвеш алмый,**
**ничек кенә ымын салмый ут теле.**

**Әллә инде шәһит киткән затлар җаны**
**чыгып оча кызгылт рәшә эченнән?!**
**Мәрхәмәтсез утта яна рәхмәтләрем,**
**игелекле утта яна үч-кинәм...**

**Кара урман уртасында дөрләп торган**
**төнге утта ничә төрле ут күрдем!**
**Моң-зар белән җырлый-җырлый янды учак,**
**ә мин менә... еламсырап утырдым.**

## Хәрәкәт

*Каләм очындагы ут сүнгәнче*
*Яши алсам — калмас үкенеч.*
Фәнис Яруллин

*Милләт хәлен тетрәгән*
*куллар белән язып бирү бу...*
Габдулла Тукай

**Җаны барның юне килми калмас —**
**моны тоеп яши карт-яше.**
**Хәрәкәтсез килеш бәрәкәтне**
**яулап ала урын хастасы.**

**Һәркем күрә белми яшәү ямен**
**тәкъдир суккан кара тамгада.**
**Галәм иңнәр акыл тетрәп тора**
**селкенмичә яткан тәндә дә.**

[2] Тукыну – баш ию мәгънәсендә.

Дөнья тоташ киртә корып куйган,
кичкән бахыр ничә бусага, —
билгеләнгән язмыш биләмәсе
ятак хәтле генә булса да.

Тынгы белмәс йөгрек зиһен белән
кузгалышсыз күпме үр алган;
тамыр буйлап аккан терек каны
Җирне мең-мең тапкыр ураган.

Милләткенәм, диеп әйләнгәндә
йөрәккәе ничек савылган!
Иман качкан чирле илдә яшәп,
ярый әле рухы сау булган...

Зәгыйфь гомер җебен ялгап торган
Аллаһ насыйп иткән һәр рәхмәт.
Бимазалы урын хастасының
үзәгендә типкән хәрәкәт.

Куктән ярдәм көткән адәм генә
кыла алыр мондый гамәлне.
...Җаны барның юне килми калмас —
гаҗәп хәлләр була кай мәлне.

## Ай юлы

Кендек бавы миңа хөрлек биргәч,
дөнья буйлап күпме юл үттем!
Төнге күздә салкын айга карап,
садә уйларымны җылыттым.

Терек җанга туктый алмау төстер:
мүкәләдем, чаптым, ук булдым;
гаҗиз башны горур чөйгән хәлдә,
алга таба атлап егылдым.

Миңа шулай илтү тиеш иде
«Тәпи бастым!» дигән хәбәрне.
Инде хәзер акыл аша барлыйм
хәтеремә сеңгән һәр мәлне.

...Сабан туе. Чүлмәк ватам, имеш,
җиде-сигез адым ясадым.
Күзне чишеп, арткы якка баксам —
шундый ерак калган яшь чагым.

Серле төстә гелән раска чыкты —
төштә очсам, өндә алдырдым.
Кыеш эшкә намус киртә куйса,
үз-үземә бераз ял бирдем...

Тизрәк суксын, диеп, безнең сәгать,
кичтем гомеремнең ай-елын;
даим йөреп торгач, аяк шәрфем
мөһерләде бөтен ай юлын.

Салган эзләр үзем кадәр булды —
мин кәрлә дә түгел, алып та.
Адәмлекне сынар адымнарның
барысы да калды алыста...

Кендек бавы миңа хөрлек биргәч,
кирәк иде күпме чаялык!
Айга кадәр атлап үттем бугай,
инде кире кайтыр чамам юк.



Вахит
Имамов

# УТЛЫ ДАЛА

ТАРИХИ РОМАН

## ИКЕНЧЕ КИТАП*

### БЕРЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

1

Тимучинның тантанасы озакка сузылмады. Хан итеп keләмгә күтәрүләренә ике-өч ай да вакыт үтмәгәндер, әрем суыдай ачы хәбәр китерделәр.

— Җәмуганы гади хан гына түгел, гүрхан итеп сайлап куйганнар. Үзенең чатҗират кабиләсе белән безнең күптәнге көндәшләребез — тайҗутларны әйткән дә юк инде. Алардан башка да Кырүлән буендагы җәйләүгә уникеунөч кабилә-ырулардан вәкилләр җыелган ди. Коралас, сәлҗүт, икәрәс, хадакин ырудан берәр күрем нәүкәр кушылган. Татарлар үзләренең коңгырат, җыен, дөрбән кабиләләреннән меңәр-меңәр яугир җибәргәннәр. Җәмугага найман кабиләсенең башлыгы Даян ханның энекәше Боерык-хан белән яубашлары Күксәй-Сабыр, синең кан дошманың булган мәркетләрнең бәге Кара-Чылгыр килеп кушылган. Һәм ышансаң ышан, ышанмасаң юк, ул җыенда синең җан дустың булып кыйланып йөргән Тогрул ханның улы Сәнгум катнашкан ди. Менә шулар барысы бергә укмашкач, Җәмуганы өлкән хан, гүрхан итеп келәмгә күтәргәннәр. Хак булса, Җәмуга кул астындагы җайдакларның саны хәзер утыз мең чамасы исәпләнә икән...

Тимучин әүвәл эчендәге утны күрсәтмәде. Бүрехан тавының иң яшерен бер почмагына менде дә уйга калды.

Җәмуганы гүрхан итеп күтәргәннәр. Күпчелек кабилә, берничә кавем юлбашчысы, димәк. Аны инде магуллар гына түгел, күршедәге найман, мәркет, гәрәй кабиләләре дә, кара татарлар да якын-тирәдәге бөтен дала

---

* Журнал варианты.

Романның беренче китабы "Казан утлары" журналында 2000 елның 1-3 саннарында басылды.

---

Вахит ИМАМОВ (1954) – *прозаик; «Нәзер», «Сәет батыр», «Татарлар Пугачев явында» һ.б. китаплар авторы. ТР Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премиясе лауреаты. Чаллыда яши.*

хакиме итеп таный дигән сүз бу. Ә син, Тимучин-кара, бернинди Чыңгызхан да, юлбашчы да түгел. Торгытай кулында әсирлектә чакта ниндирәк кол, нинди карачу булгансың, магул кабиләләре өчен син бүген дә шундый ук мескен бозау икәнсең бит. Чыңгызхан итеп сайлаганда алты кабилә катнашты дип син үзеңне юкка гына юатасың икән. Урут, мангыт, исут кабиләләрендәге аксөякләрнең һәм нәүкәрләрнең күпчелеге, әнә, синең кичәге атаулы туганың Жәмугага барып кушылган. Синең атаулы атаң булып саналып йөргән Тогрул ханның улы Сәнгум да Жәмуга ягына чыккан. Даладагы күпчелек кабилә-ыру Жәмуга ягына ауган, син үзеңнең карендәш-кардәшләрең белән генә торып каласың түгелме соң? Житмәсә, агаларың — Алтын, Кучар, Сачә бәкләргә таянырлыкмыни?! Алар әле тегенди, әле мондый тәкъдим белән кергән булып, сиңа үзләренең көенә биетмәкче. Ә хәвефле хәл туа, халыкларны үзебезгә буйсындырмый торып, ошбу жир йөзендә берчакта да гадел хәят нигезләп булмаячак. Бер генә юл кала һәммәбезгә. Яу һәм кылыч, яу һәм кылыч! Жиһандагы соңгы диңгезгә, жир читенә барып житкәнчегә кадәр шул гына юл!..

«Бөтен жиһанны соңгы диңгезгәчә үзеңә буйсындырып бетерәсең икән, ул чагында син жир өстендәге Мәңгелек Күк Тәңре буласың түгелме соң, атай?» — дип кычкырасы килде Жучиның шул вакытта, әмма үзенең үлем белән уйнавын чамалап, телен тешләп калды. Ә Чыңгызхан исә сөйләмендә инде тәгаен адымнарга да күчкән иде.

— Мин әле кояш баешы ягындагы илләрне генә телгә алдым. Ә мондый суеш һәм кан коюлар жиһанның һәрбер тарафында хөкем сөрә. Шуңа күрә жир йөзендә тәртип урнаштыру өчен мин Мәңгелек ил гаскәрен дүрт өлешкә бүләргә карар кылдым. Шушы дүрт өлеш гаскәр, жиһанның дүрт ягына таралып, бар илләрне безнең каханатка кушарга тиеш була. Тибет тавында минем шәхси дошманым Шидүр хан бар. Мин үзем шул тарафка юнәләм дә аны буйсындырам. Башка тарафларга минем өч угылым гаскәр башлыклары булып барачаклар.

Шул чагында каханатның баш казые булып торган Шаһи-Котыг нойон аваз салды.

— Син үзең дә, янә өч улың да яу сәфәрләренә чыгып китсә, безнең Мәңгелек илнең үзәк канаты, мондагы пайтәхет белән идарә итәргә кем кала соң?

Чыңгызхан, чебен куган сыман, кулын гына селтәп жавап тотты.

— Арбаны атның алдына китереп жигәргә маташма инде, ашыкма син, казый. Барысы да төптән уйланылган. Мин моңа чаклы бер улыма да хан дәрәжәсе йөртергә юл куймаган идем. Ә менә моннан ары безнең каханат жирләре белән миңа буйсынган янә дүрт хан идарә итә башлаячак. Илнең үзәк канаты, элеккеге мәңгелләр иле, пайтәхетебез итеп күтәрелгән Каракорым, Чин дәүләте белән чиктә яткан жирләр — һәммәсе дә моннан ары төпчек улым Тули ханга буйсыначак.

Нойон-бәкләр, вак-төяк кабилә солтаннары һәм, аеруча, Онон, Аргын елгалары, Буир-Нур, Колын-Нур күлләре буеннан ук Харәзем жирләренә тикле килеп житкән карт мәңгелләр дулкынланып-шашып кычкыра башладылар.

— Тули хан! Тули хан! Иске мәңгел жирләренең ханы, үзебезнең хаким!

Аның каравы, шул минутларда ук Чыңгызның өлкән уллары йодрыкларын кысып йомарлады. Каен тузы сыман бөтәрләнгән куе кашлары астында усал ут кабынды. Моны үтәли күреп торса да, Чыңгыз кахан ашыкмыйча гына, бик вәземли-вәземли дәвам итте.

— Мәңгелек төн ягында, котып якта йөзәрләгән вак-вак ыру-кабиләләр

көн итә һәм алар бер-берсен туктаусыз кыра булыр. Алар арасында кыргызларның Сип-ир кабиләсен[1] аеруча көчле, гаярь диләр. Мин ул котып ягындагы Сип-ир җирләрен дә, Таш Билбау артындагы Болгар ханлыгын, урыс кенәзлекләрен, Кыпчак далаларын, Кырын Атауны буйсындыру бурычларын өлкән угылым Җучи ханга йөклим.

— Бик хуп, бик хуп, бик әйбәт! — дип инкүлектә бердәнбер ир-ат кына аваз салды. Ул эче-җаны үч һәм мәкер белән тулы Чагатай иде. Башка һичбер кеше эндәшмәде. Җучи үзе кара көеп чыкты. Уртларын, йодрыкларын усал шыгырдатты. Зиһене аша, чебен-черки болытыдай мыжгып, меңләгән уй үтте. «Тартар теленнән табар ди. Вакытында телне тешли белмәгәнем өчен бер җәзадыр инде. Юкса ул мине фарсылар сөйли торган җәһәннәм артына җибәрер идемени? Мин — өлкән угыл, атай урынына алмаш булып игълан ителергә тиеш кеше. Ә алмаш угыл андый җәһәннәмгә озатылырга тиеш түгел иде. Димәк, тәхеттән еракка җибәрә, юри читләштерә мине атай-кахан. Ә ул чагында кахан алмашчысы булып кем кала соң? Каһәр төшкере Чагатай-имгәк түгелдер лә инде?..»

Җучи күнелендә янган утны сизеп алды бугай, тамак кыра-кыра Чыңгыз янә тезде.

— Мин сиңа, өлкән угылым буларак, иң күп, иң чиксез җирләрне бирәм. Иң җаваплы яу ягы да — сиңа! Урыслар җиреннән соң да әле көнбатыш ягында дистәләгән яңа илләр ята. Һәммәсен дә үз аяк табаның астына тезеп сал! Синең атыңның тояклары соңгы диңгез ярына тикле барып житсен. Әгәр ул яктагы барча илләрне дә буйсындырсаң, җир йөзендә синнән дә гайрәтлерәк хаким булмаячак!

Җучи әле һаман авыз ачмый торгач, аның янындагы Сүбүдәй телгә килде.

— Син бик дөрес хәл иткәнсең, кахан. Ул якта Җәбә белән миңа әҗәтле Болгар иле ята. Шул Болгарны минем ат тояклары таптап үтми торып, җир йөзеннән китәргә хокукым юк! Шушы җайны биргән өчен рәхмәт!

Җучиның да, башка нойоннарның да сорау тулы караш белән күзәтүен күргәч, Чыңгыз кахан бераз ашыга төшебрәк игълан итте.

— Менә шушы Җидесу җирләрен, Хорасанны, угыз һәм уйгыр җирләренең һәммәсен дә икенче угылым Чагатай ханга бирәм.

— Үзәк миңа икән, алай булгач, сиңа алмаш булып та мин каламын инде! — дип Чагатай инде кояш кебек балкырга тотынган иде дә, Чыңгыз аны чираттагы сүзе белән, йөзенә утлы күмер ташлаган кебек, шундук зәһәр өтте.

— Шушы ук үзәктәге Алтай тауларын, Иртеш буйларын уртанчы угылым Үгәдәйгә бирәм. Мин бүген-иртәгә Шидүр ханга каршы яу сәфәренә чыгып китәчәкмен. Мин югында Мәңгелек ил белән идарә итү хокукы да Үгәдәй ханга кала!..

Бер Үгәдәй генә җиде кат болытлар өстенә менеп китте, калган өч угыл үзләрен йөзләренә төкерелгәндәй хис иттеләр. Кичке караңгылык төшкән чакта Чәрчек елгасы ярында Үгәдәйнең чатыры гына торып калган, ә аның өч туганы өч якка аерым ханнар гына түгел, мәңгелек кан дошманнар булып та таралышкан иде. Моны Чыңгызның үзенә җиткерергә фәкать Шаһи-Котыг кына җөрьәт итте.

— Ярты дөньяны яулауга ирешкән җиһангир булсаң да, хата кылдың, кахан. Чирек алма ашап кем туйсын ди? Моннан ары син берчакта да улларыңны кабат үз учагың янына җыя алмаячаксың! Син бүген алардан гомерлеккә колак кактың инде!..

[1] Шушы кабилә исеме соңыннан Себер, Сибирь булып таралган.

## 2

Тангыт ханлыгына төбәп барган чакта Чыңгызхан Киндерле елга ярында туктап, бик олы ау үткәрмәкче булды. Җиһангирнын ау дигәндә ашын да, ялын да оныта торган фидаи вә комар җан икәне хәтта колчура хезмәтчеләргә дә күптән мәгълүм иде, нойон-бәкләр каршы тормадылар. Чыңгызхан үзе шушында яраннарын төркемнәргә бүлде. Киндерле буйлары — кыргый кулан көтүләре белән бик данлыклы дала. Кулан — юлбарыслар, каплан, бүреләр шикелле хәвефле мал түгел. Аны-моны уйлап тормыйча, Чыңгызхан үз янәшәсенә гомер буе җансакчы булып йөргән Каратайны гына бердәнбер юлдашы итеп алды. Башкалар кулан көтүләрен Чин диварлары ягыннан куып китерергә тиеш, ә Чыңгызхан, үз нияте буенча, тайларны, бияләрне куак арасыннан чүкеп кенә утырмакчы иде.

Корып куйган уйлар баштук җимерелде. Көтү башлыгы булып йөргән айгыр аламасын әле күптән түгел генә котырган чүл бүресе тешләгән, шуннан өркеп калган мал хәзер юк кына хәвеф-хәтәрне дә бер-ике фәрсах арасы ераклыктан сизеп ала икән. Кахан яраннары көтүләрне Чыңгыз качкан куаклыкка таба китерә алмыйча хәлдән таеп бетте. Ә ул арада инде Чыңгызның үзенен дә түземлеге коргаксыган иде. Ул яшеренеп утырган ерымнар арасыннан калкынды да, унбиш-егермеләп кенә куланнан торган нәни бер төркемне Киндерле елга ярына таба куып алып китте. Куланнар елга суыннан куркып кала торган беркатлы мал түгел, алар рәхәтләнеп елга аша да кача ала иде. Ләкин көтү башлыгы урынына баскан яралы айгыр качып йөри-йөри өнсез калган бугай. Һич тә уйламаган бер мизгелдә ул капылт борылды да, пычактай тешләрдән хасил уртларын чүлмәк сыман ачып, Чыңгызхан чаптары өстенә ябырылды. Кахан моның ише котырган, чая һөҗүмне бөтенләй дә көтми, шуңа күрә җәясе — иңбашында, кылычы кында иде. Чаптарын аралап калырлык берни кыла алмады. Ә котырган куланның тешләре атның бер як арткы ботын ярып үткән икән. Өнсез калган чаптар җан ачысы белән кешнәп әүвәл аягурә басты, аннары, кан сиптереп, читкә томырылды. Чыңгызхан, баш аркылы әйләнеп, җир өстенә очты. Эчтә нindидер җеп шартлап өзелде, күрәсең, җиһангирның борын тишекләреннән дә, авызыннан да куе кан бөртекләре чәчрәп чыкты.

Җансакчысы Каратай килеп җиткән чакта Чыңгызхан әнә шулай, кара кан тәкеренә-тәкеренә аунап ята иде. Каратай алны-артны уйлап тормый, саксыз сүз ычкындырды.

— Һо, болай булса, эшләр харап, кахан! Синең эчеңдә үпкән шартлаган бит, атна-ун көн эчендә аяк сузуың бар!..

Чыңгызхан ярсу-котырудан күм-күк булып чыкты. Кылычы кыны белән бергә билбавыннан өзелеп читкә очкан иде. Чыңгызхан тезләре өстенә күтәрелә-күтәрелә, Каратайга бер генә сүз әйтте.

— Миңа кылычымны китереп бир әле!

Каратай үзенең нинди хата кылуын аңлап алды бугай, бөтен тәне манма суга батты.

— Куланнар качып бетте. Кылыч бирсәм, минем башны кисәсең лә, кахан.

Чыңгызхан иягенә, сакалына ябышкан кара канны кул аркасы белән сөртеп, күз дә йоммый дәште.

— Коллар хакимнәрнең мескен чагын күрергә тиеш түгел! Кылычны китереп бир!

Каратай читтә яткан кылычны кынынннан тартып алып, ике кулы өстенә сузып килде. Бәлки, гафу итүне дә өмет иткәндер ул. Хуҗасы каршына

тезләнеп, башын түбән иде. Каратай чамалап-үлчәп бетермәгән икән, Чыңгызхан бер мизгел эчендә жансакчының башын чабып атты. Кылычын җилән итәгенә сөрткән чакта бер үк сүзне янә кабатлады.

— Коллар хакимнәрнең мескен чагын күрергә тиеш түгел!

3

Чыңгызханның имгәнүе житди булды, ахры, картайган кахан, ризыксудан калып, түшәк өстенә ауды. Куштаннары моны олы хәвеф сыман кабул итте, шулар хан-угыллар артыннан чапкын юлладылар. Чагатай белән Үгәдәй кул сузымында гына иде, алар үләксә чукырга ашыккан козгын төсле бик тиз килеп житте. Чыңгызханның сырхавы әлләни хафаланырлык түгел икәнлеген белеп алгач, Чагатай вакытны юкка сарыф итеп маташмады, Жучи югалганнан бирле ялгыз аккош төсле каңгырап йөргән Куланхатынның чатырына чумды.

Төпчек Тули да әле Орхон, Онон ярларына кайтып йорт кормаган булган, аны да житез генә кире куптардылар. Ләкин Тули килеп житешкән чакта Чыңгызхан инде хаста түшәгеннән күтәрелгән һәм авыр гыжылдап булса да, барыбер, тернәкләнү ягына баскан иде.

— Мин теге дөньяга күченергә исәпләмим әле, юкка гына гауга куптаргансыз, — дип битәрләргә маташкан Чыңгызханның сүзләрен ахырына тикле тыңлап та бетермәделәр. Жай чыгудан файдаланып, Чагатай янә әтисенә Жучи ханны чакты.

— Бөек каханның хасталануын ишеткәч, сангa санап килеп житәр микән? Менә күрербез инде, менә искәрербез...

Көн артыннан көн, аннары инде тулы атналар да үтеп китте, Жучи ханнан һаман булса хәбәр ирешмәде. Чагатай инде һәр таң саен диярлек Жаек тарафына ермак йөзләр куды, үзе Чыңгызхан алдында абыйсын ачыктан-ачык мыскыллауга күчте.

— Башка улларың, менә, хасталану хакында хәбәр алуга ук, лачын коштай очып килеп житте. Ә Жучи угылың, әнә, бар дип тә белми. Күрәсең, синең жан биргәненне көтәдер инде ул. Син китүгә тәхетне канлы кылыч белән яулап алмакчыдыр...

Бер көн кичен офык сызыгында жан-фәрманга чабып килгән жайдак пәйда булды. Ләкин кахан чатыры күзаллана башлагач та, чаптарыннан сикереп төште дә, иярен салдырып, кулларына алды. Үзе инде әллә каян ук хәвефле авазлар белән кычкырып елый-сыктый якынлаша башлады. Чыңгыз чатырын әйләндереп алган аксөякләрнең һәммәсе дә шундук төшенделәр: аларга таба каханга авыр хәбәр китерүче чичән кеше якыная иде.

Чыңгызханны бик көчле сак астында чатыр тышындагы бүкән өстенә чыгарып утырттылар. Чичән кеше бик салмак адымнар белән генә кахан каршысына килеп житте дә, тезләренә чүгеп, хәвефле жыру сузды.

Диңгез баштан болганды, кем тондырыр, и ханым!
Тирәк төптән егылды, кем торгызыр, и ханым!

Чыңгыз кахан — йөзәрләгән яулар кичкән, күнеле тимерләнеп каткан кеше. Нинди хәбәр килүен сиземләде, ахры, чичән жаена торыбрак жавап тотты.

Диңгез баштан болганса, тондырыр улым Жучидыр,
Тирәк төптән егылса, торгызыр улым Жучидыр.
Күзең яшен йөгертер, күңелең тулды булдыгый?
Жырың күңел өркетер, Жучи үлде булдыгый?

Янак битләрендәге күз яшьләрен сөртә-сөртә, чичән авыр хәбәрне ачып салырга мәҗбүр булды.

Сөйләмәккә иркем юк, син сөйләдең, и ханым!
Үз гоманың үзенә туры килде, и ханым!

Чыңгызның да яңакларына шундук эре яшь бөртекләре бәреп чыкты, ул чичән белән ике арадагы жыруны тизрәк түгәрәкләргә ашыкты.

Колынын жуйган куландай, колынымнан аерылдым.
Ялгыз калган аккоштай, ир баламнан аерылдым...

Чыңгызның тагын да түзәрлек куәте беткән иде. Ул колларын күк йөзенә сузып, яшьләренә тулы ирек бирде...

Жучи ханны Киндерле елгасы ярына китереп, жиргә иңдерделәр. Җәсәд озату мәшәкатьләре түгәрәкләнгәч тә, вилаят-бәйлекләр буенча «озынколак» үтте.

— Хаста кахан янына килеп яткан чакта Жучи ханны юлда көнче Чагатай жибәргән Кулан-хатын агулаган икән. Кулан-хатынның пыяла савыттагы «сине сагынып җыйган күз яшьләрем» дип эчергән сулары елан агуы булып чыккан диләр.

## 4

Чыңгызхан гаскәре Тибет тауларының итәгенә зәмһәрир салкын кыш уртасында аяк басты. Моны тангыт ханы Шидур белеп алгач, тау өркәчләре өстеннән кар ташкыны кузгалырлык итеп, ихахайлап көлде.

— Ком даласыннан башканы күрмәгән мәңгелләр тау кәҗәләре дә үтә алмас тарлавыкларны ничек узсын да, бөркетләр генә оя кора торган кыялардагы минем мәркәземә ни рәвешле менеп җитсен инде? Юкка гына үзен җиңелү белмәс җиһангир дип төш күреп саташкан ул сукбай. Минем тауларым өстенә аяк баскач та, муенын сындырачак әле ул карт бүре!

Чыннан да, Кулан Башы дип аталган бер өркәч яныннан узып барган чакта кар ташкыны кузгалып, Чыңгызханның төмән ярым җайдагын тарлавык ерымнары астына мәңгелеккә күмде. Калган унбер төмәндәге нәүкәрләр дә пошаман-хәвеф эченә чумган иде. Чыңгызхан ашыгыч әмирләр биреп, сәфәр юлын көтелмәгән якка үзгәртергә мәҗбүр булды.

— Шидүр, мүкләк, безне юлда кырылып бетәр дип өметләнә. Инде Тибет тауларын үтеп чыккан очракта да, ул безне фәкать тарлавыклар, уйсулыклар аша гына килер дип көтә. Төнкунган дигән шундый бер тарлавык башында безне кырык мең гаскәр белән көтеп торуы да мәгълүм. Ләкин без ул корган капкын авызына барып керәчәк түгел. Мәңгел нәүкәрләре узалмаган киртәләр юк! Безнең атларыбыз тау кәҗәләреннән дә чыдамрак. Шуңа күрә без тангытлар мәркәзе Нинсяга уйсулыклар аша түгел, ә менә шушы тау сыртлары аша һөҗүм итәчәкбез!

Таш кыялардан гына хасил сыртлар аша күчеш бер айга сузылды. Упкыннарда мәңгелләр тагын бер төмәнгә якын җайдак югалттылар. Ләкин көннәрдән бер көнне бер йөз меңлек Чыңгызхан гаскәренең Нинся кирмәнен камап алуы Шидүр хан өчен аяз көнне яшьнәгән яшен сыман булды. Ул күзенә ак-караны күрмичә, бернichә яраны белән генә, мәркәзен ташлап, тагын да биектәрәк урнашкан таулар өстенә качарга мәҗбүр булды.

Тау мәркәзе гаҗәеп бай икән, йөзәрләгән олау алтын-көмеш ганимәт булып колларына төште. Чыңгызханга җир йөзендәге теләсә кайсы хакимне өнсез калдырырлык бер байлыкны шәхси бүләк итеп сөйрәп китерделәр.

Саф алтыннан койган канатлы аждаһа. Олылыгы дөядән чак кайтыш. Моны бер генә арба да күтәрә алмас, күчерә алмас сыман.

— Юк, монда калдырмыйбыз, барыбер апкайтабыз! — дип барча мәңгел карарын җиткерде Җәбә нойон. — Мондый байлык безнең җиһангирны Каракорым сараенда шанлап торырга тиеш!

Таулар мәркәзендә Чыңгызханны әле алтын аждаһаларга да биргесез яңа бүләк көткән. Җучиның сылу егет булып җиткән өлкән улы Бату тау хакиме Шидүр ханның иң яшь хатынын кертеп күрсәтүгә, җитмеш яшьлек Чыңгыз булып Чыңгызның да ияге кукрәгенә бияләй шикелле салынып төште. Кәләшкә күп булса унбиш яшь чамасы, ә чибәрлеге, сыны бер генә чичән дә мактап бетерә алмастай шаккатмалы иде.

— Күрбалдисин, — дип таныштырды ул үз исемен, Чыңгызхан аның алсу ефәк аша төртеп торган ими башларын учына алып кыскалый башлагач та. — Элек мин Һималай таулары аръягында, болытлар арасында йөзгән тау өстендә генә яши идем. Әткәй мине таос кабиләсен кырылудан саклап калу өчен Шидүр ханга хатынлыкка бирде.

Чыңгыз чибәркәйнең ефәк аша үтәли күренеп торган яшь каен кәүсәседәй нечкә билләрен, җәннәт бакчаларына биргесез гаурәт җирен, алма кебек тыгыз күкрәкләрен капшый-капшый иләсләнеп-янып утыра иде, Күрбалдисин сылу аны көтелмәгән үтенече белән янган утка салды.

— Мин Шидүр хан ятагында бер генә төнне дә рәхәт үткәрмәдем. Ул карт пәри кочагында яту салкын баз эченә салгандай михнәт-газап булды. Төннәремдә һәрчак синең менә шушы онычыгың Бату кебек яшь кияүләр турында хыялландым. Син болай да бөтен җир йөзенә хуҗа җиһангирсың. Күрбалдисин атлы бер тау кызын кочмый калу гына сиңа зур югалту булмас. Гадел хөкемдар икәнсең, шул Бату атлы онычыгыңа кияүгә бир мине?

Чыңгызхан үзен котырган эт талаган шикелле чыгырыннан чыгып тузынды, аны бу минутта хәтта аркан белән бәйләп тыешлы да түгел иде.

— Аһ, әле сиңа җиһангир хәтле җиһангир ярамый да Бату сыман айгыр кирәкмени? Миннән Мөхәммәт шаһ булып Мөхәммәт шаһ кызлары баш тартмады! Алай бик нәфселе булсаң, ике айгыр койрыгына бәйләп аертам сине! Йә минем ятагымны уртак бүлешәсең, йә үзеңне урталайга өзәм!

— Ярар алай булгач, ятак икән, ятак, — диде кыргый таос кызы, күндәм-юаш кына. — Әмма исеңә ал. Ат табунына да, зур-зур илләргә дә йөгән кидереп була, ләкин хатын-кыз кочагы камчы-күсәк күтәрүдән генә ачылмый ул...

Таос кызын, яшьтәшләр дип, Чыңгызханның вәлидәсе Кулан-хатын бүлмәсенә бикләгәннәр иде. Алар озын кич буена чышан-пышан килде, астыртын күз-колак булырга кушылган хезмәтчеләр һични аңламады. Күрбалдисинны шушыннан алып чыгып, Чыңгызхан каршына китереп бастырдылар. Еламады, карышмады кәләш, чал җиһангир ым кагуга, анадан тума чишенде дә атты. Ятакка да ятим сабый күндәмлеге белән менеп яткан иде. Кара төн уртасында Чыңгызханның илереп кычкырган авазы бар мәңгелне тораташтай итте.

— Авызында нindидер ясалма теше бар иде. Җан җиремне тешләп әрәм итте, кара елан!

Дистәләгән ирләр, таос кызын эзләп, сарай бүлмәләре буйлап ташландылар. Күрбалдисин кәләш беркайда юк, нindидер юллар аша инде кирмән тышына ук чыгып качкан иде. Нойон-бәкләр аны исеме дә билгесез тирән елга ярында гына куып җитте, әмма тота алмады.

— Хатын-кызга йөгән кидермиләр! — дип шашып кычкырды да Күрбалдисин, кочакларын җәеп, биек ярдан таш упкынга очты.

Елганы икенче көнне үк «Кыргый Хатын» дигән кушамат белән йөртә башладылар.

## 5

Чыңгызхан шушы егылудан соң аягына кабат баса алмады. Ләкин зиһене аек, холкы корычтай көчле иде әле, шундук әмер бирде.

— Дошманым Шидүр хан янына илче җибәрегез. Мин аны «атам» дип атыйм һәм бер кызын хатынлыкка сорыйм. Шидүр хан үзенен кияве дип кабул итсә, аның бар байлыгын кире кайтарып бирәм һәм Нинсядагы бер генә алачыкны да җимермичә, кире мәңгел даласына төшеп китәм. Шидүр ханга моны уйлау һәм Нинсяга кайтып минем белән туганлашу өчен бер ай вакыт.

Илчеләр Тибет өркәчләре өстенә менеп югалуга ук, Чыңгызхан, меңбашларын җыеп, яңа нотык тотты.

—Һәммәгезгә бер үк төрле фәрман. Минем белән алай-болай булып, хәтта теге дөньяга китеп барсам да, Шидүр хан таулардан төшеп тез чүккәнче, җәсәдемне моннан кузгатмагыз. Әгәр мин Шидүр ханны юк итмичә китсәм, теге дөньяда да тыныч кына ятачак кеше түгел. Шуңа күрә кабат-кабат тукыйм: Шидүр ханның башын кыймый торып, сезгә минем үлемем турында игълан итәргә бер рөхсәт юк!..

Чыңгызханның юха теленә алданып, Шидүр хан ике атна дигәндә тау өстеннән төште. Кахан катилләре аны Нинсяның үзәк мәйданында, сорнай-дөмбаклар шавы астында башсыз калдырдылар. Шуннан соң гына Чыңгызхан үзен Тибет өстеннән Шәм-су елгасы ярына төшерергә рөхсәт бирде. Тангыт ханлыгының башкаласы урынында кара күмер өемнәре генә калды.

Чыңгызханга дала һавасы да ярдәм күрсәтмәде. Берзаманны ул күзгә күренеп өзлегә башлады, килеш-килбәте язгы боз шикелле көпшәкләнде. Татар хатыны Ясүн бер генә минутка да яныннан китми иде, шул барча угылларына тиз арада кахан чатыры янына җыелырга әмер юллады. Чыңгызхан да соңгы көннәре якынлашуын сизенгәндер инде, үзен уратып алган якыннарына төбәлеп, иреннәрен ялмый-ялмый дәште.

— И, сез, минем аркамдагы кабыргаларым кебек якын туганнарым, балаларым! И, сөекле халкым! Ишетегез, зинһар, ишетегез? Мин бүген шул дәрәҗәдә җәфаланамын ки, үземнең олуг милләтемне җыю юлында күргән михнәтләрем бүгенге сызлануларым белән чагыштырганда берни түгел икән. Мин сезнең өчен тырышкан чагында ныклы каештан ясалган өзәңге баулары да өзелә, аның тимер аеллары камыш урынына шартлап сына иде. Халкымны җыяр өчен бурсыгыма кәҗә бәрәненең итен бәйләп тагар идем дә чыгып чабар идем. Ачыга, яна, сусый идем, ләкин миңа бервакыт та бу дәрәҗәдә кыен һәм газаплы түгел иде. Ә бүген мин тиздән сезнең белән аерылачагымны сизәм. Миңа сезне ташлап китү шулкадәрле авыр ки, хәтта аны аңлатып та булмый. Бу җиһанда әле мин башкарырга өлгермәгән никадәрле эшләр тау-тау булып өелешеп кала. Ләкин ни хәл итәсең, яшен ташлары да сына, корыч та ярыла шул. Безнең тәнебездә дә җаннарыбыз мәңгелеккә кала алмыйлар. Мин башлаган эшләрне, ичмаса, угылларым-оныкларым дәвам итсә, мин тергезә башлаган ил-йорт нигезен алар исән-сау көенчә саклый алса иде!..

Чыңгыз бармак белән изәп кенә үз янына Үгәдәй белән Тулины, ярты ел элек кенә вафат булган Җучиның улы Батуны дәшеп алды. Тамак төбеннән гыжылдап-ыслап чыккан тавыш белән каты итеп дәште.

— Мин сезгә җиһанның дүрт ягына да ат өстендә берәр ел буе чабарлык бөек ил төзеп калдырам. Аны дошманнарыгыздан һәм җимерелүдән саклыйм дисәгез, сез гомер буе гел бер сүздә булырга тиешлесез. Ә моның өчен сезгә бер генә кояш бар, ул да булса «Яса». Шуннан йөзегезне читкә чөермәгез, шуңа табыныгыз!..

Чыңгыз көпә-көндез, Мәңгелек ил ягына төбәлеп, мәңгелеккә тынды. Даладагы һава хәтта күктә очып барган чебен-черкине дә көйдерерлек эссе, челлә иде. Тибет таулары итәгеннән алып Балдак Далага чаклы юл бик ерак, әбөек каханның җәсәден туган туфрагына исән-сау көенчә кайтарып житкерергә кирәк. Чыңгызның гәүдәсен тоташ бал эченә чумдырып, юлга кузгалдылар. Артта җансакчылар тангытларның кахан белән бергә күмеләчәк кырык чибәр кызы белән кырык егетен дә Мәңгелек ил ягына төбәп куалады.

Жир йөзендә мең ике йөз дә егерме жиденче елның җәе тәмамланды.

## ИКЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

### 1

Үзен барча урыс җирләренең башкаласы итеп танытырга маташкан Владимир-Суздаль кенәзлеге бер-ике ел гына булса да күндәм-үзбаш, тыныч-ипле яшәргә теләмәде. Баш кенәз булып саналган Юрийның энекәше Ярослав сакал-мыек җибәреп канат яраган иде, өстәл янына утырган саен абыйсыннан үзенә аерым биләмә дәгъваларга тотынды.

— Якын-тирәдәге барча калаларны үзеңнең кодаңа, кайнешләреңә, тагын әллә нинди шайтаннарыңа-женнәреңә өләшеп бетердең дә, мин авызны чөйгә элеп утырырга тиеш буламмыни? Минем дә бит, әнә, үкчәмә басып, ничәмә-ничә улым үсеп килә. Мин инәйнең кара холоп белән уйнаштан туган малае түгел әле. Тәхет булып тәхеткә утырырга да синең белән бердәй хокукым бар! Давай, минем гаиләмә аеры биләмә тап!

«Бирәм дисә колына, чыгарып куяр юлына» дигәндәй, нәкъ шул айларда Балтыйк буендагы Бөек Новгород белән Торжок калалары тагын бер-берсен канга батырып суешырга тотынганнар иде. Илдә тәртип урнаштыруны сәбәп итте дә Юрий кенәз бихисап гаскәр белән Торжок каласын әйләндереп алды. Торжок кына түгел, Новгородныкылар да үзләре өчен санаулы сәгатьләр генә калганлыгын сизгәннәрдер инде, көнендә үк бөек кенәз ыстанына арадашчы бояр озаттылар.

— Без үзара суешабызмы, әллә үбешәбезме — синең ни эшең бар? Торжок — синеке түгел, Новгород кенәзлегенә буйсына торган гади кала ласа. Чит биләмә эшенә кысылып йөрмә, гаскәреңне җыеп, кире сыптыр!

Дошман якның болай бик тәкәбберләнеп сөйләнүен ишеткәч, Юрий кенәзгә гайрәт күрсәтеп алырга туры килде.

— Мин үземнең атыма Клязьма, Ука, Иделдән тыш әле Днепр суларын да эчергән бар. Алай бик каты кәпрәясез икән, ярар, аргамагымны сезнең Волхов суларына да чумдырып йөздерермен!

Владимир-Суздальныкылар шул көнне кичкә үк Торжок урамнарындагы халыкны урып-турап чыкты. Шөбһәгә төшкән Новгородныкылар алдагы таңда күндәм бия кыяфәтендә икенче төрле кешни башладылар.

— Бар халкыбыз Изге София соборы каршына тупланып, синең белән туганлашырга әзер тора. Безгә туганнарың, угылларың арасыннан бер хаким бир.

Юрий кенәз Ярослав энекәшен бу рәвешчә тиз котылуына сөенә-сөенә озатып җибәрде. Ә теге күз алдыннан китеп югалугa, үзе белән килгән дружиначыларга яңа әмер бирде.

— Коры кул белән генә әйләнеп кайта калсак, эт тә яламый бит. Торжокның бар казнасын алып ычкынырга кирәк.

Суздальлылар Торжоктагы барча бай йортларны астын-өскә китереп таладылар да, «ай күрде, кояш алды» дигәндәй, күз ачып-йомганчы чыгып сыпырттылар. Таякның юан башы аеры түрә булырга хыялланган Ярославка эләкте.

— Үз җирен яклый белми торган бозауның безгә кирәге юк! Синең

кебек әрәмтамакны сыртта утырткaнчы, без каланы теләсә нинди узгынчы этләргә талатабыз.

Сонгы сүзләре Ходай Тәгалә колагына барып ирешкәндер, ахры. Ярославны чуклы пумалалап куганнар гына иде, Волхов дәрьясы аша бер түбән чамасы алман-латыш алпарлары бәреп керде. Хәерче Новгород, Торжок жирләрендә сәнәк очына эләктерерлек байлык-зиннәт тапмадылар бугай, Торопец, Смоленски, Полоцки биләмәләренә чаклы акыртып таладылар. Новгородлылар ярдәм-яклау сорап һаман да шул Суздаль тарафына чапкын куды. Юрий кенәз мондый форсатны оста файдаланды, Ярославны янә боларга аткарды ул.

— Каз булып йөрмәкче булып карга аяк сындырган ди. Минем энекәшне куып бик әтәчләнгән идегез дә, борыныгыз белән жиргә кадалдырып куйдылармы менә? Шулай, бик күп очынган күбәләкнең канатлары утта көя бит ул. Сез дә кабат минем энекәшне кабул итәргә риза булсагыз-буласыз, юк икән, нигә кадалмыйсыз!

Новгородныкылар дисталәгән яучыны кире борып яткан хан кызларына тиң кәләш түгел, башларын түбән иеп, тагын ризалашты. Ярослав Илмень, Малога, Псков тирәләрендәге бар ирләрне көчләп жыя торгач, ниһаять, алман алпарларын куып жибәрделәр. Әмма көрәйгән кенәз дә новгородлылар утарына кирәкмәс мал икән. Жиңү шатлыгын юарга да ирек калдырмыйча, Ярославны янә тәкәббер каладан куып жибәрделәр.

— Безгә чит дилбегә белән идарә ителгән чаптар кирәк түгел! Әнә, Александр[2] белән Федор атлы малайларын Владимирдагы Юрий кубызына биергә өйрәнмәгән әле. Син безгә менә шул колыннарны калдыр. Без аларны үз жаебызга чабарга үзебез өйрәтербез.

Ярослав әнә шулай итеп бу юлы да абыйсы Юрий янына иреннәрен тешләп кайтып ауды. Тагын берәр калада үзара суеш чыкканын көтеп тын яттылар. Озак саргаерга ирек бирмәделәр, Курски ягыннан чапкын килеп житте.

— Чернигов кенәзе Михаил, Курскига килеп, андагы Олегнын башын чабып өзгән. Хәзер берьюлы ике калага хужа булмакчы ди.

Юрий үзенең кызын Михаилга биреп, бу низагны жинел генә хәл итте дә куйды. Хәзер инде Ярослав Курски хужасы исәпләнә иде, әмма аңа бу түшәк тә төс булмаган икән. Көнбатыштан урыс жирләренә әүвәл ләһләр[3] хөкемдары Бельский бәреп керде. Кияү тиеш Михаил болар ягына ауды. Ярослав Курскидан эт өстереп куган төсле бик тиз чыгып сызды. Аптыраган Юрий хәзер инде аны кеп-кечкенә Волок-Лам каласына утыртып торырга мәжбүр булды.

Ә Михаил белән Бельский ул арада качак кыпчаклар ханы Китән белән дә бәйләнешкә кергән икән. Бергәләшеп, өчесе өч яктан Киев каласына барып ябыштылар. Андагы бөек кенәз булырга маташып йөргән Владимир Рюрик кыпчаклардан бушаган далага чыгып качты.

Владимирдагы Юрий үзәктәге барча вак кенәзләрне кул астына жыеп Киев каласына төбәлмәкче иде, үз оясында хыянәт учагы пыскып яткан булган. Тишек кәвеш сыман теләсә кая тибелеп йөргән Ярослав Юрийнын малайлары Всеволод белән Инварны котырткан да бөек кенәзне теге дөньяга озатмакчы икән. Моны белеп алуга ук, Юрий әүвәл ике улын да зинданга ташлаттырды, аннары карчыга шикелле котырынып энекәше өстенә ябырылды. Ярослав — икейөзле, мәкерле жан. Жавапны тиз тапты.

— Болай да дөрләп янган йортка күрше ихатадан да кисәү ташымыйлар.

[2] Александр — булачак Невский.
[3] Ләһләр — поляклар.

Өстебезгә читтән килгән дошманнар да байтак. Без, ике туган, үзара чәкәләшеп кеше көлдермик, абый.

Ярослав үтә дә үкенгән кыяфәттә кочаклап та алгач, Юрий кенәз сынды. Җыйнаулашып, олы өер булып, Киев каласы өстенә юнәлделәр. Кыпчак Китән — Ярославтан кайтыш соран түгел, дистә меңәрләгән булып килгән урыс алайларын күрүгә үк Юрий кенәз ышыгына чыкты. Ләһләр белән Черниговныкылар үз якларына кайтып сыпырттылар. Әйдә, өнең тыгылмасмы дигән сыман Юрий кенәз Киев тәхетен убыр Ярославка тәкъдим итте.

— Киев — барча урыс калаларының анасы булып исәпләнгән шәһәр. Анда утыру безнең ничәмә-ничә бабаларыбыз, әтиләребез өчен зур дан булган. Минем көньяктагы ышанычлы канатым шикелле утырасы булсаң, бу каланы сиңа бирәм. Тик онытма, Киев берчакта да кабат мәркәз булып күтәреләчәк түгел. Владимир каласына буйсынудан чыксаң, мин Киев урынында көл калдырып китәм!

— И-и, Киев әле көнчыгыштан адашып килеп чыккан мәңгелләр җимерүеннән соң да аякка басмаган бит. Мин нигә генә аркаланып сиңа каршы баш калкыта алыйм? — дип Ярослав нык күндәмлек күрсәтеп ялагайлангач, Юрий кенәз аны кочагына кысты.

Шулай бер-берсен үтә дә нык хөрмәт итүче изге туганнар сыман кыйланып хушлаштылар. Ләкин күңелләре белән икесе дә тоя: җай табылса, болар бер-берсен котырган бүреләр урынына ботарлап атарга һәрчак әзер.

## 2

Юрий кенәз, Ашлы каласы янында әсирлеккә эләктергәннән бирле, Гази-Бәрәҗне Нара күленең уртасындагы кулъяулыктай кечкенә бер утрауга бикләп тота иде. Атауны тулысынча диярлек кылыч йөзе сыман текә, үткен кыялар әйләндереп алган. Аның бер ягыннан гына олы дөнья белән алыш-биреш алып барып була. Тоткынның берүзенә илледән артык сакчы, бер генә минутка да ялгыз калдырмыйлар. Бөтен күргән ризыгы — балык та су. Кичә генә ул Биләр чаклы Биләр белән тирәшеп маташкан Сувар каласының олугбәге иде. Бүген исә — чылбырга утыртылган эт хәленә калган мескен тоткын. Аның биш-алты ел гомере чыра сыман әрәм янып үтте һәм Гази-Бәрәҗ үзенең кабат зур җиһанга әйләнеп кайтасына тәмам өмет өзгән иде. Бактың исә Юрий кенәз Гази-Бәрәҗгә карата әллә нинди астыртын ниятләр корып йөргән икән.

Беркөнне атау ярына җилкәннәре ак парча белән бизәлгән олы баркас килеп туктады да, шундагы түрәләр Газины учларына күтәреп диярлек кертеп утырттылар. Тоткын боларның өтәләнеп йөрүләреннән үк сизде: элек сынык динар урынына да санамаган Юрий киләчәктә аңа бирәр төрле этлек-мәкер йөгәне кидермәкче була.

Владимирга кайтып төшүгә үк Газины йөгертә-йөгертә олуг кенәз сараена кертеп җиткерделәр. Тоткынның күзен маңгаена мендереп, Юрий аны кочагына алды. Гази кояшның шәрекъка батышын күргән төсле тораташтай калды, арадагы бозны эретү өчен Юрий тезеп китте.

— Туган энекәшләренә, үз балаларыңа да таянырга курка торган заман килеп житте. Һәркайсысы синең башыңны ашап, тәхетенә утырмакчы була. Читтән терәк-таяныч эзләми мөмкин түгел. Миңа үземнең күзләрем яки калканым булырдай ышанычлы дуслар, аркадашлар кирәк. Син кенәз тәхетенә өмет тота алмыйсың. Шулай булгач, үз балаларыңнан тайчанган вакытта да сиңа икеләнми таянырга мөмкин. Ләкин моның өчен безнең ике араны өзелмәс җепләр белән нытыртырга кирәк. Мин сиңа үземнең теләсә кайсы кызымны бирергә дә риза. Әйдә, киявем бул.

Гази уттай мунчага килеп кергән сыман байтак вакыт тын алалмый торды. Ияге муенына салынып төшкән иде. Камыр булып таралган иреннәрен көч-хәл белән жыеп, гыжлап жавап бирде.

— Б-б-бәй, әтәйнен «утын ярырга ярамаган балта боз чабарга булса да ярап тора», дигәне хакмыни ул? Сина да минем сымак тоткын кирәктеме?

— Бүген тоткын, ә иртәгә, бәлки, Болгарына кайтып хан булырсың. Безнен язмыш үзебезнең кулда. Икәү бергә булсак, Болгар сыман кыятауны әйләндереп атулар да ерак йөрмәс, шаять...

Көннәр узган саен Юрий кенәз үзенен йөзен, елан кабыгын салган төсле, акрын-акрын гына ача барды.

— Безгә Болгар илен тулысынча көе кабып йоту, мөгаен, насыйп булмас. Ни әйтсән дә, безнең Владимир-Суздаль кенәзлеге Болгар ханлыгы янәшәсендә эскерт янындагы түмгәк кебек кенә. Ә урыс жирендәге барча кенәзлекләрне бер йодрык шикелле итеп туплау — төшкә кермәс хыял. Аннары чит кенәзләрне үз канатым астына туплаунын, чынлап баксаң, бөтенләй кирәге юк. Чөнки үзем тапкан малны алар белән бүлешү мина дан китерми. Мина Болгар илен япа-ялгыз көе кулга төшерү күпкә хәерлерәк. Ишекне жимереп керергә жегәре житмәгән тычкан-күсе, тишек ясап булса да, амбардагы малны кимерә бит. Безгә дә Болгар иленербөтен икмәкне сындыра-сындыра ашаган шикелле ваклап-ваклап кимерү — отышлырак алым. Арлар белән чирмешләрнең Илһам хан талавына түзмичә жәһәннәм аръягына качарга әзер торулары турында ишеткән бар. Безгә менә шул арларны, чирмешләрне Илһамга каршы котыртып, Болгар иленнән аерырга кирәк. Ә кара чирмешләрнең бәге Пургас сине биш бармактай белә. Бу очракта безнең өчен синнән дә отышлырак арадашчыны эзләп тору артык...

Суздаль, Владимир, Мәскәү, Волок-Лам калаларындагы дружиналарны, чит-ятларга әйтми-нитми генә, ерак сәфәргә әзерли башладылар. Гази-Бәрәж гаскәрләрдән алда ил эченә сизгер күз-колаклар озатырга кинәш итте.

— Мин тышкы дөнья белән алыш-бирешне өзеп, әллә ничә ел буена ябык утрау эчендә гомер сөрдем. Бу еллар эчендә Болгар буйлап нинди жил-давыллар уйнаганын белмим. Әйдә, сәүдәгәрләр кыяфәтендә ил эченә шымчы ирләр озат. Болгарлар — сәүдә дигәндә мич башыннан егылып төшүчән халык. Безнен шымчыларны бернинди тоткарлык-киртә куймый, теләсә кая үткәреп жибәрерләр. Алардан без көткән хәбәрләр килеп ирешкәнче мин үзем дә тик ятарга исәпләмим әле. Юлга чыгар алдыннан аяк чолгавына тикле барлап кую хәер. Мин элек синең кулыңа төшкән әсир болгар ирләре арасыннан үземә ярдәмчеләр эзләп таба торам.

### 3

Мәмдеш белән Кашан арасында өр-яңа өч кирмән төзеп бетергәннән сон, урыс әсирләрен әүвәл шуларнын берсенә, Шөн елгасы ярындагысына биклəп яткырганнар иде. Ләкин «эшсез яткан ир-ат белән юлбасар арасында аерма юк», дигән сүзләр хак шул. Болар атна-ун көн эчендә тиктомалдан берсен-берсе суя башладылар. Кашан бәге Шуран, Илһам ханга ялварып, урыс әсирләрен ваклап бүлә-бүлә, төрле калаларга озаттырды. Биләргә килеп урнашканнары пайтәхет читендә аерым урам корырга тотындылар. Болар инде болгар телен шактый үзләштергән һәм мондагы халык белән һичнинди каршылык-низаглар чыгармыйча гына яшәр сыман иде.

Владимир каласыннан килгән сәүдәгәрләр менә шушы өр-яңа урамга кереп төпләнделәр. Сәүдәгәрләр кәрванының башлыгы Аврамий атлы елгыр бәндә икән. Шул килмешәк бер ай чамасы вакыт үтүгә үк Варлам дигән

әсир яшәгән йортның түбәсенә биек, текә гөмбәз күтәрттерде. Әллә каян гына табып, шул гөмбәзнең иң очына алтын йөгертелгән тәре мендереп куйдылар. Гөмбәз эченә бакырдан коелган олы чаң асылды. Аврамий әлеге йортны чиркәү, үзен поп дип игълан итте дә чем-кара киемгә төренеп йөри башлады. Варлам аның ярдәмчесе итеп билгеләнгән икән. Анысы кирәксә-кирәкмәсә дә чаң шаулатты. Бу чаң тавышы да, Аврамийның кыланмышлары да болгарларның үзәгенә үтә, ләкин алар әле һаман тешләрен кыса-кыса түзеп яши иде.

Беркөн кичен Чүлмәкчеләр бистәсендә яшәгән Фазылҗанның тугыз яшьлек кызы гаип булды. Күрше-күлән хатыннары, бергә җыелышып, ни кылырга белми елаштылар.

— Шушы капка төбеннән беркая да китми йөгереп йөргән иде. Өермә сыпырып алгандай капылт юкка чыкты. Кояш бата башлаганда теге, кара җиләнгә бөркәнеп йөри торган урыс пубы гына үтеп киткән иде. Шуннан кала урамга бер чит-ят кеше кермәде лә юкса...

Бер атна үтүгә нәкъ шундый хәл Сары Базар урамында кабатланды.

— Йозаклар ясаучы Миргазимнең сигез яшьлек кызы гаип булган.

Икенче атнада — берьюлы ике урамда шундый ук хәл. Илһам ханның абзарында ат караучы булып торган ике ирнең янә сигез-тугыз яшьләр чамасындагы бәп-бәләкәй кызлары суга төшкән балта сыман юкка чыккан икән. Иң сәере шул: ике урам халкы да бу мөнәсәбәттә гел бер үк кешеләр исемен телгә алып сөйли.

— Алдагы көндә дә, ул кичтә дә урам буйлап арбаларына олы мичкә салган кара урыс белән шадра Варлам гына үтеп киткән иде. Асылгәрәйнең дә, Мәннанның да кызы нәкъ шулар артыннан ук җен алгандай булды.

Ни әйтсәң дә, Асылгәрәй белән Мәннан — хан атларын караучы «күз өстендә кашлар». Шыгавыллар[4] башлыгы Әбүзәр сыбай[5] аша кайгы-шөбһәләрен Илһам колагына илтеп җиткерделәр. Хан шушы ук сыбайга кискен әмер бирде.

— Бер йөз яугир ал да ул урыс чиркәвенең астын өскә китер. Ага-Базар урамындагы хатыннар инде болай да миңа элегрәк «кара Аврам ирләребезне исертеп чукындыра», дип елый-елый зарланганнар иде. Хәзер менә атна саен сабый кызлар юкка чыгып тора. Дин сайлауны тыю гөнаһ саналса да, бу килмешәк урыс сәүдәгәрләре йөзләренә юха битлек япкан зыянчылар, карагруһлар бугай.

Ташкын булып бәреп кергән болгар җайдакларын Урыс урамының баш-башына куелган җиде-сигез сакчы гына тыя алмады. Кулына ялан-кылыч тоткан Әбүзәр сыбай үзе чиркәү саналган йортка барып керде. Беренче бүлмә идәннәрендә әле исереп аунаучы алты-җиде болгар ирләренә генә тап булганнар иде. Иң түрдәге, баз рәвешендә яртылаш җиргә индереп ясалган тар бүлмәгә кергәч, Әбүзәр дә, аннан калмыйча атлаган яугирләр дә тораташтай булып таң калдылар.

Бүлмә түрендәге агач сәке өстенә Биләр урамнарыннан урланган сабый кызларның икесен берьюлы шәп-шәрә көенчә бәйләп ташлаганнар. Бәгырьләрнең күкрәкләре-аяклары канга батып беткән. Авызларында — дыңгычлап тутырылган чүпрәк кисәкләре. Тәннәре читән башына эленгән иске юрган сыман теткәләнгән, кара янып чыккан. Күз карашларында һичбер төрле зиһен-төсмерләү юк. Күрәсең, бичаралар акылдан ук ычкынганнар бугай.

Яннарында гына Кара Аврам белән шадра Варлам ауный. Икесе дә билдән түбән чишенеп ташлаганнар. Икесе дә күз ача алмаслык ләх исерек.

[4] Шыгавыллар — эчке сакчы, сарай сакчылары.
[5] Сыбай — хәрби отряд башлыгы, офицер.

Монда бәреп кергән болгарлар бу хәшәрәтләрне шундук турап ташламакчы иде дә, аларның кылыч йөзенә яланкул ябышып, Әбүзәр сыбай тыйды.

— Дин йортында кан коюлар гөнаһ. Аннары, исерек көе турасаң, бу еланнар үлем ачысын сизмичә дә кала. Без аларны иртәгә, бөтен Биләр халкы каршына чыгарып юк итәрбез. Ә бу еланнар оясына инде бүген үк ут төртсәк тә була.

Бичара сабыйларны ике яугир бер-бер артлы күтәреп алып китте. Ике исерек «дин әһелен» аякларыннан гына сөйрәп чыгардылар. Болдыр янындагы беренче бүлмәне дә исерек болгарлардан чистартканнар икән. Әбүзәр сыбай үзе «чиркәү»гә ут төртте. Ләкин тавышы ачынулы һәм үпкәле иде.

— Биләр жиренә китереп корган беренче чиркәүләре үк елан оясы булып чыкты боларның. Ә ялгыш болар табаны астына эләгә калсаң, нинди зәхмәт көтә? Болар безнең тиреләрне тере көе тотып туначак икән!..

Икенче көнне таңда «дин әһелләре»ннән элегрәк югалган ике сабый язмышы турында сораганнар иде, аларның җавапларыннан соң бар хатын-кыз елый-елый җир өстенә чүкте.

— Алар ике көн дә түзми үлделәр бит. Абзар артына чыгарып күмдек инде...

«Бөек дин әһелләре»нең гомерен дар агачына мендереп өчладылар. Биләр һавасы җиләсләнгән, сафлангандай булды. Шушы ук кичтә пайтәхет капкасыннан Идел ягына таба ялгыз чапкын чыгып ычкынганын һичкем сизенмәде.

4

— Аврамий атабыз Болгар иленә барып тәүге чиркәү төзеткән, христиан динен бөтен Идел буена иң беренче булып иңдерә башлаган фидаи җан иде. Аны христиан диненең явыз дошманнары кара эштә гаепләп юк иттеләр. Аврамий атабыз безнең бөек динебез хакына газиз башын салды. Ул монда алып кайтып яңадан җирләнергә һәм гасырлар буена фәкать изгеләр рәтендә генә йөртелергә тиеш!

Бу сүзләрне Юрий хакимгә гади чапкын түгел, ә Владимир кенәзлегенең баш архиепископы булып исәпләнгән һәм руханилар арасында беренчелек өчен хәтта Киев патриархына да баш бирмәскә маташкан Гермоген атакай үзе тезә иде. Юрийның берчакта да аңа каршы әйткәне юк, бу юлы да һәрбер сүзен йотып кына барды.

— Карагруһ болгарлар Аврамий атакайны гына түгел, безнең изге динебезне мыскыл итте. Алар Аврамий атакай белән бергә сине дә, мине дә, бөтен урыс илен, бар христиан дөньясын аяк астына салып таптадылар. Мондый вәхши җинаятьләре өчен болгарлардан үч алырга кирәк. Ул басурманнар яңадан безнең изге динебезгә хәтта тел дә тидермәслек итеп сабак алып калсын. Бөтен урыс ирен үз канатың астына бер йодрык итеп тупла да болгар илен канга батырып кайт! Христиан соборы синең походыңны изге сәфәр санап игълан итә! Бездән сиңа хәер-фатиха, якты теләкләр һәм тулысынча ирек. Болгарларның олысын-кечесен ас, кис, бөтенләй турап бетер — христиан чиркәүләре синең гаскәреңне гаепләячәк түгел! Сәфәргә чыгачак барча ирләр алдан белеп торсын: бу яу корбаннары чиркәү тарафыннан изге җаннар булып саналачак. Аларның һәркайсын мәңгелек дөньяда якты җәннәт көтә...

Юрий кенәз арлар, чирмешләр җиренә унбиш меңлек гаскәр белән аяк баскан иде. Гази-Бәрәҗ көтүдәге үгез урынына үзе дә гел гаскәр маңгаенда барды, өстәвенә, Мәскәү, Суздаль зинданнарында тотылган болгар әсирләрен дә ермак алай итеп алга куган иде. Юрий кенәз чит-

ят ил хакиме булса да, дөрес чамалаган. Илһам ханның талавыннан рәнҗегән Пургас батыр аларны Кисек Бармак кыясына басып каршылады. Кара чирмешләр бәгенең алдан күзаллап торган үз мәнфәгатьләре бар иде, күрәсең, чит баскыннар аяк астына келәм булып җәелергә бер дә ашыкмады.

— Мин чамалыйм, нинди генә хуҗа табылмасын, ул үз абзарына килеп кергән һәрбер яңа атны тәртә арасына китереп җикми калмый, — дип башлады ул сүзен, бар далага хаким булып очкан горур бөркет сыман. — Бар мәсьәлә шунда: ул син тартасы арбага нинди йөк сала да ничек ашата бит? Әгәр урыс кенәзе чирмешләрне нәкъ Илһам хан төсле соңгы кабым ризыгыңа чаклы талап китә һәм чыбыркыдан башка алым белми икән, безгә арба яки йөгән алыштырудан бер мәгънә юк.

Юрий кенәз урынына ашыга-кабалана Гази җавап бирде.

— Урыс халкы ким дигәндә беренче ун ел буена синең кабиләңнән берниндиде салым-ясак җыярга исәпләми.

Пургас мыскыллы елмая-елмая баш чайкады.

— Барча яңа малны да әүвәл шулай юха наз күрсәтеп кулга ияләндерәләр, хәтта учтан ашаталар булыр, монысы Илһам хан безне «кара» дип кимсеткән чирмеш халкы өчен дә зур яңалык түгел. Бу — шул, өйгә яңа кәләш төшерү шикеллерәк инде. Әүвәл өрмәгән җиргә дә утыртмыйлар, ә атна-ун көн үтеп китте исә, кичә сөекле булып йөргән килен юынтык су тулы чиләкләргә чаклы үзе түгә башлый. Без дә алда нинди талау, нинди җәберләүләр көткәнен барыбер чамалыйбыз.

— Ну инде, ну! Әйткән сүз — аткан ук, — дип Юрий кенәз сүзгә кушылса да, Пургас бу җирләргә хуҗа кеше икәнен онытмыйча, кулын югары күтәреп кенә шып туктатты.

— Безне барыннан да элек тик бер тараф борчый. Сез безгә көчли-көчли тәре такмассызмы? Чирмешләрнең изге урманнары — кюсотолар чиста калачакмы?

Кенәз даирәсенә ияреп йөргән бер поп алга чыкты.

— Син әле генә телгә алып үткән ат-малкайны аксак-туксак яисә сыңар куллы гарип бәндәләр дә инеш буена төшереп җиткерә ул. Әмма, хәтта, кырык-илле иң гайрәтле ирләр ябышса да, алар үзе сусамаган, үзе теләмәгән атка кыйный-кыйный су эчерә алмый. Дин дә шуның кебек. Әгәр үзегез теләп күченмисез икән, сезне бер генә поп яки йөзләгән алайлар да христиан бакчасына куып кертәчәк түгел.

— Аһ, менә монысы шәп! Бу сүзләрең күңелебезгә хуш килде. Авызыңа бал да май, — дип Пургас янәшәсендә торган кам-түрәләр рәхмәт сүзләре яудырырга ашыкты.

Кисек Бармак кыясы каршындагы ялан берәр сәгатьтән соң инде сый-нигъмәтләрдән сыгылып торган өстәл-ашъяулыклар белән тулган иде.

## 5

— Хания, хания! Кушнур дәрьясы ягыннан урыс кенәзе Юрий бәреп кергән! Кара чирмешләр тулысы белән аңа кушылганнар. Хәзер бөтенесе бергә, кара болыт булып, Казан кирмәне ягына төбәп баралар ди.

Илерә-илерә кычкырып килеп кергән каравылбаш Камалның шушы хәбәреннән соң Илһам хан тәхетеннән егылып төшә язды.

— Нинди Юрий кенәз? Теге чакта Ашлы каласын яндырып юк иткән Тиле Юргамыни? Соң, без аның белән ун ел буе үзара яу йөрешмәскә солых төзедек лә! Нишләп солых боза? Безнең Болгар илендә ул тилегә ни кишерем калган?

Өркү-каушаудан бөтенләй нигез-кысасыз сораулар яудыра башлавын

чамалады бугай, Илһам үзен бик тиз кулга алды. Баш карачы булып йөргән Дәүләтьярны күз ачып йомган арада чакырып китерделәр.

— Хәзер үк, кош шикелле атылып, Тиле Юрга каршына шәхсән үзен юнәл! Солыхны ник бозган, ни кирәккән ана? — барысын да бәйнә-бәйнә шунда ачыкларсын. Әле Жаек аръягында мәнгелләр яккан учакның ялкыныннан кая качарга икәнен дә белеп булмый. Шуңа өстәп, хәзер инде Идел яклап Тиле Юрга да ут кабыза икән, без ике учак арасында калып, шундук юк булабыз. Теләсә нинди шарт-таләбен тынла, илле мәгәр Тиле Юрганы кире бормый торып, пайтәхеткә кайтма!..

Дәүләтьяр Юрий кенәзне дала уртасында арба-киртәләрдән корылган гап-гади ыстанда эзләп табарга исәпләп якынайган иде, Кушнур елгасы ярында инде яртылаш калкып өлгергән өр-яңа кирмәнне күреп, күзе шакмак булды.

— Моннан соң кара чирмешләрнең үз мәркәзе булачак! — дип каршылады аны иң олы хужа кыяфәтендә имән капка алдына чыгып баскан Пургас. — Исемен дә Мәркәс йә булмаса Ар-Йорт дип кушарга исәплибез. Болгарларнең нәфсе белми торган Илһам ханнары каршында кара кол шикелле бил бөгеп яшәүгә чик куябыз. Алга таба чирмеш кабиләсе урыс ышыгында, әмма мөстәкыйль, үзбаш кенәзлек булып яши башлаячак!

Тирә-юньдә менәрләгән баскын кылыч тагып йөри, бәладән баш-аяк. Карачы Дәүләтьяр гыйсъян бәк сүзләрен су шикелле тавыш-тынсыз йотарга мәҗбүр булды. Әле Юрий кенәз авызыннан бөркелгән кайнар ялкыннарга да көясе калган икән.

— Сез безнең изге Аврамий атакайны юк иттегез. Безгә каршы беренче булып кылыч күтәрдегез. Ике арадагы солых, дуслык дигән килешүләр бетте! Тәүге адым итеп безгә Аврамий атакайның җәсәден бар булганы көе китереп тапшырыгыз! Аннан соңгы таләпләребез дә өйлә вакытындагы көн шикелле анык. Моннан ары чирмеш иле Владимир кенәзлегенең аерым биләмәсе булып саналачак! Аның белән генә дә тукталмыйбыз. Казан кирмәненә кадәр сузылган барча Идел яры безнең кенәзлеккә кушылырга тиеш!

Дәүләтьяр карачы әүвәл авызын соскы сыман ачып сүзсез калды. Гыжылдап кына эндәшкән авазы да байтак вакыт узгач кына ишетелде аның.

— Сез ярты Болгар илен аерып алырга җыенасыз түгелме соң, кенәз?

Юрий кенәз ыжлап та карамыйча үз сүзендә торды.

— Яртымы, чирекме, анда бер эшем юк. Безгә әзериләр-гөрҗиләр белән сәүдә итү өчен Идел кирәк! Хәзәр диңгезенә чаклы аккан Идел тулысынча урыс елгасы булып саналырга тиеш!

Кенәзне тилемсә уеннан биздерү черек агачны кытыклап көлдерергә маташудай файдасыз бер гамәл тоелса да, вәзир барыбер дә дошманын ипкә-сапка килергә чакырып сүз башлады.

— Шәрекъ яктан кыямәт туеннан ким булмаган мәңгел явы котырынып килә. Алар Болгар илен әйләндереп атса, аннары синең урыс кенәзлегенне дә үгез сыман сытып китәчәк бит. Саламны саламга кушып үргән чагында да әрсез тәкәләрне тышаулардык аркан ясап була. Ә Болгар белән синең кенәзлегең иңгә-иңне куеп басса, туфан-гарасатлар ега алмаслык калкан булыр иде. Хәтта ишәкләр булып ишәкләр дә, бүре көтүен күрсәләр, бер төергә укмашалар ди. Мәңгел явы өстебезгә егылырга торганда юкка гына безнең белән тибешәсең булыр, Юрий кенәз.

— Андагы дуамал Чыңгызхан күптән аяк сузган. Син мине җиде дала, җитмеш дәрья аръягындагы кыргый мәңгелләр өере белән өркетеп маташма әле. Минем бүрәнә аша бүре куа торган куркак гадәтем юк. Мәңгел килә икән, аны печеп җибәрерлек кенә куәтем бар! Менә, ар-чирмешләр минем

якка ауды, гаскәр саным артты. Әле минем учак янына мукшыларның килеп кушылуы да әлләни ерак йөрмәс. Шулай булгач, миңа хәзер җиде дошман явын борып җибәрү дә берни тормый!

Дәүләтьяр карачы авырсынып кына ияренә менде.

— Гомер буе кысыр яшәгән анадан туган сукыр малай көпә-көндез көе ай күргән ди. Син дә шуның кебек, юкка гына үзеңне җиһангир сәргаскәр урынына куеп ялгышасың, кенәз. Яңа кое казымыйча торып, искесен орды-бәрде күмеп китмиләр бит. Сиңа сатлык әмир-бәкләргә аркаланып, кичә генә терәк-таянычың булып яшәгән болгарларның битенә килеп төкерүдән тайчынырга иде.

Баш карачының анык җавап бирми кузгалуы сәерсетте бугай, Юрий кенәз тота-каба ашыгып сүз ташлады.

— Ә син, кайтып, Илһам ханга нинди карар җиткерергә булдың?

— Акылы бар кеше илен-җирен бер карыш та сатмый. Чөнки дошманына хәтта сыңар бармагын гына каптырган кеше дә соңыннан кулын беләгенә тикле югалта ул. Без синең бер генә шартыңа да буйсыначак түгел! Атларны утар эченә кереп урларга маташкан ташбаш караклар күп очракта тешләрен учларына җыя торган була. Син дә бу эшеңә үкенерсең әле!..

Юрий кенәзнең биш меңгә якын сугышчысы Идел буйлап сузылган авылларны талап-айкап йөри, урысларның мондый этлек-бирәнлеген күреп, чирмешләрнең дә юлбасарлар белән ингә-иң торудан күңеле кайткан иде. Алат урманнары аша үтеп чыккан болгар явын һичбер төрле каравыл тозагы да абайлап өлгермәде. Ә утыз меңлек гаскәр башында килгән Илһам таждар чирмешләрнең Мәркәс атлы өр-яңа кирмәнен бер көн эчендә кырмыска оясы урынына тузгытып-чәчеп атты. Яу кырыннан әүвәл Пургас үзе, аның артыннан ук барча чирмеш качты. Юрий кенәз мунчадан гына чыккан кеше шикелле дала уртасында ярымшәрә көе басып калган иде, ул алны-артны карап тормый, килгән юлы буенча кире үз ягына чапты. Илһамныкылар ун чакрым арада биш меңгә якын баскын җайдакларын турап бетерделәр. Әмма үч һәм шашынудан уяулыгын җуйган Илһам үзенең алда нинди тозакка эләгәсен абайламый калды.

Җәтмәгә куып кертелгән җәнлек хәленә калган Пургас, кача-кача барып, янә Кисек Бармак кыясының өстенә менеп яткан иде. Текә яр астындагы яланда бөтенләй жансакчыларсыз диярлек пәйда булган Илһам ханны күргәч, әүвәл үз күзенә үзе ышанмыйча торды. Менә, ул гомер буе табынып яшәгән изге кюсотоны кырып чыккан дошман кул сузымында гына. Әле кайчан гына шушы хаким аны йөзәрләгән кара чирмешләр каршында эт урынына тотып ярган иде.

— Әй, Илһам мордар! — дип кычкырып аваз салды үзен болытлар өстендәге Кирәмәт[6] урынына хис итүче горур Пургас. — Сукыр этне тавыш чыккан якка карап, әҗәленә каршы чаба, диләр. Син үзеңне мәңге үлем белмәс Алла сыман санап йөргән идең. Менә, изелгән-таланган чирмешләр каршында әҗәтеңне түләр көнең җитте. Ат шикелле изге малның сыртын синең хәшәрәт каның белән пычратасым килми. Ияреңнән төш тә бер читкә бас!

Илһам иярендә кадакланган сыман тик утырды. Аның янына инде дистәләгән җансакчылар якынайган иде. Чирмеш бәге корыч башаклы, озын саплы укны җәясенең керешенә салды. Пургас — үзенең кабиләсендәге иң-иң оста мәргән. Ул очырган укларның хәтта кара урман уртасында да корбаннарын тапмый калганы юк. Кыя башыннан, иң әүвәле, Пургас бәкнең мәсхәрәле тавышы ишетелде.

— Хуш, Илһам хан! Син үзең чирмешләрне аяк астына салып таптамаган булсаң, мин Болгар илен җимерергә уйламаган идем.

[6] Кирәмәт — явыз рух.

Икенче мизгелдә яман сызгырып авыр башлы ук килеп кадалды. Илһам хан арыш капчыгы урынына чирәм жиргә ауды...

Мәрхүм хан гәүдәсен күтәреп Мәркәс хәрабәләре янына әйләнеп кайтсалар, Сувар каласыннан жыелып килгән биш меңлек нөгәр уртасында әллә каян гына хасил булган Гази-Бәрәж йөри. Яман хәбәр кырык аяклы бит, инде Илһам ханның әрәм булуы хакында да ишетеп өлгергәннәр. Суварлыларның телендә бер генә сүз:

— Әмир Гази — Бәрәж хан оныгы! Аның хан тәхетен яуларга тулы хокукы бар!

Әмир Алтынбәк шәрекъ як чикләрен саклау өчен калган, ә Илһам ханның хәтта иң өлкән улы Самат та әле җиде-сигез генә яшьтә иде. Мәркәс хәрабәләре өстенә җыелган барча болгар ире хафа тулы аптырашка төште. Суварлылар шуны сизеп тора, казан астына яккан шикелле һаман кыздыралар.

— Илебез әле баскын дошманнан да азат ителмәгән. Хансыз калуыбызны белсәләр, яна чиру, яна аркадашлар табып, аларның ил эченә саранчалар сымак үтеп керүе бар. Гази-Бәрәжне кичекмәстән ак киез өстенә күтәрергә кирәк!

Казан каласыннан килгән Ясаф атлы меңбаш каршы чыкты.

— Явыз бүреләр көтүе чолганышында калган чакта бер генә сунарчы да поши яки кабан дуңгызының тиресен тунап ятмый. Чөнки бирән нәфесенә буйсынмыйча, үз башыңны исән-имин килеш алып качу хакында уйлау хәерлерәк. Сез дә юкка гына тәхет турында уйлап баш ватасыз. Урыны бу түгел. Һәрхәлдә, тәхет кемгә тиеш — аны Биләргә җыелган түрәләр хәл итәр. Ә Гази-Бәрәж нисбәтендә минем фикерем шул. Ул — тугыз елга якын гомер буе урыс куенында яткан тоткын. Урыс ашы ашап яткан икән, урыс көен көйләми калмагандыр. Юкса, баскыннар аны монда тиктомалдан гына түрә итеп алып килмәс иде. Ул элмәккә утыртылган, тышауланган малдан кайтыш түгел. Урыс төрткән, урыс яклаган түрәне ил башына утыртабыз икән, димәк, ул шулар кубызыннан арына алмаячак.

— Әле син суварлар әмирен жык-нәжескә батырмакчымыни? — дип кылыч айкый-айкый аңа каршы Сувар меңбашы Урман чәчрәп чыкты да Ясафны күз ачып йомган арада башак тураган шикелле айкап-телеп атты.

Жик мәргән белән Баян батыр бар гаскәрне акылга килергә чакырып карадылар.

— Тәхет язмышын басуда хәл итмиләр. Илгә, илгә кайтыйк.

Әмма суварлар белән казанлылар тотыш тыешлы түгел, алар диварга-дивар килеп баскан, озакламый Мәркәс хәрабәләре өстенә мәетләр юрганы түшәләчәк иде. Шул мизгелдә Алат урманы ягыннан артыннан дию парие кугандай шәр кычкырып чапкан жайдак пәйда булды.

— Бәла, бәла! Олы каза килә, туганкайлар! Шәрекъ яклап ил өстенә мәңгел төмәннәре бәреп керде!

## ӨЧЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

### 1

Чыңгыз вафатыннан соңгы ике ел матәм тамгасы астында үтеп киткән иде. Аннары мәңгел түрәләре Кырүлән елгасы ярында зур корылтай җыеп, аның уртанчы улы Үгәдәйне кахан тәхетенә күтәрделәр. Бату хан үзенең кәрванын Бохарага таба алып кайта башлагач та, Сүбүдәй батыр аның ияре янында яшь танага тагылган үгез сыман бөтерелеп йөрде. Теленә менгән җыры зәһәр шөпшә гөжелдәвеннән һич кенә дә кайтыш түгел иде.

— Чыңгызхан бабаңа утыз ел буена хезмәт иттем, йөзләгән яу кичтем.

һичкайсында җиңелү ачысын татыган юк иде. Җигулат янында тозак корып, тик болгарлар гына мине тар-мар итте. Шулар белән орышып, сыңар күз югалттым. Инде алты ел буена башка нойон-бәкләр күзне ачырмыйлар. Миңа җиңелеп кайткан батыр данын тагып йөрү хурлык. Теге дөньяга кара дан күтәреп китәргә хокукым юк! Мин болгар еланнарыннан үч алырга тиеш! Синең кул астындагы нәүкәрләрнең саны унбиш төмән. Шуларның биш төмәнен миңа бүлеп бир дә болгарларны сусар оясы урынына пыр туздырып кайтам!..

Тамчы булып тамчы да, туктаусыз тама торгач, мәрмәр ташны тишә. Ә Бату хан өчен Сүбүдәй — атасы урынына калган якын кеше. Чагатай белән Үгәдәй агалары эт типкесе хәленә куйган чагында да әтисе Җучидан бигрәк Сүбүдәй баһадир канаты астына ышыкланып үсте, ныгыды бит ул. Бату хәзер бик котырса, Үгәдәй булып Үгәдәйне дә күз чалымына китермәскә мөмкин. Чөнки аның бөек Чыңгыз бүлеп биргән үз ханлыгы, тегеннән-моннан ялпый-ялпый җыйган мәгъруր гаскәре бар. Бүген Чыңгызның Чагатай, Үгәдәй, Тули атлы өч улы бергә кушылса да, үзләренә җигән[7] тиеш булган Бату ханга каршы тора алмый. Әмма акылны җуймаска, узынмаска кирәк. Бердән, бабасы язып калдырган «Яса» кануннары бар. Икенчедән, Үгәдәй кахан да — мәңгелек Тәнре түгел. Тәхет бушаса, Чагатай белән Тули дигән агаларының да юл ярырга ярап куюы бар. Ә бүгенгә, иң мөһиме, Сүбүдәй шикелле тугъры этләр һәрчак янда йөрсен. Сүбүдәй баһадирның зәһәр кылычыннан ага тиеш ханнар да дер калтырап торсын. Баһадирны «болгарлардан җиңелгән» дигән яманаттан чистартырга кирәк. Җиңү Сүбүдәйнең үзеннән дә бигрәк Батуга шан китерә. Барсын, җиңсен, хәзер инде Чыңгызханның оныгы Бату ханны дан-шөһрәткә күмсен.

— Өч төмәнне ал да юлга кузгал! — диде ул батырга, үзе уйлап тапкан, үзе тәгаенләгән яу сәфәренә озаткан кыяфәттә. — Байлык-зиннәтләрең кирәк түгел, ханлык өчен яңа җирләр яулап кайту кыйммәт. Болгарларның умырткасын сындырып, бер-ике вилаятьләрен булса да миңа аударып кайт!..

Сүбүдәй Җаек елгасын кичеп чыккан чакта көзге тоташ яңгырлар коя иде инде. Болгар вилаятләре ягында аңа каршы бер көч күренмәде. Сүбүдәй Сакмар тамагында тукталып, атна буе урыныннан кузгалмыйча көтеп тә карады. Һаман сыңар алай дошман да чалынмагач, хорафатка төште. Адым саен болгарлардан янә этлек көтеп ятты, тирләп бетте, чыгырыннан чыкты. Сүбүдәй — яу сәрдәре, ул далада мангайга-маңгай килеп орышлар белән генә егет чактан таныш, ә бу көннәрдә болгарлар мәркәзе Биләрдә нинди пычрак сәясәт уйналганын хәтта күз алдына да китерә алмый иде.

2

Суварларның Мәркәс хәрабәләре янында нинди тавыш-гауга кузгатканын Алтынбәккә көне-сәгате белән кайтарып җиткерделәр. Тәхеткә аннан кала һичбер кемнең дәгъва итә алмасын яхшы аңласа да, Алтынбәк, яман корт тешләгән шикелле, Биләр каласын ташлады да чыкты. Сәфәрдәге гаскәр әле пайтәхеткә кайтып күренмәгән дә иде, ә инде Биләр урамнары халык белән тулды. Ярсып кычкырган ризасызлык-низагъ тавышларын туктатырлык түгел.

— Тугыз ел буена урыс куенында яткан сатлыкҗанны хан тәхетенә мендереп утыртырга безнең башка әле тай типмәгән. Гази-Бәрәҗ безнең өчен инде күптән мәет. Бу чаклы гомер адашып йөргән малны көтү булып көтү дә кире кабул итми. Биләрнең үзендә хан итеп утыртырдай аксөяк әмирләр бетмәгән бит әле. Гази-Бәрәҗне марҗа хатыны алган,

[7] Җигән — туганнан туган баласы, русча - племянник.

тәре таккан, диләр. Иманын саткан әмир кабат урыс бабакае янына кайтып китсен!..

Гази-Бәрәж биш меңлек суварлар нөгәре божрасында кайтып күренгәч тә, халык таралмады. Ай-капу, Шәрекъ-капу аша калага Биләр, Болгар, Кашан, Тубылгытау алайлары да кереп килә, алар исә пайтәхет халкына, әйтерсең лә, канат куйган иде. Янартау тавышлары чыгарып, йодрык болгый-болгый янә кычкырдылар.

— Бар мәркәзне канга батырсаң да, без синең шикелле өрәккә ант эчәчәк түгел! Сине безнең илгә янә урыс баскыннары гына кире кайтардылар. Урыс кулы белән утыртылган ханның урыс кубызына биюдән барыбер туктыйсы юк. Курчак-хан кирәкми! Болгар тәхете, беренче нәүбәттә, Алтынбәккә тиеш! Тиле Юргага кияү булып сатылгансың икән, бар, урыс куенына кит тә олак!

Болгар иленә нинди хәвеф янавын чамалап, мәйдан уртасына Гали сәет чыкты. Ул кыяфәте белән үк утә тыныч иде. Гази-Бәрәж йөзенә текәлеп, иплэп сүз башлады.

— Син, мөгаен, мине белмисеңдә булыр. Чөнки атаң Чилбир ошбу мәркәзебезне яклап шәһит киткән чакта син борын асты кипмәгән сабый бала идең. Синең борыныңыс тоя башлаганда инде мин гыйсъянчыны Шайтан каласына илтеп бикләделәр. Сират күперен кичкән шикелле, житмеш дәрья аша кире кайтсам, инде син юк. Элек мин Болгар иле өчен чичән аламасы булып кына исәпләнә идем, бүген исә сәет...

Карашында шайтан утлары биетеп, Гази-Бәрәж бүлде.

— Менә, сине унбиш ел буена сукбайлыкта йөргән чичән аламасы, дип тә тормаганнар, илнең баш сәете итеп күтәргәннәр әле. Ә миңа, әмир булган кешегә, хан тәхете хакында хыяллану язык адыммыни?

— Мин илемне вә динемне сатмадым! — дип җавап кайтарды Колгали, лаек, горур итеп. — Ә син үз халкыңның өстенә этләр алып килдең. Сиңа Болгар иле, болгар халкы түгел, фәкать тәхет кыйбат! Тайгак юлга баскан түрә, боз өстенә куып кертелгән сыер төсле, һәрчак абына ул. Бер ялганны каплау өчен ун ялган да җитми. Син дә, кирәк икән, тәхет хакына безнең илне яңадан ун дошманга да сата алачаксың. Синең ише әмир Болгар өчен, асылда да, артык. Бигайбә вә дүрт ягың да кыйбла, Гази-Бәрәж. Мин сиңа мәчетләребез вә мөселманнар исеменнән ант китерә алмыйм.

— Син ант итмәсәң, миңа бер түрә дә ант итәчәк түгел. Иң зур дошманым син! — дип котырып кычкыра-кычкыра Гази-Бәрәж ияреннән сикереп үк төште.

Колгалинең әрәм булуыннан шөлләделәр бугай, ике арага дистәләгән ирләр тезелеп басты. Ә Колгали үзе һаман тыныч тавыш белән, әмма нык үкенеп әйтте.

— Атаң рухы син соранны күреп ничек түзә икән? Миңа ул кызганыч...

Гази-Бәрәж суварларга ияреп каладан чыгып китте. Шул сәгатьтә үк Алтынбәк артыннан дистәләгән чапкын озаттылар. Ни галәмәт, аларның берсе дә карт әмирне атна буе эзләп таба алмады.

### 3

Түземлеген җуйган Сүбүдәй үз кул астындагы өч төмәнне Таш Билбау итәкләре буенча, Агыйдел башына төбәп алып китте. Бу тарафта башкортларның бөрҗән, юрмат ырулары корган тирмәләр генә тезелешеп тора, яуга яраклы ирләрнең күпчелеге Таш Билбау тармаклары арасында яткан җәйләүләрдә иде.

«Җиңелмәс баһадир» җыен карт-коры, малай-шалай карамагында гына

калган тирмәләрне талап-җимереп йөрүдән ямь тапмады, ярсыган селәүсен шикелле ыргый-сикерә, Кикрикле тау, Бөркет-оя дигән биек, текә өркәчләр өстенә томырылды. Сәфәренә Мәңгелек Күк Тәңре хәерхаһлык күрсәтмәгән, ахры, өркәчләр өстенә менеп житүгә үк ул гарасат шикелле уйнаклаган янгыр давылы астында торып калды. Барча болытны да билгесез пәһлеван күзгә күренмәс кылыч белән урталай ярган диярсең, күк йөзе җиргә убылган шикелле, янгыр ике көн буена котыра-котыра, бертуктамый койды. Инде шул янгыр дингезеннән качып, Сүбүдәй ике өркәч арасындагы инкүлеккә шуып төшкән иде, анда җайдакларны да кумәрлек сазга кереп батты. Ул да түгел, янгыр тынуга ук әллә каян гына килеп чыккан салкын китереп бәрде. Өй бүрәнәләре шартлап ярылырдай зәмһәрир суык көннәр тезелешеп китте. Сазлык эченә батып әрәм булган мәнгелләргә суыктан катып үлүчеләр өстәлде. Җайдакларны хәзер бер саз гына түгел, һәр меңлектә купкан бизгәк, үләт чире йөзләп-йөзләп йотты.

Өч-дүрт меңгә якын нәүкәрен югалтып Нокыш дигән елга ярына төшсә, ике тау битендә билгесез дошман гаскәре урман сыман тезелешеп тора. Башларында төлке йә сусар тиресеннән теккән тирән бүрек, кулларында көянтәдәй җәя. Сан ягыннан болар ун меңнән дә артмый. Әмма өчәр садактагы укларын давыл куптаргандай койдылар-койдылар да, дулкын юып алгандай, шундук юк булдылар. Яр буенда янә ике мең чамасы мәнгел сугышчысы аунап калды.

Сүбүдәй берьюлы өчәр-дүртәр тарафка ермак нөгәрләре куарга мәҗбүр булды. Эзләренә тиз төшкәннәр икән, ике йөзләп җайдак кичкә чаклы әйләнеп тә кайтты. Ялгыз гына түгел, алты-жиде саугат эләктергәннәр.

— Без — башкортлар, башлыгыбыз — Иштәк, — дип анлатты берсе, һич кенә дә кыстатып тормый-нитми. — Җәйләүләрдәге тирмәләребезне яндырмый үтсәгез, сезгә каршы кузгалмас та идек. Безгә янә дошманнар бер дә кирәк түгел, алар болай да күп.

Тоткын, хәтта, Сүбүдәй күзләрен акайтып тыңлый башлагач та, барыбер тукталмады.

— Әнә, башлыгыбыз булган Иштәк бәкне болгар түрәләре тагын рәнжеттеләр. Аның бабасы Алтынбәк Болгар тәхетенә утырырга тиешле әмир иде. Сувар дигән кабилә бирәннәре әллә каян гына Гази-Бәрәҗне чокып чыгарып, безгә кода тиеш булган Алтынбәкне Биләр каласыннан куып җибәргәннәр. Алтынбәк хәзер дөнья белән алыш-бирешне өзеп, Талказ күле буендагы Кабак атлы мәгарәдә ята. Ә бездә болгар төмәннәрен әйләндереп атарлык көч-куәт юк. Иштәк болгарлардан ничек үч алырга белми өзгәләнә.

— Әйдә, миңа Иштәк чатырына илтә торган туры юлны күрсәт. Мин анын янына бер ялгызым барам, — дип эндәшкән Сүбүдәйнең тәкъдимен ишетүгә, хәзер инде башкорт тоткынының күзләре мангаена менде.

— Ни... ни... ничек... бер ялгызың?

— Капкынга эләккән бүрегә ризык кирәк түгел. Шуңа күрә япа-ялгыз барам...

Ык елгасы ярында яткан Иштәк Сүбүдәйне күреп телсез калды. Ләкин берникадәр вакыт узуга ук ат шикелле туарылып ташлап анлаштылар.

— Мәрхүм Чыңгыз кахан җиһанда күрелмәгән Мәнгелек ил төзеде, — дип ялагайланырга ашыкты башкорт бәге. — Ул безнең гел аксаклый торган Болгар ханлыгы да, берсен-берсе туктаусыз суешып ятучы бетле урыс кенәзлекләре дә түгел. Мин барча башкорт ыруларын алып, Бату ханга кушылырга вә ант эчәргә риза. Иллә мәгәр без ошбу җиребезне берчакта да ташлап китмәячәкбез. Без дә, күбесенчә, сезнең шикелле үк, Күк Тәңрегә табынып яши торган халык. Дин-кардәшләр икән, Бату безгә аерым вилаят

булып яшәргә ирек бирсен. Безне болгарлар шикелле адым саен килеп таламагыз. Ханга тиешле ясак-бүләкләрне без кеш, төлке, сусар тиреләре белән илтеп житкерербез...

Өршәк елгасына таба бергә кузгалдылар. Таш Билбау ягыннан килгән буран һаман күз ачырмый, үзәкләргә үтәрдәй булып уйнаган жил камчы белән ярган төсле кисә-талый иде. Ничек ярарга белмәгән Иштәк мәнгел сугышчыларының байтагына киез япма, төлке тиреләреннән теккән тун өләште. Шайтан туедай котырынган кар дивары аша жиде-сигез фәрсах арасы да үтә алмадылар. Иштәк үзенең меннәрен барларга борылган бер арада, качып-посып кына, аның янына көтелмәгән чапкын килеп житте.

— Теге сатлык бәкне... Гази-Бәрәжне Биләр каласыннан куып чыгарганнар. Болгарлар Алтынбәк кияүне жир бетереп эзли. Безнең кияү хан тәхетенә менеп утырачак!..

Кырык-карта дигән үзәнлектә төнгелеккә аннан-моннан гына ыстан корып, ялга тукталдылар. Таң атканда башкорт меннәреннән жилләр искән иде.

4

Алтынбәк тәхеткә утыруга бер ай үтмәгәндер, Биләр урамына бүре талагандай кылка киемнәргә төренгән кызы кайтып керде. Ил хакиме аны әллә «талак» сүзе белән мыскыллап аткардылар микән, дип хафага төшкән иде. Алтынчәч, сугым мал түшкәсендәге үт куыгын хәнжәр белән кисеп ташлагандай, үзе өзеп әйтте.

— Иштәк сине сатты. Жан сөймәгәнне сөюдән әрем ашау татлырак, ди картлар. Мин дә үз атамның кан дошманы белән бер тирмә эчендә гомер кичерә алмыйм!..

Янә берәр ай чамасы вакыттан соң башкортлар бәге юллаган арадашчы ирләр килеп житте. Алар каршында Гали сәет горур жавап тотты.

— Коръән, никах дигән булып, авызны капламагыз! Аларның берсе дә ил сатарга, үз мәнфәгатенне хатының илә газиз Ватаныңнан өстен куярга кушмый. Иштәк Коръәни-кәрим кануннарын иң беренче бозган. Килен-балакайны еланга тиң ир куенына кереп ятарга бер кодрәт тә мәжбүр итә алмый. Аллаһ-Тәгалә каршында аның гаебе юк. Иле белән гаиләсен саткан Иштәк бәккә үзенә тиешле жәзаларны ошбу фани дөньяларда алып китү язган...

Иштәк белән Алтынбәк арасына мең учак ягып та жылытып була алмас, салкын котып ятты. Үзен янә хан дошманы дип игълан итүчеләр бер ул гына түгел икән әле. Болгар илен көпә-көндез уйнаклаган яшен төсле шаккаттыргыч хәбәр көйдереп-урап үтте.

— Сатлык Гази-Бәрәж мәнгелләргә качкан!..

5

Урыс кенәзлекләре эчендә янә мәхшәр, янә кара кайгы. Үлем каракошы Болгар иленнән аякларын сөйри-сөйри кайтып егылган ирләрнең яртысын туган жирләрендә көтеп яткан икән.

Иделдән алып Балтыйк диңгезенә тикле сузылган басулардагы барча ужымнарны көз башланган беренче көннәрдә үк әллә каян гына килеп чыккан котып салкыннары китереп суккан иде, яз керүгә тын да ала алмаслык корылык көйдерә башлады. Жиһан учак өстенә сусыз көе утыртылган чуен казанмыни, дистәгә якын кенәзлек жирләре әнә шулай кипте. Халык инде болай да кара кайгыга кереп чумган иде. Беркөн таңда тарихта күрелмәгән кыямәт-гарасат тавышына куркып уяндылар. Күз ачсалар, өйләре гыйфрит тавының авызына мендереп утыртылган шикелле

дер селкенә. Түшәм-идән сайгаклары кыйшаешып беткән. Туфракса, су шикелле, өй эченә ага. Өстәл-урындыклар шайтан кытыклавыннан качкан сыман почмактан-почмакка чабып йөри.

Акылын җуйган халык ярымшәрә көе урамга атылды да баш түбәсенә күсәк белән орган төсле янә өнсез калды. Нинди галәмәт, ниткән кыямәт бу? Җир өсте кыялардай олы тәрән сөйрәп аждаһа үткән сыман ермакланып, урамнарга тикле чалшаешып беткән. Моңа чаклы куначадагы яшь әтәч шикелле кукраеп утырган чиркәүләр тезләренә чүгеп калган йә янтаеп бер кырыйга ауган. Күз күреме җитәрлек бар тарафта чыр-чу килгән тавыш, тотып тыялмастай коткы-мәхшәр.

— Кыямәт көне җитте, ахырзаман! Ходай Тәгаләнең генә каргышы бу!..

Табигатьнең мондый җен туеннан соң барча халык атна буе тәгәрәшеп эчте. Инде ипкә-сапка керә генә башлаганнар иде, яңа мәхшәр, янә адәм баласы ишетмәгән афәт.

Барча халык урамда аңгыраешып йөргән бер мизгелдә, көпә-көндез кинәт кенә кояш капланды да җир өстенә караңгылык инде. Бичаралар сугым малы кебек үкерешеп җиргә егылдылар.

— Ахырзаман, ахырзаман! Соңгы көнебез, әҗәлебез җитте![8]

Берникадәр вакыттан соң күк йөзендә кояш янә пәйда булганнан соң да тынычлана алмады, басылмады халык.

— Кенәзләребез Ходай Тәгаләне санга санамаганга, чыгырдан чыгып узынганга килгән җәзалар бу! Үзебез юкка чыкканчы, әйдә, иң элек, ул канәчкеч кандалаларны кырып бетерәбез! — дип дәррәү куптылар да, дистәләгән кала-кирмәннәрдә аксөяк түрәләрнең үзләрен ботарлап, байлыкларын талап бүлештеләр.

Иллә мәгәр афәт чигенмәде. Башлап Новгород ягында яман ачлык купты. Кала урамнарында һәр иртәдә өчәр-дүртәр мең мәет таба башладылар. Коры сөяккә калса да әле аяк өсте көе сөйрәлеп йөргәннәргә мәетләрдән үләт чире йокты. Ачлык белән үләт кырган корбаннарның саны берзаманны кырык меңгә җитте. Калада кенәз итеп калдырылган Александр белән Федор яшүсмерләр язмышларын сынап маташмады, караңгы төн уртасында ияргә атланып, Киевтагы әтиләре Ярослав янына чыгып чапты. Юлда Смоленски каласындагы афәт турында да ишетеп өлгерделәр.

— Ачлыктан үлүче мәрхүмнәр утыз меңгә җиткән!..

Үләт каракошы бар халыкны чалгы белән урган шикелле кырып бара иде. Һәр каланы биек койма, каравыл манаралары белән урап бетерделәр. Һичбер кала капкасына якын килмәле түгел. Ук очардай арага якынайдыңмы, кемнең кем булуына карап тормый атып үтерәләр. Кайбер каланыкылар инде бөтенләй акылдан ук ычкынганнар икән.

— Новгородта үләт чирлеләрдән арыну өчен Салам Түбә урамын, ут төртеп, тоташы белән яндырып бетергәннәр!

— Черниговтагы Михаил сыену эзләп килгән Галич байларын әүвәл юхаланып кала эченә уздырып җибәргән дә, аннары берсен-бер калдырмый суеп чыккан! Байлыклары Михаилга калган!..

Уллары килүгә канатланган Ярослав кенәз дә тик ятмады. Чит биләмә булып исәпләнгән Серенски белән Мосаль калаларын караңгы төн уртасында барып таладылар. Олауларын төяп капкадан чыгуга ук, ике каланы да шундук ут ялмады. Кара гавам ни кылырга белмәгән сарык көтүе урынына уңга ябырылды, сулга ябырылды. Афәт болай чигенмичә торса, явыз тәкъдир озакламый барча урыс кенәзлекләрен дә ялкын сыман ялап үтәр иде...

[8] 1230 елның 3 маенда Рәсәйнең Аурупа өлешендә коточкыч җир тетрәүләр булып уза, ун көннән соң Кояш тотыла.

Юрий кенәз ачлык дигән зәһәр буар елан Владимир белән Суздаль жирләренә керә башлагач та, Болгар тарафына зур илчелек куды.

— Үләт чире безнең жиргә йокса, аннары сезнең Болгарны да камыш түтәлләре урынына кырып бетерәчәк. Сезнең белән тагын жиде елга солых төзергә дә, киленнәр биреп кодалашырга да риза, тик ачлыктан гына коткарыгыз, зинһар!

— Ярар, — дип кул селтәде Алтынбәк. — Илле караб ашлык каян килеп, кая китмәгән дә, без бер уч хәер-сәдакага терәлеп калган мескен кавеммени? Тизрәк төягез дә тизрәк жибәрегез. Игелекне аңлап, берәр заман ашка аш белән җавап бирмәсләрме?..

Урыс жирендәге ачлык аждаһасының умырткасы әнә шулай сынды.

## 6

Өйлә намазын куптән укыганнар, чиллә вакыт үткән, көн кичкелеккә авышып бара иде инде. Шәрекъ капуга алып килгән юлда дистәләгән хәерчеләр төркеме пәйда булды, игътибар бирмәделәр. Капка төбендә торучы тоткавыллар сәер бу нөгәрне һичбер тоткарлыксыз көе Биләр эченә кертә башлады. Каравыл манаралары өстенә менеп баскан сакчы ирләр генә аптыраудан башын чайкап куйды.

— Эт талаган сыман кылка киемнәргә төренгәннәр, ә үзләре үгез тотып ботарлардай таза. Болар хәерчеләр булып кыйланып йөрүче юлбасарлар-мазар түгелдер лә инде?

Хәерчеләр үшән генә ат җигелгән бер олауны сырган көе атлый, ә арбада ертылып-умырылып беткән сарык тиреләренә төренгән ир ыңгыраша-сыкрый аунап ята иде. Каравылбаш Тажи печән чүмәләсе биеклегендәрәк ясалган күперчек өстеннән сикереп төшеп, шушы олау янына килеп житте.

— Кайсы яктан килә бу эт өере? Биләрдә сезнең ише хөрәсәннәргә ни пычагым калган?

— Шәрбән мәгъдәнчеләре без, Шәрбән каралары, — дип берсен-берсе уздыра-уздыра тезеп китте сәер хәерчеләр. — Сездәге Айтуган остага ялланып иртәдән кичкә кадәр Мораса буендагы базларда казына идек тә, менә, башлыгыбыз Фаяз өстенә жир убылып, бахырыбыз бөтенләй ушсыз калды. Имче Гәйнекамалга күрсәтеп баккан идек, ул убырлы карчык «бахырыбызның инбашындагы шәпиеннән кулы әллә тайган, әллә ычкынган», ди. Ә Айтуган оста әле безне яллаган чагында ук әйтеп куйган иде. «Ул-бу булса, тавыш чыгармагыз, барысын да үзем жайлармын», дип. Оста сүзеннән узып кая барасың ди? Менә, шуның хозурына аппарабыз инде. Кертсә, шул Айтуган гына рәткә кертә безнең атаманны.

Айтуган — бар мәркәзгә мәгълүм шәп тимерче. Хан булып ханнар да аргамакларының тоякларын шушы тимерчегә генә дагалата. Каравылбаш Тажи әле аларына да төкереп бирер иде. Ул Шәрекъ капу өчен хан белән вәзир каршында жавап тота торган кеше. Аның теләсә кайсы узгынчыны тотып тентергә дә, кирәк була-калса, кул-аягына богау кидертеп, зинданнарга ташлатырга да тулы хокукы бар. Әмма Айтуган оста исеме белән бәйле кешеләрне алай итеп булмый. Сере дә зур түгел. Айтуган — бер сугуда теләсә кемнең билен сындырырдай таза, гаярь. Холкы да кырау тиюне мәңге белми торган шайтан таягыдай кызу, кадау. Аның белән телгә кермәвең, аның кыңгыр эшләренә күз йомып кала белүең мең мәртәбә кыйбат.

— Мин сезне урыс чигендәге олыслардан киләсез дип торам. Үзебезнең Шәрбәннекеләр генә булгач, куркыныч юк икән, — дип иске табак сыман жәелеп елмаерга мәжбүр булды каравылбаш Тажи. — Урыс жирендә үләт чире яман котыра бит. Уяу булу кирәк. Ул афәтнең Болгар жирләренә үтеп керүеннән Ходай саклый күрсен.

Кылка киемләләр каз көтүен дә көнләштерерлек итеп бердәм каңгылдады.

— Алла сакласын, Алла сакласын. Бәла-каза безнең илкәйләрне берүк урап үтсен...

Каравылбаш Таҗи сукбайларның тимерчеләр бистәсенә юнәлүен күргәч инде тәмам тынычланган иде, ашыга төшкән икән.

Төн керүгә, хан сараена терәлеп утырган мәхәллә-бистәләр өстендә кинәт кенә җир астыннан калкып чыккан аждаһа-гыйфрит телләредәй яман уйнаклаган ялкын көлтәләре пәйда булды. Шәрекъ капу янында торучы toткавыллар әле шайтан сыман котырып биешә башлаган ялкын шәүләләрен күрүгә үк манаралар өстенә йөгереп менгән иде. Ул да түгел, аларны салкын тиргә батырып хәвефкә калдырырдай хәбәр килеп җитте.

— Янгын, янгын! Ханның чаптарлары ябылган каралтылар яна! Бер золымчы ирне эләктергәннәр. Абзарларга пайтәхеткә бүген үтеп кергән шул хәерче сукбай ут төрткән, ди.

Каравылбаш Таҗи үзенең табаннары астына ут капкандай хан сарае ягына томырылды. Килеп җитсә, чыннан да, ханның иң шәп чаптарлары ябылган абзарлар яртылаш янып ауган, андагы малкайларның күбесен коткарганнар, калганы исә җир йоткандай юкка чыккан икән. Сарай сагында торган шыгавыллар кыямәт көнендәге шикелле күз-башларын акайтып йөгерешә. Ике арада дүрт-биш тыкрык ятса да, Курсыбай бистәсендәге угълан-газиләр дә сөңгеләрен тырпайтып килеп җиткән. Иң алда көмеш очлым түбәсен тәвис каурыйлары белән бизәп куйган Җик мәргән күркә сыман кабарынып, канлы яу барышын хәл итүче сәрдәр кыяфәтендә көрпәләнеп йөри. Дөрес, хан үзе яши торган таш кирмәнгә бернинди дә хәвеф-шом янамый. Әмма итәкләренә ут капкач, андагылар да тыныч кына ята алмагандыр инде. Әнә, капкаларыннан сулы ерым өстенә төшерелгән күпер каршында Алтынбәк хан үзе чабышка чыгарга җыенган айгыр төсле унлы-суллы сикереп бәргәләнә. Таш диварлар өстенә менеп баскан Фатыйма ханбикә Алтынбәкнең үзеннән дә уздырып хәвефләнә бугай. Ул әнә бозлы бәкегә чумарга җыенган бичара шикелле йомарланып калган. Кулларының дер-дер калтыравын һич кенә дә туктата алмый, ахры, әле култык асларына тыгып карый, әле ут шикелле кызган яңакларын тота. Аның каравы, әнисенең янәшәсенә чыгып баскан Алтынчәч ханәкәнең йөзендә сызлану-кайгыны сиздерердәй бер чалым юк. Иштәк бәкне үзе ташлап кайткан бу кызыйга кара гавам юкка гына «Атакай» белән «Ирдәүкә» дигән кушаматлар такмагандыр инде. Алтынчәч бүген дә башына яулык-калфак элеп тормый гына чыгып баскан. Әлбәттә, хәситә-мазар кию хакында да уйламаган инде, муены шыр-ачык. Берәр һөнәрче яисә гади сәүдәгәр кызы гына булса, имам-хатыйп чалмасын ничек эләктерергә белмичә аптыраган мулла-мунтагайлар инде әллә кайчан аңа каршы эт өере сыман өрә башлар иде. Ләкин алар өчен Алтынчәч ханәкә — күк йөзендәге якты ай шикелле үк үрелеп буй җитмәс бөек алиһә шул. Шуңа алар дәшми. Ә Алтынчәч, әнә, тегеләрне юри котырткан шикелле, әле бер, әле икенче кулы белән чәчләрен төзәткәләгән булып, өстә балкып тора.

Каравылбаш Таҗи шул рәвешчә, карашын аера алмыйча, хан кызына текәлеп тора иде. Аның артында капылт кына пәйда булган бер шәүләне күреп, тораташтай калды. Хата-шик туардай бер нигез юк — бүген көндез генә ертык сарык тиреләренә төренгән көенчә, чытыр арбадагы кабыклар өстендә ыргырашкан-аунаган булып, аның борын төбеннән Биләргә үтеп кереп киткән йолкыш сукбай бит бу! Әгәр Таҗиның ачыгавызлыгы, пошмаслыгы Алтынбәк хан колагына барып ишетелсәме?!.

Шәрә тәненә җиннәре өзгәләп ташланган тире җилән генә киеп алган сукбай Алтынчәч ханәкәне каурый сыман җинел элəктерде дә, таш диварлар өстеннән күз иярмәслек тизлек белән йөгерә-йөгерә, Олы Күпер урамы ягындагы капкага томырылды. Әле һаман янып яткан абзарларны шундук оныттылар. Таш кирмән каршындагы барча мәйдан тәшвиш катыш аваз белән тулды.

— Ханәкәне, ханәкәне урлап апкиттеләр!

— Хан кирмәне эченә үтеп кергән нинди албасты бу?..

Алтынчәчне иңбашына салып чапкан сукбай мәһабәт нарат агачы сыман төз гәүдәле, хәтта, өстенә кигән ертык тиреләр дә аның тазалыгын, гаярьлеген киметеп күрсәтә, каплап бетерә алмый. Биек таш диварлар өстенә менеп баскан бу пәһлеванның һәрбер хәрәкәте төнге янгын яктысында аеруча дәһшәтле һәм серле булып тоелгангамы, чынында да, ул әкиятләрдәге куркыныч албастыны хәтерләтә иде. Манаралар ышыгына поскан шыгавыллар аңа каршы чыгарга җөрьәт итмәде. Ә «албасты», чебеш урлап качкан тилгән сыман, дивар өстеннән сикереп гаип булды...

«Хәерчеләр» хан абзарындагы иң гаярь чаптарларны урлап качкан иде. Шәрекъ капу аръягына чыккач, ялан кырда аларны фәкать Җик мәргән генә япа-ялгыз көе куып җитә алды. Сарык тиреләренә төренгән «албасты» сукбай ханның сәрдәреннән качып маташмады, дөядәй зур гәүдәле аргамагын аңа таба борды. Булат кылыч очларын күккә чөйсәләр дә, орышларга кереп сынашырга җай чыкмады. Алтынчәч ханәкә үзе «албасты» сукбайның кочагына сенеп, бик бәхетле елмаеп утыра иде, сәер аһәң белән шул туктатты.

— Мин шушындый бәхетне гомер буе көттем, Җик мәргән. Бачман мине хәтта Иштәкнен үз тирмәсеннән урлап китәргә килгән булса да, мин аның белән бергә качуга каршы төшмәс идем. Безнең бәхетебезгә аркылы ятма, кире борылып кит. Шулчагында син миңа гомерлеккә туганымдай якын кеше булып калырсың...

Пәһлеваннар бер-берсенә сынар сүз дә кушмый аерылышты.

## ДҮРТЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

### 1

Өченче яз борын төртүгә үк Сүбүдәй батыр Бату ханны янә тыкырдатты.

— Теге чакта котсыз буран юлыбызны бүлде, өстәвенә башкортлар да сатты. Җигүле тау янында болгарлар тарафыннан җинелү хурлыгы таш кыя шикелле һаман сыртка басып тора. Миңа кара табымны юарга яңа мөмкинлек бир. Болгар илен умарта оясы урынына туздырып ташлаячакмын. Биш төмән җайдагынны бүлеп бир дә озат. Хәзер, әнә, синең кул астында болгарлардан килгән сатлык әмир Гази-Бәрәҗ дә бар. Юлны шул күрсәтер. Җиңү тапмый кайтмам!

Бату ике җәй, ике кыш буена ыжлап та карамаган иде, Сүбүдәй аны салкын тиргә чумдырырлык коткы уйлап тапты.

— Болгарлар өстенә барырга яңа чирү бирмәсәң, мин бабаң яткан Балдак Далага кайтып китәм!..

Бату шушы коткыга каршы тора алмады. Уен-муен түгел, Сүбүдәй — аның ханлыгында меңләгән фәрсах юл үтеп, Таш Билбау тауларыдай тәҗрибә-түл туплаган бердәнбер зур сәрдәр. Көндәшләре булган Чагатай-Үгәдәйләрдә аның янәшәсенә тиң куярлык бер батыр юк. Сүбүдәй белән эш иткәндә кайнар учак янында утыргандай саклана белү кирәк. Гел кирегә торсаң, борын чөйсәң, «сукыр баһадир»ның шул Чагатайлар ягына чыгып

сызуы бар. Бозавынны бүре ашап китсә, бау күтәреп йөрүдән бер файда да килми. Сүбүдәйне читкә типкәләп, соңыннан үкенерлек була күрмәсен. Эт күнеле — бер сөяк ди. Кул астымдагы алайлар сазлыктагы черкидән дә күбрәк. Ике-өч төмән югалып торудан гына олы зыян килмәс. «Сукыр шайтан», әйдә, бер җилләнеп кайтсын.

— Ярар, әнә, кыргызлардан тупланган өч яңа төмәнне ал да Болгар өстенә кузгал, — дип «юмартлык» күрсәтте яшь Бату хан. — Ичмаса, яңа нәүкәрләрне аз булса да сугыш гыйлеменә өйрәтмәссең микән?

Сүбүдәй керпе сыман энәләрен кабартырга мәҗбүр булды.

— Борын аслары да кипмәгән ул кыргызлар белән мин янә адәм хурына калып кайтыйммыни? Кычытканны арт ягыңны ачып куркытмыйлар. Юк, чи күкәй шикелле мәлҗерәп торган андый ангыралар көтүе белән бармыйм! Миңа ярдәмгә тагын үземнең малаем Үрәнгатайны бир?

Бату хан болытлар өстендәге Күк Тәңре шикелле кул селтәде.

— Ал инде, ал...

Бату чатыры янына килеп сыену-казан тапкан Гази-Бәрәҗ, чәчләре чалара башлагач кына кияү төшәген татуга ирешкән сазаган кыз сыман, инде ничәмә-ничә айлар буе шым да чыгармыйча яшәп ята иде. Җәйләүнең аулак, ятимрәк читендә, иң кысынкы почмакта корылган болгар тирмәләре уртасына көтмәгәндә ханның шәхси батырлар алаендагы йөзбаш килеп кергәч, Гази-Бәрәҗ ак канатлы фәрештәне күргәндәй куырылып калды.

— Хан сине үз хозурына чакыра, әйдә, җыен!

Хан чатырында Сүбүдәйдән башка кеше күзгә чалынмады. Бату исә сүзләрне сагыздай чәйнәп тормады, мөгезеннән тотты.

— Мин Болгар өстенә дүрт төмәнлек олы чиру юллыйм. Бу юлы Сүбүдәй аны тез астына салмыйча борылачак түгел. Сиңа нахакка читкә тибелгәнең өчен үч алырга иң кулай җай. Син, мөгаен, Сүбүдәй гаскәренең мөгезенә басарга атлыгырсың инде. Әллә ялгышаммы?

Гази-Бәрәҗ авызына үткен хәнҗәр китереп тыккан шикелле озак вакыт тын ала алмый торды. Бату хан моны үзенчәрәк аңлады, күрәсең, сатлык әмирнең иңбашына кулын салып, юаткандай тезде.

— Әлбәттә инде, тырышлыгың, тугрылыгың бәяләнми калмас. Сәфәр вакытында сиңа үзеңне Сүбүдәйнең уң кулы итеп таныттыру кыйммәт. Минем Урдам котып яктан, туң даладан алып Каф тауларына, Кырын Атауга хәтле сузылачак. Бөек җиһангир булган Чыңгыз бабам миңа соңгы диңгез ярына тикле яткан бар җирләрне үз канатым астына алырга нәзер әйтеп китте. Бүген аерым ханлык саналса да, сугым малы сыман дер калтырап яткан синең ул Болгарың иртәгә инде минем иге-чиге күренмәс Урдамның бер олысы гына булып калачак бит! Җиләндәге ямау төсле генә бер өлеше, шуны аңлыйсыңмы? Сине менә шул Болгар олысында баскак булу мөмкинлеге көтә...

Гази-Бәрәҗ Бату хан каршында йөз кат иелә-бөгелә чатырдан чыгып киткәч, корыган таяк сындыргандагы шикелле чарт-чорт килеп торган кырт тавышы белән Сүбүдәй сүз катты.

— Сатлык әмирләргә тәхетләр вәгъдә итә башладың. Бу тумаган тайның билен сындыру шикелләрәк була түгелме соң?

Бу юлы Бату хан да остазына азау тешен күрсәтеп җавап бирде.

— Яулык чаклы бәп-бәләкәй генә Болгар иленә дә инде ничәнче мәртәбә яу чабасың. Аркаңа бөкрең чыга башлады бит инде, карт алаша! Шулай булгач, бозаулый алмыйча интеккән тана сыман үзеңне дә, мине дә кабат-кабат интектереп йөрмә. Соңгы тапкыр сиңа гаскәр бирәм. Яуламыйча кайтма!

## 2

Сүбүдәй әле юлга кузгалгач та Болгар иленә йөзәрләгән сукмак буйлап йөзәрләгән шымчы озаттырган иде. Жаек ярында «сукыр» баһадирны берәм-берәм шулар каршылады.

— Бачман тархан Алтынбәкнең кызын урлап качкан өчен Биләр белән Саксин калалары арасыннан кара мәче узган. Үзара берләшеп яуга йөрү түгел, алар арасында хәзер хәтта килен алышулар, сәүдә дә юк.

— Башкорт бәге Иштәк Биләрдәге Алтынбәк ханга да, Саксинда утырган Бачманга да коргаксымас үчле. Аны янә Бату ханга тугрылыкка ант эчерү өчен сынар бармак белән чакыру да житә...

Сүбүдәй бертуктамый елан теледәй уйнап торган сынар күзен кичә әмир булып йөргән Гази-Бәрәжгә текәп карар кылды.

— Сина үзенне танытырга вакыт житте! Икейөзле Иштәк каршына, иң әүвәл, син барасың! Сәфәр чыксаң, яман юлдаш белән йөрүгә караганда яхшы таякка таян, ди. Ышанычлы юлдашмы син, әллә таяк кынамы, менә, күрсәт инде.

Гази-Бәрәж Сүбүдәйне әле һаман тирестән сәнәк булган колчурага санап йөри иде, шуны яшермичә ирен читләре белән мәсхәрәләп дәште.

— Безнең якта «көтү кирегә борылса, аксак тәкә алга чыга», дигән бер әйтем бар. Нәрсә, мине дә шулай, качаклыгымнан файдаланып, башкортлар белән япа-ялгыз көе сөзештерергә жыенасынмы әллә? Ә үзең соңыннан, мин яккан учак ягына килеп кул жылытмакчымы?

Өтек әмирнең болай тәртәгә тибә башлавын күреп, Сүбүдәй батыр яшен угы төшкән житен кибәнедәй гөлт кабынды.

— Аh, оясыз кәккүк! Кырда тапкан карганы жылытыйм дип куенына кертсәң, ул соңыннан синең күзенне чукып чыгарыр ди, хак икән. Син ожмахның түренә шулай, чит кешеләр сыртына атланган көенчә барып керү хакында хыялланасыңмыни? Юк, сина бер генә кеше дә үз учында тәбә кыздырып бирмәс! Кабат Болгарына кайтып хан баскагы булырга жыенасың икән, ана чаклы юлны үз күкрәгең белән ерып бар инде син!..

Гази-Бәрәж юеш борынлы малай-шалай сыман башын түбән иеп китәргә мәжбүр булды. Ни галәмәт, Иштәк аны үз меннәре белән Сакмар ярына килеп һәм кочагына кысып каршылады. Сернең төбе хәл-әхвәлләр белешүдән соң ук шактый ачыкланды.

— Теге сөйрәлчек еланны сонгы сулышым житкәндә дә гафу итәсем юк. Аны кире кумаган Алтынбәк тә, ул фахишәне урлап качкан тилемсә Бачман да — гомерлек дошманнарым! Элек мин адәм баласы өчен иң хәтәре үлем дип саташып йөри идем. Юк, аннан да яманрак куркыныч бар икән. Ул — хурлыкка калу! Ул — яманат! Минем алда ике генә юл хәзер. Йә ирлегемне исбат итәр өчен мин ул кәнтәйнең башын чабып өзәм, йә аны яклаучылар минем гомеремне кыеп ташлый...

Сүбүдәйнең көче жинел генә жиде менгә артты.

## 3

Шымчылар дөрес такылдый: Биләр белән Саксин арасында бердәмлек жепләре күптән өзелеп беткән иде инде. Бачманның Алтынчәчне урлап китүе бердәнбер сәбәп түгел, әле өч ел элек, Сүбүдәй Болгар жирендә икенче мәртәбә жинелеп качкач та башланды бу хурлык.

Бачман тархан шулчакта ук бертуктамый тәкрарлаган иде.

— Сыерларынны ач бүреләр ашап киткәч кенә капкын корып йөрүдән ни файда? Ишекне карак кергәнче бикләп кую хәер. Безгә дә Болгар чикләрен төрле яклап ятьмә-капкыннарга төрү кирәк. Уяныгыз инде, әйдә, уяныгыз!

Алтынбәк хан пырдымсыз, мәсхәрәле сүзләр белән авызын томалады.

— Башны бүрек сакламый. Тилгән күләгәсен күрүгә үк мәрткә китә торган куян сыман калтыранма, тархан! Үзең шаһит. Сүбүдәй моннан алты ел элек эт көтүе талаган бүре хәленә төшеп, аякларын көч-хәл белән сөйри-сөйри чыгып качкан иде. Менә хәзер янә илебезнең мәркәзенә дә килеп җитә алмыйча, койрыгын утта көйдергән угры бүре шикелле чиный-чиный качты. Тагын килә икән, анысында да урыс дуңгызы сыман шәрә калдырганчы өтеп җибәрербез. Тик син генә, зинһар, тычкан баласы күргәч тә, аны филгә санап, барабан кагып кычкыра торган булма...

Бачман тархан хан сараеннан ул вакыт кабат мәңге аяк басмаска антлар эчеп чыгып киткән иде. Соңыннан Алтынчәч ханәкәне урлап китү мәрәкәсенә дә барып капкач, Алтынбәк белән ике ара бөтенләй җимерелде. Хәзер дә Саксин вилаятен дошман каршылауга Бачман тархан япа-ялгыз көе генә хәзерләгән иде.

Җаек белән Сакмар буена җибәрелгән каравыл йөзләре вакытында кайтып хәбәр итте.

— Мәңгелләр чирүе Кондызлы белән Кинил елгалары арасында яткан инкүлекләр буйлап тезелешеп килә. Ермак төмәннең мангаена Сүбүдәй үзе түгел, сатлык Бәрәҗ белән сатлык Иштәк баскан. Иштәк Җаек белән Этил арасында яткан бар даланы биш бармагы кебек яттан белә. Башына капчык кидереп куйсалар да, башкорт бәге бер карыш та ялгышачак түгел.

— Сукыр Сүбүдәй үзе, аның кебек үк ике соран качак Иштәк белән Бәрәҗ, — дип уртларын усал кыса-кыса санап чыкты Бачман. — Үләксә барын сизенгәннәр диярсең, карале, никадәрле козгын бергә җыелышкан. Үз башларына килгән булсалар гына ярый инде.

Бачман тархан үзенең нибары бер төмәннән торган гаскәренә ашыгыч рәвештә Чуерташлы инеш тамагына юнәлергә кушты. Икеләнми таянырдай ярдәмчеләре әлләни күп түгел иде аның. Алтынчәчне урлаган чакта үзе белән бергә Биләрдән качып килгән Айтуган оста да, тагын шул — ничә еллар буе яу сәфәрләренә йөреп сыналган кыпчаклар сәрдәре Исәнбай бәк кенә. Бачман үзенең сер-ниятен фәкать шулар колагына чиште.

— Сүбүдәй кул астында биш төмәнгә якын җайдак исәпләнә. Ул кадәрле куәт безнең төшебезгә дә керми. Без Сүбүдәй белән дала уртасында йөзгә-йөз килеп орыша алмыйбыз. Мәңгелләр безнең бер төмән яугирне, үгез көтүе ятим бәрәннәрне таптаган сымак, сытып кына үтә. Саксин диварлары артына кереп бикләнсәк тә, бу чаклы саранча көтүе кирмән эченә үтеп керми калмый.

— Син, нәрсә, әле дошманны күргәнче үк сыртыңны күрсәтеп качарга булдыңмыни? — дип тимерче Айтуган котырынып купты. — Саксинга мәңгелне кертү — иленне сату ла ул!

Бачман тавышына корыч чыны өстәп җавап тотты.

— Син үзең мәрткә киткән карчык төсле саташасың, оста. Ахмак булсалар, әнә, кош-кортлар, ояларына елан шуып кергәч, шуның белән чукышып утырыр, сугышып ятар иде. Чукышмыйлар, чыгып качалармы? Чөнки алар яши-яши кибән чаклы акыл җыйган инде. Ботак-сатактан, салам-куралардан торган ояларны һәрбер агач ботаклары саен һәм көн саен янадан-яңаны корып куеп була. Аларга өр-янадан йомыркалар салып һәм өсләреннән купмый җылыта-җылыта унар, йөзәр бала чыгарып була. Ә бурсык йә бүре урынына өнгә кереп качсаң, сасып беткән өненне саклап ятсаң, иң ялкау сунарчы да ике чиләк су агызып ул ахмакны өненнән куып чыгара һәм элмәккә каптыра ала. Төлке булып төлке дә өненә кереп качмый, ул хәйләкәр. Тәхет саклау хакына сараена кереп бикләнгән хаким дә фәкать ахмак булып кына саналырга хаклы. Юк, Саксин — Аллаһ түгел! Мин Саксинга табынып та, капланып та ятмыйм!

— Алай булгач, кая барабыз соң?

Тавышыннан ук сизелеп тора, Айтуган оста тутык тимер сыман сынып төшкән иде. Бачман тархан элеккечә кыю итеп тезде.

— Безгә бердәнбер юл кала — Жигулат өркәчләре өстенә менеп яшеренү. Сүбүдәй, тинтәк, умарта күче сымак укмашып, таралмыйча килә. Әгәр ул гаскәрен берничә нөгәргә бүлмәсә, Жигулат тауларындагы тарлавыкларга кергәч, юньле-башлы селкенә алмаячак. Аранга кертеп ябылган буаз сыер хәленә төшәчәк ул. Менә шул чагында без аерым-аерым меннәр белән тилгән өере сымак тау башыннан очып кунабыз да, ул буаз сыерны төрле яклап телгәләп һәм чукып бетерәбез! Аһ, ник туганына үкенәчәк көнгә төшерәбез әле без ул Сукыр Сүбүдәйне!..

Бачманның кисәтми-нитмичә ияргә сикереп атлануын күргәч, иң беренче янә Айтуган оста хафа-шомга төште.

— Син кая барырга жыенасың болай? Япа-ялгыз көе Сүбүдәйгә каршы чыкмакчымы әллә?

— Кайгырма, мин ул чаклы ташбаш түгел әле, — дип туарылып көлде Бачман тархан. — Әйттем бит инде, без Саксин каласын саклап кала алмыйбыз. Шулай булгач, Алтынчәчне берәр кая озатырга кирәк...

Алтынчәч аерылышу турында ишетергә дә теләмәде хәтта.

— Мин сиңа «көмәнем бар» дип биш-алты ай элек әйттем ләса. Бу көенчә мин кая барыйм да, нигә синнән аерылыйм әле? Ана каз йомыркалар өстенә менеп утырганда ата каз анын оясыннан бер адым да читкә китми саклый. Ә син? Ә син?

Алтынчәчнең күз яшьләре жанын тырмаса да, Бачман каты торды.

— Сүбүдәй, әлбәттә, сине түгел, мине аулаячак. Әмма аңа тагын Иштәк дигән эт тә ияреп килә. Башка вакыт булса, ул Сүбүдәй чакыруына, мәңгелләр явына төкереп тә бирмәс иде, шаять. Мәгәр хәзер хатынын, балаларын сунарчылар үтереп киткән ата бүре, яралы һәм үчле жанвар хәлендә ул. Аның төп максаты — сине кулга төшерү, синнән үч кайтару. Тәкъдир явыз. Ул үзе белән үчекләшеп уйнаган бәндәләрне бер дә сөйми. Без эт авызындагы сөяк белән шаяра торган ике ахмак булмыйк. Сиңа Биләргә китеп, әтиең канаты астына ышыклану файдалырак бүген. Сине озатырга бер мең жайдак бирәм. Хәзер үк юлга чык!..

Мең газаплар белән кавышкан ике яр беренче мәртәбә сызлана-сызлана аерылышып торырга мәжбүр булды.

## 4

Сүбүдәй гаскәрен һаман таркатмыйча, бер йодрыкка туплап килә иде. Чуерташлы инеш тамагына житәрәк, алда гажәп матур манзара ачылды. Ике якта биек, текә таулар. Уртада сыер теле сыман сузылган тар ялан. Шуны кыл икегә бүлеп, казандагы су шикелле кайный-кайный, ап-ак ташлы инеш агып ята. Яндагы тау итәкләрендә — камырлыклар, гөлжимеш һәм балан куаклары. Табигатьнең хозурлыгына карап, онытылып китәргә дә мөмкин.

Сакмар, Үзән елгалары тирәсендәге риваятьләр, әкиятләр белән күбесенчә Иштәк таныштырып бара иде, хәзер көтмәгәндә Бәрәж телгә килде.

— Бу урынны «Женле ялан» диләр, Сүбүдәй батыр, ишеткәнең бармы?

Сүбүдәй борын астыннан гына елмаеп сорарга мәжбүр булды.

— Ә ни өчен женле?

— Ул борын-борыннан бирле шулай атала инде. Кайчан, нигә шулай дигәннәрдер, төгәл белүче юк. Иллә мәгәр аны бик сакланып, тавышсыз үтү хәерлерәк диләр. Имеш, элек бу яланга Аттила кул астындагы

сөннәр гаскәре килеп кергән дә, шушы тирәдә яшәгән кабиләләр аны тозак корып көтеп торган икән. Монда яман каты орыш булган, ялан мәетләр белән тоташ түшәлгән ди. Аттила — гаярь, көрпәле җиһангир бит. Яуны отуын-откан, ә мәетләрне җыеп маташмаган. Шуңа ярсып, ул елны Идел елгасы ярларыннан чыгып ташыган ди. Монда купкан үләт чире хайваннарга йоккан, шул зәхмәттән янә меңәр-меңәрләгән кешеләр үлеп беткән. Әле ярый, корылык ел килеп, барча үләксәне, үләт базларын яндырып бетергән ди. Иллә мәгәр әлеге ялан иясе гомерлеккә үпкәләгән икән. Хәзер яман юлга чыккан адәм балалары шушында күмелгән кеше сөякләре өстенә төнлә килеп менсә, ялан иясе бик каты тузына да, әллә ничаклы өрәкләр җир астыннан калкып чыга икән. Шулар угъры юлда йөргән сәйяхларны әнә теге тау битендәге чытырманлыклар эченә алып китеп адаштыра диләр. Менә шул уйдырма, әкиятләр аркасында бу урынга «Женле ялан» дигән яманат тагылып калган инде. Әлеге уйдырмага күпләр ышаналар. Мин Суварда яшәп яткан чакта безнең сәүдәгәрләр бу ялангa һәрчак атларын туктатып, аларның күз-колакларын чистартып, өркәк малларның башына капчык бәйләп, ыңгырчак-камытларын тарттырып кыса-кыса җайлап керә иде. Монда чыбыркы шартлату — иң-иң олы гөнаһ, шуңа күрә юлчылар һәрчак атларының муеннарыннан сыйпап иркәли, көйли торган иде. Хәзер ул хорафатлар сакланганмы-юкмы, ул тиклесен белмим. Мәгәр яманатлы исеме хәтерләрдән бер дә китми әле.

Сүбүдәй шүрәле кытыклаган сыман ихахайлап көлде.

— Мин әле үземне генә картлыкка бирешә башладым дип эчтән ашап, көлеп йөри идем. Син әле кырык тирәсендә генә булсаң да, җанын белән миннән картрак икән. Әби-чәби әкиятенә ышана димени акылы бар ират?..

Сүбүдәй сүзләрен дә йотып бетермәде, ике яктагы биек тау өстеннән өермә шикелле уйнап ук яңгыры очты. Беренче ташкын ук мәңгеләрнең меңнән артык җайдагын ияр өстеннән әйләндереп җиргә аткан иде. Ук ташкыны бозлы яңгыр сыман һаман яуды, һаман котырынды. Үгез тиреләрен сумалалап, катлы-катлы итеп ясаган түбәләр астына иң беренче булып Бәрәҗ кереп качты. Иштәк тә яшь киленнәр кебек ачыгавыз түгел, беренче чиратта үзен чүкиячәкләрен бик тиз чамалады.

— Юк, мина ярты юлда ятып калырга ярамый! — дип такылдады ул, Бәрәҗ янына кереп чумуга ук. — Мине әҗәт тота. Бачманнан шул әҗәтне түләтмичә китмим!

Сүбүдәйнекеләр — дистә еллар буе утлар-сулар кичкән, яуда йөри-йөри эт каешына әйләнеп беткән шәп җайдаклар. Алар әүвәл сәрдәрләрен урап алсалар да, берникадәр искә килүгә үк, ике якта сузылышкан биек таулар өстенә ыргылдылар. Йөзләгәне тау битендә ауды, ләкин мең артыннан меңнәр кыргаяклар, селәүчәннәр сыман өскә үрмәләде. Әмма кыялар үренә менеп җитсәләр, анда беркем дә юк, Бачман гаскәре җил юып алгандай юкка чыккан иде.

Сонынннан санадылар. Беренче яуда ук җиде меңгә якын ирне югалтканнар. Ул көнне Сүбүдәй белән Гази-Бәрәҗ эчтән генә гел бер үк сүзне кабатлады.

— Юкка ышанмадык. Женле ялан икән бу, яман ялан икән!..

## 5

Бачман тархан Тугыз Тимер тарлавыгында тозак корып куеп, Сүбүдәйне аранга куып кертелгән мал көтүе урынына янә бер мәртәбә усал дөмбәсләде. Бу юлы инде чолганышка эләккән бүре кебек уяу-сак кыйланганнар, Бачманның тәүге этлекләрен сизеп алгач, үгез көтүедәй ярсып, һөҗүмгә

дә ташланганнар иде. Ләкин саксинлылар түмәне, кырыкмыш тай сыман койрык уйнаклатып, янә күз ачып йомган арада юкка чыкты. Мәнгелләр аларның күп булса ике-өч йөз чамасы жайдакларын гына чүпли алды бугай. Ә баскыннар ягыннан шушы тарлавыкта тагын ике меннән артык ир-ат башын салган иде. Байтак менбашлар белән нойоннар пошаманга төште. Күпчелек кичләрен тирмәләренә бикләнеп үткәрә башладылар. Алар бер тарафта гына укмаштырып куйган камыр сыман бердәм — һәркайсы да, ин тәүге чиратта, Гази-Бәрәж белән Иштәк бәкне эттән алып эткә сала-сала каргый-сүгә иде.

— Йә икейөзле пычак кебек сатлык жаннар болар, йә икесе дә ташбакадай ахмак! Затлы жаннар булса, аларны болгарлар үзләре үк тишек кәвеш урынына чыгарып атмас иде!..

Барыннан да бигрәк Бәрәж газапланды. Инде ничәнче мәртәбә ак болытлар өстендә очына-очына юлга чыккан була, һәркайсында алсу күк йөзеннән сасы сазлык эченә сөйрәп төшерәләр. Тиле Юргага ияреп, тәхет турында хыяллана-хыяллана, туган иле өстенә килгән булды — битенә төкерделәр. Кара чирмеш Пургас Илһам ханны дөмектереп аткач, суварларны өсләтә-өсләтә, янә тәхет эләктермәкче иде — нәжес өстенә йөзе белән китереп капладылар. Тәкъдир-явыз — ахмак кысла сыман, гел кирегә сукалый да тора. Хәтта, моннан өч ел элек Бишколын яланында үткәрелгән гап-гади бәйгедә дә, чи йомырка сыман чәлт ярылып, тәмам адәм хурлыгына калды бит ул.

Алтынбәк үзенә кияү тиеш Иштәк бәк аркасына ышыкланып, Талкас күле ярында качып яткан иде. Анын Кабак мәгарәдә икәнен ачыклагач, Биләрдәге ин абруйлы аксөякләр барып, ялына-ялвара дигәндәй, аны пайтәхеткә кайтарып утырттылар. Шул хөрмәткә Чирмешән буендагы Бишколын яланында, менәрләгән батырларны чакырып, жыен үткәрделәр. Ат чабышы, бил алышу, чүлмәк ватыш, колгага менүләр — барысы да булды. Тантанага бик күп кенә кыргыз, аймык, кыпчак бәкләре дә килгән иде. Шулар соңгы кичтә «Кәләш тоту» бәйгесен башладылар. Әле Кернәк каласыннан, әле Жүкәтаудан килгән кызларны чыгаралар. Тегеләр, эсселәренә чыдый алмаган сыман, әллә юри кыйланып, әллә чынлап, чапкыннарга бик тиз тотыралар. Уен-бәйгенең бер кызыгы йә комары калмый, шундук тәмамлана.

Түше кызган яшь тавыктай бертуктамый кытаклап торган өр-яңа хан алдагы бәйгедә жиңүчегә ин гаярь аргамак белән саф көмештән койган очлым вәгъдә итте. Шуны гына көтеп торган диярсен, бәйге сызыгына туры бияга атланган, курчак сыман бәп-бәләкәй гәүдәле кызый атылып чыкты. Барча тамашаны тын алмыйча күзәткән кунаклар арасында, су өстенә төшкән таш кузгаткан вак дулкыннар сыман тәгәрәп, кайнар чыш-пыш купты.

— Бачман тарханның сенлесе Замирә бу.

— Әт-тәч, әт-тәч! Аңа унике-унөч тирәсе генә түгелмени әле?

— Әй, булса соң! Анын каравы, Замирә кайчак чабышларда хәтта абыйсына да койрык тоттырмый ди...

Гази-Бәрәж Алтынбәк игълан иткән бүләкләргә төкереп кенә караган иде дә, шушы чыш-пыш авазларын ишеткәч, талга кунып сайрарга жыенган сандугачтай очынып-кубып куйды. Бәйге юкка гына «Кәләш тоту» дип аталмаган. «Кәләш»не куып тоту бәхетенә ирешкән чапкыннар соңыннан, гадәттә, үзләренең шушы «корбаннары» белән өйләнешә. Замирә карап торышка әлләни дан түгел. Көтүдән аерылып калгач сазлыкка кереп баткан сарык бәрәне шикелле ябык-хөнжү генә. Анысына түзәрсен, тора-бара, мөгаен, үсәр әле. Ин мөһиме, Бачман сенлесе ул! Ә Бачман кебек башбирмәс

һәм жегәрле тархан-бәкләр белән туганлашып алдыңмы, тәхет юлында терәк табылу бар! Шулай икән, бу форсатны үз файдаңа йөгәнләргә кирәк!

Бәйге сызыгына Бәрәҗ атылып чыккач, күпләр «аһ» иттеләр.

— Мондый карт алаша кая бара тагын? Аңа үз кызларын кияүгә бирергә вакыт ласа инде!

Бәрәҗ әүвәл таш кыя шикелле кымшанмый гына басып тора иде, аны да көйдереп уятырдай кисәү табылды бит. Мәйдан читендә аягына гер аскандай пошар-пошмас кыймылдаучы җайдак пәйда булды. Яндагы бар халык авызларына су капкан шикелле бердәм тынсыз калды. Яңа чапкын — килмешәк кыргыз-аймыклар арасыннан чыккан кара җайдак түгел, ә үзенең тәхеткә менүен тантана итүче Алтынбәкнең улы Булат әмир иде.

Әтисе җиде кат болытлар өстендә йөри, ә Булат әмир йокысыннан айнымаган сыман. Йөзе боек, иреннәр кысулы, карашында бер төрле дә комар-дәрт чагылмый. Ул ак бәкәлле шомырт-кара бер айгырны җитәкләгән булган. Әмма ай буе ач торткан шикелле икесе дә ябык, кипшенгәннәр. Хәтта, Булатының — калак, айгырының оча сөякләре бау китереп бәйләр дәрәҗәдә калкып, төртеп тора.

Бәйге сызыгы Асылтамак дигән челтерәвек чишмә янындарак иде, шунда тезелделәр. Гази-Бәрәҗ барыннан да бигрәк Булаттан күз алмады. Төп көндәш — шул. Чөнки ни әйтсәң дә, ул — хан малае. Казый булып йөргән карачыларның, алдап-хәйләләп булса да, нәкъ Булатны алга чыгаруы мөмкин. Аннары... аннары Замирә сылуның да, хан малае дип, шул Булатка җайлашуы, аның күләгәсенә елышуы да бар бит әле. Һәрбер тарафны да истә тотсаң, беренче чиратта менә шул әмирне читкә кысрыклау, аның юлын кисеп кую мәхкуль.

Кашаннан, Кернәктән килгән бәк малайларының чаптарлары елан таптарга җыенгандай биеп кенә тора, ә Булатның йончу, чак айгыры, мәрткә киткән сыман, юньләп кымшанмый да. Гази-Бәрәҗ юри әмирнең янына барып басты.

— Бисмиллаһи рахман, — дип укына-укына, Терсәкле күл ягына сузылган дала өстенә иң әүвәле Замирәне чыгарып җибәрделәр. Ул ук очарлык ара киткәч кенә ир-егетләр өчен әмер ишетелде.

— Һәммәгезгә дә тик гаделлек кенә юлдаш булсын. Хәерле сәгатьтә, кузгалдык, оланнар!

Кашан-Кернәкнекеләр сызыктан ук эт өере сыман алга томырылгач, Гази-Бәрәҗ дә яңа бия күргән айгыр дәрмәне белән аларга ияреп китәргә мәҗбүр булды. Ләкин күзләре арт чүмеченә көйләп куелган диярсең, Булат әмирне бер мизгелдә дә күз карашыннан ычкындырмады. Аның айгыры сөлек сыман сузылган, борын тишекләре йодрык сыярдай булып киерелгән. Айгыр тулысынча диярлек тузан болыты эчендә калып чаба, әмма үзе гыжлап та карамый, буразна сөрергә чыккан эш аты шикелле башын түбән иеп, бер адым да калышмыйча бара.

Бачман үзе сайлашканмы әллә, Замирәнең аты бер генә «аучы»ны да якын җибәрмичә, өстәвенә, әле үчекләгән төсле, койрык чәнчеп чаба. Корыган Кушкаен янына барып җиткәнче бер җайдакны якын китермәде. Шул Кушкаен яныннан кире борылды ул. Бәйге кануннары кыя-яр шикелле тайпылышсыз, «аучылар»га Кушкаенны «корбан» кызсыз көе генә урарга туры килде. Кирегә борылгач, күпләр әрсезләнде. Менә Кашан җайдагы күрше чаптарның чыраена камчы белән орды. Әнә икенче як читтә әллә Җүкәтау, әллә Тубылгытау җайдагы иярennән чәнчелеп төшеп калды. Аргамакларның кайберләренә якын килмәле дә түгел, алар алдан өйрәтелгән бугай. Якынайдыңмы, йә көндәшләрен тешләп артта калдыралар, йә чапкыннарның үзләрен үк тартып төшерәләр.

Замирә Терсәкле күл буена сыенып, яр өстеннән чаба. Гази-Бәрәҗ бау белән тагылган шикелле, бер дә аннан калмый. Кызга чаклы ике-өч көянтә генә ара бар. Тагын бер ыргы да бу курчакны уң кулына эләктер. Аны ияреннән сосып алып, үз тезенә кучереп кую Гази-Бәрәҗ сыман елгыр ирләр өчен берни тормый.

Хәвеф сиздe бугай, Замирәнең күзләре гүя ут бөркеде, бер кулында каурый сыман нәфис хәнҗәр ялт-йолт килеп алды.

— Кагыласы булма, карт алаша! Синең ише урыс ялчысына яр булганчы, мин, ичмаса, көтүчегә барам!

— Һи-һи, сары чебеш! — дип мәсхәрәләп көлде Гази-Бәрәҗ. — Синдәй бозауга да тышау кидермәсәм, ирлегем корысын ла!..

Шул мизгелдә әллә каян гына ике арада Булат калкып чыкты. Йөзе терелә тотып ашардай булып кара янып чыккан, күз карашы каен тузы урынына бөтереп көйдерердәй ярсу һәм ачулы.

— Замирә минеке, якынаясы булма! Көзән-селәүсеннәр сымак бугазыңа теш белән ябышып булса да үтерәм мин сине!

— Аһ, әле син селәгәй дә мине өркетәсеңмени! — дип яман сүгенде дә Гази-Бәрәҗ кулындагы камчысы белән яшь егетнең йөзенә сыдырды.

Булат әүвәл ияр өстенә бөгелеп төште, аннан инде җиргә авып калды. Тик Гази-Бәрәҗгә дә ерак ара үтү тәтемәгән икән. Әллә каян гына хасил булган тар ерым өстенә абынып, ул да ат тояклары астына очып төште. Замирәне шулай бер җайдак та эләктерә алмый калды...

Бу хәлдән соң ничә айлар үтеп китсә дә, Гази-Бәрәҗ Замирәне һич оныта алмый, чибәр кызый аның хәтерендә төнге йолдыз сыман күз кыскалап, әле булса үзенә тартып, кат-кат ымсындырып тора иде. Ул шушы хатирәне Сүбүдәй тирмәсендә сөйләп ташлады да аны-моны уйламый өстәп куйды.

— Женле ялан янында Хөбби дигән бер хөрәсәнне саугат итеп эләктергән идек бит, шул житкерде. Замирә әле булса Саксинда яшәп ята, җиләк сыман пешеп житкән икән.

Шуны ишетүгә, барыннан да уздырып, Үрәнгәтай купты.

— Тәбегә килеп капмый торган төлке булмый. Әйдә, Саксинның эченә үтеп кереп, ул сылуны урлап апкайтабыз!

— Тәкъдир белән качышлы уйнамыйлар, бала-чага булма! — дип Сүбүдәй үзенең улын акылга килергә чакырып караса да, Үрәнгәтай үҗәт, каты торды.

— Үзеңне бел, атай! Әле ничә еллар элек кенә син Карлыгач дигән болгар хатыны өчен башыңны салырга да әзер иден. Миңа да болгар җиләген авыз итеп карарга бик ярыйдыр!

Кай арада һәм кемнәр аша ишетеп өлгергәндер, кич житүгә Сүбүдәй тирмәсенә тоташ үчтән торган Иштәк килеп керде.

— Бачман миннән хатынымны тартып алган иде. Мин аның сеңлесен урлап булса да аннан үч кайтарам. Үгетләп йә өркетеп маташмагыз, ул кыргый кызыйны урларга мин дә барам!

Һич тә көтмәгәндә берьюлы өч көндәш «кияү» менә шулай бергә берләштеләр.

## 6

Төн. Идел ярына сыенып утырган Саксинның дивар алларында гына анда-санда тезелешеп киткән учаклар пыскып ята. Шәһәр капкаларыннан алар янына чыгучы, утын өстәүче юк. Төннең иң хәвефле вакытлары үткән, таң атар мизгелләр якыная инде. Диварлар өстендә сакчылар күп түгел. Байтагы — сакал-мыекларына чал төшкән карт-коры. Шул, күбрәк йокыны

качырыр өчендер инде, ара-тирә, анда да чышан-пышан гына итеп сүзләр алышалар.

— Бачман «Женле ялан»да ике мең башкортны урып салган, диләр. Иштәк, сатлык, безгә котырган эт сымак ябырылыр инде.

— Саксин өчен сугышып көч-куәтен әрәм итәр микән? Аның төп максаты — Алтынчәчне кулга төшерү бит. Ә ул, әнә, атасы Алтынбәкнең куенына качып ята. Иштәк Алтынчәч артыннан Биләр каласына чыгып китмәгәе.

— Ай-һай, туган. Куәте җитәрдәй булса, Сүбүдәй, сукыр, инде әллә кайчан Биләр каласына төбәп китәр иде. Аннан шөлләп безгә төбәлгәнме? Димәк, бәдәне бик сыек. Биләрне кабып йота алмасын аңлагач, һич югы Саксинны яулап булса да, женен тутырмакчы...

Ялан яктан дивар буена шуышып килеп җиткән дистәгә якын шәүлә пәйда булды. Бер манарадагы тоткавыллар шәйләде, күрәсен, шулар аваз салды.

— Кем бар анда? Нинди угры йөри бу вакытта?

Аста бик басынкы тавыш ишетелде.

— Үзебезнекеләр лә инде, Кызыл Сырт кыясыннан килгән казанчылар.

— Бүген «ачкыч» нинди?

— «Иштәккә — шеш».

— А-ha-ha-ha, дөр-рес! Иштәккә шул кирәк. Сары Тимер чишмәсе янына барыгыз, шул яктаны басманы күтәрәбез...

Унлап дилбегә арасы ераклыкта чылбыр чылтырауга, эчке якта шөбһәле бер аваз яңгырады.

— Бәрәч, нинди чит-ят ирләр ияртеп алып килдең безгә, Кылый Хөбби?..

Аннары кылыч чынлаган тавыш ишетелде һәм барысы да тынды. Тирән кара башлык киеп алган ирләр берникадәр вакыттан соң каладагы бәк кирмәненә үк үтеп кергән иде.

— Хөбби, Сәрвәр! Сез шушы капка төбен саклап каласыз! — дип әмер бирде араларындагы иң зур гәүдәлесе. — Ә син, Иштәк, әйдә, Бачман сараена юлны күрсәт!

— Япь-яшь бер кызыкай япа-ялгыз көе тархан сараенда яшәп ятар микән? Аны канизәкләр тотыла торган арттагы йортлардан эзләү урынлырак булыр, Үрәнгәтай.

— Тархан сеңелесе нишләп канизәкләр лапасында йоклап ятсын инде? Тәвис кошы карга оясына күкәй саламыни? — дип Үрәнгәтай мүкләк сыер кебек каршы торгач, олы төркем булып, Бачман сараена таба кузгалдылар.

Нинди гамьсезлек һәм нинди пошмаслыктыр, сарайдагы ишек төпләрендә беркем дә юк. Бер бүлмә артыннан икенчесен печән кибәне урынына актара-актара, алга ыргылдылар. Һәммәсенең күзе тонган иде, Гази-Бәрәҗнең шыпан-шыпан гына читкә аерылып китүен һичкем сизенмәде. Ә сатлык әмир чоланныкы кебек кенә бер бәләкәй ишек астында тонык ут яктысы шәйләп өлгерде дә, карак мәче сыман бик сак басып, шунда томырылды.

Ишекне сызак кына итеп этеп ачса, почмактагы мичтә соңгы кисәү агачлары пыскып ята, ә түрдәге тар сәкедә ялгыз чибәр йоклый. Кызый ята-ята тирләгәндер инде, дөя йонынннан суккан ак юрганын читкә тибеп аткан. Өстендә үтә күренмәле ефәк күлмәктән башка бер кием юк. Анисынын да итәгеннән бер кулына йомарлап кендегенә тарткан. Тыгыз, алсу ботлар уртасында сихри җәннәт елмаеп күз кыса. Ачык изүләрдә очларына ике

чия төше кунган пар алмалар күзне камаштыра. Алиһәдәй керсез бу кыз бала нининдер матур төш күреп ялкынланган бугай. Ягымлы наз көтеп, алсу иреннәренә чаклы чәчәк тажы кебек ачып куйган бит ул.

Ишек артында усал аяк тавышлары ишетүгә үк Гази-Бәрәҗ Замирәне юрган каплап томалаган иде дә, явыз куллардан аралап кала алмады. Күз-башын тондырып кереп житкән Иштәк жанвар убырлыгы белән ана чат ябышты.

— Бачман, кабих, Алтынчәчне урлап, сине түгел, мине мыскыл итте. Бу кызыкай Ходай Тәгалә тарафыннан жибәрелгән гади әҗәт кенә. Бачманның сеңлесе син кяферга түгел, миңа тиеш!

Гази-Бәрәҗ телсез-өнсез калган Замирәне янә сәкегә ташлады да билбавыннан кылыч суырып алды. Икенче мизгелдә очкыннар чәчрәтеп орыша башладылар. Бер селтәнү вакытында Иштәк кылычы Гази-Бәрәҗнең беләген ярып узды. Орыш дәвам итсә, болар бер-берсенең гомерләрен кыеп ташлаганчы сугышачак иде. Әле ярый, тар ишектән арбалы ат кебек орыла-бәрелә Үрәнгәтай килеп керде дә, печән кибәнедәй зур гәүдәсе белән ике калай әтәч уртасына басты. Сәргаскәрнең улы гыжлап кына дәште, әмма тавышы, барыбер дә, усал, коры чыкты.

— Ике тәкә сөзешә башладымы, икесе дә ач бүреләр авызына барып эләгәчәк. Ә без бу килеш тә дошман авызында. Дәгъвагызны ыстанга кайткач та ачыкларга өлгерерсез әле. Безгә тәртәләрне кире борыр вакыт.

Иштәк белән Бәрәҗ авызларын ачып торган арада Үрәнгәтай Замирәне курчак сыман гына итеп иңенә күтәрде дә, сарык бәрәне урлаган бүре шикелле, куе караңгылык эченә томырылды. Башкалар да шул караңгылыкта кар шикелле эреп юк булдылар.

## 7

Сатлык Бәрәҗ, селәгәе дә кипмәгән малай-шалай урынына алдап, Бачман кадәр Бачман тарханны төп башына утыртты. Бер кич дәвамында, казанда су кайнап чыгарлык вакыт арасында.

Сакчылар Бачманның Кызыл сырт өстендә корылган чатырына инде кичке караңгылык төшеп беткән чакта чем-кара калпакка төренгән тоткын сөйрәп кергәч, тархан әүвәл ыжлап та карамады. Берәр менбаш гап-гади узгынчы чапкынны кулга төшергәндер дә, эш күрсәтмәкче булып, тархан хозурына озаткандыр инде. Моның ише чапкыннарны сәгать саен диярлек эләктереп торалар, әмма табаннарын ярып ат кылы йөгертсән дә, аларның берсе дә асылкошка тиңнәрлек табыш булып чыкмый. Монысы да шул, аяк сөртергә ярамас бушкуыктыр әле, дип тархан яткан урыныннан селкенмичә калды. Аннары, бу карап торышка зыян-зәүрәт китерә алырдай пәһлеван да түгел. Кирәк була калса, Бачман бер үзе дә моның ише өтек-хөрәсәннең унысын берьюлы тез астына бөкләп сала ала. Житмәсә, әнә, ишек төбендә эт шикелле уяу торган ике жансакчы бар.

Тоткынны алып кергән яугир аваз салды.

— Без эләктермәдек аны. Атка атланган көе үзе безнең якка качып чыкты. Кем икәнен әйтми. Бачман тарханның фәкать үзенә генә ачылам, ди.

Тоткын калпагын салып ташлагач, Бачман тере шайтанның үзен күргән сыман аптырашка калды. Аз да түгел, күп тә түгел, аның каршында Болгар илен ташлап качкан сатлык әмир — Гази-Бәрәҗ басып тора иде.

— Әттәгенәсе! Менә сиңа кунак! — дип Бачман тархан сикереп кузгалырга мәҗбүр булды. — Әле кичә генә Бату хан белән Сукыр Сүбүдәй тәлинкәләрен ялый идең. Минем янга нинди җен китерде?

— Үч, үч, бетмәс-төкәнмәс үч! — диде Гази-Бәрәҗ корычтай нык итеп.

Ул, чыннан да, тоташ үч хисеннән генә тора бугай. Күзләре ут бөрки, куллары йодрыклы, үзе дер-дер килә.

— Бату хан янына үз теләгем белән чыгып качмадым мин. Алтынбәк хан куды, харам эш качырды. Алтынбәк хан тәхетенә менәргә тиеш түгел иде, ул харамлап менде! Минем бабам — анын әтисеннән әле күпкә иртә хан тәхетен яулап торган кеше. Илһам үлгәннән соң тәхет миңа тиеш иде, ә Алтынбәк аны, кызын Иштәк бәккә биргән булып, аның көчен кулланып яулап алды. Аның белән генә тынмады, Суварга чирү җибәреп, минем бөтен ихтыярыма тышау, богау салды. Яшәргә көн калмаганга күрә генә мин Болгар иленнән качарга мәҗбүр булдым. Сукыр Сүбүдәйгә дә үз ихтыярым белән бил бөкмим мин, ә чарасыз калганга, Алтынбәк мине кол хәленә төшергәнгә күрә шулай җан асраган булам.

— Ә шулай да, ник нәкъ менә бүген минем янга качып чыгарга булдың соң әле син? — дип кабатлады Бачман. — Мин бит үземне Алтынбәкнең кияве дип санасам да була. Сине чыбык-чабык урынына җыеп бәйләп, Алтынбәк бабакаем янына озату да берни тормый. Шуны белә торып, ник килдең соң? Үлемнән курыкмыйча йөртә торган нинди өметең бар?

Гази-Бәрәҗнең йөзендә төк тә селкенмәде, элеккечә кыю итеп дәште.

— Син дә яшереп кенә булса да Болгар тәхетенә утырырга җыенасың, тархан. Мин бит белеп торам. Алтынчәчне урлап китүең дә — шуның бер сәбәбе. Алай-болай була калса, син дә Болгар тәхетенә менеп утыруга каршы түгел. Дөрес пупалыйммы?

Бачман тархан угрылыкта тотылган кеше сыман карашын аска яшерде. Гази-Бәрәҗ аны башкача газаплап маташмады, ниятен тезеп китте.

— Саксиннан Болгарга чаклы юл Җидесу белән ике арага караганда күп мәртәбә кыска. Менә шуңа күрә синең янына килдем. Минем өчен синең канат астында булу күпкә отышлырак. Өстәвенә, синең миһербанлыгыңа, синең ихтыярыңа ышанып кына да килмәдем мин. Дуамаллыкларың да, кайнар гадәтең дә миңа яхшы таныш. Синнән мине чыбык-чабык урынына төйнәп озаттыру, чынлап та, ерак йөрми. Андый хыйлафлыклардан аралап калу өчен олы тауар, олы сер төяп килдем мин синең янына. Буш кул белән түгел. Юк, буш кул белән түгел.

Бачманның борын тишекләре бәйгегә кузгаласы ярсу чаптарныкы сыман киерелде.

— Нинди тауар, нинди сер ул тагын? Йә, сагыздай сузма.

Гази-Бәрәҗ әүвәл җим генә ташлады.

— Синең сеңлеңне Сүбүдәйнең малае Үрәнгатай саклый. Замирәне урлап кайткан өчен Сүбүдәй белән Үрәнгатай икесе үзара яман бозылыштылар. Сүбүдәй хәтта Замирәне бөтен гаскәр каршында турап ташламакчы булды. Шуннан соң Үрәнгатай Замирәне Сүбүдәй ыстаныннан читкә алып качарга мәҗбүр булды.

Бачман Гази-Бәрәҗнең беләгеннән чытырдатып кысты.

— Кайда минем сеңел? Йә, тизрәк әйт! Мин синең алда гомерлеккә бурычлы булачакмын.

Гази-Бәрәҗ җилем сузган сыман көттерә-көттерә тезде.

— Очкылык тавы артындагы Күмерле Балак яланы хәтереңдәме?.. Үрәнгатай үзенең төмәне белән хәзер менә шунда тора... Төмәне тулы түгел, җиде мең чамасы. Бер меңгә якынын син Женле яланда кырып салган идең. Тагын ике меңе Сүбүдәйнең шәхси фәрманы буенча Кернәк каласы ягына җибәрелде.

Бачман тархан ут капкан шикелле коралларын барлый башлауга ук, Гази-Бәрәҗ дә жеп урынына аңа тагылды.

— Мин үзем дә барам. Айлар буена эт типкесендә йөрткән өчен ул Үрәнгатайдан әҗәт аласым бар!..

Бачман тархан унбиш мен яугирен дәияргә күтәреп юлга чыккан иде. Таң атканда Күмерле Балак яланына барып житсәләр, инкүлектә бер көтү елкы ат утлый да, куй көтүе йөри. Тагын шул, көтүчеләр итеп калдырылган мәнгелләрнең саны ике йөзләп бардыр.

— Теге сатлык кайда? Гази-Бәрәж кайда? — дип Очкылык тавын ишәрдәй куәт-ярсу белән үкереп жибәрде Бачман.

— Ул ярты юлда ук егылып калды ла инде. Әллә аягы чокырга эләгеп аягын сындырды аның аргамагы, әллә янып ауды, — дигән жавап бирүче бер йөзбашы табылган иде дә, котырынган Бачман ул мескенне икегә телеп атты.

Башкалар да ярсудан мәнгел көтүчеләрен турап ташладылар.

Берәр сәгатьтән соң тәннәрне чымырдатырдай хәбәр килеп житте.

— Сукыр Сүбүдәй Саксинны яулап алган!

## 8

Бачман тархан тирән тарлавык төбе буйлап аккан Акчишмәгә текәлеп тик утыра. Аның инде ике тәүлек буена авыз ачканы, ризык капканы юк. Йөзе корым яккан сыман кара янып чыккан. Күзләрендә үкенү һәм сагыш. Жир ярылса, шул мизгелдә кереп чумар иде, ул да тынламый бит. Башны ташка орасымы әллә? Күк капусы сыман ишелеп төшкән бу кадәрле хурлыкларга ничек түзәргә соң?

Бачман Акчишмә янына беркемне дә якын жибәрмәскә әмер биргән иде. Тау юлында кисәк кенә аяк астыннан ычкынган таш тавышлары хасил булгач, ярсыган үгез шикелле урыныннан сикереп купты да, үзен-үзе белештермичә, жиргә тибә-тибә, үкереп үк куйды.

— Башыгызны кисеп атам хәзер! Миңа комачаулыйсы булмагыз, дидем түгелме соң сезгә?

Тарлавык юлына борылып карагач, Бачман тархан ташка кадаклап куйгандай хәрәкәтсез калды. Тау итәге буйлап күтәрелеп килүче егет — Алтынбәк ханның улы Булат әмир иде. Бачман аны соңгы елларда якыннан бик тә сирәк күрә, әмир буйга нык калыккан. Борын астына чем-кара тар мыек сызылган, куе кашлар астындагы күзләр утлы күмер сыман янып тора. Инбашлары да таза, шәпле инде, берсе-берсе эре чүлмәк чаклы.

Булат әмир Акчишмә янына менеп житте де, бер сүз әйтми-нитми, Бачман тарханны кочагына алды. Бачманның күңеле аша, ут шикелле яндырып, матур, жылы хатирәләр үтте. Егетнең кайчандыр Замирә өчен бәйгегә генә түгел, хәтта, Гази-Бәрәж белән орышка да керүе хакында ишеткәне бар иде аның. Ләкин бәйге — дала егетләре өчен күнегелгән йола, ир булып житлегү юлында котылгысыз уен гына ул. Кайсы ир-ат кына үз гомерендә фәлән кабат чабышка кермәгән дә, кайсы ташбаш кына кызлар өчен йодрыкларын төйнәп орышмаган? Ә сайлаган мәхәббәтең хакына канлы яуга керү, үлем аждаһасы белән хисаплашмау — анысы бөтенләй башка. Жегәре сыек йә ялкыны сүрән бәндә тәкъдир белән бил алышу ише тәвәккәллеккә бармый.

Булат әмир өлкән илдәшенең күзләренә нык тәвәккәл багып, өзгән сыман әйтте.

— Мин Замирәне алырга килдем, Бачман батыр. Сүбүдәй батыр жиде башлы аждаһадай көчле, анысын бик беләм. Әмма Замирәне шул аждаһа авызыннан тартып алмый торып, кире борыласым юк!.. Чөнки... Замирәдән башка миңа яшәү дә юк!.. Яшәп булмый, менә шуны аңла...

Акчишмәнең салкын суын учларына алып эчкәч кенә, яр буендагы ташлар өстенә тезләнеп торган көе янә өстәде ул.

— Мин коры кул белән килмәдем. Атам миңа биш мең яугир бирде.

Бачман тархан күзләрен акайтып гел шаккатты.

— Алтынбәк хан... чиру бирдемени? Әллә... әллә ул да, ниһаять, мине кияве дип таный башладымы?

— Танымый нишләсен? Алтынчәч апа бүген-иртәгә синнән бәби табачак бит, — дип көлемсерәде Булат әмир һәм шул мизгелдә Бачман элек белгән шаян һәм кайгысыз бер малайга әйләнде дә куйды.

Хәер, бу чаклы шаклыктан дүртенче дистәсен кырлап барган Бачман да акылдан шашкан иде. Алар — әмир дәрәҗәсендәге ике ир-ат — бар кайгыларын онытып, бер-берсенә су чәчрәтеп уйный башладылар.

## 9

Көн артыннан көннәр үтә башлагач кына үзенең ни тикле яман һәм хәвефле ятьмәгә кереп кабуын чамалады Сүбүдәй сәргаскәр. Саксин өстенә һөҗүм итүче дә, диварлар каршына килеп көч-гайрәт белән масаеп йөрүче гаскәр дә юк, ә кала бөтен яклап бикләп куйган төсле. Сүбүдәй сәрдәр сынау өчен генә әле төнлә белән, әле таң атканда берәр-берәр төмән җайдагын Идел ярына чыгарып карады, утлы кисәү белән пешекләгән шикелле куып, янә кала диварлары эченә кертеп бикләделәр. Төмәннәрне далага чыгарып җибәргәндә бөтен җиһан мәрткә китеп тынган, ук очышы түгел, хәтта җиде-сигез фәрсах арасында сыңар каравыл-торгак та гел юк төсле. Ләкин җеп шикелле сузылган меңнәреңне тәгәрәтеп чыгара башладыңмы, йә Җигүлат тау сыртыннан, йә Идел уртасындагы бер утраудан ярканатлар кебек пырхылдап чыгалар да, төмәнең өстенә умарта күчедәй ук янгыры коеп каршылыйлар. Җайдаклар кайнар таба өстенә эләккән борчак урынына сикерергә мәҗбүр. Беренче казыкны каккан кеше Саксин каласын, әй, мәкерле һәм отышлы җиргә китереп кора белгән дә соң! Идел белән Җигүлат арасында, каеш яисә тасма сыман сузылып, тар гына җир ята. Уң таба да, сул таба да борылмалы түгел, телисеңме-юкмы, фәкать шул тар каеш-тасма өстендә генә хәрәкәтләнергә мәҗбүр ителгән мескен, бичара син. Болгарларга каршы чөй яисә чылбыр шикелле сафлар корып һөҗүм оештырырга тырышып карадыңмы, тегеләр җил юып алгандай шундук юк булалар. Сүбүдәй алданган, кыйналган җайдаклар янына ярдәмгә тагын биш-алты мең генә булса да гаскәр чыгардымы, болгарлар җир астыннан калыккан өрәкләр шикелле янә пәйда була. Тагын бозлы янгыр сыман ук давылы, тагын юкка чыгу һәм хәвеф-дәһшәт бөркеп торган тынлык.

— Бу урында Идел уртасында бер-ике зур утрау бар, — дип аңлатмакчы була сатлык Гази-Бәрәҗ. — Бу хәтле тиз арада пәйда була алмаслар иде, шунда качып яталардыр инде. Аннары саксиннарны әле элек тә йөзмә утрау ясап алдарга чос халык, дип куркыталар иде. Алар Идел өстеннән узган урыс, гөрҗи, әзери байларын шулай талап ята торган булган. Без дивар өстеннән карап торган чакта тоташ таллык булып күренгән, әнә, теге атау да, бәлки, зур-зур саллар өстенә корылган күчемчәк ыстандыр әле.

— Дыр, дыр, бәлки, — дип үчекле Сүбүдәй. — Син шушы илдә туып-үскән кешеме соң, минме? Бу Бачманның кайда качып ятканын миңа кем ачыклар?..

Ташбаш малае Үрәнгатай белән шушы Гази-Бәрәҗ коткысына бирелеп, Сүбүдәй үзенең Саксинга килеп керүенә үкенеп бетә алмый. Терсәк якын да бит, тешләп кенә булмый. Аю өненә башын тыккан аучы сыман булды. Башын бик тартып алыр иде дә, гүя аның үзен аю кочаклап тоткан.

Саксиннан бер якка да аягыңны атламалы түгел. Дала уртасында, тоташ янгыр астында калган бичара юлчы шикелле тешләрен-тешкә шыкылдатып утырырга мәҗбүр...

Мондый тозак уены тора-бара саксинлыларның да үзегенә үтте. Иң беренче булып, яшь үгездәй ярсыган Булат әмир купты.

— Без һаман болай «алма пеш, авызга төш», дип утырсак, озын җәй генә түгел, көз дә үтеп китәр. Син Сүбүдәйнең Үрәнгатай белән Замирәне өйләндереп куйганын көтәсеңме әллә?

— Авызыңнан җил алсын, ни сөйлисең? — дип Бачманның чебен куган сыман җилпенүе ярдәм итмәде, Булат әмир һаман саен ярсый барып тезде.

— Соң, болай кул кушырып утырсак, Сүбүдәй өйләндерер дә. Тархан кешенең үз сарае эченә үтеп кереп, аның бертуган сеңлесен килен итеп алып кайту аңа дан китерми дип беләсеңме әллә? Китерә, әле ничек кенә! Моннан тугыз ел элек синең кулдан көч-хәл белән качып котылу хурлыгын юу өчен Сүбүдәйгә нәкъ шул гына кирәк. Җинелү хурлыгын да юып төшерәчәк, сынар күзен югалтып кайтуны да. Сүбүдәй кияве булырга җыенасың икән, әйдә, утыр инде, әйдә, утыр!

— Без болай да Сүбүдәйне утлы табага баскан шикелле биетәбез ләса. Сарык урларга килеп эт абзарына эләккән бүре хәленә калды. Без барыбер аны исән-сау көенчә чыгарачак түгел. Шуннан ары син миңа ни кылырга тәкъдим итәсең соң? — дип һөҗүмгә күчмәкче булды Бачман тархан.

Булат чигенмәде.

— Бүре сымак биетү генә дә җитми. Абзарга күселәр ияләшсә, аңа ут төртәләр. Шунсыз котылып булмый. Әйдә, уйлыйбыз, үлчибез дә Саксинның бер башыннан аңа ут төртәбез!

— Саксин минем кендек каным тамган газиз калам ласа! — дип кычкырып җибәрде ярсуыннан тыелып кала алмаган Бачман. — Әткәм-әнкәм яткан кабер өстенә мин үз кулларым белән ничек ут төртим,ди?

Булат әмир дә нәкъ Бачман тархан шикелле кычкыруын белде.

— Мин сиңа бөтен калаңа да ут төртәбез, димим. Саксиндагы ике-өч урам янып бетә икән, пычагым да булмас! «Йортың янса, шул сөенеч — кандалалары калмый», дип шаяртканнарын ишеткәнең бармы? Нәкъ менә шуның шикелле. Бер иске йорт урынына ике яңаны, бер янган урынына өчне торгызырсың. Саксин яшәреп китәр, урамнар ямьләнер. Ә иң мөһиме, ут ташласак, Сүбүдәй кул астында килгән мәңгел этләреннән котылырбыз. Янгын вакытында Замирәне коткару да уңайлырак булыр.

Бачман тынып калды, күзләре шар булды.

— Ничек, ничек итеп? Замирәне ничек итеп коткармакчы булдың?

— Мин бу хакта инде әллә кайчан уйлап куйган идем. Шул, синең туган калаңны ничек яклыйсыңны белгәнгә күрә генә әйтми түзеп килдем. Замирә әллә кайда түгел, һаман да шул синең сараеңа бикләп тотыладыр. Аның Үрәнгатай гына түгел, хәтта Бату ханның үзенә чыгарга ризалык бирмәячәгенә бер шигем юк. Ләкин вакыт дигәннәре һаман үтә тора, ярдәмнән өмет өзеп йә кул селтәп аның берәр хата эшләп ташлавы бар. Синең сараеңнан Иделгә төшә торган урамга тоташы белән ут төртергә кирәк. Йөзмә атауны нәкъ шул урам каршына агызып китерербез. Мин икеме, өчме йөз яугир белән яр астыннан урамга бәреп керәм. Ә син тагын, әнә, Олы Базар урамының бер башына, аннары... аннары Тешсез Ялан яклап бер-ике йортка ут төрт. Йә, сыкранма. Саксин берьюлы өч яклап яна башласа, Сүбүдәйнең каладан чыгып качудан башка чарасы юк. Ул вакытта аларның берсендә дә Замирә кайгысы калмый. Үрәнгатай — түбәнбаш, ул уң мең мәңгел

гомере өчен җавап бирә. Шулай булгач, Үрәнгатай булып Үрәнгатай да Замирәне ташлап яуга ыргылачак...

Яуны әзерләргә бер көн вакыт китте. Җәйге кыска төн Саксин өстенә кара юрганын ташлагач та, каланың берьюлы өч ягында янгын кузгаттылар. Булат әмир һәммәсен дә дөрес чамалаган, мәңгел яубашлары, яман хәвеф тоеп, кырык меңгә якын җайдакны да ияргә күтәрделәр. Үрәнгатай Замирәне биш йөз нәүкәр сагында калдырып киткән иде. Шулчаклы каравыл да асылкошны саклап кала алмады.

Булат дошман арасында кубачак тәшвишне чамалаган, әмма бу төннең бик җилле буласын берәү дә исәпкә алып тормаган шул. Ә Идел яклап дулаган җил янгынны тархан сараеннан тыш әле ат абзарлары, Чүлмәкчеләр бистәсе ягына куа башлады да, күз ачып йомган арада тагын ике-өч урамны котырынган ялкын чорнап алды. Монысы инде уен-муен түгел, каладан исән-сау көе чыгып кача алуны да шиккә салган иде. Замирә янында сакка калдырылган нәүкәрләрнең дә өч йөзләбе чаптарлары ябылган тар абзарлар эченә ташланды. Һәм менә нәкъ шул минутта Идел яры астыннан Саксин урамына чи ат, чи үгез тиреләренә төренгән ирләр калкып чыкты. Болар ялкыннан, кызудан да куркып тормый, җәһәннәмнән чыгып качкан җен-пәриләр шикелле сикерә-сикерә, тархан сараена таба йөгерә иде. Ара-тирә Булат әмир тавышы гына ишетелгәләп куйды.

— Хөсәен, Ильяс! Сез Олы Базар ягын каплагыз! Гафур, Әҗми! Ә сез минем белән!

Тархан сарае янындагы сугыш озакка сузылмады. Булат Замирәне сарайдагы иң ерак почмакларның берсеннән эзләп тапты. Аны дер селкетеп яисә су бөркеп караудан бер файда юк — кызыкай йөнтәс тиреләргә төренгән кыргыйларны күрүгә үк исен җуйган иде. Булат аны кочагына кысып күтәрде дә, янә колын шикелле сикергәләп-ярсып, дөрләп яна башлаган сарайдан түбәнгә, Идел ярына таба томырылды.

## 10

Өч айдан соң башын түбән иеп кайтып кергән Сүбүдәй батыр Бату хан алдындагы хисабын бик тә кыска тотты.

— Мин унбиш мең нәүкәреңне югалтып кайттым, хуҗам. Ассаң ас, киссәң кис, мин гаепле түгел. Бу болгарлар — йә сихерче бәндәләр, йә җеннәрдер инде. Суда да батмый ул дошманнар, аларны ут та алмый. Кырык мең нәүкәр белән бер Саксиннарын да ала алмагач, боларның иле өстенә йөзәр меңләгән гаскәр туплап бару мәслихәттер. Үзебез генә җиңә алмабыз сыман. Син — олуг хан. Беренче корылтай җыелгач та, алларына чыгып, үзеңә ярдәмгә бар мәңгелне чакыр.

Бату ханны, әйтерсең лә, усал корт тешләде.

— Кеше кулы белән күмер сосма әле! — дип, аяк тибеп, ярсып кычкырды ул. — Менә, корылтай булыр, чык та сөйлә! Син булдыксыз өчен бөтен мәңгел халкы алдында оятка калыр хәлем юк. Болгарлар — тик син генә эзләп тапкан җимеш. Нык ачымы? Ачы булса да, үзең аша инде!

*Дәвамы киләсе саннарда*



Әсхәл
Әхмәт-Хуҗа

# ТОРМЫШ ТОТАШ ӘКИЯТКӘ ОХШАШ

## Дөнья матур!

**Дөнья шундый матур,**
**Тормыш—гүзәл,**
**Һәрнәрсәгә бер ямь өстәлгән,**
**Бөре чатнап шытып чыгар төсле**
**Мин җыр язган имән өстәлдән!**

**Урамнарда апрель чабып йөри,**
**Яланаяк малай шикелле.**
**Күрше тирәк бүген толым кискән**
**Үзе көләч,**
**Үзе сипкелле.**

**Элеккечә түгел җир,**
**яз, һава,**
**Мин үзем дә түгел элекке.**
**Бу күкләрдән миңа тик наз ява,**
**Бу гөрләвек миңа сөекле.**

**Алтын чәч тузгытып**
**Кояш йөзә**
**Болытларның зәңгәр күлендә.**
**Кояшмыни?!**
**Юк, юк,**
**Ул салават**
**Күпере бит балкый күңелдә.**
**Өй алдында уйный бала-чага,**
**Сабый түгел—**
**Гүя нур алар.**
**Кар -**
**әйтерсең тәмам җиткән кымыз!**
**Шул исертә, диеп кем уйлар?**

**Кешеләрдән шатлык чәчрәп тора,**
**Алар күркәм,**
**Алар сылулар.**

Әсхәл ӘХМӘТ-ХУҖА (1942) – *башкорт шагыйре; рус, башкорт, татар, чуваш телләрендә чыккан күпсанлы китаплар авторы. Г.Сәлам исемендәге премия лауреаты. Башкортстанның Әбҗәлил районында яши.*

**(Тик нигәдер капылт төс җуйганнар
Кичә гашыйк иткән яшь кызлар!)**

**Өр-яңача бүген бөтен нәрсә,
Яр да ярсу хәтта елгада.
Мин үзем дә, ахры, өр-яңача
күрәм,
ишетәм,
сөям,
елмаям.**

**Дөнья матур,
Дөнья шундый матур!
Тирә-якта нәфис бер ямь бар.
Тормыш — гүзәл,
Чөнки бу дөньяда
Мин яраткан тиңсез бер җан бар!**

* * *

**Мин белмимен:
Ниләр аерып торып,
Очраштырды ниләр соң безне?
Әллә язмыш шулай юлыктырды,
Юрап безгә иң зур сөюне.**

**Әмма беләм:
Янып гашыйк булдым,
Көйдем көймәгәнчә һичкайчан!
Сөйдем.
Сөям.
Сөярмен дә һаман.
Бу бәхетемнән һич тә мин качмам!**

**Син — язмышым:
Мине ир иткән дә,
Җир иткән дә—син, дип атадым;
Син — аккошым!
Сине күңелемдә,
Килерсең, дип озак сакладым.**

**...Сине юллап күпме еллар үтте,
Күпме сулар кичтем...
Һәм таптым.
Аңладым мин:
Кайнар тир тамызып
Эзләп тапкан бәхет — иң татлы!..**

**Тау икәнмен,
Миндә тамыр ярган
Син ак гөл бит —
Шуңа сөямен.
Таң икәнсең,
Синнән нурлар алган
Мин ал көн бит —
Шуңа сөямен.**

**Бары синдә,
Гүя синдә генә
Җирдә яшәвемнең асылы,**

Синнән генә,
Синнән тормышыма
Соклангыч бер дөнья ачылды.

Тик елмайчы!
Син елмайсын, диеп
Кышны яз итәргә әзермен...
Йолдызларга сине күтәрермен,
Наз,
Хис,
Сагыш,
Күз-яшь күрсәтермен —
Тик бәхетсез итмәм, бәгырем!

## Әкияти тормыш

Тормыш тоташ әкияткә охшаш:
Яхшы... яман —
Йөри янәшә;
Сөйгән ярым —
Диңгез аръягында,
Сөймәгәнне язмыш ярәшә.

Бәгыремне аһ-зар кискән чакта
Күз яшьләрем кулгә төйнәлә.
Адаштыргыч урман урап алып,
Бер урында кайчак әйләнәм.

Кайчагымда очам толпар булып
Һәм мәтәләм кайчак упкынга;
Явыз җаннар мине буып алса,
Үреләм мин бары буш кынга...

Тылсымлы сүз табып,
Ачмак булам
Хәзинәләр тулы сандыкны;
Тылсым-сүзләр генә аз табыла,
Ачыла да сандык —
Тиз ябыла...
Кандыралмый калам тансыкны.

Канмас тансыгымны кандырырга
Җанчишмәмне эзләп юл чыгам.
Ак күңелле чал карт,
Фатихалап,
Ак юл тели миңа—юлчыга.

Туктаталмас мине:
«Йөрмә инде,
Куркыныч күп!»—дигән үгетләр...
Тормыш тоташ әкияткә охшаш:
Алда — бәхет,
Алда - өметләр.

## Шигырь

Дуен-өермәдәй хисләр уйный,
Җил-давыллар дулый күңелдә...

**Кинәт шулчак**
**Җанда яшен яшьни,**
**Күк күкрәүгә йөрәк күмелә.**

**Нәҗәгайлар балкый баш очында,**
**Гөрләвекләр ага алдында.**
**Коя яңгыр —**
**Шарлап-шартлап явып,**
**Уй ташкынын ача аңында!**

**Көтмәгәндә...**
**Салкын тәнне өтә,**
**Калын көртләр каплый тойгыңны.**
**Хыял ойый.**
**Бурый да гына бурый,**
**Буран йолка ярсу уеңны...**

**Ләкин —**
**Тагын кояш чәчрәп көлә!**
**Кыйгач болыт йөзә түбәндә!**
**Сулда — ал таң,**
**Унда — шәфәкъ дөрли!**
**Саф чык сәйлән тезә үләндә!**

**Төне буе янган аҗаганнан**
**Җан урында түгел...**
**Очасың...**
**Телгә килгән сүзне әйтмәс өчен**
**Нык иттереп**
**Тешең кысасың...**

**Зиһенеңә былбыл моңы тама.**
**Йолдыз карый сиңа елмаеп.**
**Кайчак—кырау,**
**Кайчак боз да суга**
**Төссез хәрефләрне юл саен.**

**Рухыңны йә чәчкә өне назлый,**
**Йә каезлый кышның боз-кары...**
**Тик түзәсең,**
**Тик син эндәшмисең,**
**Чын сүзләр бит, дисең, югары!**

**Асыл шигырь, дисең, томан ярып,**
**Карурманнар ерып табыла...**
**Һәм**
**Шулвакыт**
**Таудан тауга баскан**
**Җәйгор кебек**
**Илһам кабына!**

**Зәңгәр көнне күк төн алмаштыра.**
**Җиһан кочагында ай тора.**
**Шагыйрь туа —**
**Биек маңгаеңда**
**Тулы айдай**
**Шигырь яктыра.**

## Шагыйрь

*«Шаһның сүзен бүлде шагыйрь...»*
Нажар Нәжми

**Тел хакиме, шагыйрь!**
**Сиңа баглап**
**Илһам тугач мәдех әйтергә,**
**Ил хакиме—шаһлар хакындагы**
**Елъязмалар килде хәтергә.**

**Тик кызыкка әйткән сүз түгел бу...**
**Шаһ һәм шагыйрь —**
**Охшаш шәхесләр:**
**Тәүгесенә —**
**җирләр башын игән,**
**Ә бусына—**
**сүзләр, уй-хисләр.**

**Тәүгесенең фәрманнарын үтәп,**
**Яуга дип ил атка атланган.**
**Ә бусының язганнарын ятлап**
**Ил намусы таза сакланган.**

**Икесен дә халык тудырган да,**
**Икесен дә данлап күтәргән:**
**Чәчән телле иргә,**
**Гадел шаһка**
**Мәхәббәте булган киң,**
**тирән.**

**Тик тарихта ныграк эз калдырган**
**Дан-шөһрәт түгел — золым-кан:**
**Шагыйрьләрне явыз шаһлар аскан,**
**Шаһ үлемен тапкан халыктан.**
**Ил шашынса,**
**Башлап шаһ һәм шагыйрь**
**Татыр булган укны,**
**балтаны...**

**Тик**
**Шагыйрьне халык онытмаган,**
**Онытса да күпме патшаны!**

**Тик шагыйрьне халык истә тоткан,**
**Исмен аның изге ясаган,**
**Ак көннәре,**
**Кара төннәрендә**
**Шигырьләрен аның ятлаган...**

**Дөньядагы хакимнәрдән халык**
**Сүз хакимен генә күргән үз...**
**Тел хакиме!**
**Рух хакиме!**
**Шагыйрь!**
**Халык белән**
**син дә үлемсез!**

**Зөлфәт** *тәрҗемәләре*



Рифә
Рахман

# САН-ЗАТ ТЫЙЗ-ЗИ

БӘЯН

Ферма өендә көн иткән гаиләсез Сәләхны йортка керткәннән соң, Хөршид түтекәе, җае чыккан саен, сан-зат тыйз-зи, дип кабатларга гадәтләнде. Әлеге колакка чит сүзләрнең бала вакытында «Әл-пи-ти-си» догасы дип әбисе ятлаткан әлифба авазлары икәнлеген белсә дә, Гөлҗамал аларда күрше карчыгы салган мәгънә барлыгын үз мисалында аңлады. Аңлады да... хәсрәткә батты. Артыннан йөргән ничәмә-ничә егет бар, әмма һичберсен озаттырырга да, каткан сүзләренә җавап кайтарырга да базмады ул. Җылы карашларын күзләрендә күрсә, тизрәк читкә карады, уенлыкларда биергә чакырсалар, кыенсынып кына каршы басты, кино залында яннарындагы урынга дәшсәләр, тизрәк икенче җирдән табарга тырышты. Шулай итеп, яше егермегә җитеп килсә дә, Гөлҗамалның бер генә егет белән дә күрешкән-очрашканы юк иде. Алгалыда моны кайсылары кулак кызының текәлегеннән, үзенә тиңне таба алмавыннан күрсә, икенчеләре исә, киресенчә, аның оялчан холкына, каты куллы атадан алган тәрбиясенә сылтады.

Авылдашлары бер нәрсәдә хаклы иде, чибәркәйне бүген килен итеп төшерергә әзер торган ир-ат арасыннан чынлыкта Гөлҗамал үзенә тиңне таба алмый газапланды. Ата-бабадан килгән барлык мал-туар, әтисе Әхмәтша яңа гына салып кергән йорт-җир, келәт-абзарлар да тартып алынып, бер-бер артлы үсеп килгән биш ир туганы белән таралып төшкән мунчага фатирга «чыгарылгач», кыз үзен һәркемнән ким күрә башлады. Алмашы калмагач, өстендәге күлмәк-ыштанының төсе уңды, терт-терт кенә басып йөргән аякларындагы сафьян читегенең табаннары ашалды. Чәкчәк, пәрәмәч-сумса гына ашап үскән Гөлҗамалның, гаиләләре бәрәңге-катыкка киткәч, йөзләре сулыгып калды, зур кара күзләре утырды, әмма аңа бу кыяфәт тә бик килешә иде. Карашы тагын да моңлыланды, серләнде, керфек төпләренә сөрмә тартылгандай булды, йөзе озынчаланыбрак, агарыбрак китеп, аны аксөякләр токымыннан чыккан сылуларга, хан кызларына охшатты.

Алгалыга продразверстка мәсьәләләре белән районнан җибәрелгән вәкил, хуҗалыклар буйлап йөри-йөри, Гөлҗиһаннарның күршеләренә

---

*Рифә РАХМАН – язучы; «Керфекле тәрәзәләр», «Күзләрең төймәләнсә» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

кереп барганда, кыз, чияле көянтәгә асылган әлюмин чиләкләрен какча инендә тирбәтеп, тыкрыктан килеп чыкты. Көн эссесе дими ялтырап торган тужуркадан, күнитекләрдән килгән егетне Гөлжиһан әле ерактан — тыкрыктан ук күргән иде, шуна күрә дә, вәкил, алар турына житкәнче, чишмәдән кайтып, жил капканын тышкы яктагы келәсен, өйдә юклыкларын анлатып, тыштан төшереп куярга уйлады.

Гөлжиһаннын бу кыланышлары юкка түгел. Бердән, инде ашарларына дигәнен дә алып бетергән, тормышнын тәмам төбенә төшерергә тырышкан сәвит кешеләреннән ул гарык, икенчедән, кичке уенда камсамул Гарәфи, район хужалары иртәгә тагын өй борынча йөриселәр, күзләренә чалынмавыгыз хәерлерәк, аларныкын белмәссен, бер бәйләнсәләр, тиз генә котыла алмыйсын, дип, колагына пышылдады.

Үзе кайчан гына этиләрен кулак дип тенкәсен корытты, инде менә мине ничек кулга төшерергә белми, дип уйлады Гөлжиһан. Йортларыннан куып чыгарганда ярты байлыкларын үз арбасына төягән Гарәфинен дә хәзер, клубка чыкса, күзе — кызда гына. Тамагы туйгач, тиненә әйләндем дип белә торгандыр. Җае туры килгәндә, ничек тә ярдәм итәргә тырыша. Әллә тырышканга салына гынамы? Хәер, Гарәфи авыл сылуын беренче тапкыр нәкъ менә «раскулачивание» вакытында күрде. Анарчы өйдәрәк утырган, эштән башканы белмәгән, яшьләр арасында артык чуалмаган Гөлжиһанны күрде дә, үзе анламастан гашыйк булды. Контр кызларын сөяр заман идемени югыйсә!

Әйберләрне, алып чыгып, кайсын кай арбага төяп бетергәч, хужаларга икенче бер авылда буш торган йортка күченергә кушылды. Ата кеше янәшәдәге пужымда кукыраеп утырган ак мунчадан башка йорт бардыр дип белми иде, башын кыңгыр салып карап-карап торды да, үзләренә калдырылган әйберләрен жыйнарга кереште. Елашкан балалар белән урамда басып торган Сарабикәсенә сүз катмады, ярдәмгә Гөлжиһанны чакырды. Башка бер чакта авызынны ачканчы килеп житә торган кыз күренмәде.

Шунда гына Әхмәтша карт олысы Гөлжиһаннын якында түгеллеген белде. Кыз раскулачивание дигән галәмәтләрне йөрәгенә авыр алган, күз яшен күрсәтмәс, ата-анасын борчымас өчен, кичкә көтүче Гыйлембайларнын арык сарыклары кереп тулачак таш абзар артына чыгып баскан иде. Бәрәнге бакчасыннан Әхмәтша абзасына ияреп кергән житү кызны күргәч, Гарәфи анын матурлыгыннан телсез калды. Бераздан, әлеге хискә бирешеп, талап алган әйберләрен анын аяк астына ыргытыр хәлгә килде, әмма кәмитит алдында алай эшли алмады.

Шул көннән Гарәфинен күнелен ике төрле корт кимерә башлады. Берсе авылдашлары каршысында моңа кадәр кылганнары өчен оят хисе булса, икенчесе Гөлжиһанны үлепләр дә ярату, бер күрү өчен бар нәрсәдән баш тартырга әзер булу тойгысы иде.

Бер алган юлыннан китүләр юк икән. Гарәфи, тирәннән уйлый торгач күнеле кайтса да, камсамул башлыгы эшен ташламады. Аны ташлаунын бер генә юлы барлыгын, ул да булса тимер рәшәткә иканлеген ул яхшы анлый иде. Шулай да анын элекке ертлачлыгы, кеше малына комсызлыгы юкка чыкты, кырыслыгы кимеде. Тупас телле, каты куллы камсамул башлыгынын йомшакланып калуына авылдашлары да игътибар итте, һәм анын турында өй борынча сүз таралды.

Гөлжиһаннар гаиләсе каршында мен гаепле егет үзе чуалткан йомгакны ничек чишәргә белми аптыраган иде, анын урынына язмыш барысын хәл итте дә куйды. Шул ук елны кәмиссиягә каралып, Гарәфи солдатка китеп барды.

Гөлжиһанны, юллары сөю тулы хатлар язып, үзенә ничек тә каратасына бик нык ышанган иде егет. Туган-үскән жирләре белән хушлашканда бер генә нәрсә турында уйлады. Шулкадәр хатлар язарга кара-каләме

житәрме дә, ул хатларның барысы да язылып беткәнче кызый кияүгә китеп бармасмы? Район кешеләре авылга продразверстка буенча килеп төшкәндә, аның нәкъ менә солдатка каралып йөргән көннәре иде.

Әле дә ярый кызны кисәтеп өлгердем, дип уйлады Гарәфи. Гөлҗиһан гына аның бу игелекле гамәленә рәхмәтле булмады, чөнки алынасы әйберләре алынып беткән, инде чыра яндырып эзләсәң дә, табарлык әйбер, бигрәк тә ашлык дигәне юк, үзләре дә бәрәңге белән җәйдән калган алабута онында утыралар, ишегалдында каралты-кура санынннан йөргән нәрсәдән дә — ярым җимерек ызба гына. Ул аларга келәт тә, йорт та иде. Әтисе шушы шартларда авылда яшәүне артык бәхеткә санамады, анынча, читкә китеп, хәтта сөрелеп ризыклы булуың яхшырак, тик менә әле урнашмаган, гаиләсен кормаган кызын гына ерак юлларга алып чыгудан шүрләбрәк калды. Малайлары әле ничек тә чыдарлар... Хәле житәрме, рухы сынмасмы дип уйлады ул йомшак табигатьле Гөлҗиһан турында. Авылда аны ниндидер үзе дә аңламаган өмет кенә калдырды, ул өмет шул ук Гөлҗиһанга барып тоташа иде бугай.

Гарәфи хатларны үзе уйлаганча озын яза алмады. Вакытын да, язар сүзен дә таба алмый тинтерәде. Әгәренки әле авылдан чыгып киткәнче кыз белән туйганчы бер сөйләшергә өлгерсә, әйтеләсе сүзләр күп булыр иде дә, тик егет аның белән уенлыкларда кара-каршы килгәндә сәлам алышудан башкага житешмәгән иде шул. Әллә шуңа, аның хатлары хәләхвәл сорашудан башланды да, көт, кайтам сүзләре белән тәмамланды, ә Гөлҗиһан өчен болар гына аз иде.

Алай да бер хатында Гарәфи, тормышыгыз бик авырга китсә, каралтыгыз артык какшаса, минем йортка чыгыгыз, җиләк-җимеш бакчасы да зур, җире дә уңдырышлы, барыбер күршеләр бер рөхсәтсез файдалана, ичмаса, карап торырсыз, дип язып, үз хисләренең ихласлыгына ышандырды, әмма Гарәфидән зыяннан башканы күрмәгән Әхмәтша Гөлҗиһанның шул хакта башлаган сүзен кырт кисте: «Үз аягым белән кәмититчик өенә күченеп утырасым юк! Киләсе җәйгә исән чыксак, йортның яңасын барыбер корам мин!»

Бу хәлләрдән соң Гөлҗиһан Гарәфидән килгән хатларны укымый гына учакка ташлый торган булды. Күнелен егет язган матур сүзләр белән юкбарга алгысытырга теләмәде. Бераздан Гарәфи хат язудан туктады. Еллар узгач, инде хезмәт срогы тәмамлангач та, аның авылга кайтмаячагыннан, шахтада эшләп калачагыннан, аңа бөтенләй охшамаган сап-сары чәчле, зәңгәр күзле тазача гына бер мари кызына өйләнеп яшәячәгеннән, Гөлҗиһанны бөтенләйгә күңеленнән чыгарып ташлар өчен хәтта татар телендә сөйләшү түгел, якташларын күргәндә, сөйләмнәренә колак та салмаска тырышачагыннан Гөлҗиһан хәбәрсез иде шул әле.

Исән булгач, тормыш алга бара, адәм баласы зыян салып торса да, Ходай юнен бирә, дип уйлады Әхмәтша абзый. Беренче үләнгә кадәр ничек тә тартып суздылар: талдан чанасын ясап саттылар, Гөлҗиһан көздән мул җыйган чикләвекләр дә кул арасына керде, кипкән җиләкләреннән хуш исле чәен эчтеләр. Алар авылында гөмбә киптерү, тозлау гадәте юк, болар дуңгыз белән урыс ризыгы гына санала иде. Әхмәтшалар исә елынелга аны да күпләп җыялар, чөнки гөмбә — урманда кадерсез бер нәрсә кебек, аяк асты тулы. Анысы да ярап куйды, беразын сатып, беразын кирәк-яракка алмаштырып, беразын ашап, тәки кышны кышладылар. Ул арада тормышлары башка яктан да унайга китте. Мәктәптә яхшы укуы белән башкалардан аерылып торган Гөлҗиһанны уйламаганда-нитмәгәндә укытучылыкка дәштеләр.

Гөлҗиһанның башында кулак кызына мондый бәхет елмаер дигән өметнең заты да юк иде. Мәктәп директоры мәгариф бүлеге башлыгының ахирие икән дә, чибәрлеге белән дан казанган кыз ярдәмендә үзара дуслыкны

тагын да нығытырга теләп, башлангычта урын бушаута, Гөлжиһанга тәкъдим иткән имеш.

Директор ялгышмаган булып чыкты. Әнисенең кыз чагыннан сандыгында сакларга куелган затлы күлмәкләрендә бүлмә ишеген атлап керүе булды, Самат Вахитович үзе дә сизмәстән сикереп торды һәм йөгереп килеп Гөлжиһанга өстәл тирәсеннән урын тәкъдим итте һәм, шушы матурлыкка һич югы беразга якынайыйм дигәндәй, аның янәшәсенә утырды.

Завроно кызның үзенә дә ошады. Төскә чибәр, гәүдәсе килешле, киемнәре дә өстендә үлчәп теккән кебек утыра. Алар икенче мәртәбә очрашканда Гөлжиһан Самат Вахитовичларда кунак булырга вәгъдә куеп саубуллашты. Ул ризалыкны булачак житәкчесеннән курыкканга гына бирмәде, яше дә елдан-ел арта бара бит. Гаилә корып жибәрсә, ата-анасының да тормышын жиңеләйтер кебек тоелды аңа.

Гөлжиһанга завроно белән эшлекле шартларда очрашырга язмаган икән. Танышуларына ай дигәндә, хезмәт хакын алырга килүчене илтүгә сылтау итеп, Самат, кучерына күлмәк-туфли ише бүләкләр төрелгән алъяулыклы төенчек тоттырып, озын торыклы, урыннарында биеп торган, гелән чабышка алгысынган юртакларын Гөлжиһан артыннан жибәртте. Мондый чакта ялындырып тору мәгънәсезлек иде. Хужа кеше үзе килмәгән. Икенчедән, егет белән танышып кайту теләге кыз күңелендә дә юк түгел. Житмәсә, уйламаганда-нитмәгәндә, әтисе дә ризалык биреп ташлады.

Гөлжиһанны сары төймәләр белән бизәкләнгән кара кошовкада байбичәләр кыяфәте чыгарып авыл аша узу гына куркыта, оялта иде. Болай да ни гомер кулак кызы дип күзен ачырмадылар, инде онытыла бара дигәндә генә...

Бистәгәчә юыртып барган атлар таш җәелгән үзәк урамга килеп кергәч адымнарын вакладтылар, тора-бара тәмам текер-текергә үк күчтеләр. Ул да булмады, капкалары киң итеп ачылган зур йортның капка төбенә килеп туктадылар. Кунакларны зарыгып көтәләр иде булса кирәк. Тәрәзәдә егетнең әти белән әнисе, шулай ук ачып куйган ишекләрдә Самат Вахитович үзе күренде:

— Әйдүк, әйдүк, Гөлжиһан. Син киләсе дип эштән дә иртәрәк кайттым бүген, усал этебезне дә бакча артына бикләдек, әти-әни дә иртәдән гел синең хакта гына сөйләшәләр. Шушы атлавың бусагадан яшь килен атлаулары булсачы.

Кыз аптырап, күзләрен тутырып завроного карады. Бу караштa, мин урам кызы түгел ләса, чү-чү, әле үстергән ата-ана бар, үземнең дә сүземне әйткән юк, без әле бер-беребезне белмибез дә ич, дигән мәгънәләр бар иде. Самат моны аңлады. Олыларча кыланып:

— Курыкма, үскәнем, ничек кунакка килсәң, шул матур, бәхетле кыяфәттә кайтып та китәрсең, кодаларны без аны соңрак, синең ризалыгың булса гына төшерербез,— дип елмайды.

Гөлжиһан коймаларының һәр тактасы буялган, уеп ясалган тәрәз өлгеләренә кадәр муллык турында сөйләп торган йорт эченә таш түшәлгән сукмактан кыенсынып кына атлады. Самат Вахитовичның әтисе урман каравылчысы булып чыкты. Каралтының зурлыгы шуннандыр. Алай дисәң, юан имән бүрәнәләрдән салынмаган, тигез калыпларда басылган таш кирпечтән иде бу пулатлар. Ә менә ничек шушындый, кеше күзенә ташланып торырдай байлыкларны һичкем тартып алмаган да, үзен нинди зур урынга утыртканнар дип гажәпләнде кыз. Хәлле тормыш кына алып барган Гөлжиһаннарның исә торып торырлык ак келәтләре белән мүкләк сыерларын да калдырмадылар.

Кыз алтын өретелгән савытлардан кыенсынып кына ашады, затлы

фарфор чәйнекләрдә пешкән хуш исле һинд чәен тартынып кына эчте, көн дәвамында чынаяк арты чынаяк чәйләрне ялындыртып кына ясатты. Аның бу кыланышларын ата-ана таныш түгел кешеләрдән кыенсынуга, әдәплелеккә, оялчанлыкка сылтаса да, Самат Вахитович чын сәбәбен сизенә иде, алай да ул уеннан кире кайтмады, кызны Алгалыга илтә барганда, сүзне туп-туры башлады.:

— Торган җиремне, әти-әниемне күрдең, Гөлҗиһан, үзем хакында ишетеп беләсеңдер, белмәсәң, әле сорашырга көннәр бар. Аллага тапшырып, ай дигәндә әти-әниеңнән яучылап алам мин сине. Теләсәң, заманча булыр, икебез генә килешербез дә, шуның белән вәссәлам.

Кыз болай да миңгерәүләнгән кебек кайта иде, ни әйтергә дә белмәде. Егет шәһәрдә яши, умывальниклардан гына юыналар, ә безнең раскулачивание вакытында бер нәрсәне калдырмадылар, дип уйлады ул кабат. Мунча йортларының уң почмагында юыныр өчен куелган комган белән агач лакан — аның өчен иң зур байлык, чөнки мәктәпкә киткәндә ичмасам бит-күземне юып китәм дигән сөенеч бирә. Көзгедән йөзен ул сыйныф бүлмәсендә дә карый ала, чәчен дә яңадан шунда тәртипкә китерә. Озын трюмолар аңа кирәкми дә, кияргә, үзен карап хозурланырга күлмәкләре барыбер юк. Сул яктагы буын-буын җыела торган киң тимер раскладушкада биш ир бала аркылы ятып йоклый. Әти-әниләренең генә йомшак түшәкле агач караваты бар.

Гөлҗиһан юл буе уйлады-уйлады да, күңеле бик яткан егетне рәнҗетә алмаса да, ахырдан, башка сүзләр тапмагач, мин умывальниктан юына да белмим инде, сезнең өйгә төс түгелмен, дип әйтте дә ташлады.

Самат, билгеле, мондый җавапны көтмәгән иде. Кыз, үзенең яратканлыгын күргәч, бай тормышларыннан туган икеләнү уйларын башыннан чыгарып ташлар, тәкъдимен берсүзсез кабул итәр кебек иде аңа. Гөлҗиһанның да үзен ошатканлыгын күрде кана ул! Кызның әйткәннәре аның йөрәгенә ук кебек кадалды, гарьлегенә тиде. Алга таба янәшә утырып бару да мөмкин бер эш түгел санап, мәктәп турына җитәрәк, ул кошовкадан сикереп төште дә, сау бул, дип кул белән ишарә ясаганнан соң, дусты янына ашыкты.

Директор, мөдирдән уңай хәбәрләр көтеп, эшеннән дә китмәгән иде. Ялгышкан икән. Ни әйтәсен керә-керешкә уйлаган Самат аңа исе китмәгән бер кыяфәттә:

— Кыз бик матур, яхшы, акыллы да, әмма безгә рус кызына өйләнергә, югары күтәрелергә кирәк, — диде.

Директор да бу хакта еш уйлангалый иде. Килеште. Чыннан да, илдә шундый үзгәрешләр бара. Казанга, Мәскәүгә китү мөмкинлекләре бар. Матур дип шушы кыз хакына авылда калганчы урындагы бер урысның кызын кулга төшереп, министр кәнәфиенә үрләү яхшырак булмасмы? Заман хәзер безнең кулда, завроно министр булса, янында кечерәк кенә бер урын безгә дә тәтеми калмас. Шушы уйлар эчендә ул елмаеп кына баш селекте.

Заврононы озак та үтмәде, чыннан да башта Казанга чакырттылар. Инде маржага да өйләнеп, балалар ишәйтеп яши башлагач, Мәскәвенә дә алдырдылар. Дөрес, ул урыс кызын алды, балаларны чукындырды дип кенә әллә ни күтәрелмәде, үзе теләгәнчә бәхетле була алмады. Самат Вахитович үкенеп, хатынын ярата алмавыннан гаҗизләнеп Алгалыга озын-озын хатлар язганда Гөлҗиһанның икенче кешедә тормышта булуын, бик бәхетле яшәп, әти-әниләрен дә үз канаты астына алуын, берсеннән-берсе акыллы балалар тәрбияләвен күз алдына да китерми иде шул. Гөлҗиһан мәңге-мәңге аны гына уйлар, аны гына яратыр, аны гына көтәр, аңа чыкмавына үкенеп зар елап гомер кичерер кебек уйлар эчендә яшәгәнлектән, тәрәз төбендә чигү

чигеп, күз яшьләре агызып утырган Гөлҗиһанны кызганудан йөрәкләре дә кысылып куйгалый иде.

Инде кыздан сагышлы хатлар алуына тәмам өмете киселгәч, дус директорыннан да бер-бер хәбәр ирешмәгәч, кызны елатырлык, кабат яраттырырлык хатларны үзе язарга карар кылды. Тик никтер аларга кәтелгән эчтәлектәге түгел, башка төрле җаваплар да килмәде.

Заврono белән арасы бозылу аркасында эшеннән җибәрерләр дип байтак вакытлар куркып йөргән иде Гөлҗиһан, алай булып чыкмады. Озакламый Самат Вахитович Казанга китеп барды һәм аны тәмам онытты бугай. Егет кызга ошаса да, чын яратуга әле ераграк иде, Гөлҗиһанның күңеле бу очрашулардан, башта туып соныннан киселгән өметләрдән яраланмады. Ул, тора-бара, тормышлары бөтенәеп, иркенәеп китсә дә, Самат инде миңа тиң булыр иде дип һич кенә дә исенә төшермәде, бераздан аны башыннан ук чыгарып ташлады, чөнки күңеле икенче берәүгә бик ныклап яткан иде.

Алтынбәкнең рус теле укытучысы белән йөрүен Гөлҗиһан ишетеп белә иде. Шәһәрдән килгән кара кашлы, төз буй-сынлы чибәркәйнең аңа тинлеген шик-шөбһәгә алмады. Кыз үзе югында, учительскийда ул турыда сүз чыкканда, гайбәт санап, катнашмаса да, көлеп, Хөршид әбекәе кебек, сан-зат тыйз-зи, дип куя иде. Чыннан да, ана тиннәрне Алгалыда табу җиңел булмас. Үзе — сельпо председателе, үзе — колхозның комсомол секретаре.

Комсомолецның кызга гашыйклыгыннан тора-бара арыдылар, чөнки болар мәктәбенә җыелыш уздырырга килә. Колхоз яшьләренең кинәш-табыш урыны да клубтан мәктәпнең кызыл почмагына күчте, авыл советының бәйрәмнәре — хезмәтчәннәр көннәре дә, Яңа еллары да күбрәк аның иркен коридорында үткәрелде.

Гөлҗиһанга да ошамый түгел Алтынбәк. Әмма нишләсен, инде ул Раечкага караган. Алай мәктәптә янәшә дә йөрмиләр йөрүен, табын артларында да бергә утырмыйлар, тик халыкта сүз юкка гына чыкмагандыр.

Беренче күрүдә бөреләнә башлаган гашыйклык хисе, көн арты көн үтә торгач, егет тә битарафлык күрсәткәч, сүрелер кебек тоелган иде. Ялгышкан икән Гөлҗиһан. Юкка чыгу гына түгел, көчәйгәннән-көчәя барып, кыз күңелен тәмам биләде. Ахырда түзмәде, кул эше белән утыруны сәбәп итеп, Хөршид әбисе белән киңәшергә дип, кичке биләмгә керде.

Карчык, гадәтенчә, сан-зат тыйз-зи, ягъни сезнең затыгыз аның нәселенә, саның аның санына туры киләме әле, юкмы, дип әйтер дә, Гөлҗиһанны Алтынбәктән суытыр дип исәпләгән иде. Монысы да дөрескә чыкмады. Кызны аптыратып, ул егеткә синнән дә тиңрәкләр юк инде, кызым, әти-әниең аныкылар кебек укымышлы, инде байлыгыгыз да үзегезгә күрә таман гына, эшләгән урының да авылда пачутта, димәсенме! Бер тәвәккәллек кыл да, бисмилланны әйтеп, муен чокырына чәй чүбе сал син аның, имеш.

Чыннан да, нигә сынап карамаска! Һәр җыелыштан соң актив чәй эчә. Ясап торучылары — гел эшкә унган Гөлҗиһан. Укытучылар көнендә чәй ясап йөргән булды да, җаен туры китереп, бер чәй бөртеген аның муен чокырына салды ул. Үзе эченнән генә, Хөршид түтекәе өйрәткәнчә, бисмилласын әйтеп, ризыгың минем белән булса иде, дип теләде.

Салуын салды, чүт көлкегә калмады. Мәктәп түшәменнән үрмәкүч асылынып төште дә күлмәгем эченә кереп китте микән әллә, дип аптыраган Алтынбәк гел кашынып утыра башлады. Табындагылар шаулашырга, шаркылдап көләргә тотынды. Бу көлүдән Гөлҗиһан, үзен гаепле тойганын сиздереп, кып-кызыл булып чыкты, чөнки чәен тиз генә эчеп бетерер дә янасын ясатыр дигәндәй, һаман да Алтынбәк артында басып тора иде. Ахырда кыз түзмәде, муенына үрмәкүч булып мин төштем, минем яратсын

дип салган чүп кычыттыра аны, дип чын дөресен әйтте дә салды. Табын шып булды. Барысы да бер — еларга житешкән Раечкага, бер аптыраштарак торган Гөлҗиһанга карадылар. Бу тынлыкны Алтынбәк үзе бүлде:

— Ә нигә? Мин сине болай да яратам! Юкка гына һәр жыелышны мәктәбебездә уздырмыйм ләбаса! Шулай да чүпне нигә салганлыгыңның чын дөресен бүген озатып кайтканда әйтерсең әле.

Алтынбәкнең, баштарак артыннан йөрсә дә, мәктәптә тәүге тапкыр күргән Гөлҗиһанның сылулыгыннан башы әйләнгәч, Раечкадан күңеле тәмам бизгән икән. Сельпо рәисе булуына карамастан, эше күп дип тормыйча, колхозның комсомол комитетын җитәкләргә дә Гөлҗиһанны күрә алу хакына гына ризалашкан ул, җыелыш алып бару урынын әнә шуңа клубтан мәктәпкә күчергән. Син үзең ясаган чәй чүбен шул кичтә муеныма салмасаң, бу озату әле ни кадәргә кичектерелер иде икән, дип сөенечле генә елмайды ул Гөлҗиһаннарның капка төбенә җитәрәк.

Ни гаҗәп, авылда әле эшне эшләргә түгел, уйларга да өлгермисең, аның хакындагы сүз халыкка таралып өлгергән була. Гөлҗиһанның әнисе дә икенче көнне күршеләренә чыккан җиреннән кызарынып-бүртенеп кайтып керде. Бусага аркылы узганчы ук, кулын ишек тоткасыннан алмаган килеш, яучылый килгән төртмә теллерәк карчык сыман сүз башлады:

— Гөлҗиһан, син ни, бездән яшереп кенә төрле планнар корып йөрисең икән. Без тагын... Атна саен хатлар юллаган Гарәфи дә ярамагач, алтын кашыклардан гына ашаган завроно тәкъдимен дә кире каккач, бер күрмәгән Алтынбәккә ярәшү билгесе биргәнсең дип башыбызга да китермәдек.

Гөлҗиһан телсез калды. Әнисе бар нәрсәне кирегә әйләндерде дә куйды. Аның өстенә әнә нинди гаеп ташлый.

— И әнәй, сезгә, бигрәк тә сиңа әйтмичә, ничек барыйм инде мин,— диде ул, бераз үпкәләгәнрәк тавыш белән. Үзе шунда ук, ә бит, бик яратсаң, белмәссең... кебегрәк уйлап куйды.

Халыкта сүз таралуга гаҗәпләнерлек булмады. Шул көнне кич Алтынбәк Гөлҗиһанның кулын сорады. Ата-бабалардан калган йола буенча яучы да җибәрмәде, олы кеше итеп әнкәләрен дә төшермәде, эштән кайткан чагына туры китереп каршысына чыкты да, гап-гади генә тәкъдим ясады. Кыз өчен аның нинди булуы мөһим дә түгел иде, шулай да ул әти-әнисеннән шүрләде, шуңа күрә генә егеткә, тукта, башта алар белән бу турыда сүз башлап карыйм әле, диде.

Әхмәтша йола дигәндә бик каты торучан ир иде. Кызның моңарчы күренмәгән кыюлыгын өнәп бетермәде, сүзне озынга җибәрәсе килмәгәнлеген белгертеп, Гөлҗиһанга, яшь әле син, дип кенә әйтеп куйды, — кул арасына кереп кенә барасың, энеләреңне бергәләп аякка бастырасы бар.

Гомер бакый атасы рөхсәтеннән башка аягын ингарак та алырга курыккан Гөлҗиһанны, Алтынбәкне ярата башлагач, алмаштырып куйдылармыни?! Ике дә уйлап тормады, шуннан соң егеткә ябышты да чыкты.

Алтынбәк күрше авылда фатирда тора, ә әти-әниләре егеттән аерым, район үзәгендә яшиләр икән, иң башта хәбәрне аларга җиткерергә булдылар, әмма көн кичкә авышкан иде инде. Атасыннан шүрләгән Гөлҗиһан Алтынбәккә, әллә соң башта һич югы үзебезгә әбине җибәрикме, югыйсә әтәйнең балта күтәреп килеп җитүе дә бар, диде.

Гөлҗиһанның гадәттәге вакытында эшеннән кайтмавына Сарабикәттәй хафага төшкән иде. Әле сул тәрәзәдән урамга карады, әле уныннан, әле ишегалды яктагысына күз салды. Гөлҗиһан күренмәде дә күренмәде. Ахырда, энгергә китәрәк, күрше кызына керде.

Гәүһәр әле өйдә, клубка чыгарга хәзерләнә генә булып чыкты.

Гөлжиһаннын өйдә юклыгын белгәч, үзе дә аптырашка калды, чыннан да, башка бер чакта бу вакытка ахирие бизәнеп-ясанып күптән үзләрендә булыр, иренчәк холыклы, әкрен кыймылдаучан Гәүһәрне кымтыратырга тотынырие. Киенеп-ясанып та бетмәгән кыз кабалана-кабалана клубка йөгерде.

Кызны, кызыл почмакка керүгә, иптәшләре сырып алды. Аны гына көткәннәр диярсең: күрдеңме Гөлжиһанны, Алтынбәкне, алар чыннан да өйләнешкәнме, тегесе-монысы дип башын катыра башладылар. Барысы да анлашылды. Гәүһәр кире Сарабикәттәйләренә йөгерде. Әхмәтша абзасы кайтканчы ничек тә аяктан егарлык гайбәтнеме, чын хәбәрнеме житкерепөлгерергә кирәк иде.

Гәүһәрнең эше пешмәде. Курыкканы юш килде. Әхмәтша абзасы кайткан, тәрәзә катындагы урындыкта Гөлжиһанны көткәндәй урамга карап утыра. Кызының дусты белән инде клубтан да кайтмавын күргәч, әни кеше тагын да ныграк шомланды, инде телдән телгә күчкән яналыкны да ишеткәч, бөтенләй авыруга сабышты.

Ни гажәп, күршесе янында Әхмәтша үзен сабыр тотты. Авыр бәрелмәде, хатыны Сарабикәгә дә каты сүз әйтмәде. Урындыкта килеш кенә кулларын угалап утыруында булды. Малайларны күрше авылга бу хәлләргә ризасызлыгын белдерергә йөгертер иде, әле барысы да — урамда, апалары турында әллә берни белмиләр, әллә белгәнгә өйгә кайтуны кичектереп торалар. Инде аларын эзләп йөрү, халык күзенә артык ташлану да килешмәс.

Шулай озак сүзсез торганда, Сарабикә телгә килде, бераз көтик тә, инде кыз клуб ябылгач та кайтмаса, ат жигәрбез, Гөлжиһанны Алтынбәк фатирыннан төшеп алырбыз, диде. Эченнән, Ходай кушса, карты тынычлангач, ул теләгәнчә, ата-бабача бирербез дип үз-үзен сабырландырды. Әхмәтшаның үз карары карар иде, йә кешечә сорап киләләр, йә ата фатихасы белән Гөлжиһанга ир заты күрү юк.

Әхмәтша торды, түр яктан алгы бүлмәгә чыкты, самавыр жырлап утырган мич буенда агач юнгыч кечкенә балтасы бар иде, кирәк булса дигәндәй, шуны тотып-тотып карады да, ишек янагына илтеп тераде:

— Инде дә ишектән, яучылап, хатын-кыз гына кермәсен, бәрәм дә үтерәм, мине генә түгел, кызның үзен дә ахыргача кимсетү була!

Әхмәтшаның холкын белгән Сарабикә дә борчылды. Үзенә әлегә чит бер йортта уйда утырган Гөлжиһаннын да күнеле тыныч түгел иде. Ярый әле Алтынбәк жайлы кеше булып чыкты, кәләшенең гозерен үтәде, Тәкәнешкә кеше жибәртеп, әтиләренә хәбәр салды. Озак та үтмәде, каенана белән каената пар ат жигелгән матур тарантаста килеп тә життеләр, киленнен яратып аркасыннан кактылар, сөенгәннәрен белдерделәр, аннан тагын да юыртыбрак Алгалыга киттеләр.

Алтынбәкнең фатир хужасы, чын яучылар Гөлжиһаннар турына житкәндә, авылга кереп кенә килә иде. Үзен таптап китә язган тарантаска карап, бар белгәнен укыды, шушындый жаваплы бурыч үтәп йөргәндә исән калганына чын күнелдән сөенде. Инде дә каранғы урам буенча узып, Әхмәтша турына житәрәк, хәлләрнең асылына төшенде. Йортка тәгаен кодалар килгән иде. Атларның кемнеке икәнлеген таныган карчык тарантас эченә кереп утырды да Алтынбәкнең әти-әниләрен урамда гына көтәргә булды.

Әхмәтша карт, кызу канлы булса да, бусагада сәлам биреп алдан керүченең ир-ат затыннан икәнлеген күргәч, басылды, сүзләрен тынларга әзерләнгәнлеген белгертеп, сүрән лампочка янган түр бүлмәгә өстәл янына чакырды һәм Сарабикәгә чәй хәзерләргә кушты.

Кыз кодалаучыларның хәлле кешеләр икәнлекләрен дә күргәч, гомер буе таза тормыш белән яшәгән, аннан хәерчелеккә чыгарылган, инде тагын кеше арасына кергән ата йомшады. Эченнән генә, бик укымышлы сөйләшәләр,

болар безгә төс, дип уйлады. Баштарак ризалык бирмичәрәк утырса да, ахырда, чәй арты чәйләр дә эчә торгач, Гөлҗиһанның теләге хакына инде, дигәнрәк сүзләре белән, бөтенләй үк каршы булмаганлыгын аңлатты.

* * *

Еллар узды. Байтак еллар узды... Гөлҗиһанның бәхетле тормышына чикләр юк иде, әмма бар кешегә язган язмыш үзенекен итә икән, ире Алтынбәк фани дөнья белән саубуллашты. Югалту хәсрәтләре дә бераздан басылгандай бер заманда — балалары тәрбиясендә, оныкларын сөеп яшәгән бер көнендә улының төпчеге, район гәҗитен күтәреп, аның янына килде:

— Әбекәй, бу язма синең турында түгелме? Кайбер исемнәр мин белгән кешеләрнекенә туры килә. Син дә монда сурәтләгән Гөлҗиһан кебек матурсың, булгансың, яшь чактагы тормышың да кай ягы беләндер аныкына охшаган шикелле. Ә җырлавың! Хат авторы сөйгән кызының кичке уенлыкларда җырлавына таң калуын әйтә.

Гөлҗиһан абыстай «Нурлы»ның соңгы санын укырга өлгермәгән иде әле. Ул аны гадәттә көтү кайткач, балалар абзарга мал арасына чыгып киткәч, аларны кичке ашка көткәндә укый.

Илсурның сүзләре әбисен аптыраашта калдырды. Бер кулы белән — аның кулындагы гәҗиткә, икенчесе белән аш бүлмәсендәге карты Алтынбәк ясаган агач шүрлектәге күзлегенә үрелде:

−Матур җырлаучылар мин генәмени! Алай да укып багыйм әле.

Исе китмәгәнгә салышып сөйләнгәләсә дә, язманың тәүге юлларыннан ук күз аллары караңгыланып, башлары әйләнеп китте аның.

«Гөлҗиһан! Мин сине һаман да яратам! — дип башлана иде ул гәҗит кисәгендәге эчкә утлар йөгертердәй хат. — Озак еллар узар да, онытылырсың, башканы яратып китәрмен кебек тоелган иде. Хатыным да начар булмады, бер дигән балалар да үстердек, әмма күңел китеклеген, боеклыгын гомерем буена юлдашым иттем.

Әле Армиядә вакытта, салкын землянкаларда ятканда, нигә генә аны көчләп булса да үземнеке итмәдем икән, дигән үкенечле уйлар да килгәли иде, аннан бергә булу-булмавыбыз Ходай кулындадыр дип тынычландым, юкса аңарчы Аллага да, муллага да ышанмаган бер гыйбат камсамул калдыгы идем бит мин.

Инде олыгайган көнемдә, туган якка кайтып, журналист яллап, аның ярдәме белән газета аша мондый хатлар бастырмасам да булыр иде. Ялгыз калуыңны да ишетеп белә идем югыйсә. Сөйләшергә дә теләмәссең дип куркып калдым бугай мин.

Сине күрмичә, сине һаман да яратканлыгымны әйтмичә тынычлап үлә дә алмам шикелле. Урамыгыз аша узганда, капкагыз алдындагы утыргычларда хәл алдым. Яшьлектәге кебек саф калган якты тавышың түр тәрәзләрегез аша урамга кадәр ишетелеп торса да, керергә, сәлам бирергә җөрьәт итмәдем.

Ә бит әле тормышны, олы яшьтә булуыбызга карамый, яңадан башларга да булыр иде. Яраткан Алтынбәгенә карата хыянәт дип санарсың дип уйладым, шуның белән дә сине рәнҗетәсем, үземнән тагын да ерагайтасым килмәде.

Их, әз генә өметем булса, әз генә өметем! Мин шул көнне үк авылдан йорт алып, сине җитәкләп шул йортка төшереп утырткан булыр идем.

Сан-зат тыйз-зи, дип көлеп әйтә торган гадәтең бар иде. Хөршид карчык авызыннан ишеткән ул сүзнең мәгънәсен ачык аңлыйм мин. Син дә, мин дә — кулга-кул тотышып социализм төзибез, дип ярты гасыр бер юлдан атлаган совет кешеләре, үзебез корган илнең хәзер дә кимсетелгән затлары. Хөршид карчык хак та булган кебек, юк та. Сайлаганың затыңа туры килсә дә, һәрвакыт кочагыңа керми икән, затыңа туры килмәгәне белән дә

гомер итәсең. Тинлек — байлыкта, бер уйлар белән яшәүдә генәмени! Жан теләвендә дә тинлек бар! Син дә мине мин сине яраткан кебек яратмаганга бергә була алмаганбыз без. Хәзер дә, син ялгызың калгач та, бергә түгел.

Алтынбәк бәхетле. Мин аннан гомерем буе көнләштем. Ул чыннан да бар яктан синең тиңең иде. Бер карасаң, чибәр, Алтынбәгең кебек өздереп гармун сыздырткан, мул тормышта яшәгән, интеллигент, затлы нәселдән чыккан Самат та сиңа тиң, теләсә кем яратырдай егет булган бит. Ә син икенчене, чыннан да, өзелеп ятратканыңны сайлагансың.

Кызык, артыңнан чапкан, карата алмаган авылның башка егетләре ни уйлый, ничек яши икән? Саматны менә, үзем шикелле, бик бәхетсез дип ишеттем.

Гөлжиһан, бер гозерем бар: хезмәт белән туплап җыйган байлыгыгызны талап йөрүчеләр башында килүемне дә, сине — заман авырлыкларыннан йолкып ала алмавымны да кичер. Әхмәтша бабайга да, башка авылдашларга да әйтеләсе сүзләр дә бит. Соң инде. Бу юлы да соңга калам, ахрысы, дип курыктым.

Беләзекләр, балдаклар, муенсалар тутырган шкатулкагыздан, синең төсең булыр дип, бер йөзек алып калган идем. Ул минем белән гасырга торырлык юллар үтте, әмма төсен югалтмады. Синең кебек нурлы кашлы йөзек ул. Мин аны редакциядә хатлар бүлегендә, шушы язманы хәзерләшкән кешедә калдырам. Килсә, кертмичә борып чыгарма. Затлы нәселегез ядкаре булып, оныгың бармакларын бизәсен.

Самат дигәннән, әйтмәм дә дигән идем, мин бит аның белән очраштым...»

Куш бит тутырып язылган бу хатны ахырынача укып чыкса, Гөлжиһанның селкенеп кенә торган йөрәге урынында кала алыр иде микән? Хәл алгач, вакыт тапкач бер укырмын әле дигәндәй, ул газетаны бик иплән җыйды да, намазлыклары торган бүлмәгә алып кереп китте, аннан, башкалар күрүен теләмәгәнгәме, кадерле бер язма булгангамы, әллә киресенчә — яратмыйчамы, тумбочкадагы изге сүзле китаплар, догалыклар арасына кыстырып куйды.

Әбисен кайчаннан бирле күзәтеп торган Илсур, ул борылып аны күреп алганчы, әтисенә бүгенге хәлләрдән хәбәр бирергә дип бәрәңге бакчасына йөгерде.

Гөлжиһан да күргән иде Саматны... Әле карты исән вакытта ук туп-туры аларга кайтып төшкән иде ул. Кулына күн букчасыман бер нәрсә тоткан. Яхшыдан киенгән. Чәчләре агара башласа да, тешләре үзенеке булмаса да, чибәр, бик чибәр иде әле Самат Вахитович. Әгәренки шул көнне авылның теге яки бу яшь җилкенчәгенә яучы юлласа да, һичкем кире какмаслык бер ир.

Ул килеп кергәндә, Гөлжиһанның камыр куеп йөргән чагы иде. Алтынбәк диванда гармун көйләп утыра. Әллә бармаклар искерә, әллә төймәләр бозыла дигән булып үзалдына сөйләнә. Ишек какмыйча, рөхсәт тә сорамыйча кайчандыр күз атып йөргән кызының ире йортына керүен ире ошаткандырмы, юкмы, Гөлжиһанга сораулы карашын ташлап алды да, берни булмагандай, ишектән керүчегә дәште:

— Хуш киләсең. Самат туган, син дип әйтимме? Ялгышаммы? Күреп белмәгәч, саташуың да ихтимал. Кайтырга чыккан икән дип колакка гына әйткән иде аны ахириең. Мин юләр һич чынга алмадым. Йә, ни эшләр бетереп йөрүең? Әллә туп-туры безгә килүең инде? Менә монысы гына аптыраашта калдырды әле мине, дускай.

Самат көпә-көндез Алтынбәкне өйдә туры китерермен дип һич кенә дә уйламады. Тыш ишекне дә какты ул үзе, кагуы шул тикле генә булгандыр. Инде әллә ишетмәделәрме дип сагаеп кына өйгә атлавы иде.

Алтынбәк эштән кайтканчы Гөлжиһанын җитәкләп үзе яшәгән якларга алып китәргә иде исәбе. Болай булса да начар түгел. Кешедән качып

эшләгәнче, турыдан-туры гамәл кылуың яхшырак. Үзе дә куркакларны гомер бакый сөймәде. Гөлҗиһан китәргә риза булмаса, букчасы тулы акчасы дигәндәй. Йорт сатып аласы да кирәсе.

Батырларны яратса да, Саматның теле тиз генә ачылмады. Гөлҗиһан янында ир-атларча сүз башларга кыенсынганга, йорт хуҗасын ул капка алдындагы утыргычка чакырды.

Ишеккә җитәрәк, Алтынбәк хатынына:

— Матурым, без хәзер! Синең бәлешләрең пешкәнче, аяк астында чуалмас өчен генә, урамда саф һава сулап торабыз, — дигән булды.

Гөлҗиһанның бәлеше пешкәнче бите пеште. Ни уйларга, ни фаразларга да белми иде ул. Бер яктан, ир-атлар бәхәскә кереп китмәгәе дип курыкты. Икенче яктан, аның сәбәпләрен дә тапмады.

Бар нәрсә мичтән алынып, табын әзерләнгәч, чакырырга дип ишегалдына чыкса, Алтынбәк белән Саматның үзе хакында сөйләшкән сүзләреннән атлар-атламас булды. Чакырылмаган кунакның:

— Алтынбәк, Гөлҗиһаннан балаң бар, син шуның белән дә бәхетле. Туган якта яшисең. Туганнарыңның игелеген күрәсең. Авырган чагыңда хәл белергә күршеләрең булса да бар. Мин боларның барысыннан мәхрүм. Бир миңа Гөлҗиһанны. Өрмәгән-какмаган җиргә дә утыртмам! — дигән сүзләренә каршы иренең:

— Бер бәхетсез җитмәгән, өч бәхетсез булсын дисеңмени, Самат?— дигәнен ап-ачык ишетте хатын.— Син уйлаганча, сине бик яратса, ихтыяры, мин аны көчләп тота алмыйм. Ничә ел торуыбызда яратуына һич шик уятмаган Гөлҗиһан сиңа ияреп, миннән туган баласын җитәкләп күз күрмәгән якларга китеп барыр микән соң? Бу кеше көлдерергә генә кайтуың түгелме? Аның шушы авылда икенче бер хуҗалыкта яшәсенә күңелем бөтенләй ышанмый. Алай да аңлыйм мин сине, Самат. Гөлҗиһаным булмаса, үзем дә синең кебек бәхетсез булмас идеммени?

Самат уфтанды, торып басты, китәргә уйлады булса кирәк. Аны болай, кунак итми җибәрү килешми иде. Гөлҗиһан, бар көчен җыеп, урамга таба атлады:

— Алтынбәгем, кирәсезме инде сез, юкмы? Кунакны болай озаклап аяк өстендә тотма, түргә чакыр!

Самат керде. Гөлҗиһан чәйләрен эчәргә, Гөлҗиһан ашларын ашарга кайткан иде шул. Ул, көмеш билле кулъюгычлар янында йөзләрен сөртеп торганда да, аңа алтын каймалы чынаякларда чәй сузганда да, Гөлҗиһан кыз чагын, бистә үзәгендә кунакта булган көннәрен уйлады.

Аның һәр адымын, «сан-зат тыйз-зи» — дип дөресләгән Хөршид әбисе генә түгел, Әхмәтша карт та, Саматның ачык йөзле әти-әниләре дә якты дөньяда юк иде инде. Гөлҗиһан күңеленнән аларның барсына киң ачып куелган оҗмах ишекләре теләде.

Иртән Самат китте. Алтынбәк ияреп чыкты дип тормады, иң тәүдә Гөлҗиһанга күзләрен тутырып карады да, соңгы хушлашу сүзләре итеп:

— Мин сине һаман яратам! — диде. Аннан Алтынбәккә карап:

— Мин аны барыбер яратачакмын! — дип кабатлады.

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез Рифә Рахманның юбилее. Аны шушы гомер бәйрәме белән ихластан тәбрик итәбез, сәламәтлек, иҗат уңышлары телибез.*



Асия
Юнысова

# ИҖАТ КӨЧЕН ДАНЛАР АЛТЫН ҖИТМӘС

## Театр музее

ЦИКЛ

***

**Тамашачы тулган инде залга,**
**Куера төшкән олы бер тынлык.**
**Ара-тирә ефәк кыштырдый да,**
**Сыкрап куя ялгыз урындык.**

**Күзләр генә, тылсым өмет итеп,**
**Төбәлгәннәр хәтфә чаршауга.**
**Берәм-берәм бәллүр утлар сүнгәч,**
**Күзләр каршысына кем чыгар?**

**Кемнәр чыгар, ниләр булыр анда —**
**Күп уеннар күргән сәхнәдә?**
**Балтамы соң, оҗмах алмасымы**
**Өстен калыр соңгы сәхнәдә?**

**Гыйлем җыйган мәгърур мәгарәнең**
**Ачылгандай серле ишеге,**
**Хәтфә чаршау, салмак шуышып,**
**Серен ача көткән кешегә.**

**Ике-өч сәгать сәхнә гомере,**
**Ике-өч сәгать артист уены —**
**Шунда сыйган янып-көюләре,**
**Бер гасырлык уты-ялкыны.**

**Янган-көйгән, янып беткәнме,**
**Калмаганмы әллә кузы да?**
**Яшьнәп үткәннәрнең эзен таптым**
**Сандык кебек затлы музейда.**

---

Асия ЮНЫСОВА – *шагыйрә, прозаик, публицист; «Айлы юл», «Сагынырсың але», «Алмагач песие» һ.б китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре; «Татнефть» һәм Татарстан Язучылар берлегенең С.Сөләйманова исемендәге әдәби премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Кариев йөзеге

Тәгәри китте йөзек, тәгәри китте,
Исән үтте еллар өзеген.
Театры белән гасыр кичте
Кариевнең көмеш йөзеге.

Тәгәри китте йөзек, тәгәри китте,
Югалтыйча чылбыр үзлеген.
Театрда иң кадерле мирас
Кариевнең ядкарь йөзеге.

«Театрны сакла! — бу әманәт!» —
Кабул итеп алган Тинчурин.
Кариевтән калган йөзек кашы
Тинчуринның саклый күз нурын.

Ильская, аннан Сәлимҗанов,
Бикчәнтәйгә күчте әманәт.
Театрның яңа варислары
Әманәткә итмәс хыянәт!

Тәгәри китәр йөзек, тәгәри китәр,
Югалтмыйча чылбыр үзлеген.
Буыннарны бер-беренә ялгар
Кариевнең затлы йөзеге!

## Кәрим Тинчуринның кесә сәгате

Ай бу сәгать — ап-ак циферблат,
Ак җирлектә рим саннары.
Кем уйлаган аның иясенә
Гомер елын бик аз санарын!

Һәрбер сәгать вакыт символы ул,
Ә җиһанда вакыт олы сер.
Күкрәгендә кайнар йөрәк барда
Шушы сергә хуҗа режиссер.

Елгыр сәгать угы ваемсыз ул —
Мизгел сәйләннәрдән ел тукый.
Театр дип янып-көйгән дәвер
Ашыктырып торган бу укны.

Алтатардан ядрә атылганда,
Калкан булып йөрәк өстендә —
Яткан булса әгәр бу сәгать,
Ятим калмас иде бер сәнгать.

Явызлыктан койган тиле ядрә
Сәгатьләрен кыйган ул чорның.
Туктап калган гомер тынлыгында
Үлмәс исем яна — Тинчурин!

## Ильяс Кудашев-Ашказарский скрипкасы

Скрипка дибез — шуңа күнеккәнбез,
Төркичәсе, юкса, кимәнә.

Исемдәме хикмәт. Кылларына сыйган
Үзәк өзгеч җырлар, көй менә,
Сызгыч тию белән,
«Чын безнеңчә» сагыш-моңы белән
Татар җаннарына түгелә.

Дүрт кылында аның дала җиле,
Авыл көе, Шәрык мәкаме.
Сызгыч тию белән уянган ул,
Сызландырган аны ил гаме.

Ашказарның атын адаш иткән
Ырымбурдан Ильяс Кудашев —
Киманәче чичән мөгаллим
Көй тылсымы белән татарларны
Театрга җыйган, мөгаен.
Ашказарлы егет — Кудашевтан
Татар сәхнәсенең юл башы..

Үзе киткән менә, ядкарь булып
Киманәсе калган музейда.
Кудашлардан,Сәйдәшләрдән мирас —
Театрда яши музыка.

## Галиәсгар Камал өендәге көзге

Көмеш яктылыкны йоткан көзге —
Хуҗа куйган өйнең түренә.
Каршы алган, озатып калган ул —
Өй түреннән яхшы күренә.

Камалларга килгән артист-кунак,
Үзен күреп трюмо-көзгедә,
Өс киемен сыйпап төзәтенгән,
Көязләнеп алган әз генә.

Кайберләре — Мутин кебекләре,
Тукталып та анда беразга,
Көзге тылсымыннан сихерләнеп,
Кергән булыр тәмам образга.

Һәрбер уен — затка төрләнү ул,
Вөҗүдеңне туплау, әүрелеш.
Холыклардан мең кат хәбәрледер
Әүрелешкә таңгәл бу көмеш.

Тонык амальгама[1] яктысына
Эленгәндер соңгы ым гына.
Үз йөзеннән йөзеп үткәннәрне
Сагынадыр көзге тын гына..

## Габдулла Кариевның чәй әсбабы

Чәй әсбабы!
Урын алган музей киштәсендә.
Дәрәҗәле урын биләү өчен аңа
Бар, әлбәттә, җитди сәбәбе.

[1] Төрле металлның аккургаш белән кушылмасы.

Көмеш савыт — чәйле җамга оя,
Балкашыгы — сабы аюлы.
Сәер бизәк — «Сәйяр»ләрдән бүләк,
Тигән аңа Миңлебай кулы.

Спектакль тәмам. Пәрдә төшкән.
Дусны җыя чәйле дастархан.
Кариевнең үз әсбабы анда —
Балкашыгы һәм дә стакан.

Сагынмаклык бүләк, кинаяле,
Кушаматы Аю ла аның! —
Җаһилият чытырманын җиңгән
Аюы ул милли дөньяның.

Чәй янында бөтен дуслар тигез,
Шуклык белән биргә иләслек.
Театрның яшь чагына һәйкәл
Садә генә шушы истәлек!

## Юлтыева калфагы

«Гөлҗамал»ны җырлап, кызлар аны
Энҗе-мәрҗән белән чиккәндер.
Калфаклы кыз Нинель — Сөембикә
Балетта да «чүпләм чиккәндер»[2].

Калфаккаен кыңгыр гына элеп,
Чыккандыр ул биеп сәхнәгә.
Балитәкле па-де-дены күрү
Бәхет булыр иде безгә дә.

Балет хикмәт — пуантларда бию,
Шпагатлар ясау, антраша...
Падеграслар — вак-вак атлап «йөзү»
Татар калфагына яраша.

Энҗе калфак алкышларны күрде,
Софитларда алды балкып та.
Күзге шаһит — Раушан, Зөһрә кызлар
Бик бәхетле иде балетта.

Алкышлар юк хәзер, балкышлар да...
Күзге генә аңа ахирәт.
Калфак матурлыгын данлар өчен
Татар балетына кайт, Гайрәт!

## Алтын битлек

Хәтерлибез, икемеңдә бердә
«Битлек» кайтты Марсель абыйга.
«Алтын битлек» лаек бәя иде
«Намус өчен һәм дә абруйга».

Хезмәтеңне алтын белән үлчәү!
Ни уйлады икән режиссер?

[2] «Чүпләм» — татарның түгәрәк уен биюе.

Йөз ел юлга тезгән маякларда
Белә, юкса, аның эше зур.

Асылташлар белән бизәлсә дә,
Битлек ябып булмый абруйга.
Тик алай да тамашаның кайсы
Лаек икән кызыл рубинга?

Битлек артындагы дөнья кайчак
Хокук даулый аннан сәхнәдә.
Гөлнарының гүзәллеген күрде,
«Сүнгән йолдызлар»да — Сәрвәрдә.

Ә без? Ә без? — диеп әнә яна,
Күзен кыса ничә асылташ!
Йөзләп спектакль — йә кайсына,
Йә кайсына тиеш ташлы таҗ?!

«Качаклар» мы, әллә Сәлимҗанов
Үлмәс иткән шанлы «...Әлмәндәр»?
Иҗат көчен данлар алтын җитмәс,
Битлектәге җитмәс мәгъдәннәр.

## Туфан Миңнуллин күзлеге

Үзеннән дә алда күзлек кирә —
Каймаланган калын пыяла.
Тукайчалап әйтсәк, күпне күрә–
Язарына мая җыйнала.

Хикмәтле бу күзлек, тылсымлыдыр,
Күзлек кенә түгел, микроскоп.
Берәмтекләп барлаганны көтә —
Татар дөньясында мирас күп.

Калын күзлек кия, ә үзе ул,
Карый илгә күңел күзеннән;
«Затым шушы, йолам шушы», — диеп,
Горурлана дөнья йөзендә.

Минус уналтылы калын күзлек
Телескоп та була кайвакыт.
Күзле сукыр әле күрмәгәнне
Аңлата ул безгә уйнатып.

Йомык халык уен уйный белми,
Куркак булган өйдә — хыял юк!
Калын күзлек кигән Туфан барда
Китмәде күк илдән уяулык.

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аны бәйрәме белән ихлас котлыйбыз, исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

Таһир
Нурмөхәммәтов

# КАБАН КҮЛЕ, ӘЙ, АЛКЫН

БӘЯН

***

Сугыш кайгысының, хәстәрлегенең безнең, ягъни балалар арасына да килеп керүе бүтән яктан да сиздерде. Әле кайчан гына бергәләп Ботан бакчасы каршындагы күл болынына үлән йолкырга йөргән, Казанны урап тәпи-тәпи сәяхәт кылган вакытта безгә, әле борын аслары кибеп тә бетмәгән малайларга, бик олы сымакланып җитәкчелек иткән, бездән нибары дүрт-биш яшькә өлкән булсалар да, тиндәш саналган малайлар кинәт күз алдыбызда үсеп киттеләр. Подвал Кәрименең урта мәктәпне дә бетермичә, самолет заводына эшкә керүен ишеткәч, без шаккаттык. Кая инде хәзер аңа безнең белән уйнап йөрергә. Ул хәзер бик сирәк күренә, безнең күзләрне кызыктырган, май таплары белән чуарланган зәңгәр комбинезонын киеп кайткан чакларында ул безгә кулын күтәреп, ягъни сәлам тапшырып елмайган сымак була да, шундук подвалларына төшеп югала: аның әле ял итәсе дә бар, китап-дәфтәрләренә күз саласы да бар, чөнки ул укуын кичке мәктәптә дәвам итәргә хәзерләнә иде. Өлкән малаеның заводка кереп ишле гаиләгә ярдәм итә башлавына бигрәк тә Хәят апа сөенә: бу аның ишегалдында башына япкан яулыгын җилфердәтә-җилфердәтә җинел генә атлап йөрүләреннән дә күренә иде. Ләкин бу сөенечләр вакытлы сөенечләр генә иде шул. Нурулла абыйның электр станциясе бүрәнәләрен ташып йөргән кара йонлы атының артиллерия хезмәтенә алынуы турындагы хәбәрен ишеткәч, без өнсез калдык.

Каракайны без бөтен ишегалдыбыз белән өзелеп ярата идек. Ул вакыт Казан урамнарында инде тыз-пыз җиңел машиналар, полуторкалар, ягъни әрҗәләре зур булмаган йөк машиналары, аннан сирәк-мирәк шактый зур «Зис»лар йөреп торса да, атка бәйләнешле нәрсәләр күп иде. Мәсәлән, Ике бистә арасында Ат аланы бар. Безнең яннан гына, яр башыннан, акрын-акрын сөзгәеп Ат юлы төшеп китә, без аннан, әле бәләкәй чактан ук, курыкмыйча чана шуа идек. Боларына өстәп, бездән чак кына читтәрәк, Әхтәмов урамы башыннан ук җәелеп сөзәк тау төшә. Бу сөзәк тау күлнең эченә үк кереп китә булса кирәк, чөнки Кабанның бу турысы сай, малайлар коенырга да куркыныч түгел. Төбен бик мактап булмый булуын, ләмлерәк иде. Ләкин монда да су керергә малай-шалайдан бигрәк атларның хакы күбрәк, бу махсус ат коендыра торган урын иде.

*Ахыры. Башы узган санда.*

Без әлбәттә Нурулла абыйның Каракүз белән эштән кайтуын көтеп кенә торабыз. Каракүз тирләп, ә кайвакыт ак күбеккә батып та кайтып керә. Ул көне буе кояш астында йөреп янган. Ат үзе дә безнең аны күлгә алып төшәсебезне белә, шуна күрә түземсезләнеп башын чайкаттыра. Менә, ниһаять, Нурулла абый тезгенне өлкәнрәгебезгә тапшыра да, без атны җитәкләп, үзебез дә аның тирәсендә яшь колыннар кебек терт-терт атлап су буена китеп барабыз.

Каракүз күл буена төшкәч, сак-сак атлап кына суга керә, борын яфракларын калтыратып суны иснәгәндәй итә, аннары йомшак төкле иреннәрен тигезер-тигезмәс су чөмереп куя һәм, башын күтәреп, үзенең иптәшләренә — колакларын кайчы кебек селкеткәли-селкеткәли йөзеп йөргән атларга кыска гына сәлам бирә: «Әһә, сез дә кайттыгызмыни эштән, менә шәп булган, бер кат чистарындыгыз!» Шуннан соң гына ул безнең әйдәкләүгә буйсынып күлгә түгрәрәк уза. Без аны әүвәл суда бер кат әйләндереп йөздерәбез, аннары, корсагын суга тигезер-тигезмәс кенә кире алып чыгып, үзен юарга, кыргычларга керешәбез. Без үрелә-үрелә аның аркасына чиләк белән су койганда Каракүз рәхәтлектән керфекләрен йомгалап ала, аның сыртына атланып без аны йөздерергә керешәбез, үзебез дә аның әйләнә-тирәсендә чыр-чу килеп, су чәчрәтә-чәчрәтә, йөзәбез.

Каракүз артык дәү булмаса да, биек торыклы, эчләре җыелып килгән бик җыйнак яшь ат иде. Ул чем-кара кыска йонлы булып, бигрәк тә су коендырып чыгарганнан соң, кара бәрхеттәй җемелдәп тора иде. Менә шул атны хәзер сугышка алырга булганнар. Әле нинди хезмәткә диегез! Йөз потлы орудиене тартып йөрү өчен. Аның нечкә билләре, уйнаклап торган бәкәл-сыйраклары әнә шул тимер тавын тартып йөрергә чыдар микән соң? Циркта гына биеп йөрерлек ат иде бит ул үзе югыйсә!

Каракүз озатыласы көнне без аны соңгы мәртәбә Кабан күлендә коендырып мендек. Әле кибенеп тә бетмәгәнгә, аның сыртлары, арт савырлары кара көзгедәй ялтырап тора иде. Менә ана җиз тәпкәле йөгәнен, түшенә шулай ук җиздән йолдыз ясап куелган янтау каешларын кигезделәр. Хәят апа Каракүзнең маңгай чәченә дә, ял-койрыкларына да кызыл чуклар такты. Шуннан ат белән саубуллаша башладылар. Иң элек Хәят апа атны муеныннан кочаклап:

— Бәхил бул, ике күзем, Каракүзем, — дип, аңа сырпаланып торды, аннары атка карамыйча да, сөякчел иңбашларын калтырата-калтырата подвалына төшеп китте.

Ат янына аларның бөтен гаиләсе чыгып тезелгән иде. Башта балаларның иң өлкәне Кәрим үзенең саргылт яңагын ат яңагына куеп нәрсәдер пышылдап алды. Аннары тулырак гәүдәле Рәшит, алпан-тилпән килеп, атның башын үзенә ия төшеп маңгаеннан үбеп алды. Кечерәкләре Харисның да, Рахипның да атка буйлары җитми иде, алар Каракүзнең түшенә сарылышып тын гына басып тордылар.

Нурулла абый Каракүзне кузгатырга торганда гына, алар, җибәрәсе килмәгәндәй барысы берьюлы аңа килеп ябырылдылар һәм еларга тотындылар. Без дә, ишегалдының бүтән малайлары да, түзмичә, атның ботларына, янтауларына килеп сарылыштык, Хәят апаның сүзләрен кабатлап:

— Бәхил бу-у-улл! — дип елаштык. Ат, мескен, башын як-якка боргалап калтыранып куйды, тоякларын алмаш-тилмәш күтәргәләп алса да, безнең аякларыбызга ялгышып кына да басмады.

Сугыш тора-бара безне кырыслыкка өйрәткән, бик күп коелырга тиешле күз яшьләребезне дә без, җиргә тамызмыйча, үз эчебезгә йотып кала идек. Ләкин Каракүзне сугышка озатканда без бөтен ишегалдыбыз

белән үкерешеп елап калдык. Ат була торып, Каракүз дә елый иде кебек. Нурулла абый:

— Әйдә, малкай, кузгалдык, — дигәч, ул башта көчәнә-көчәнә авыр йөк сөйрәгәндәй, борын тишекләрен зурайтып, бот мускулларын кабартып бөтен гәүдәсе белән тартылып торды, гүяки туган җире аның үзен дә ычкындырмыйча тотып тора иде. Шуннан ул артына каерылып карады, безне, абзарларны күзеннән үткәрде. Аның күзеннән бүтән вакыттагы кебек яшел очкыннар чәчелми иде инде, ул күзләр мөлдерәп яшь белән тулган иде.

Шулай да Каракүз тәвәккәлләде, акрын гына атлап капкадан чыгып китте.

— Хуш, бәхил бул, Каракүз!.. Орудиеләрне армый-талмый тарт, исән-сау әйләнеп кайт!!.

Яр буйлап безгә таба сузылып киткән әүвәлге духовный семинария бинасын казармага әйләндерделәр. Биек-биек тәрәзәле бик зур бу казармага солдатлар бик күп сыйгандыр, күрәсең — алар күнегүләр ясарга, һәртөрле солдат хезмәтенә өйрәнергә чыккач, кош базары кебек бөтен күл буйларын тутыралар, безнең Сафиян урамына кадәр килеп җитәләр, анда яр читләренә, агач төбе һәм урам читенә яшеренергә, аннары дошманга мылтык төбәргә дә өйрәнәләр иде. Кызылармеецларны япь-яшь кече лейтенантлар өйрәтеп йөри. Алар өр-яңа яшькелт гимнастерка белән галифе чалбар кигәннәр, хром итекләре кояшка җемелдәп китә, ә портупеялары сап-сары каештан ясалган иде. Алар җир өстенә яткан кызылармеецларга аякларын җәебрәк ятарга, терсәк белән бик каты таянмаска кушалар, терсәкне артык нык терәсәң, мылтыгыгыз калтырый, диләр. Аннары алар күн итекләре белән каеш портупеяларын шыгырдатып берәр кызылармеецның баш очына иеләләр дә:

— Дөрес төзәмисең бит, уңгарак, сулгарак, — дип яки:

— Цельнең туры үзенә төзәмә, астынарак төзә, — дип төзәтмәләр кертәләр.

«Бу лейтенантлар ялгыш төзәгәнне каян белә икән?» — дип, мин бер мәртәбә хәйранга калып торганнан соң кинәт прицелның уң ягына беркетелгән почмаклы көзгене күреп алдым. Командирлар кызылармеецның «дошман»га мылтыкны ничек төзәгәнен әнә шул карасу көзгедән карап белә икән.

Кызылармеецлар арасында куллары сөңердән генә торган базык гәүдәле, мыеклары тәмәке төтененнән саргая башлаган өлкәнрәк агайлар да күзгә чалынгалый. Алар бу хәрби өйрәнүләрне гомумән өнәп бетермиләр кебек, яшь лейтенантларның сүзләрен дә илтифатсыз гына тыңлыйлар. Йөзенә тирән жыерчыклар яткан әнә шундый агайларның берсе көлемсерәп кенә прицел янындагы көзгене алып куйгач, яшь лейтенант:

— Кем кушты сезгә, отставить! — диде. Агай гыжлак тавышы белән:

— Без мондый көзгеләргә өйрәнмәгән, нервыга тия, иптәш командир, — диде һәм тагын йонлач кашлары астыннан гына елмаеп куйды.

— Ә мин ничек тикшерермен сезнең мылтык төбәвегезне?

— Безнең өчен кайгырмагыз, иптәш лейтенант. Без гражданкада немецларны да, акларны да күп чәкегән.

Лейтенант бик кызуланып вәгазь укырга керешмәкче иде дә, нишләптер бүтән дәшмәскә булды.

Июль башлары житеп, кояш бик каты кыздыра, гел салкынча күләгәле җиргә кереп кенә торасы килә иде. Әүвәлге байлар ак ишек дип атаган, без исә парадный дип кенә йөрткән, Сафьян ягына караган баскыч төбебез нәкъ әнә шундый хәл ала торган урын иде. Кояш кыйблага борылып

йортыбызның бу ягына кояш төшү белән анда тымызык җил уйный башлый, өстәвенә ике басмалы гына мәрмәр баскычның үзеннән үк салкын бәреп тора.

Ике яшь лейтенантның ак баскыч төбенә утырып тәмәке тартуларын мин әле дә хәтерлим. Алар фуражкаларын тезләренә куеп, зәңгәрсу яулыклары белән ара-тирә маңгайларын сөрткәләп:

— Нишләргә инде бу картлар белән. Әйтсәң — сүз, төртсәң — күз, — дип зарланыштылар. Ә бит бүген-иртәгә фронтка озатулары мөмкин.

— Барып җитәрбезме икән?

— Җитмәсәк кенә!.. Отпускамны да файдаланмый калдым бит. Их, болынга төшеп печән чабасы иде!..

Яшь лейтенантларның әңгәмәсе мине менә кайсы җәһәттәнрәк сөендерде. Алар Хәкимнең әтисе Зәйнулла абыйның да сүзләрен куәтли бит әле: сугыш бер-ике айда төгәлләнәчәк. Димәк, аяк-куллары чатлы-ботлырак булган Илгизәр белән саргылт чәчле, аксыл керфекле Илдусның әтисе Сәфәргали абый да, чатаклабрак йөргән Ринатның безгә сабый чакта «Ванька-встанька» кәмитләрен күрсәткән Сирай абый да сугышка китми калалар. Бигрәк тә подвалдагы Нурулла абый китми. Ник дигәндә, алар, беренчедән, сугышка атларын бирделәр бит инде. Ул барыбер гаилә башыннан бер җан иясе киткәнгә саналадыр ич инде. Аннары Нурулла абый сугышка алынса, бер Кәрим генә шундый ишле гаиләне ничек туендырып тора алыр? Ә Каракүз, күп тә үтмәс, үзе тартып йөргән озын көпшәле орудиенең немецлар окобына берәр дистә снаряд тондыруын сәерсенеп карап торыр да, Казанга кире кайтып китәр. Сбруендагы алтын тәңкәләрен елтыратып, җиз кыңгырауларын чыңлатып, барыннан да битәр, матур түшенә икенче йолдызны — «орден-йолдыз»ны кадап капкабыздан кайтып керсә, әмма да кызык булыр иде.

Каракүз дигәннән, бездән ике йорт аша булган тимерче алачыгына бик күп атлар килә башлады. Аларны аякларын дагалатырга алып киләләр иде. Ике-өч тимерче чүкечләре белән чаң-чоң килеп көнозын эшләсәләр дә, атларны дагалап өлгерә алмыйлар, атлар өер-өер булып урамны биләп торалар. Алар уттай көйдергән кояш астында әлсерәшеп торсалар да, көтмәгәндә шарт-шорт тибешеп китәләр, ә кайвакыт бәйләүдә килеш аллары белән сикерә алмаганга күрә, артларын һавага чөешәләр, кыскасы, алар эсседә бик тынычсызланалар иде.

Без тимерчелек ханәсенә атлар китерелүен беренче мәртәбә ишеткәч, ишегалдындагы малайлар белән дәррәү кубынып, шунда йөгердек. Каракүзне дә күрмәбез микән дигән өмет белән шатлана-шатлана йөгердек. Ләкин бик жыйнак, сөлектәй матур байталыбызны без тузанга баткан, яллары чуалып беткән атлар арасыннан таба алмадык. Болар ерак районнардан куып китерелгән атлар булып, алар барысы да ямьсез һәм мескен төс-кыяфәттә иделәр, тик аерым баганага авызлыклап бәйләп куелган туры айгыр гына арада үзенең мәгърурлыгы белән аерылып тора, ул дагасыз тоягы белән дә үзалдын тырнап, казып бетергән, авызы исә ак күбек кенә иде.

Без Каракүзне очрата алмавыбыз өчен кайгырып кирегә борылмакчы идек инде, тик шулвакыт арада бик чая Хәкимебез, атларга чиләк белән су эчертеп йөрүче, зур гимнастеркасының инбашлары салынып төшкән өлкән яшьләрдәге бер кызылармеец янына килеп:

— Абзый, атларыгызны коендырып кайтыйкмы? — диде.

Кызылармеец, кулына буш чиләген тоткан килеш, Хәкимгә сәерсенеп кенә карап куйды:

— Кая коендырмакчы буласың, Кабан күле бик тирәндер бит ул. Атның берсе генә батса да — военный трибунал! — диде.

Без шунда ук аны әйләндереп алдык:

— Батмас, абзый, күлнең сай җирләре бар!

— Әйе, бик якында!

— Урам аша гына!

Татар абзые, саргылт тырнагы белән колак артын кашыштырып, уйлана калды.

— Мәгез әле, фонтаннан чиләккә су агыза торыгыз, мин хәзер чыгам, — дип, тимерчелек ишегалдына кереп китте.

Без, өч-дүрт малай, фонтан токтасына барып ябыштык та, тотканы аслы-өсле күтәреп чиләккә су агыза башладык.

Хәким чиләкне чайкалдыра-чайкалдыра, капка төбенә китереп утыртты.

Менә кызылармеец, командирын ияртеп, капкадан килеп тә чыкты. Озын буйлы командир безгә өстән генә карап:

— Шулармы? — диде.

— Әйе! — дидек. — Без! — диештек без.

— Кая, болар ат башыннан да тота белми бит.

— Беләбез! Безнең коендырганыбыз да бар!

— Без үзебез дә Каракүзне эзләп килгән идек.

— Нинди күзне?

— Каракүзне!

— Әллә Казбек атынмы?

— Юк, Нурулла абый атын.

Командир безгә ягымлы гына карап куйды да:

— Менә нәрсә, Ахмеров, айгырны үзең җитәклә, ә боларны малайлар алып барсын, — дип, ул бәйдәге бер төркем атка күрсәтте. Без шатлыктан:

— Ура! — дип кычкырып җибәрдек.

Без атларны күлгә алып киттек. Алдан айгырны, авызлык чылбырларын шалтыраткалап, Әхмәров абзый җитәкләп бара. Айгыр артыннан йоннары нинди икәнлекләре дә рәтләп беленмәгән дистәгә якын ат, башларын салындырып, ияреп бара. Иң арттан, дүрт атны тезген бауларыннан тотып, без ашыга-ашыга атлыйбыз. Сөзәк таудан төшеп җитүгә, кояшта пешкән атлар шундук, тояклары белән су чәчрәтә-чәчрәтә, күл эченә кереп киттеләр, сыртлары суга күмелгәч, күзләрен йомгалап оеп кына басып тордылар. Абзый атларны аз гына ярга таба чыгартты да һәрберебезгә чыпта кисәкләрен тоттырып атларны юырттыра башлады. Без узыша-узыша атларның янтауларын, арт савырларын ышкырга керештек. Шулай ышкыйышкый юа идек тә, үзләрен бер кат йөздереп алып яр буена чыгарып куя идек.

Аларны күргәч,  командир:

— Карале, боларны хәзер танып та булмый бит. Булдыргансыз, егетләр, молодцы! — дип безне мактап куйды.

Без тагын бер өер атны коендырып кайткач, кич җитте. Икенче көнне дә без атларны су керттек. Тик без бер нәрсәгә гаҗәпләндек. Бүтән атларны дагалатканнан соң һәм коендырганнан соң дистәләп-дистәләп озатып җибәрәләр, ә кара яллы туры айгыр гел кала бирә.

— Аның чираты күптән узды бит инде, нишләп аны һаман баганага бәйләп тотасыз? — дигәч, Әхмәров абзый безгә:

— Ул айгыр бит, көтү башы. Аякларын җиргә тибеп куйса да, атлар аңардан куркып шундук тыналар, тешләшмиләр, — дип аңлатып бирде.

Ә күлгә төшкәндә Әхмәров абзый туры айгырны үзеннән бер дә калдырмый иде. Тагын да гаҗәбе шул: Хаким гел шул айгыр тирәсендә кайнаша, Әхмәров абзый аны чипта белән юган чагында аны тезгененнән

тотып тора. Берничә мәртәбә юуудан соң айгырның тәмам үз төсе кайтты, ул кызгылт хәтфәдәй ялтырый башлады. Шулай да аны йөздереп алалар, әле кем йөздерә диген. Ат кебек үк кызгылт-җирән башлы Хәким. Аны Әхмәров абзый ат сыртына күтәреп утырткач, ул, авызын колагына хәтле ерып, айгырны күлнең түреннән үк йөздереп чыгара иде. Айгыр аңа тәмам ияләшеп җитте булса кирәк.

Менә шулай атларны матур гына коендырып йөргәндә нәкъ әнә шул ташбаш Хәким бөтен эшне бозды. Бер мәртәбә командир, капка төбенә чыгып:

— Әхмәров, отставить пока атларны коендырырга. Тимерчеләр ардылар, ярдәмгә кер, — диде.

Абзый көйдергеч кояш астында башларын салындырып торган атларга кызганып кына карап куйды.

— Жалкы бит, иптәш командир, — диде ул. — Әллә малайлар үзләре генә алып барсыннмы?

— Үзләре генә булдыра алырмы?

— Алырбыз!! — дип кычкырып җибәрдек без.

— Булдырырлар! — дип безне яклады Әхмәров абзый.

— Смотри, башың белән җавап бирерсең.

— Есть баш белән җавап бирергә, иптәш командир!

Ул баганадан айгырны чишеп алды да тезген бавын Хәкимгә тоттырды, һәм без атларны тып та тып атлаттырып күлгә таба киттек. Ләкин Хәким айгырны җитәкләп бару белән генә ризамыни:

— Егетләр! Мин атланам! — диде ул. Без, бердән өшеп китеп:

— Кирәкми! Атланма! — диештек. Ләкин үзебезнең парадныйга барып җитүгә, Хәким атны баскыч төбенәрәк китерде дә шул баскыч өстеннән җиңел генә ат сыртына менеп атланды. Су эчендә күндәм генә булган ат әүвәл башын борып малайга усал гына карап куйды, бер урында тыпырдап биеп алды, ләкин Хәким йөгәннең икенче ягын тартып, атның башын шундук тигезләде. Ат янә, баскан җиреннән кубып китмичә, тыпырдап алды һәм кинәт артын калкытып куйды, Хәким ат өстеннән очып төшә язды. Шуннан ат бер заман, биеп торган җиреннән, капыл гына артына чүгә төште дә башын чайкый-чайкый, алгы аякларын һавага чөйде — Хәким аның кара ялларына чытырдап ябышты, ә сипкелләре балтырларына үк чыккан ак аяклары белән ул айгырның янтауларыннан кысκан иде. Юк, бу юлы да егылмады ул. Шуннан ат сикерә-сикерә алга томырылды. Бүтән атлар да, үз артларында тузан өермәләрен уйнатып, айгыр артыннан чабып киттеләр. Алда кешеләр кычкырган, этләр өргән тавышлар ишетелеп калды. Янә дә тагын ат ялына түнегә төшеп чаптырып барган Хәкимнең ялкындай сары башы чагылгалап китте.

Без дә иңрәшеп, ә кайберләребез елашып алга йөгердек.

Ә инде күлдән атлар да, үзебез дә суынып кайтканда, командирга тәртипсезлегебез турындагы хәбәр килеп тә җиткән, һәрвакыт безнең яннан узып йөрүче бер мәчет карты, башын калтырата-калтырата:

— Рәзве можно манка малайларга ышанырга, прәме мине бәреп ега яздылар, — дип командирга шикаять итеп тора иде.

Командир:

— Извините, папаша, — дип гафу үтенде. Аннары ат багучы абзыйга җитди күзләре белән карап: — Ахмеров, на двое суток в гауптвахту! — диде.

— Есть на двое суток в гауптвахту, иптәш командир, — дип честь бирде Әхмәров абзый. Аннары аяк астына караган килеш саргылт тырнагы белән колак артын кашыштырып алды.

— А пока исполняй свои обязанности.

— Есть исполнять итәргә!

Командир капкадан кереп киткәч, Әхмәров абзый безгә борылып:

— Кайсыгыз?! — дип кыска гына сорап куйды.

Без җавап бирмәдек, башларыбызны түбән идек. Хәким исә артына карангалап шыпан-шыпан гына китте дә аннары бер генә дә борылып карамыйча йортыбызга таба элдертте.

Икенче көнне без малай-шалайны атлар янына якын да җибәрмәделәр, аларны су коендырырга яшьрәк кызылармеецлар йөртте. Абзыебыз гауптвахтага утыртылган иде булса кирәк. Командир үзен орышканда салынкы инсәләренең тагын да түбәнрәк салынып төшүләрен исемә төшереп, Әхмәров абзыйны күңелемнән бик кызганып куйдым мин.

Ә берничә көннән Сафьян урамында тояк янган исләр бетте, колакны тондырып чүкеч суккан тавышлар да тынып калды, бары әллә нигә бер тимерче алачыгы эчендә тимер чыңлаулары гына янгырый һәм ул авазлар ни өчендер минем колагыма сагышлы, моңсу булып ишетелә иде.

Ләкин атна-ун көн үтәр-үтмәстә безнең Кабан буйлары тагын бер мәртәбә шаулап алды.

Безне, су станциясендә ара-тирә чуалышкан малайларны, Андрей дәдә җыеп алды.

— Бик ашыгыч эш бар бит әле, оланнар, — диде ул. — Көймәләрне зуррак ярык булганнарыннан аерып алырга, су кергән булса түгәргә, «Перевоз» каршына, яр буена чыгарып куярга. Моны, оланнар, бик тиз эшләргә кирәк, хәзер үк.

Кояш кичкә таба авышып бара, безнең тирәкләр очыннан төшкән күләгәләр, киртләч тауларны хәтерләтеп, Кабан уртасына ук сузылып кергәннәр. Без дистәгә якын көймәне нәкъ йортыбыз каршына илткәндә анда ике кызылармеец, штыклы мылтыкларын иңнәренә асып, су читендә арлы-бирле йөренәләр иде. Алар без китергән көймәләрне ярга чыгарыштылар.

Без су станциясенә йөгереп тагын дистәдән артык көймәне китереп куйгач та, Андрей дәдә:

— Нишләргә инде, азрак бит әле. Кырык көймә табарга кушканнар иде, ә монда утыз тирәсе генә, — диде.

— Балыкчыларныкын да өстәргә кирәк, — диештек без.

— Шулай дисезме?.. — дип, Андрей дәдә фуражкасын салып, беравык уйланып торды.

— Менә болай инде алай булгач, оланнар, — диде ул. — Иртәрәк уяна алмассызмы икән? Кем уяна ала, шул таң алдыннан, сәгать өчкә менә монда су буена төшсен иде. Кысташ юк, добровольно! Ә мин балыкчыларны йөреп чыгыйм.

Һәм Андрей дәдә, моторын тырылдатып, Ерак Кабан ягына китеп барды.

Шул кадәр көймәләрнең ни өчен кирәклеген Андрей дәдә әйтмәсә дә, без моны штыклы солдатларга карап сизенә идек: казарма өчен кирәк бу! Тик алар, тыныч, имин чактагы кебек, гармун уйнап җырлый-җырлый йөрмәсләр бит инде?

Кыскасы, без бу кичне түшәккә иртәрәк ятарга, тизрәк йоклап китәргә тырыштык. Дустым Ринатларның кыңгыраулы түгәрәк сәгатьләре бар иде, кайчан шалтырар икән дип, аларның бик зур сандыклары өстендә озак кына борсаланып ята торгач йоклап киткәнбез.

Бер заман «тырт! тыртыт!» итеп пулемет ата башлады. Бу әлбәттә «Чапаев» киносындагы Анканың пулеметы. Аның бер ягында мин, икенче ягында

Ринат ята. Анка пулемет көпшәсеннән ут бөркетеп аклар өстенә пулялар очыра, ә без Ринат белән аңа патрон тасмасын җайлап биреп торабыз. Пулемет тырылдый-тырылдый тасманы суыра гына, без аны тартмасыннан көчкә генә чыгарып өлгерәбез. Тукта, нишләп туктап калды әле бу пулемет? Нишләп атмый әле Анка? Кара мундир кигән котырган аклар күтәрелеп өенә ябырылып килә башладылар бит инде.

«Анка! Ат тизрәк!..»

Ә Анка ни өчендер ирләр тавышы белән:

«Кысташ юк, добровольно!» — ди.

«Туктале, Андрей дәдә түгелме соң әле бу?»

«Мин шул, мин, йоклыйсызмыни?

«Алайса булмәгез инде тәмле йокыгызны, өлгерерсез әле, өлгерерсез...»

«Юк, өлгермибез, Андрей дәдә, өлгермибез-з-з!»

Һәм шунда без Ринат белән икебез дә сикереп торабыз. Пулемет та, Анка да, Андрей дәдә дә юк. Бары Ринатларның күл ягына караган ачык тәрәзәсеннән мыдыр-мыдыр сөйләшкән тавышлар гына ишетелгәли.

Без сикереп тә тордык, ачык тәрәзәгә йөгереп тә килдек. Көймәләрне суга төшергәннәр, аларга кызылармеецлар кереп утырган иде инде.

Без су буена йөгереп төшкәндә алар кузгалырга торалар иде инде. Ниндидер бер зур командир белән Андрей дәдә кызылармеецларга соңгы боерыкларны биреп йөриләр иде.

— Иң мөһиме — як-якка кузгалгалап, көймәне чайкамаска, — диде Андрей дәдә акрын тавыш белән. Моны ул яр буеннан атлап берничә мәртәбә кабатлады, чөнки көймәләр күп, иллеләп бар иде.

— Көймәне чайкамаска!.. Ишкәндә иплəп ишәргә!.. Менә малайлар әйткәләр!..

Тик малайлар бер дистәдән чак кына артык, житмәсә «пулемет атып» без дә соңга кала язган идек.

Безне өч-дүрт көймә саен бүлеп утырттылар. Андрей дәдә:

— Оланнар, сез көймә холкын беләсез, әйткәләгез! — дип соңгы фатихасын биргәч, без бердәм кузгалып киттек.

Задание: кызылармеецларны аргы якка исән-сау алып чыгу икән. Кычкырып сөйләшмәскә, теге якта посынган дошманга сиздермәскә!

Ләкин көймәләр кузгалу белән ашык-пошык итүләр, берсенең борыны белән икенчесенең кабыргасын төртешүләр башланды. Ишкәкләр бер-берсенә бәрелеп дыңгыр-дыңгыр килештеләр.

Мин күрше көймәдәге яшь лейтенантны танып алдым, ул артка утырган, ә ике якка тезләрен тезгә куеп чүмәшеп утырган кызылармеецларның берсе шулай ук таныш — Әхмәров абзый иде ул. Ат караучылар да десант була ала микәнни соң? Атларын ничек чыгарырлар икән? Мойканы паром ясап чыгарсалар гына инде. Хәер, атлар күренми күренүен. Аларны икенче маневрга калдырганнардыр.

Безнең көймәгә яшь кызылармеецлар утырган. Берсе — юкарак җилкәле, подвал Кәриме кебек озынча йөзлесе яшь малай кебек кенә, ә үзе зур тәлинкәле кул пулеметы тоткан. Ул пулеметны ничек урнаштырырга белмичә, көймәне селкеткәли башлады. Ишкәккә утырган яшь грузин да кабалана. Ишкәкне әле бик тирән батыра, әле су өстеннән шудырып җибәреп, үз хәрәкәтенә үзе үк кереп, артына егылып-егылып китә. Күрше көймәдәге лейтенант ана:

— Георгадзе, осторожно! — дип берничә мәртәбә кисәтү ясады инде.

Шуннан мин ишкәккә үзем утырып, көймәне бөтенләй бер читкә каерып читкә алып киттем.

— Әхмәров абзый, миннән калмагыз, — дип аларга да үземә иярергә куштым.

Безнең көймә дә, яшь лейтенант белән Әхмәров абзый утырган көймәдә бөтенләй читкә тайпылып уң якка чыкканнан соң, мин ишкәк белән тормоз биреп көймәмне капыл гына туктаттым. Кәримгә охшаган яшь кызылармеец аягына басып:

— Пулеметны алга куйыйк микән әллә? — дип икеләнеп торды.

— Куегыз, — дидем мин.

Ләкин ул алга үткәндә авыр итекле бер аягы белән көймә читенә басып алды да аны аудара язды, кулындагы пулеметны чак кына төшереп җибәрмәде — минем бөтен эчем жу итеп китте. Ләкин көймә шактый гына су чумырып алган иде инде. Мин утыргычым аша пулеметчыны алга уздырып җибәрдем дә, Георгадзены яңадан ишкәккә утыртып, үзем исә койрык ягына ашыгып тирән калай банка белән тиз-тиз су түгә башладым. Суны шундый кызу түктем, мускулларыма каты чыккандай булды, ә тамак төбемә кайнар төер утырып пешерә башлады һәм мин хәлсезләнеп туктап калдым. Күрше көймәдәге лейтенант:

— Курейчик, помоги мальчику, — диде.

Аксыл чәчле Курейчик шундук мылтыгын көймәгә аркылы салып кулымнан калай банканы алды:

— Держи ружьё чтобы не выпало, — диде һәм нәкъ минем кебек җәһәт-җәһәт су түгә башлады.

Ә безнең сул тарафта мәхшәр диярсең. Ишкәкләр чупырдый, тигез ишмәгәнлектән көймә борыннары әле бер, әле икенче якка борылгалый. Ә без әҗәл тагарагы дип йөрткән тигез төпле балыкчы көймәләре исә гел бер урында бөтереләә. Дүрт пар ишкәкле зур гына көймә Суконный ягына бөтенләй арты белән карап тора, чөнки ул, бүтәннәре китереп кысканлыктан, борыла алмый азаплана иде.

Шунда безнең малайларның тычкан чыелдаган сымак фәрманнары ишетелә башлады. Алар да безнең кебек читкә чыгарга өндәделәр, көймәләрне тарата төшәргә куштылар. Чынлап та көймәләр читкә тайпылышып әлеге кыямәт бошрасыннан берәм-берәм чыга башладылар, хәтта дүрт пар ишкәклесе дә, соңга калып булса да, борынын аргы якка бордырып куя алды. Хәзер инде дошман ягына кичекмичә чыгу ишкәкчеләр сәләтенә бәйле. Бу җәһәттән көймәбезнең хәле шәп түгел. Көймә төбендәге су кимеп килсә дә, Георгадзе тигез генә ишеп бара алмый. Өстәвенә ишкәкләрнең озын тоткалылары туры килгән. Мондый ишкәкләр белән бик сак ишәргә, йодрыкларны чиратлап куеп, ягъни уңын үзенә якынрак, ә сулын үзеңнән чак кына ераграк тотып ишәргә кирәк. Ә ул йодрыкларын бертигез куеп ишмәкче була, һәм ул олы-олы йөнтәс йодрыклар зур келәшчә белән китереп кысканадай кысылып кына торалар. Грузиядә бер дә ишкәк ишмиләр микәнни соң? Хәер, таулар арасында, ашкын елгаларда көймә йөрми булыр.

Ниһаять, Георгадзе бер мәртәбә йодрыкларын каты гына китереп кыстыргач, авыртуга чыдый алмыйча, ике кулын да селкеп торды, көймә бөтенләй туктап калды. Шуннан мин аңа ишкәкләрне ничек тотарга икәнен күрсәттем, бик ашыкмаска, ләкин туктамыйча тигез-тигез алдырып ишәргә куштым. Георгадзе бераздан эше җайлангач ак тешләрен күрсәтеп елмаеп куйды. Ләкин без бик артка калдык. Командир безгә:

— Георгадзе, подтянись! — дип кисәтү дә ясады.

Грузин егете тагын тигез ак тешләрен күрсәтеп елмаеп куйды. Дөресендә, аның хәле бер дә елмаерлык түгел, ул бая йодрыкларын сыдырып, хәтта канатып та бетергән. Ул аларның берсен бик зур кул яулыгы белән ураган

булса да, барыбер анының аша кан саркып чыга һәм Георгадзе кулын суга тыгып-тыгып ала иде.

— Кая үзем, — дигәч, берни әйтмәде тагын, минем урынга утырып елмаеп кына куйды.

Мин, суны каерып, салмак кына ишәргә керештем. Каушамыйча тигез генә ишәргә тырышам. Көймә кыенлык белән генә алга бара. Дүрт пар ишкәкне көймә, тәртипсез божра эченнән чыгу өчен бик зур әйләнеч ясаган булса да, ул инде хәзер хут алган, кургашындай соры су өстен борыны белән хәнҗәр кебек кисеп бара. Мин ирексездән көнләшеп куйдым, чөнки анын койрыгына Ринат утырган. Ул русчага оста, китапларны бик күп укый, кызылармеецларга ничек ишәргә кирәк икәнен тиз генә төшендереп биргән иде. Мин исә русчаны ватып-сындырып дигәндәй, телсез кешеләр шикелле күбрәк ишарәм белән аңлатып биргәч тә Георгадзе елмаеп утыра бирде, йодрыкларын суеп бетерде, шунлыктан менә хәзер үземә көчәнергә туры килә. Хәрби десант ул койрыкка кош мамыгыдай кызларны утыртып су өстеннән шуып йөрү генә түгел икән. Минем инде өч өлкән кешене, пулемет белән мылтыкларны сөйри-сөйри муен тамырларым бүртеп чыкты, ә битемнән тир тамчылары тәгәрәп-тәгәрәп төшә. Шулай да мин, кабаланмыйча, тигез-тигез ишәргә тырышам. Курейчик, минем ишкәкне бик батырмыйча чупыр-чупыр гына итеп баруыма күз салгалап, су түгүен белә. Су шактый кимеде, көймә күтәрелеп җиңеләеп киткәндәй булды, ләкин хәлем бик мөшкел шул. Аягымны нык-нык терәп, һәрбер тамырымны киереп талпына-талпына ишәргә теләсәм дә, юк, булмый, кулларымның тәмам җегәре бетте, хәтта суны мең газап белән каерсам да, ишкәк калагын су агымыннан чыгара алмыйча гаҗиз булып утыра идем. Бәхетемә каршы Курейчик моны сизде:

— Ну-ка, малыш, — дип, калай савытны миңа тоттырып, үзе ишкәккә утырды.

Шуннан без, безне адәм мәсхәрәсе ясап узып киткән әҗәл тагаракларын да берәм-берәм артта калдыра башладык, ниһаять, лейтенант белән Әхмәров абзыйлар утырган көймәне дә куып җиттек. Лейтенант ишкәкчебезнең якякта әйләнмәле уймаклар калдырып ишүенә сокలануын белдергәндәй:

— Молодец, Курейчик, так держать! — диде һәм шул мактавы белән безгә тагы да көч өстәде. Менә инде десант Кабан уртасына җитте, кайбер каеклар, көтүдән алгарак чыккан җитез юртаклар кебек, талпынып-талпынып алга баралар, ләкин аларның берсе дә Ринатлар көймәсен куып җитә алмый иде. Ләкин бер мәлне, аргы якның яр башында калкып утырган Осводо йорты чарлагыннан, бөтен Кабан өстен яңгыратып, пулемет «ут» сиптерә башлагач, әлеге дүрт пар ишкәкле көймә дә сөртенеп куйгандай булды, яны белән борыла башлады. Пулеметтан чарлак тәрәзәсеннән утны шундый мул итеп сибә, аннан көлтә-көлтә утлар бөркелә. Мин куркуымнан кинәт кенә иелеп көймәне чайкалдырып аңа тагын «су эчертә» яздым. Курейчик:

— Малыш, не бойся, это учебные, — диде һәм ишүен белде.

Ул да түгел, яр буеннан бүрек хәтле ялкыннар бөркетеп «дөмбер!», «дөмбер!» нәрсәдер аттылар һәм десант алдында гына тау-тау су фонтаннарын күтәрделәр. Минем йөрәгем ярылырга җитте, бөрешеп килеп, көймәнең төбенә үк постым. Бүтән көймәләрдә дә малайларның куркышып кычкырганнары колакка чалынып калды. Көймәләр яр буе кыясына килеп төртелгәндәй туктап калдылар. Ләкин әле аннан, әле моннан командалар ишетелде:

— Наступать! Наступать!..

— По противнику огонь!..

Көймәләрдән залп белән мылтык ата башладылар, берничә җирдән кул

пулеметы сиптерергә кереште. Безнең яшь пулеметчыбыз, пулемет аякларын көймәнең алгы сәкесенә нык кына кадап, үзе исә көймә төбенә тезләнеп, «тырт!», «тырт!» аттырып юка гына аркасын калтырата башлады. Георгадзе да мылтыктан ата, яулык бәйләгән кулы белән шалт-шолт затворын ачып яба һәм тагын чакмага баса. Безнең өстә яшькелт-соры төтен сәләмәләре күчеп йөри башлады, алар күксел томан белән кушылып бөтен яр буйларын каплап алды.

Иң куркынычы хәзер: зур көймәләр аркылы төшеп туктап калмасын, бер-берсенә төртелеп туктадылар исә, баягы мәхшәр кабатланачак. Моны командирлар да белә, «Вперед!», «Вперед!» дип ашыктыра.

Ринатларның көймәсе, ниһаять, тураеп, очлы борыны белән «Спартак» комбинатының сул канатындагы тыкрыкка таба йөзеп китте. Каршы «уттан» бераз читләшеп алар бик дөрес эшләделәр әлбәттә. Алардан күрмәкче, тагын безнең берничә зур көймәбез уңгарак күчеп тиз генә яр читенә якыная башлады — андагы малайлар да бик зирәк булып чыкты: алар турыдан аткан пулемет утыннан да качтылар, дошманны читтәнрәк килеп камап алырга да уйладылар. Чынлап та дошман пулеметы хәзер нишләргә белми: уң якка атса, сул ягында көймәләр ярга кадалырга тора, сул тарафка атса, уң канатта Ринатларның көймәсе торпедо кебек су өстеннән очып бара. Көймәдәге мәргәннәр дә осталыкларын күрсәттеләр. «Фашист» минометчыларын (әллә тупчылары микән?) бик тиз чүкеделәр, безнең алда су чүмәләләре хәзер күтәрелми иде инде. Шуннан файдаланып, уртадагы вак көймәләр ташкын булып ярга омтылдылар.

Безнең Курейчик та җилкенә-җилкенә «очты». Көймә төбенә тезләнгән яшь пулеметчыбызның иңбашы һаман әле калтырап-калтырап китә, ул яр буена кыска чиратлар белән аткалый. Георгадзе да, тау ягы кешесе бит, снайперлардан калышмый, Освод чарлагына мылтыктан чәпәвен белә һәм дошман пулеметчысы тынып калган саен, энҗе тешләрен күрсәтеп, елмаеп куя.

Шулай әйбәт кенә хут алдырып барганда, инде ярга чыгып җиттек дигәндә, дистәгә якын көймә шып туктап калдылар. Безнеке исә җай гына килгән шәпкә каплана язды. Георгадзе көймәнең чөйкәлеп киткән читенә басасы урынга, каушаудан, авышкан якка китереп басты да шундук, мылтыгын тоткан килеш суга очып төште. Курейчик ишкәкне ычкындырып аркасы белән дыңгыр итеп көймә төбенә ауды. Ләкин барыннан да күңелне өшетеп җибәргәне шул булды: яшь пулеметчыбыз ике потлы гер кебек келт итеп су төбенә төшеп китте. Бу тирәләрне мин беләм: өч метрлы колга күмелерлек, ләкин күлнең төбе нык, каты кызыл балчык. Без хәтта Кабанны аркылаганда, ярга чыгып җитәргә хәлебез калмаса, тирән генә сулап күкрәгебезне һава белән тутыра идек тә, аягүрә акрын гына су төбенә төшә идек, инде төшеп җиткәч, сыгылмалы тез буыннарыбызны чүгәбез дә табаннарыбызны салкын балчыкка терәп, капыл гына өскә сикергәндәй итәбез һәм шундук судан калкып чыгабыз. Бу арган тәнебезне яздырып алырлык бер үзгә хәрәкәт булса, шул арада кулларыбызны да ял иттереп алырга өлгерәбез һәм инде җинел генә йөзеп китеп яр буена чыгып та җитәбез. Ләкин бу ялан тән, нибары ят җиребезне капларлык яулык кисәгедәй трусиктан килеш йөзгән чакта шулай. Хәзер исә хәл бөтенләй башка. Солдат мундиры, бигрәк тә кирза итеге су йотып, таш кебек аска сөйри башлый. Өстәвенә яшь кызылармеец пулеметны һич кулыннан ычкындырасы килми. Инде бер кулы белән суны көри-көри өскә йөзеп чыккач та, басмаларның черек субае кебек тагын акрын гына су төбенә төшеп китте. Инде бу вакыт Курейчик сикереп торган иде һәм ул, бер мәртәбә пулеметчыбыз чәчләрен озын чуклы пумаладай чайкалдырып чыкканда, аны шул чәченнән тартып

өскә сөйрәде, аннары без аны икәүләп көймәгә тартып алдык. Ул күп кенә су йотып өлгергән, чырае үлек кебек агарып килгән. Курейчик аптырап торганда, мин пулеметчыны тиз генә көймә төбенә сузып салырга куштым, үзем күз ачып йомганчы костюмым белән чалбарымны салдым да, — мина шундук каз тәне чыгып чиркәнчек булып алды, — шул киемнәремне бөкләп аркасы астына кыстырдым һәм суына башлаган кулларыннан тотып, әле терсәк турысыннан бөкләп, күкрәгенә баса төшеп, әле кулын үземә тартып, ясалма сулыш алдыра башладым. Шулай бик үк калку булмаган күкрәкне бер кысып китерәм, бер бушатам. Тырыша торгач, тимерче күрегендәге шикелле, кызылармеецның күкрәк куышлыгында һава сызгыра башлады, ул да түгел, кызылармеец селкенеп куйды да, бер мәлне голдыр-р итеп ярты чиләккә якын су косып чыгарды. Менә ул аңына килде, күзен ачып, «Пулемет...» — диде.

Инде яр буенда «ура!» тавышлары янгырый, шарт-шорт мылтык атканнары ишетелә, безнең гаскәр дошманны штурмлый. Ә без кызылармеец белән булашабыз. Ул арада Әхмәров абзый белән лейтенант килеп җиттеләр. Лейтенант кыска гына боерык бирде:



*Т.Нурмөхәммәтов — бакча йортында.*

— Әхмәров, немедленно его на берег! — диде.

Абзый башта кызыл хачлы сумкасыннан бер бәләкәй шешә чыгарып, бөкесен ачты да, аны яшь кызылармеецка иснәтеп алды, тегесе исә борынын җыерып каты гына төчкереп җибәрде.

— Болай булгач, гөлкәем, Берлинга да барып җитәрсең әле син! — дип аның җилкәсеннән кагып куйды абзый.

Яр буенда «ура!» тавышлары көчәя төште. Күп тә үтмәде, усал эт телен селкеткәндәй ут сиптергән пулемет авызын да «тыгылдырдылар», пулеметчының кулын күтәртеп яр буена алып төштеләр. Анда көймәләребез алдында су өермәләре күтәрткән минометчы да бар. Ике «әсир»нең икесе дә дошманга шундый охшатылганнар, хәтта башларына мөгезле каска, аякларына чиләк сыман киң һәм кыска кунычлы итекләр дә кигәннәр иде. Тәмам яктырды. Кояш чыгып Кабанның яртысына, безнең йортыбыз ягындагы яр башларына укалы нурларын сипте. Ләкин күләгәле бу яклар әле караңгырак иде. Шулай да суга батырыла төшкән басманың такталары беленә башлады инде. Менә күксел томан да таралып, су өсте көзгедәй яктырып китте.

Күл төбендәге пулеметны озак кына күзләдек, ниһаять, озынча бер шәүлә күреп алып, аңа ишкәк төртеп карадык. Пулеметның басма астынарак шуып керүе дә хәлне катлауландыра төшә, чумып алам дисәң, пулеметны бер кулың белән тотып, ә икенчесе белән су көри-көри читкә үк йөзеп чыгарга кирәк, моны исә һәркем булдыра алмый. Ике кызылармеец төшеп күтәрсә бик яхшы булыр иде дә, тик Грузиянең таулар арасында яшәгән Георгадзе йөзә белми икән. Шуннан без Курейчик белән икәү төшәргә булдык. Чишенеп суга сикердек. Ләкин кинәт кенә су төбенә чумарга

ярамый әле. Шунлыктан, без көймә артында бераз чапыр-чопыр килеп йөзеп йөрдек. Һава салкынча булса да, су үзе җылы сөттәй парлы, рәхәт иде. Ниһаять, без Курейчик белән су төбенә төшеп киттек. Ләкин таза тәнле Курейчикны су бик тиз күтәреп алгач, мин дә башымны калкытып судан чыгарга мәҗбүр булдым.

Без көймә кырыена тотынып аз-маз хәл алдык та, янә суга чумдык — бу юлы без, килешенгән буенча, суны башыбыз белән сөзә-сөзә, аякларыбыз белән этенә-этенә төштек һәм икебез бер үк вакытта пулеметка килеп ябыштык. Ләкин ул әллә ләмгә бата төшкәнгә бик авыр идеме, без аны бу мәртәбәсендә кузгата алмадык һәм судан чыгып тагын еш-еш суларга тотындык, ял иттек.

Икенче төшкәндә без аны ләмнән суырып чыгарып байтак кына күтәртә алдык. Ләкин мин лайлалы көпшәсеннән тоткан булганмын ахрысы, чыгып җиткәндә генә кулымнан шуып ычкынды да, шактый авыр тимер Курейчикны төпкә сөйрәп алып китте. Ул да аны ычкындырып, су өстенә калыкты. Хәзер инде пулемет тагы да тирәнгәрәк шуыша төште, өстәвенә болганчык су төбендә аны аерып та булмый, бераз су тынганын көтәргә кирәк иде. Без көймә читенә асылынып кабат ял итеп алдык. Шунда Курейчикның башына бер уй килде — ул тиз генә Георгадзега бил каешларын бәйләп куярга кушты. Ләкин ике каешны ялгагач та әле, алар су төбенә җитәрлек түгел, монда тирәнлек кимендә дүрт метр бар иде. Башымнан бер уй ялтырап узды: мин Георгадзе абыйга көймә сәкесе астыннан озын чылбырны сөйрәп чыгарырга куштым. Ул:

— Молодец, малайка, — дип, каешларны чылбыр очына ялгап та куйды.

Мин ике кулымны да алга сузып башым белән чулт итеп суга сикердем һәм суны як-якка көрәп пулемет янына төшеп тә җиттем. Каешны пулемет биленнән бер кат әйләндереп алдым да, тиз генә чалыштырып бәйләп тә куйдым һәм, чак кына тончыкмый калып, судан атылып та чыктым. Георгадзе белән Курейчик су төбен болгата-болгата, бокыр-бокыр китереп, пулеметны суырып чыгардылар.

Пулемет көпшәсеннән кызгылт ләмле су агарга тотынды. Георгадзе пулеметны чиста суда бер кат чайкап аны селеккәләп торды, аннары аяклары белән көймә сәкесенә кадатып бастырып куйды. Инде яхшы гына җылыта башлаган кояшта бер кат кибенеп алганнан соң, без җәһәт кенә өстебезгә киендек. Георгадзе күгелҗем корычлы пулемет көпшәсендәге һәм патрон тәлинкәсендәге терекөмештәй су тамчыларын чүпрәк белән сөртте һәм, чакмасына басып, һавага кыска гына бер «чират» бирде. Пулемет, җанлы җәнлектәй дерелдәп, текелдәп алды. Кабан өсте яңгырап китте, пулеметның кайтавазы Ерак Кабанда ук калтырап ишетелгән кебек булды. Бу ату тавышларының соңгысы иде. Аннары мотор тавышы ишетелде. Калын толымнардай дулкыннар тәгәрәтеп, безгә таба катер килә. Анда койрык тотып Андрей дәдә утыра, ә уртага күкрәгенә бинокль асып, башына шулай ук пилотка кигән бер шпаллы майор баскан иде. Майор ярга чыгып лейтенантларга боерыкларын биргәч, кызылармеецлар шундук кире көймәләренә утырдылар. Яр буенда Освод водолазчысы күренде, аңа да басмаларны кире урыннарына утыртырга фәрман бирелгән иде бугай.

Майор малайларны көймәләрдән җыеп алгач безне су станциясенә илтеп куйды. Андрей дәдә безне Кабанга каратып тезгәннән соң:

— Рәхмәт сезгә, оланнар, сынатмадыгыз, — диде.

Ә майорның сүзләре безгә аеруча тантаналы булып тоелды:

— Сез үзегезне чын лоцманнар һәм боцманнар итеп күрсәттегез. Килер шундый көн, сез бүгенге кызылармеецларга чын арадашчы булып үсеп җитәрсез. Кабан күле сезне ерак киңлекләргә алып чыгар. Сез диңгез

карабларында йөзеп Ватаныбызны дошманнан күз карасыдай сакларсыз. Ә бүгенге десантны аргы якка төшерүдә катнашуыгыз өчен, безгә ярдәм итүегез өчен сезгә кызылармеецлар исеменнән рәхмәт белдерәм, — диде майор.

Артык тыйнаксызлык булыр дип, әйтмәскә дә булган идем. Ләкин китап киштәсе каршына килгән саен күзем беренче булып саргылт тышлы хикәяләр җыентыгына төшә. Бик матур тышка төренгән, исемнәре алтын яки көмеш белән язылган иптәшләренә караганда да бу катыргы тышлы иске китап минем өчен бик кадерле булып тоела. Аны миңа фронтка китәр алдыннан пулеметны суга батырмас өчен җанын да фида кылырга әзер торган теге яшь егет бүләк иткән иде. Әлеге десант вакыйгаларыннан соң берме, икеме көн үткәч, су буенда малайлар белән мәйханә килеп йөргән чагында ул егет мине казарма тәрәзәсеннән күреп калган икән. Командирыннан ун гына минутка рөхсәт сорап ул минем янга су буена төште. Егет ябык булса да, ләкин нык авыр кулын минем иңбашыма салды да, мине үзе белән ияртеп, чирәм өстенә салынган сукмак буенча атлап китте. Ерактан караучы кешеләргә без мөгаен агалы-энеле бертуганнар булып күренгәнбездер. Ул кызлар кебек бик матур озын керфекле, подвал Кәриме кебек үк аксыл чырайлы буйчан егет иде. Аның Кәримнеке шикелле үк яшьлеге, хәтта суырыла төшкән яңагында мамыктай йомшак бала төкләренә кадәр исемдә калган. Без шулай арлы-бирле сөйләшеп йөргәндә, казарманың ачык тәрәзәсеннән безгә дәшкән кебек булдылар. Әйләнеп карасак, егетне иптәшләре чакыра, ана ашыга төшәргә кушалар икән. Егет мине соңгы тапкыр күкрәгенә кыскандай итте дә:

— Менә сиңа бер ядкарь булсын, — дип миңа әлеге китапны тоттырды, аннары кирза итегенең резин табаны астыннан балчыклар аттырып, йөгерә-йөгерә, тау башына менеп китте.

Мин китапка күз салдым. Аның тышына: «Антон Чехов. Лошадиная фамилия. «Рассказы» дип язылган иде. Ул вакытта атлар белән кышкырыч килеп йөргәнгә, «Әллә язучы шуларның берәрсе турында язган иде микән?» — дип малайларга көлеп тә куйган идем мин. Соңыннан алай түгел икәнлеген белдем әлбәттә һәм бераз бу китаптан гайрәтем кайткан кебек тә булган иде. Ләкин хикәяләр җыентыгының титул битенә кыйгачлап язган сүзләр шундук минем әле нарасыйлыктан чыгып бетмәгән йөрәгемә кереп урнашты һәм мине байтак вакытлар дәвамында уйландырып торды. «Энеләрем, сез сугышка китмәсәгез дә, барыбер солдат идегез. Совет гаскәренә пулеметны һәм бер кызылармеецны кайтарып биргән өчен рәхмәт сиңа. Үлем немец фашистларына!» дип язылган иде ул китапның алгы битенә.

Шуннан соң нинди юллар үтте икән ул егет? Нинди утларны, суларны кичте икән? Өенә исән-сау әйләнеп кайтты микән? Һәрхәлдә, ул үзенең ике аяклы корыч дусты белән байтак дошманны кырган булгандыр. Ә инде сугыш тынып торган вакытларда, окоп аркасына шинельле аркасын терәп, әлбәттә, Кабан малайларын да, күлнең үзен дә кабат-кабат исенә төшергәндер һәм акрын гына башын чайкап елмаеп та куйгандыр. Мин дә ана ерактан торып елмаям: «Нихәл, окоп бик туңдырмыймы? — дип сорыйм һәм:

«Син, кайткач, безнең Казанга бер килеп чыгарсың бит. Күлне иңләп көймәләрдә йөрер идек, ә?» — дим. Егет тә: «Обязательно йөрибез, көт яме?» — дип башын кагып куя һәм зәңгәр энгер эчендә күмелә барып акрын-акрын күздән югала. Мин күземне каты гына йомып, аны яңадан күрмәкче булам, ләкин аның аксыл чырайлы сурәте күз алдымда ни өчендер янармый һәм ниндидер хәвефле уйдан минем бөтен эчем жу итеп китә. «Нәрсә, син яраландыңмы? Әллә... Юк, юк, булуы мөмкин түгел. Син безнең кебек үк яшь бит әле. Синең безнең кебек үк яшисең килә бит әле? Шулай бит?» Ләкин ул дәшми...

Казарма, аның бер авылны сыйдырырлык ишегалды шау-гөр килеп тора-тора да, тагын тынып кала. Тик бу тынлык озакка сузылмый, чөнки гаскәриләр колоннасы музыка уйнатып вокзалга озатылганнан соң бирегә кабаттан әле генә армиягә алынучылар килеп тула, аларны командирлар яңадан сугыш һөнәренә өйрәтергә керешәләр. Ләкин Кабан күлендә десант төшерүләр бүтән бер дә кабатланмады кебек.

Безнең йортта сугышка алынучылар арта тора. Аты Каракүздән соң сугышка безнең чапаевчыбыз Нурулла абый китеп барды. Ул да түгел, Илдус белән Илгизәрнең әтисе Сәфәргали абзый да, Ринатның әтисе Сирай абый да армия сафына алынды. Инде көз якынлашып килә, укыр вакытлар житә, ә ишегалдындагы ир-ат һаман саен кими бара. Хәзер инде «Жизни абый»ның, ягъни Зәйнулла абыйның утын сарайларына аркаларын терәп тәмәке тартып утыручы агайларыбыз каршында: «Без фәлән дә, без төгән, немецны без аны хәзер тукмап кайтабыз!» — дип күкрәк төюләре бетте. Аның җилкәләре дә, күкрәге дә бик киң. Әнә шул кызгылт йөнтәс күкрәген ул буш мичкә тавышларын чыгарып хәзер дә кагыр иде, тик кем каршында каксын ул аны, кулы энә генә күтәрерлек, сугышка яраксыз минем әти каршындамы, Илгизәрләрнең бабасы, бик акрын кыймылдаучы Хөсәен бабай яки аның җәмагате чүрәкәй хәтле генә Зәйнәп апа каршындамы? Хәер, аларның буйчан гына оныклары, кул чуклары да кызларныкы шикелле озынча булган кара тут йөзле Тәлгать бар әле. Ул ниндидер хәрби заводта монтер булып эшли. Әнә шул мин әйткән озын бармакларын кыймылдата-кыймылдата, чыбык очларын әле пычак, әле карга борыны белән кискәләп, сугыш алдыннан гына безнең йортыбызга электр уты керткән иде ул. Бу унжиде-унсигез яшьлек егетне заводта бронь гына тотып тора булса кирәк, ә бронь дигәненең дә кодрәте бетсә, ул да сугышка китеп барыр микән?

Сугыш үзенең толлары, хәсрәтләре белән акрын гына безнең йортыбызны били. Ләкин сугышның беренче айларында әле без кытлык дигән нәрсәләрне ул кадәр сизмәдек. Күрәсең, балалыгыбыз белән һаман әле тыныч-имин чактагыча ваемсыз гына яши биргәнбез. Ә инде безнең уеннар арасына казарма күренешләре, Кабан күлендәге һәм урамнардагы хәрби өйрәнүләр дә килеп кергәч, бу безнең өчен гаҗәп кызык булып тоелды.

Казанга эвакуированныйлар килә башлады. Ринатлар фатиры ул еллардагы үлчәм белән караганда шактый иркен иде, аларга бик нечкә сынлы, очлы борынлы кызы белән зур битле, тулы гәүдәле яһүд маржасы Раиса Марковнаны урнаштырдылар. Раиса Марковна соңга таба безнең әниләребезгә үзләренең «җәннәт бакчасы» Гомель шәһәре турында сөйли торган булса да, үзләре алар Ленинградтан килгәннәр иде бугай. Озакламый аның сеңлесе Фаина Марковнаны да шул ук фатирга сыйдырдылар. Раиса Марковнаның бәләкәй күзләре безгә — татар малайларына, ниндидер сер белергә теләгәндәй, бик кызыксынып карый, вакыт-вакыт күңелле генә очкынланып китә. Ләкин ул барыннан бигрәк үзенең таркау чырае белән, гәүдәсен кая куярга белмәгәндәй һәрвакыт диярлек үзенең почмагында утырып торулары белән хәтердә калган. Ә менә Фаина Марковна, киресенчә, Ринатларның биек тәрәзә катына килеп баса да, кулларын күкрәгенә кушырып, зур күзләрен Кабанга төби. Аның чем-кара чәчләре дулкын-дулкын булып муенына ишелеп төшкән, ишелеп төшкән дә ефәк чәч үргече белән биләп куелып, ике кыска толымга аерылган. Юкарак борын сыртының чак кына бөкрәеп торуы аны бөркеткә охшата сымак. Ләкин аның горур карашы саргылт чыраен йомшарта төшкән. Бу саргылт төс яки аның, немец самолетлары астында ерак юл килеп бик каты аруыннан, яки бәләкәй кызы белән вакытлыча аерылып торуыннан булырга тиеш. Немец Гомельне бомбага тоткан да, аның Полина исемле кызы балалар составы белән Урал ягына китеп барган, ә ул үзе ни

сәбәптәндер тоткарлана төшкән. Ана белән бала тиздән кавышырга тиеш булса да, Фаина Марковнаның карашы шулай да бик моңсу булып тоела, аның зур күзләрен кайчагында яшь пәрдәсе каплап ала торган иде. Бу яһүд маржаларының Полина М. исемле иң кече сеңелләре дә бар, ул Нәриман урамындагы элекке байлардан калган бик һәйбәт йортның түрге өлешендә яши. Анысының чәче дә бөдрә түгел, борыны да аерылып тормый, бик төз, матур гына. Гомумән, ул уртадан чәч юлын салган бик ачык чырайлы рус хатынына охшап тора.Аның ирен махсус самолетларда очып йөрүче бик зур хәрби начальник дип сөйлиләр. Менә бу өч хатын-кыз туганнарының бер тирәгә урнашуына да аның ярдәме тигән икән.

Йортыбызның парадный ягында торучы Шәүкәтләргә дә  Мәскәүдән бер гаилә килеп урнашты. Безнең арада озынлыгы белән аерылып торган Шәүкәт куш иренле иде, шуңа күрә малайлар ана, жинел куллан, «Губа» кушаматын такканнар иде. Аның әтисе дә баһадир гәүдәле, кызыл чырайлы бер мишәр агае булып, яшьлегендә ул Караганда якларында күмер чапкан. Аны да повестка белән армиягә чакыртып караганнар иде. Ләкин Җиһангир агайны өенә бик тиз кайтардылар, ул шахтада эшләгән чагында ул йөрәк чирен алган булган. Менә шушы мишәрләр өенә дә эвакуированныйларны китереп кертеннәр иде. Аларның әти-әниләре бар идеме, юк идеме, анысы безгә кирәкми дә, белми дә идек. Ләкин без үсмер малайлар белән бик тиз танышып өлгердек. Безне аларга бигрәк тә якынайткан нәрсә — чып-чын мылтык патроннары иде. Алар ул патроннарны каян тапканнардыр — монысы малайларның тирән сере иде әлбәттә. Ләкин, әйтәм бит, безгә анысы да кирәкми. Безгә барыннан да бигрәк шунысы кирәк: берәр патронны ничек тә эләктереп булмасмы, шуңа күрә бу урыс малайлары урамга чыксалар, без аларга, кендекләребез береккәндәй, тагылып йөрибез. Ләкин Губа, хәерсез, ул патроннарга күптән хуҗа булып алган инде, аларны кесәсендә генә шалтырата, без исә хәзер аның тирәсендә бөтерелергә мәҗбүр була идек.

Мәскәү малайларының өлкәне Мәскәү белән Казан арасында берничә мәртәбә китеп-кайтып йөрде бугай, шуңа күрә без аңардан безгә дә патрон алып кайтуын үтенеп караган идек. Ул сүзебезне тыңлап алып та кайткан иде кебек, ләкин болары инде буш эчле гильзалар гына иде. Ләкин без анысына да шатландык. Мин кесәмне тишкәнче бер гильзаны саклап йөрүемне хәтерлим, кулыма алдым исә, җиз калаеннан бигрәк үземнең күзләрем сөенечтән елтырап китә иде сымак. Ләкин буш гильзаны берничек тә «тормышка ашырып» булмаганлыктан, мин ана коры куаныч булып карап йөрдем-йөрдем дә калын калакны чүкеп бармак буе гына кинжал ясаганнан соң, аны әнә шул гильза белән саплап куйдым.

Без буш гильзалар белән мавыгып йөргән арада, мәктәпнең өлкән укучыларын, алар белән берлектә, бишенчеме, алтынчымы класста укучы Нурияне дә Идел буендагы бер совхозга эшкә җибәргәннәр иде. Нуриянең аякларын инде көзән җыермый, җыера торган булса, Мәрьям апа аны ничек тә җибәртмәү ягын караган булыр иде. Ләкин китәсе кителгән, бер үк хәерле булсын. Сугыш елында ниләр генә күрелмәде. Тик Мәрьям апа кызын сагынып микән, кызганып микән, хәл-әхвәлләрен беләсе килеп ык-мык итә башлагач, мин үзем Нурия янына барып кайтырга ризалыгымны бирдем. Әлбәттә, Мәрьям апа кызына коры сәлам тапшырырга гына уйламый, ашамлыктан нәрсәдер салып кулыма сумка да тоттырган иде. Һәм менә без күрше Насыйри урамындагы Самат исемле малай белән, аның да апасы совхозда иде, — мехкомбинат артларыннан Иделгә таба китеп бардык.

Самат белән урманда адашып йөрүебез хәтердә калган. Ул вакытта дезертирлар турында шомлы хәбәрләр колакка чалына башлаган һәм без, берүк очрый күрмәгәйләре дип, котларыбыз ботларыбызга төшеп, урман

эченнән элдерәбез. Матюшино тирәсендә әнә шулай буталып йөргәндә, без берничә ир кешене очраткан да идек. Ләкин алар һич тә йолкынган, йончыган кешеләргә охшамыйлар, безне күрсәләр дә әллә ни игътибар бирмиләр, җиләк чемченеп йөргәндәй итәләр һәм кайвакыт таркау гына елмаеп куялар. Бу ирексез елмаюлардан без шуны укыйбыз: «Юк, без дезертирлар түгел, курыкмагыз, балалар». «Алайса кемнәр соң сез? — ди безнең күзләребез дә. — Артык купшы киенмәгән булсагыз да, изүләрегезне чишеп нигә туарылып йөрисез урманда?» Алар тагын таркау-хәлсез генә карап безгә җавап бирәләр: «Нишлик соң, гаеплебез әлбәттә. Ләкин...» Әмма без аларның «ләкин»нәре белән нишлик, тез буыннарыбыз ансыз да йомшарган, шуңа күрә без, артыбызга борылып карый-карый урман түренә шыңкаерга ашыгабыз.

Калын-калын нарат урманы. Аяк асты ком булу өстенә тигез дә түгел, дулкын-дулкын. Шул дулкыннардан бер төшеп, бер менеп тәмам арып беттек. Баш түбәбездә чак кына нурланып торган күк йөзенә караганнан соң мин кинәт әйтеп куйдым:

— Самат, әйдә агач башына менеп карыйбыз? — дидем.

Һәм шундук югарак бер наратны сайлап үрмәләп менеп тә киттем. Әллә ни күп менәргә дә туры килмәде. Комлы җир түбән таба сөзәкләнә бара һәм урман анда кинәт ачылып китә. Агач башлары чайкалыбрак торган әнә шул зәңгәр ачыклыктан да түбәнрәк көзгедәй ак тигезлек җәйрәп ята. Су әлбәттә бу, Идел бу! Безнең күңелләребез тантана итә. Чөнки Идел буенда балыкчылар булырга тиеш. Һәм без йөгерә-йөгерә шунда төшеп китәбез, бер урыс авылына барып керәбез. Безне ак башлы урыс малайлары урап ала. Минем бердәнбер бурычым — Нуриягә дигән сумканы саклап калу. Әгәр һөҗүм итсәләр, минем коралым әзер һәм мин аны, малайлар күрсен өчен, кечке кояшка ялтыратып та куйгалыйм.

Ниһаять, өлкәннәр дә килеп чыгып, безнең адашуыбызны белгәч, совхоз юлын өйрәттеләр. Өстәвенә бер олау да шунда менеп бара, кояшта янып беткән һәм бирчәйгән кулы белән арбаның арткы карамасына ябышып, көн бик җылы булса да, өстенә брезент плащ кигән бер урыс агае атлый иде. Ул безнең белән сүз алышкалап нәкъ совхозның үзенә алып барды.

— Шәһәрдә нихәлләр соң анда? Немец заводларны шартлатыр өчен десант төшергән дип сөйлиләр монда, шул дөресме? — диде урыс агае бик борчылып.

Без бу хәбәрдән кычкырып көлдек:

— Ничек килеп җитә алсын ул Казанга хәтле? — дидек.

— Алла диген, җитәр дә...

Безнең адашып йөрүләр дә онытылды. Ниһаять, без совхозга менеп җитеп, апаларыбыз белән дә күрештек, анда кунып икенче көнне, өйләдән соң, Казанга кайтып кердек. Мин бу кечкенә сәяхәттән соң урамнарга элеп куелган бер плакатның мәгънәсен шунда гына аңладым. Анда берәүнең авызына бармагын куйдыртып бик җитди карашлы сурәте ясалган һәм: «Теленне тый, артык сүз — дошман сүзе» дип язып куелган иде.

Плакат дигәннән, аның берсе безнең өебезгә дә кереп урнашты. Әйткәнемчә, йортыбызның өске каты бүрәнәдән салынган. Элек бездә ел саен, кышны чыкканнан соң, өмә ясап өй юу гадәте бар иде. Хатын-кызлар казанда су кайнарлап, пычак белән кыра-кыра, һәм мунчала белән ышкый-ышкый юалар иде өйне. Бүтән фатирдан аермалы буларак, безнең өйне, әүвәлге кухняны, нихәтле генә кыргычлап юма, гомер буена бай ашларын пешерә-пешерә җыелган сөремне бетереп булмый, аның карасы һаман әле суга чыга иде. Шулай да безнең өебез, бер кат «мунча» кергәннән соң, чистарып китә, һавасы сафлана, ә инде сөйләшкән чагында тавышлар янгырап-янгырап китә иде.

Тора-бара өй юулар бетте, стеналарга обой ябыштыра башладылар. Йортта беренче булып, әле сугышка хәтле, без ябыштырдык обойны. Ләкин тәүге тәҗрибәбездән унмадык шикелле. Коры бүрәнәне генә кәгазьләргә ярамый икән, ул яргаланып чатнап бетә, ямьсезләнә. Менә шулай безнең обой бүрәнә араларыннан ярылгалап ертылып беткәч, әти бер як стена уртасына Мичурин сортлы алма сурәтләре төшерелгән плакатлар ябыштырып чыкты.

Әти сәер кеше иде. Анының белән Югары Утарга Шәймәрдән урманы аша кайткан чакларыбыз да бар. Ул анда һәрвакыт кордондагы бер авылдашына кереп чыга. Урман аланындагы кордонда кунып калган вакытларыбыз да бар иде. Һәм менә ул, жае чыккан саен, мине киләчәктә урманчы булырга кыстый башлады. Урманы, саф һавасы дисенме, аерым утары тагын. Дачник кебек кенә дә түгел, алпавыт булып яшисең инде менә. Аннан инде, картлык көннәрендә, әти-әниеңне дә үз яныңа алдырасын. Нинди рәхәт тормыш.

Ләкин мин сугыш башланасы елны дүртенчегә күчеп кенә калган идем әле. Мина әле урманчы булырга иртә иде. Шуннан әти, запаска опас дип, мина тагын бер һөнәр табып куйды: һич югы бакчачы булсаң да яхшы, диде. Никадәр жиләк-җимеш үстерәсең! Ул язларын бакчаң шау чәчәктә утыра, бал кортлары безелдәп очып йөри, — балы да була, димәк. Ә инде ул көзге байлыкны күрсән... Юк, бакчачы булу әйбәт ул. Акчасы да була. Һәм менә әти хыялының чагылышын — кызарып пешкән алмаларны — стенага ябыштырып куйды. Мин анда «бельфаркитайка» дигән һәм бүтән сортларны белдергән хикмәтле сүзләрне укыйм, кайвакыт үзем дә: «Чынлап та нигә әле бакчачы булмаска?» — дип дәррәү кызыксынып, уйлар канатына утырып, бик ямьле бакчаларга кереп китәм.

Әтине 1941 елда сугышка алмадылар әле. Анын бердәнбер броне — бүтән ир-ат кебек таза булмавы иде ахрысы. Анын болай күренеп торган авыруы да юк, ләкин беренче бөтендөнья сугышында алман гаскәре жибәргән зәһәр газ бөтен сәламәтлеген суырган, анын кул-бит тиреләре үк беленер-беленмәс саргаеп тора, зәнгәр кан тамырлары киндерә кебек бүртенгән, әле бишенче дистә белән генә барса да, тешләре какшаган, яртысы диярлек төшеп беткән, шунлыктан яңаклары батып тора, өстәвенә ул борынын сызгыртып йокларга да ярата, кыскасы, әнием аны өнәп бетерми, «өшән, фәлән», — дип аны төрлечә сүккәли иде...

Әти анысы гел йоклап кына тормады. Ул тегүче иде бит. Бәлкем әле төнге каравыл эшен сайлап алуы да әнә шул «Зингер»ын текелдәтеп кәсеп итештерү өчен кирәк булгандыр. Чалбардыр, костюмдыр, пәлтәдер — барысын да тегә, тик яңасын тегәргә бик сирәк китерәләр, күбрәк иске пәлтәләрне әйләндертәләр, моның исә мәшәкате бик зур: сүтәсе бар, тузанын кагасы-чистартасы һәм өлгеләп үтүклисе бар. Аннан инде тегәргә һәм һәр тегелгән өлешен су бөркеп, чыж-чож китереп янадан үтүкләргә кирәк. Әнә шулай кием әйләндерү атналар буена сузыла ул, анын каравы, әйләндерелгән пәлтә заказчы өстендә койгандай утырып тора, янага бер дә биргесез иде.

Әлбәттә, тегү эшенең кайбер яшерен серләре минем күзгә дә күренгәли. Кайвакыт тишелгән терсәк башларын тупчып ямарга, анда да материалның үз ише жеп белән сизелмәслек итеп тупчырга кирәк, ә инде жин очы бөтенләй изрәгән, тузган булса, аны кисеп ташлап, үзе кебек үк драп яки сукно белән ялгап куярга, гомумән, яхшылап сипләргә кирәк. Аннары әти киемнең жилкәләре тулып торсын өчен, кайтарма якалары күкрәккә сыланып торсын өчен киндерен дә, капчык кисәкләрен дә кызганмый, эченә таслап, сабын сылый-сылый үтүкләп калдыра һәм киемне тегеп бетергәннән соң инсәләр дә, күкрәк тирәләре дә кеше өстендә сыланып катып тора һәм инде заказчы, пәлтәсенме, костюмынмы киеп караганнан соң, үзе дә

бик канәгать булып, уклау йоткандай, кукраеп тора иде. Ул, әлбәттә, эти аның киемен әйләндергән чакта ялгышып сул җиңен уң иңенә, уңын исә сул якка утыртканын һәм: «Кире тәре!» — дип заказчыны сүгә-сүгә янадан сүтүләрен, типчүләрен, җиннәрне кабат утыртып чыгуларын белми. Эти хезмәте өчен өсти төшәргә кушкач, тиененә хәтле сатулаша һәм әлбәттә инде артыгын түләмичә китеп бара. Ул кайчан да булса барыбер эти янына әйләнеп киләчәк әле, ул аның осталыгын онытмый, яңа заказларын китерә. Ләкин эти дә аны онытмый бит, чиратны бик озак көттерә, аның киемен тегә башлагач та тегеләй-болай сәбәп табып, заказын бик озакка суза. Хәер, ул үзе дә бик ашкынмый, бөгәрләнеп, ике кулын да тез араларына кыстырып йоклый-йоклый гына тегә. Әни аны: «Нишләп суздың инде шул хәтле!» дип, исенә төшереп тиргәп торса да, ул бер дә кабаланмый, дәшми, саңгыраурак колагы белән артык сүзләрне ишетергә теләмичә генә күбрәк эченнән кичерә иде.

Әле өч-дүрт яшемдә чагында ук әтинең миңа агачтан бик матур буяулар белән буяп ясалган пугач-мылтык алып биргәнен хәтерлим. Атып җибәргәч, шарт итеп бөтенесе очып чыга. Ләкин ул әллә кая атылып китми, җебендә чайкалып тора. Яңадан корасың да тагын атасың — бу малай кеше өчен бик күңелле булып тоела иде. Әмма пугачның юкка гына алынмаганын мин соңыннан, бераз үсә төшкәч кенә аңладым. Бер-берсен өнәмәгән әни дә, эти дә мине үз якларына аударырга тырышалар иде булса кирәк. Әниенең миңа уенчык-мазар алып биргәнен хәтерләмим.

Ләкин ул мине бик кадерли, матур киемнәр тегә, уенчыктай ботинкалар алып бирә, мине, үзенең бердәнбер калган йөрәк парәсен сөя-иркәли иде. Нәрсә ул уенчыклар! Алынган көнне шатланып уйныйсың, малайлар алдында мактанасың — бәйрәм итәсең. Ләкин бу бәйрәм озакка сузылмый, уенчыгың йә ватыла, йә аннан туя башлыйсың, ул инде тегендә-монда сөйрәлеп йөри, карала, уңа. Ә әниемнең назы, мине сөюе бервакытта да бетми. Ананың балага булган мәхәббәте чиксез ул! Күп сөйләшергә яратмаган, эченә йомылып яшәгән этием исә бу яктан бик саран. Ләкин мин этине хәзер аңлыйм инде, моның өчен аны гаепли дә алмыйм. Тумыштан ук килгән холкыннан, килеш-кыяфәтеннән һәм бигрәк тә физик житешсезлекләреннән тыш, аның эчтән кичеренеп яшәргә бүтән сәбәпләре дә булгандыр, дип уйлыйм.

Әле без чынын әкияттән, әкиятне чыннан аера алмаган чакларда ук безгә «Ванька-встанька!»лары белән кәмит ясаучы Сирай абый хакында мин бер-ике мәртәбә алда исегезгә төшереп киткән идем инде. Сирай абый эре дулкынлы чем-кара чәчле, карасу йөзле буйчан кеше булып, телгә дә бик оста һәм бик мут бер кеше иде. Өстәвенә ул бер дә төшеп калганнардан түгел, киресенчә, бик булдыклы ир-ат булып хәтердә калган. Әйтергә кирәк, сугышка хәтле булган еллар бик романтикалы, үзенең яңалыклары белән һаман саен күңелләрне дәртләндереп торган еллар булса да, бу елларның юклык белән җәфа чиктергән караңгы көннәре дә бихисап иде. Сирай абый эше буенча атналап-атналап, ә кайвакыт айлар дәвамында командировкаларда йөри һәм һәр юлында диярлек районнан сарык түшкәләрен алып кайтып тора иде. Без дә ансы бу яктан алай ук ким-хур түгел. Әниенең уңган кулы пәрәмәч, сумса ише ризыкны пешергәләп тора, алары булмаса, картаның да иен китереп, бәлешләр салгалый. Ләкин кытлык елларда булдыклы күршеңнең сарык түшкәләрен ташып торуы бу инде инәң белән чокчынып, кеше киеменең тузанын исни-йөта тормыш итү түгел шул. Монысына да өстәп, Сирай абый этине гел ирештереп тора, этигә карата мәзәк бер сүз әйтеп тә, этинең җавапсыз калуыннан юри кычкырып көлгән сымак була иде.

Сирай абый безгә үзенең якташы, шулай ук Рузаевка ягы мишәре Каюм исемле кешене ияртеп кергәли иде. Каюм абыйның егет чаклары узып барса да, ул ифрат чибәр кеше. Буйга Сирай абыйдан да калкурак. Матур итеп ятып торган куе бөдрә чәчләре кара һәм, менә шушы каралык белән капма-каршы төстә, ап-ак йөзе сузылып — очлаеп төшкән. Аның иреннәре дә кыз балаларныкы кебек сызылып кына киткән, һәм бу бөрлегәндәй кызыл иреннәр Сирай абыйның тиктормас авызы шикелле түгел, алар сабыр гына, хәтта оялчан гына булып сөйләшәләр кебек. Ләкин Каюм абый оялчан гына, сабыр гына сөйләшүләрен кул ишарәләре белән тутыра һәм жанландыра төшә сыман. Ул житкән кызларныкыннан да озын ак бармаклары белән күпереп торган бөдрә чәчләрен аралап артка сыпырып куя, ә кайвакыт, кирәгрәк сүзне сайлап әйтә алмыйча торганда, әнә шул бик жыйнак нәфис кулын артистлар кебек, һавада сыгылдырып изәп куя.

Шәмси апа Газиз жизни белән Әстерханга киткәч, әнием Жиһан апа исемле яшь кенә бер тол хатынны үзебезгә квартирга керткән иде. Жиһан апаның миннән өч-дүрт яшькә кечкенә Рәүф исемле малае булса да, бу малай бездә сирәк күренгәли, ул Тау якларындагы бер авылда бабасы тәрбиясендә яши иде бугай. Жиһан апаның әле яңа гына авылдан килеп эш тә, фатир да таба алмыйча йөдәп йөргән чаклары булып, әни менә хәзер аны үзебезгә өйрәтә икән, аңа үзе эшли торган мех комбинатына эшкә урнашырга ярдәм дә иткән иде. Әни дә, мин дә Жиһан апа белән бертуганнар кебек бик тиз якынлашып киттек. Жиһан апа Рәүфне бик сагынган чакларында мине үз улыдай күреп, алдына утырта һәм мине назлый-иркәли торган иде. Ул биткә әллә ни чибәр булмаса да, аның карасу шома йөзеннән үзалдына якты нур бөркелеп тора иде. Ул эрерәк сөякле бик таза хатын иде.

Әниемнең, бик зурдан купмыйча гына, чәй мәжлесе уздырганы истә калган. Без, Ринат белән бер кат тамак ялгап алганнан соң, почмакта нәрсәдер ясарга тырышып кайнашабыз. Әтинең әйтүенә караганда, Семипалаттан ук ияреп кайткан кечерәк өстәл тирәсендә әти үзе, Каюм абый, Ринатның әнисе Ниса апа, аннары бирге якта Сирай абый утыралар. Әни табада чыжлатып, бавыр белән дөгедән микән инде, пирожки пешерә. Жиһан апа аларны кунаклар алдына ташый. Өстәлдә пар бөркеп самавыр утырса да, табын әле өлгереп житмәгән һәм кунаклар уен-көлке сөйләп шау-гөр килеп утыралар иде. Менә шунда, Жиһан апа тәлинкә белән пирожки ташыганда, Сирай абый, өстәлгә яны белән борылып, эре бәдәнле яшь хатынга күзләрен тондырып карап тора башлады. Жиһан апа мул күкрәкләре белән тулы балтырларын селкеткәләп нык-нык атлап йөри, Сирай абыйның майлы күзләре исә өйдәшебезнең килеш-килбәтен күзәтә. Жиһан апа моны сизеп алып бөтен инен-сыннарын юрамалый биетеп йөри башлагач, Сирай абый түзмәде, гадәттә балыкчылар шундый балык тоттым дигән вакыттагы ишарәне ясап:

— Их! — дип башын селкеп алды. Табындагылар кычкырып көлешкән кебек булсалар да, Каюм абыйның ак йөзе бердән алсуланып китте, ул хәтта оялуыннан башын иде. Каюм абый яшь чагыннан ук Казанга килеп, минем жизни кебек, шоферлыкка өйрәнгән. Ләкин гомер буе рәссам булырга хыялланган Газиз жизни, полуторкадан ЗИСка күчсә дә, шоферлык өлкәсендә артык еракка китәргә теләмәгән. Ә Каюм абый исә, полуторка, ЗИС дигән баскычларны да узып, беренче класслы шофер булып, ул көннәрдә ялтырап торган жинел машинада бер зур заводның директорын йөртә. Ләкин ул, үзлегеннән укып, инженер-механик та булмакчы икән әле.

Ләкин безнең сүз, Каюм абыйдан бигрәк, аның артык дәрәжәдә кылтайчык һәм гарьсез якташы турында иде бит һәм Каюм абыйны искә алуым да аның, бик нәфис чибәр булуы өстенә, гаять дәрәжәдә

инсафлы һәм башы-аягы белән интеллигент булуына соклануыбыздан гына иде.

Хәер, Каюм абыйның әтиемә бәйле рәвештә бер эше дә булды булуын. Сирай абый аны бер мәртәбә безгә алып кергәч, ул әтидән машина радиаторы өчен җылы чехол тегеп бирүен сорады. Әтинең мондый нәрсәне гомер эчендә теккәне булмаса да, ул Каюм абый кебек мөрәвәтле кешенең үтенечен кире кагарга базмады. Бер мәртәбә, кышкы зәмһәрир суыкта, моның кара машинасы ишегалдыбызга чаптырып кергәч, әти аның капоты тирәсендә әйләнгәләде, карандаш белән кәгазьгә сызыклар сызгалады.

Ниһаять, әти кара дермантин белән астарлык арасына калын гына мамык түшәп, сыра-сыра чахолны тегеп чыкты, радиатор алдына кигезеп кую өчен, ана ниндидер колаклар ясады, тасма җепләр такты. Чехол әзер иде, машинага хәзер суык та тимәс, төчкермәс тә ул. Ләкин Каюм абый аны алырга килгәч, Сирай абый әтиемнең эшен һәрьяклап хурларга тотынды, бернигә ярамый бит бу, диде. Әтинең саргылт чыраена да кызыллык йөгергәндәй булды, ә чигә тамырлары исә типкәндәй итеп тагы да бүртеп киттеләр. Әти белән Каюм абый тышка чыгып чехолны радиаторга кигезеп карадылар: ул матур гына кереп утырган, колаклары да әйбәт кенә кигезеп куелган иде. Каюм абый кешенең хезмәтен санга санап әтине мактап куйды, рәхмәт әйтте. Инде өйгә кергәч, исәп-хисапны өзмәкче иде, әти бәясен әйткәч, Сирай абый тагын аркылы төште:

— Бу нинди комагайлык, юк эш өчен шул хәтле сорамасаң! — дип, әтине тагын яманлый башлады. — Төш әйдә бераз! — диде.

— Сон, төшсәм, материал расходын да капламый бит, — диде әти теләр-теләмәс кенә. — Болай да инде мин теккән өчен алмыйм.

Каюм абый итагать белән генә дәшеп:

— Мирзагаллэм абый, сез аның сүзенә ышанмагыз, шаярта гына ул, — дигәч, Сирай абый башларын калтырата-калтырата озак кына көлеп торды.

Каюм абый тагын бер кат рәхмәт әйткәннән соң алар чыгып киттеләр, өстәлдә әти сораганнан да артыграк кәгазь бишлекләр калды. Әти аларга тимәде. Моннан соң ул тагын да йомылыбрак йөрде.

Әни аны:

— Җебегән, ичмаса эшләгән акчанны да ала белмисең бит! — дип орышты. Бу юлы минем дә Сирай абыйга ачуым килгән иде. Ничек инде, әтием бөтенләй дә булмастай эшкә тотынды, кәгазьгә машинаның мангаен — радиатор тирәләрен, хәтта фараларына хәтле ясап куйды, шул рәсемгә карый-карый дерматин өстенә сызымнарын, үлчәүләрен томырды, «Зингер»ында матур күпертмәле итеп буй-буй сырып чыкты. Инде Каюм абый, бик нәзакәтле, гыйлем иясе кеше үзе ягымлы тавышы белән рәхмәт әйтте, кызларныкы шикелле озын чуклы, ләкин бик олы кулы белән әтинең зәңгәр тамырлары беленеп торган сөякчел кулын йомшак кына итеп кысты һәм шуннан соң да мыскыллап торсын бу Сирай абый әтине. Ничек түзмәк кирәк мондый хәлгә?

Малайлар арасында ачу килгән чакта әйтә торган сүзләребез бар иде безнең. Мин нәрсә әйтим икән моңа дип уйлап тордым да: «У, кәбәй, у, маем!» дидем. Аннары янә үзалдыма нәфрәтем кайнап: «У, мишәр, борыны белән боз тишәр!» дип өстәп әйтеп куйдым. Шуннан үземне җиңеләеп калгандай хис иттем.

Ләкин бу вакыйга бер дә онытылмады, тормышның кечкенә генә булса да бер фәлсәфәсе булып күңелемә сеңеп калды. Кайберәүләргә йомран кебек өенә бөтен нәрсәне ташырга ярый, ә кайберәүләргә хәләл көчен белән эшләп алган хезмәт хакыңны да алырга ярамый. Житмәсә синен

өстеннән көләләр, сине адәм мәсхәрәсенә калдыралар һәм син шуна, әти кебек башынны иеп, риза булып тор. Юк, болай яшәргә ярамый! Ярамый да бит... Минә әти белән әни мине һаман уйландыра бара. Нигә тыныша алмыйлар алар бер дә? Мин, карточкадан карап, әтинен дә ярыйсы гына спай, күренекле чакларын беләм. Ул фоторәсемгә озын чалбар, матур гына пиджәк киеп төшкән, үзенең буе да озын. Башына каракүлдән теккән кырку бүрек кигән. Ә борын астында төртеп куйган кебек кенә бәләкәй дүрткел мыегы бар. Әллә ни зур булмаган түгәрәк күзләре белән тыныч кына карый. Бу анының беренче Бөтендөнья сугышыннан бик алҗып-авырып кайтып авылда бер кат тернәкләнеп, тазарып киткәннән соң төшкән рәсеме. Аннан инде ачлык елы башлана. Монда инде кешеләрнең рәсемгә төшәрлек бернинди кыяфәтләре калмагандыр. Кая инде, ачтан үлүчеләрне җиргә тапшырырлык хәлләре дә булмаган. Менә шундый кыямәт көннәрендә әти халыкны эшелонга туплап, үзе исә шул эшелонның начальнигы булып ерак казакъ җиренә юнәлгән. Күрәсең, тегүчеләр дә ул вакытта төшеп калган кешеләрдән булмагандыр.

Инде бер-бер артлы балалары, ягъни минем туган апаларым үлгәннән соң Казанга кайтып төшүләр. Нәрсә, әтинен кояш батышы булганмы бу. Әни исә моңлы, тулы ай булып калка башлаганмы?

Әйе, тегүче хатыны да булгач, әнинең дә тегү эшенә кулы ятып торган, ул мех комбинатына кисүче булып эшкә кергән. Безгә анын таныш-белешләре, шулай ук күрше-күлән дә мех яки иләнгән тиреләрен күтәреп йә пәлтә якасы, йә ул вакытта бик модада булган «манто» кистерергә керәләр иде. Әни тирене йон ягы белән өстәлгә каплап җәеп сала да, кәгазь өлге буенча башта акбур белән сызымын сыза. Аннары бармакларын, чеметеп кенә тоткандай, шул сызыклар өстеннән бик тиз йөртеп ала һәм тире үзалдына аерыла бара. Моны ул, фокусчы кебек, шундый оста эшли, гүяки ана бармак очын мех өстеннән күз ачып йомган арада йөртеп алу да җитә. Ләкин мин анын ике бармак арасына өчпочмак сыман кечтеки генә пычак кыстырылганын беләм. Ул әнә шул күзгә дә күренмәслек тылсымлы пычагы белән мехны кыеп кына бара.

Әни үзенең осталыгы белән комбинатта макталуга да ирешкән күрәсен, чөнки ул еш кына «премия» дигән сүзләрне дә әйтә. Шуннан инде мина ялтырап торган яна ботинкалар кайта, ефәк бизәкләр катнаштырып тукылган ак яки зәңгәр күлмәклек кайта. Әни үзен дә өлешсез калдырмый. Инде ул вакытларда ситсыдан башка «мая»лары, «маркизет»лары чыга башлаган иде. Әни матур күлмәк кияргә ярата, ул үзенә чуар маркизеттан күлмәкме, сарафанмы тегеп ала да, аны кигәннән соң зәңгәр күзле бик матур күбәләккә охшап кала. Үзе дә шатлана, мин дә шатланам моңа. Ләкин өйдә нәрсәдер җитешми, өйдә уртак шатлыгыбызның ямен җибәрерлек нәрсәдер бар кебек.

Кечкенә чакта кешеләр арасында килеп чыккан низаг сәбәпләрен аңлап бетерә алмыйсың. Ә инде әни белән әтинең бер-берсен күрәлми яшәве баланы бөтенләй аптырашта калдыра. Ни генә димә, әти дә мина бик якын кеше бит инде, чит-ят адәм түгел. Әнине инде әйтәсе дә юк, ул минем өчен бик газиз. Ничек инде менә үзем яраткан шундый якын кешеләрем бер-берсе белән тату гына яши алмыйлар, бер-берсен кадерләмиләр — бу минем һич кенә дә башыма сыя алмый иде. Инде менә хәзер үзем олыгайгач, балачагым күптән инде томанлы еллар эчендә күмелеп калгач та мин әти белән әнинең сугышыр дәрәҗәгә җитүләрен уңайсызланып кына, хәтта сыкранып кына исемә төшерәм. Сугышыр дәрәҗәгә җитәләр иде дип, бу сүзләр гомумән тешемә тигәнгә, йомшарта төшеп әйтүем ул. Чынында исә алар чынлап та сугышкалыйлар иде. Нарасый чакта арт күмәченә

аз гына чәпәп куйсалар да үкереп елыйсың, сиңа кул тигезгән кешегә үпкәлисең. Димәк, авырту белән гарьлек хисе кечкенәдән үк барлыкка килә. Менә шундый хисләрне үзеңдә тоеп торгач, әле әтигә, әле әнигә төшкән йодрыкларның, яки бер-берсенең чәчен йолкуларның алар өчен гадәттән тыш җәбер-золым икәнлеген ничек инде аңламыйсың?! Мин әнинең дә, әтинең дә кыерсытылуын, рәнҗетелүен теләмим, кулымдагы матур уенчыкларны да ташлап тиз генә аларның арасына керәм, әле әнинең итәгенә ябышып, әле әтинең тезенә сарылып үкерә-үкерә елыйм. Ләкин алар кызган, һич туктый алмыйлар, минем барлыгымны да тоймыйча ялгыш этелеп үземне тәгәрәтеп җибәрәләр. Мин тагын идәннән сикереп торып, әле берсенә, әле икенчесенә чытырдап ябышам. Минем инде хәзер иңәлеп кычкырудан тавышым беткән, мин тамак төбем белән сызгырып үксим генә һәм инде бер очып киткән жиремнән тора да алмыйча, чалып ташланган малдай, калтыранып ятам. Шуннан мин, һушымны югалткан хәлдә, бик озак йокыга талам. Бик йомшак куллы «берәүнең» мине түшәккә алып салуын да тоймыйм һәм түшемдә дә үкси-үкси сискәнгәләп ятам.

Кайвакыт йолкынган пәрдәләр, ауган өстәл-урындыклар берничә көн буена шулай тәртипсез хәлләрендә ята бирәләр. Урындыкларны утыртып куйсам да, өстәлне бастырып куярга хәлем җитми һәм мин, өстәлгә барып ябышкан килеш, әтиемә тилмереп карап торам. Шуннан ул яныма килеп, бер кәлимә сүз дә катмыйча, миңа «булыша» башлый.

Менә шундый хәлләр туып, берничә мәртәбә һушым алынганнан соң, миңа нерв авыруы белән түшәктә ятарга да туры килде. Бу инде әти белән әнинең соңгы баладан да язулары мөмкин дигән сүз иде. Шуннан алар кинәт кенә тындылар, бүтән бер генә дә якалашмадылар. Әмма алар арасындагы киеренкелек моңа карап кына кимемәде. Ләкин әти хәзер инде әнидән күбрәк дәшми калуы белән үч ала иде бугай. Дустым Ринатның әнисе Ниса апа да ни өчендер аны кызыштырып карагач та, ул өшеткеч бер битарафлыкта кала бирде.

Безнең йорт каршында Ат тавыннан бераз сулгарак яр башына бүрәнә аяклы сузма эскәмия утыртылган иде. Аннан түбәнрәк, перевозга алып төшүче баскыч читендә бер каен агачы да үсеп чыкканга микән, аны безнең тирәдә кызлар эскәмиясе дип атыйлар. Бу бер яктан сәер, ләкин янәшәдә генә су читләтеп бик биек тирәк егетләренең тезелеп киткәнен искә алсак, әлеге ялгыз каенның шәрә ак тәнен һичничек яшерә алмыйча оялчан гына басып торган бер чибәркәйгә охшавына, аңа карап эскәмияне дә кызлар эскәмиясе дип әйтүләренә бер дә гаҗәпләнәсе түгел. Инде монысына да ышанып җитмәсәләр, икенче дәлил дә бар: безнең күршебездә генә сары төстәге таш йорт ишегалдында эшче яшьләрнең тулай торагы урнашкан. Андагы кызлар кичләрен яр башында әйләнгәләп йөриләр дә шушы эскәмиягә килеп, кайсысы бөдрә чәчтәй чукларын кичке җилгә селкеткәләгән каен агачына, кайсысы сер һәм моң тулы Кабан өстенә күзләрен төбәп, башларын акрын гына як-якка чайкаттырып, авыз эченнән генә диярлек җырлыйлар.

Әлеге кызлар эскәмиясенә, командировкадан кайткан чакларында, Сирай абый да чыккалый. Ләкин ул чыкканда кызларның ямансулаулары бетә, Сирай абый аларны туктый белмәс авызына каратып берәр мәзәк сөйли һәм кызлар, дәррәү көлешеп, үзләренең көмеш чыңнарын күл өстеннән еракка ук тәгәрәтеп җибәргәндәй булалар. Ләкин кызларның күңелле авазы, Сирай абыйның исә, казлар арасындагы ата каздай чаңгылдап куюлары бер кешегә ошап бетми. Йортыбызның күл ягындагы тәрәзәсеннән тавыш ишетелә:

— Сирай, баланы уятасың, тора салып кычкырма!..

Яки:

— Кызлар, куып кертегез әле шул абыегызны, баласы жылый!..

Ләкин кызлар тынып торалар да, Сирай абый нәрсәдер әйткәч, тагын күл өстен янгыратып, көлеп жибәрәләр. Кайвакыт Ниса апа эскәмия янына Ринатны чыгара. Ул:

— Эти, эти, — дип, фәлән-фәсмәтән, дип чатанлый-чатанлый анын тирәсендә тулгана, ә үзе башын тәрәзәгә борып карап куя, анда исә: «Шулай, шулай, улым», — дигән төсле, Ринатны хуплап, Ниса апа кулын кагыштырып ала.

Шуны да искәртү кирәктер, бу вакытта Ниса апаларнын икенче балалары да үсеп килә. Радий исемле кече малайлары инде бишектән төшсә дә, тәпи басмаган әле, әмма үрмәләп йөреп тә өйдәге бөтен нәрсәне кырыштыра торган бик тере малай иде.

Ниса апа тәрәзәдән сөрән салгалап та кызларны тыя алмаса, бигрәк тә Сирай абыйны туктата алмаса, ул үзе Радийны күтәреп эскәмиягә чыга. Ул:

— Ягез әле, кызлар, тыгызлана төшегез, — дип арага кереп утыра да ни өчендер кинәт кенә елый башлаган Радийны (әллә чеметеп куя инде) тез өстендә тыпырдатып яки куенында селкеткәләп юатырга керешә һәм күзләрен челт-челт йомгалый. Кызларны сыпырып алгандай була, алар башларын ия-ия, учларына пырх-пырх көлешеп, тулай торакларына таба сызалар.

Минем әни кызлар эскәмиясенә бик сирәк чыга. Ул анда, тын калып, берүзе генә утырырга ярата. Ләкин әрсез Сирай абый барында ялгызын гына ял итеп утырып буламыни?! Ләкин Сирай абый әни чыккан көннәрне мәзәк сөйләп хахылдамый, ул ни өчендер чыш-пыш килә. Һәм эскәмиягә дә мәче кебек сак кына атлап килә, үзенчә сиздермәскә тырышып, мыштым гына утыргач, әни аны танып алганнан сон дерт кенә селкенеп куя һәм шундук кузгалып китә. Бөтен йөрәгемнен теләгәненә юш килеп, әниемнен өйгә таба менеп китүен күреп торсам да, барыбер ул мина су буенда басып калгандай тоела. Кай тарафкадыр атлап киткән Сирай абыйнын тонган күзенә ул чалынмый әлбәттә, аны мин генә күнел күзем белән күрәм. Минем әни дә, модадан бик калышасы килмичә, чәчен кистергән. Ләкин ул, бүтән хатын-кызлар кебек, муенын артык ялангач итмәгән.

Киресенчә, анын чәчләре жилкәсенә үк төшеп озын ак муенын ышыклап тора. Үзе дә ак чырайлы, төз аяклары да ефәк оек аша да беленерлек ак булганга мин аны әлеге каен кызына охшатам. Ул күлдәге шәүләсеннән аерыла алмагандай нишләп шулай зәнгәр күзләре белән монсырап басып тора икән?

...Көннәрдән бер көнне, Кабан аръякларыннан актарынып ага-ага кара болытлар килеп чыкты да, кинәт кенә чыбыркы шартлаткандай итеп, утлы тырнакларын ак каен башына сузды, ул да түгел, каенны ялкын чолгап алды, анын ботак-яфраклары четердәп яна башлады. Янгыр коярга керешкәч тә ул әле дөрләп китеп, әле сары төтеннәрен бөркеп, озак кына көйрәп утырды.

Икенче көнне чыгып карасак, куе тармаклардан бер-ике кисәү генә калган, ап-ак кәүсәсе төтенгә саргаеп беткән...

Әйе, сүз күршебез Ниса апа турында иде бит әле. Көн белән төн бер-берсеннән аерылып торган шикелле, кешеләрнен йөзләре дә якты һәм карангы чырайлы булуы белән аерыла икән ул. Өстәвенә Ниса апа күзләрен челт-челт йомгалап ала. Ул гадәтенчә бик житез хәрәкәтле булса да, өйдәге эшләрен бик кызу башкарса да, кайвакыт туктап кала, ике кулы да салынып төшә һәм ул үзалдына каранып озак кына уйланып тора. Ул әни фабрикада чагында еш кына безгә кергәли. Әти төнгелектән кайтып гырылдап йоклап ятса да, хәзер инде анын бу йокылары да кача башлады. Әти белән Ниса

апа күздән-күзгә генә сүз алышкалыйлар, ә кайвакыт ым кагып кына сөйләшәләр. Колагыма командировка дигәннәре генә чалынып кала. Ләкин Ниса апа әтинең сансызлыгын күреп, аны һәр юлы орышырга керешә:

— Син ир кеше бит! — ди. — Ничек инде моңа түзеп торасың. Сыер уҗымга кергәч, аның сыртын әйбәтләп каезлыйлар. Ә синең чыбыркы шартлатырга котың алынып тора! — ди.

Ниткән сыер, ниткән уҗым тагын бу? Һич сүзләре башыма сыймый. Аннары ни өчен әле Ниса апа безгә бик ешлый башлады? Менә шулай ул әтине төрткәли торгач, бер көнне әти биленә алъяпкычын бәйләп, кечкенә табада йон киләбен күбекләндерә-күбекләндерә юып торган әниемнән сорап куйды:

— Сирай да Мамадышка бардымыни?

Әни дәшмәде. Кинәт аның зәңгәр күзләрен Идел томаны каплап алгандай булды, ак матур яңагы калтырагандай итте.

— Бәлки ул Ушмыга ук бармагандыр? — дип әти янә тәкрарлап сорады.

Бу юлы әни дымлы керфекләрен сирпеп алды да:

— Барса соң, һәркем синең кебек йоклап гомер уздырмый бит, эше булгандыр... — диде.

— Алайсам, Ниса дөрес әйткән икән, — дип, әти алга чыгыбрак торган ябык ияген учлап торды: — Дөрес икән, дөрес... — дип сүзен кабатлап куйды.

Ул бөтенләй бөкшәеп киткәндәй булды. Миңа әйләнеп карады. Әтинең дә күзләре күгелҗемрәк иде, ләкин кургашын төсенә якынрак күгелҗем иде. Һәм хәзер менә бу күзләр, агы да, күгелҗеме дә бергә кушылып бөтенләй үк төссезләнеп киткәннәр һәм ялтыравык пыяла сымак җансыз гына карыйлар шикелле иде.

— Беләсеңме, анаң кем синең? — дип акрын гына миңа дәште әти.

— Кем?! — дип, эшеннән туктап калды әни, күбекле кулларын алъяпкычына сөртте. Аның ике каш арасындагы бәләкәй генә аркылы сызыгы тирәнәеп киткәндәй булды.

— Нигә соң алайса синең артыңнан Мамадышка барган? Нигә? — диде әти, башын чак кына калтыратып. Аның пыяла күзләре хәзер дәррәү эрегәндәй, аларга җан кергәндәй булды.

— Үзеннән сора йөрәгең житсә, үзеннән! — диде әни һәм, көтмәс жирдән, йон киләбен таздан алып, әтигә тондырды.

Йон киләбе әтигә тимәде, лач итеп минем аяк астыма килеп төште. Мин:

— Әни!!. — дип өзгәләнеп кычкырдым да чытырдап аңа барыпябыштым.

Ул, башымны күкрәгенә кысып, аркасын калтырата-калтырата, еларга кереште.

— Үтте бит гомерем аягүрә йоклаган шушы хөрәсән белән! Авызына капканны да йота алмаган бәндә белән!.. — дип бик озак елады әни мине кочагыннан жибәрмичә.

Нишләп әни дөресен әйтмәде икән, югыйсә Сирай абыйның Ушмыда үзе түгел, эзе дә булмады бит. Һәрхәлдә әнием мине ташлап беркая да китеп йөрмәде.

Ниса апалар белән безнең ара бу вакыйгадан соң бик каты суынды. Өлкәннәрнең бер хәл, Ринат та миңа дәшми башлады, әнисе аны безгә кереп йөрүдән тыйды. Шуннан инде мин дә аларга керми торган булдым.

Малай чакта юк кына нәрсәдән дә ызгышып китә торган буласың. Әле Ринат белән аралар өзелгәнче үк, әтисе аңа күн тышлы туп алып биргән иде. Ул кул тубы, ягъни волейболныкы булса да, малайлар аны шундук

футболныкына әйләндерделәр. Мәктәп белән йортыбыз арасында, тузанлы урам уртасында туп тибеш китте. Без дүртме, бишме кешедән торган ике төркем булып тупны үзебезнең капкабызга кертергә тырыша идек. Ә анда һәрвакыт капкачы булып бирәр бот буе малай тора, чөнки берәүнең дә капкага басасы килми, ялан аяк булсаң да үзеңне чып-чын бутыйлар кигән атаклы футболистай хис итеп туп тибәсе килә.

Безнең өчен иң куркыныч уенчы — җирән башлы Хәким иде. Аның ут кебек йөгереп йөрүе бер хәл. Ул туп өчен тартышканда бөтен кагыйдәләрне боза, аяк та чала, этеп тә ега, туп капка баганасына бәрелеп кире чәчрәсә дә, керде, капкага керде дип ант итә. Алар командасына көндәш якта да булгач, аңа каршы уйнавы минем өчен бик кыен, мин аның җиленнән дә егылып китә яза идем. Ләкин без нәкъ шундый хәрәмчеләргә каршы уйнап әрсезләнергә дә өйрәндек. Мәсәлән, бу уен вакытында да Хәким үзенең камырга охшаган зур көпшәк гәүдәсе белән мине бер якка сөзеп җибәрәм дигәндә генә мин кинәт бер якка тайпылдым һәм ул шунда, аяк-кулларын җәеп, лап итеп җиргә килеп төште, киемнәрен әйтәсе дә юк, ул бите белән дә тузанга капланды, хәтта авызына кергән комнарын төкереп торды.

Минем бернинди гаебем булмаса да, безнең якка штраф билгеләделәр. Бары үзебез уйлап чыгарган кагыйдә генә иде микән инде, ул вакытта кем гаепле булса, шуның үзен капкага бастырабыз, ә инде егылганмы, имгәнгәнме — малай моның җәзасын бирә — капкага пенальти тибә иде.

Мин бер сүз дә әйтмичә, карусыз гына, капкага килеп бастым. Ә миннән унбер адым алда Хәким тупны җиргә куеп, авызын кыегайтып, көлемсерәп тора. Менә ул акрын-акрын артына чыкты да, кызыл башлы үгез кебек тупка томырылды, сул тезен бераз бөгә төшеп, минекеннән ике мәртәбә диярлек зуррак уң аягы белән тупка китереп типте. Гүяки ялкын кебек җирән кара баштан бер кара баш аерылып китте дә, миңа таба ракета шикелле очып килә башлады. Ул капканың сул ягынарак, футбол телендә «девятка» дип аталган почмагына очып килә иде. Минем белән шулчак гаҗәеп бер хәл булды. Мин, ике аягым белән үземне җирдән этеп җибәргәннән соң, гүя гәүдәмнән аерылдым. Үзем дә, ике кулым белән ике күзем генә калгандай булды. Менә теге кара баш сул ягымдагы һавадан сызгырып очып бара кебек инде. Ул ике күземне дә көчле магнит кебек үзе белән ияртеп алып китмәкче. Менә ул аларны суырып алам дигәндә генә, алар мизгел эчендә күзгә күренмәс бик нечкә җепләре белән ток йөгерткәндәй миңа хәбәр иттеләр: «Тиз бул, кулыңны суз!» — диделәр. Мин кичекмәстән ике кулымны да сузып баш очымнан узып барган кара тупны бармакларым белән кармак кебек эләктереп алдым да аны шундук пәйда булган эчемә таба йомып сул як башым белән җиргә килеп төштем.

«Песием, песием, перес!» дигән уенны беләсезме икән сез. Өстәлгәме, сәке өстенәме кулыңны җәеп куясың да, икенче берең: «Песием, песием» дип сыпыргандай булып кинәт: «Перес!» дип кул сыртына китереп суга. Ләкин уенның хикмәте дә шунда — бик уяу булып кулыңа суктырмаска, аны суккан чакта тартып алырга кирәк. Ул вакытта инде синең белән уйнаучының кулы тактага чап итеп килеп төшә.

Әлеге кара туп үзе миңа сугарга дип очып килсә дә, мин аңа, таштай булып тоелган каты тупка үзем китереп суккандай иттем, учларым ачытып авырту гына түгел, бөтен сөякләрем янгырап киткәндәй булды, күз алдымда очкыннар бии башлады һәм мин сыным катып җирдән тора алмый яттым. Ярый әле шунда йорт чатындагы балконда безнең уенны тамаша кылып утырган Нурия:

— Иһи-һи, кертә алмады, иһи-һи кертә алмады! — дип чыркылдап көлеп җибәрде. — Шулай була ул хәрәмләсәң, шулай була!

Мин җирдән торып, тупны кулым белән акрын гына тәгәрәтеп җибәрдем

һәм уен янадан башланып китте. Минем әле дә учларым әчетә, ә янбашым үтереп сызлый иде, шуңа күрә артык хәвәсләнеп уйный алмадым. Шулай да тора-бара гәүдәм язылып китте һәм мин тагын Хәким тирәсендә буталып аның аяк астындагы тупны гел диярлек алып тордым. Аның миңа ачуы килде: «Ах, чебеш!» — дип уен арасында ысылдап та куйды. Хәкимнең малайлардан үч ала торган янә бер ысулы бар, ул туп белән сиңа китереп тибә. Эчеңә тисә, бөгәрләнеп кенә төшәсең. Яки тупка битеңне сыдырасың. Тагы да яманы — маңгаеңа тия күрмәсен, андый чакта һушыңны да югалтасың. Ә Хәким һаман саен минем башны чамалый, үзара килешү буенча тупны өскә чөйдерергә тиеш булмасак та, аны гел югары күтәртә. Менә бервакыт ул, уенның тузаннар тузып бик кызган бер чагында, тупка каты гына китереп типкәч, ул минем колак төбемнән генә выжылдап очып китте. Шул минутта ук чылтырап пыяла коелган тавыш ишетелде. Туп, мәктәп тәрәзәсенә бәрелгәннән соң, биек рәшәткә белән ике арага сикереп төште.

Ул да түгел, Хәким:

— Чебеш типте! Ул ватты! — дип кычкырып җибәрде.

— Нәрсә ялганлыйсың! — дидем мин, ачуымнан буылырга җитешеп.

— Син шул, чебеш, син! — диде Хәким, күзен дә йоммыйча.

Алма кебек кызарган, тирләп беткән Илдус, өске каттагы аксыл керфекле күршебез, мышнап килеп:

— Ул түгел, син! — дип әйтеп караган иде, Хәким аны шундук артка сыпырып җибәрде.

Мин бик өзелеп, тирән өмет белән балконга күтәрелеп карадым. Ни үкенеч! Кирәк чагында гына Нурия балконнан югалган иде.

Гадәттә ялгышып берәр тәрәзәне ватсак, малайларны шундук урамнан себереп ташлагандай була, минут эчендә качып бетәләр, чөнки пыяла ул заманда үзе бер кыйммәт булса, аны куйдыру үзе бер дөнья бәһасе тора иде. Ләкин бу юлы малайлар нишләргә дә белми аптырашып калдылар. Аларны рәшәткә артындагы туп тота иде. Минем бу рәшәткәдән үрмәли-үрмәли әле кичерәк чагымда ук өр-яңа чалбарымны ертканым бар. Хәзер инде аның аша сикереп төшү миңа берни тормый иде. Һәм мин шулай иттем дә. Ләкин мин киредән сикереп төшәргә өлгерми калдым. Мәктәптән киң каеш буып, яшел төстәге гимнастерка кигән, сыйракларына тар кунычлы хром итек тарттырган кызыл чырайлы завхоз йөгереп чыкты да, минем үземне дә, тупны да эләктереп мәктәпкә алып кереп китте. Мин аннан, тәрәзә пыяласын куйдыру шарты белән бик тиз чыктым чыгуын, ләкин тупны залогка дип алып калды.

Ринат дустымның да:

— Кара аны, тубым югалса, шундый ук яңасын алып бирәсең, — дигәч, мин аның сүзенә бик гарьләндем. Димәк, ул да тәрәзәне мин ваткан дип белә.

Безнең борын бу вакытларда олылар арасындагы кайбер мөнәсәбәтләрне сизенә башлаган иде инде. Ниса апаның минем әнине ни өчен каһәрләгәнен, әтинең Сирай абыйны ни өчен бер дә яратмаганын без икебез дә аз-маз тойгалыйбыз һәм монда безнең бернинди катышыбыз, печтек кенә гаебебез булмаса да, ниндидер бер эчке закончалык безне, ике дусны, ерагайта бара иде кебек. Чөй өстенә тукмак дигәндәй, туп вакыйгасы да килеп туды. Әни тупны икенче көнне үк алып чыгып бирде, әлбәттә, ул штраф түләгән булса кирәк, ләкин ул аның гаиләбез капкасына нинди авыр «пенальти» булганлыгын миңа сиздермәде, бары тик:

— Саграк уйнарга кирәк, улым, — дип башымнан сыйпап кына куйды.

Ичмаса бер каеш белән сыдырсын иде, орышсын иде, юк шул, алай итмәде. Шулай да аның ягымлы тавышын, кисәтүен мин бик зур шелтә итеп аңладым. Малайларга, бигрәк тә Ринатка ачуым ташыды, урамга чыктым да:

— Мә, башына капла! — дип тупны Ринат өстенә аттым. — Мамадышка командировкага барган өчен авызыңны майладыңмыни?! Сыймый бит ул авызга, — дип көлеп тә куйдым әле мин.

Ринат читкә сикергән тупны чатанлый-чатанлый барып алды да, яныма килеп, туп тотмаган буш кулы белән миңа селтәнде, ләкин сукмый калды. Ләкин аның зур кара күзләре ут булып яна иде. Шундук безнең тирәбезгә Хәкимнәр, подвал Рәшитләре һәм котыртырга бик яратучы Фәһим йөгереп килеп життеләр:

— Сук берне, Ринат!

— Син дә авызыңны ачып торма, Чебеш, чукып ал үзен! — дип кызыштырдылар алар безне.

Ә Хәким, казый кебек:

— Тик, егетләр, монда түгел, койма буенда! — диде һәм безне иңнәребездән кочаклагандай итеп арткы капкадан гына алып чыкты да, яр башындагы коймага ияртеп китте.

Бу Әхтәмов урамының Кабанга килеп терәлгән башы булып, нәкъ шушы тирәдә текә яр өсте бер уелып куя, акрын гына сөзәгәя барып су читенә килеп тоташа. Инкүлек текә яр башыннан ук койма белән әйләндереп алынган, койма эчендә, аерым утрау сыман, бер йорт утыра. Аның хуҗасы, олы яшьләрдәге бер абзый, җәйге челләдә дә сыгыла төшкән аякларына читек-кәвешен, башына исә бүреген киеп, бер дә ашыкмыйча гына безнең тирәләрдән дә узып, мәчеткә барып-кайтып йөри. Бу йорт безгә бик серле булып тоела, кайвакыт койма ярыкларыннан күз салып, андагы кырмыска оясыдай хәрәкәтне күзәтәбез. Шул ук вакытта йортка ачу да килгәли. Аның кырык ямаулы тигезсез коймасы күлнең читенә үк төшә. Су буенда йөргәндә йә аны, тау башына ук менеп, бөтенләй урап узарга, яки, чалбар балакларын сызганып, су эченнән үк узарга туры килә — ә бит безнең чебиле аякларыбызны суга тигезергә ярамый торган чакларыбыз да була.

Ни генә димә, ишегалдыннан туйган чакларыбызда, йә инде анда сыймый торган вакытларыбызда, койма буе уйнар өчен менә дигән урын: кыр кәҗәседәй сикергәлим дисәң, текә тавы бар, ятып ауныйм дисәң, яр өстендә чирәмле тип-тигез яланчыгы бар. Өстәвенә әти-әниләр күрми торган аулак җир. Һәм әлбәттә инде күчәр башлары эләгешеп киткәндә чәкәләнеп алу өчен бик җайлы урын.

Менә хәзер дә без малайлар камалышында әнә шул койма буена килдек. Бер мәшәкатебез ким: сугышу кагыйдәләрен искә төшереп торулары кирәкми, чөнки тимер перәшкәле каешыбыз да, ә кулларыбызда таш-фәлән дә, яки шуларга охшаган катырак нәрсәләр дә юк. Кара-каршы бастык та, кем беренче сугар икән, дип көтеп торабыз. Ринат белән безнең гомердә дә сугышканыбыз юк, шуңа күрә бер-беребезгә кул күтәрүе әллә ничек кенә шунда. Ләкин малайлар безне, әйдә, башлагыз дип дәртләндерәләр. Фәһим Ринатны миңа таба этеп куя, Хәким мине, кош мамыгыдай, аның өстенә этеп җибәрә. Ринат миннән ярты башка калкуырак, шуңа күрә ул ачуы сүрелә төшкән зур кара күзләре белән миңа өстәнрәк, мин исә каш астыннан аңа сөзебрәк карыйм. Ә малайлар шау килә, «әйдә!» дә «әйдә!» дип ашыктыралар. Менә Ринат чатан әтәч кебек минем янымарак чыкты, кулын күтәреп кизәнгәндәй итте, мин шундук читкә тайпылдым. Ләкин мине шул мәлне үк, аркамнан этеп, үз урыныма кайтардылар. Теләсә ни эшләтсеннәр, минем бәләкәй сөякчел йодрыгымның беренче булып сугасы юк, чөнки мин Ринатны болай да инде бер кат рәнҗетелгәнгә саныйм, ул гарип иде. Шулай уйлап та өлгермәдем, ул минем күкрәгемә китереп төртте. Менә монысы әйбәт, менә син шулай башлап сук! Тукта, чү, нишләп әле минем колагым чыңлап китте? Ә, Ринат колагыма суккан икән. Болай булгач җавапсыз

да калырга ярамыйдыр бит инде. Шуннан инде тәпәләшү китте. Әлбәттә йодрыкларыбыз күбесенчә һаваны бушка айкый, чөнки малайлар гомумән күзләрен йомып сугышалар, бер кыза башлагач, берни күрмиләр...

Югыйсә, бәргәләшкән чагында чак кына айнып, иелергә генә кирәк бит инде. Иеләсен дә, дошманыңның корсагына нык кына чиртәсең. Ул шундук бөгәрләнеп төшә. Тирә-яктагы тавыштан колак тонды. Күз алдымда әллә, шайтаннар кебек, малайлар сикерешә, әллә Ринат миңа шулай бик күп булып күренә. Менә бервакыт Ринат миңа башы белән китереп сөргәндәй булды. Алай дисәң, Ринатның башы кара бит, ә бу — миңа җирән төстәге таш туп кебек китереп сукты. Күз алларым карангыланды да, өстемә Кабан күле килеп аугандай булды. Ләкин нигә кычкыра ул Кабан күле кызлар тавышы белән? Мине берәү, җилкәмнән йомшак кына тотып, җирдән күтәреп торгызды. Бу — Нурия иде...

— У-у! Олы күсәк Фәхши! — дип кычкырды ул Фәһимгә, минем өстемне кага-кага. — Кечкенәләрне котыртып йөргәнче, бар әнә сидекле көрнәңне киптер! Ә син тагын! — дип Хәким өстенә очынып килде ул. — Әтиеңнең кешеләр башын ашаганы гына җитмәдемени, инде син дә малайларны чүпләргә тотындыңмыни?! Шундый гәүдәң белән ничек оялмыйсың?!

Хәким кызарынып-бүртенеп аңа китереп сукмакчы булды. Ләкин Нурия керфеген дә селкетмәде:

— Сугып кара, мин синең кулыңны бик тиз кыскартырмын! — диде.

Шуннан Фәһши белән Хәким, артларына карана-карана, өйгә таба китеп бардылар. Нурия башта Ринатка, аннан миңа шелтә белән карап:

— Их, сез, ике дус! — диде. — Алар юри котырталар, ә сез көчекләр кебек котырасыз!

Ләкин бүтән безне бер дә орышмады, икебезне дә ике яктан җитәкләп өйгә алып кайтып китте.

Ничек күреп калган ул безне, кай арада йөгереп килеп житкән? Хәер, аларның балконнары су станциясендәге вышка күперчегедәй, йорт чатыннан чыгып тора шул, аннан Сафьян якларын да, күл буйларын да бик әйбәтләп күзәтергә була. Нурия безне шуннан шәйләп калган булган, күрәсең.

«Командировка» дигән юк сүзләр, аларны кырыкмаса-кырык шиккә төреп күпертүләр нәтиҗәсе буларак, Ринат белән икебезнең «аулак» койма буенда сугышуыбыз безнең өчен, бигрәк тә гаиләләребез өчен, эзсез калмады әлбәттә. Ринат белән без бик тиз килештек анысы, ләкин шулай да әчебез кайвакытларын тырналып, сулкылдап куя иде.

Көзгә таба Сирай абыйны да армиягә алдылар. Аларны башта шул ук күл буе казармасында элемтәче булырга өйрәттеләр. Кызылармеецлар су буендагы бакчада окоплар казыйлар да, шунда ышыкланып, яшел, кызыл лампочкалары янып торган аппаратларын каршыларына куеп, «Волга» белән «Кабан» исеменнән сөйләшергә тотыналар:

— «Волга», ишетәсеңме, бу мин «Кабан», һәм башкалар...

Идел ягыннан пароход авазлары бик сирәк ишетелә башлады. Анда хәзер давыллы җилләр дулкын күтәрәдер, пароходлар кышкы өйләренә — затоннарга кайтадыр. Аларның кайберләренә, бигрәк тә буксирларга корыч киемнәр кигезә башладылар, палубаларына орудиеләр куйдылар һәм алар, бердән авыраеп, түбәнгә, Әстерхан якларына төшеп киттеләр.

— «Волга», «Волга», ишетәсеңме, бу мин — «Кабан»...

Әйе, кызылармеецлар, калай колакчыклар киеп, «Кабан» белән «Волга» булып сөйләшәләр. Күл ягыннан алар өстенә ажгырып җилләр исә, бөтереп-бөтереп сары яфракларны китереп каплый. Алар әле шинель дә кимәгәннәр, туңып күшегеп беткәннәр, тәннәрен аз гына булса да җылытырга өметләнеп җиргә сыенганнар. Ләкин окоптан да чыгарга

туры килә. Алар гимнастерканы аркаларына чиләктән дә зуррак кәтүкләр асып күл буйлатып йөгерәләр, артларыннан телефон чыбыклары сузылып кала. Бу чыбыклар, чыгасы ерак юлларны искә төшереп, күл буйларында да, мәчет урамы — Насыйрида да сузылып яталар. Көзге юка пәлтәләрен кигән ике малай да, борыннарын мышкылдатып, шул чыбыклар буенча ашыга-кабалана атлыйлар. Аларның берсе алгарак узып китә дә, аксый төшеп атлаган икенчесен көтеп тора. Әнә шул чыбык сузучы, яки аларны җыючы кызылармеецлар күренү белән:

— Вы не видали Невлюдова, такого высокого, а волосы черные? — дип сорап куялар. Ләкин кызылармеецларның малайлар белән сөйләшеп торырга вакытлары юк. Ә кайберләре җилдә пәлтә чабулары җилфердәгән, ә кайвакыт кепкалары да очып киткән малайларны кызганып сөйләшеп куйсалар да, сүзләре кыска була:

— Невлюдова? Кто он, татарин или русский?

— Да, татар.

— Татар? Нет не видели...

Шуннан бу ике малай Насыйри якларыннан урап янадан күл буе бакчасына килеп чыгалар. Анда яшелле-кызыллы күзләрен кыскалаган аппаратлар эчендә дә җил сызгырган кебек була. Кызылармеецларның тавышларына хәтле тунгандай булып тоела.

— «Волга», «Волга», ты слышишь меня? Говорит «Кабан». Тьфу, чорт, связь прервана!..

Безнең дә өмет җепләребез өзелә. Без Сирай абыйны таба алмыйча күл буйлатып кайтып китәбез. Шулай да, казарма яныннан узышлый, аның тимер рәшәткәсенә маңгайларыбызны терәп, ишегалларын күзәтәбез әле. Ачы җилләр тәмам үзәккә үткәч кенә, борыннарыбызны лышык-лышык тарта-тарта, өйгә кайтып китәбез.

Безгә Ниса апа да барып эзләп йөрергә кушмый кушуын. Сирай абыйны үзе кайтып китә ул, ди. Ләкин йә без мәктәптә булабыз, яки бүтән җайсызлыклар килеп чыга. Ринатның менә бер айга якын инде аны күргәне юк. Сирай абыйны соңгы мәртәбә күрүе дә бик үкенечле килеп чыкты. География дәресендә укытучыбыз Агриппина Никитична, — ул безнең класс җитәкчесе дә иде, — такта кебек юка тәнле, озын буйлы керәшен хатыны, картага очлы таягы белән төртә-төртә, Уралның казылма байлыклары, аларның бигрәк тә сугыш вакытындагы әһәмияте турында сөйләп тора иде. Шул вакыт шыгырдап класс ишеге ачылды да, — без һәммәбез дә дәррәү әйләнеп карадык, парта капкачларын шакы-шокы китереп аягөсте бастык, — куе зәңгәр френч белән галифе чалбар кигән завучыбыз Әхәт абый килеп керде. Ул ишарәләп безгә утырырга кушты, чем-кара сынык кашларын тагы да сындыра төшеп, Агриппина Никитичнага пышын-пышын нәрсәдер әйтте. Укытучы Ринатка дәшеп:

— Невлюдов, бар әтиең килгән, — диде. Алар чыгып киткәч, коридорда мыдыр-мыдыр сөйләшкән тавышлар ишетелеп торды. Укытучы, дәресне дәвам итеп:

— Урал — хәзерге авыр көннәрдә ватаныбызның йөрәге ул, — диде.

Кабан өстендә яңгыраган авазлар кебек минем чигәләрем: «Урал... Урал... йөрәге... йөрәге...» — дип тибеп торды. Ләкин мин барыннан бигрәк ишек артындагы тавышларны ишетергә тырышып утырдым. Ниһаять, «Урал... Урал» дигәннән гайре берни дә ишетә алмыйча, кулымны күтәреп, укытучыдан чыгып керергә рөхсәт сорадым, ул башын гына кагып куйды да, янә Уралны сөйләвен белде.

Сирай абый чабулары балтырына хәтле төшеп торган соры шинель кигән. Үзенең дә буе озын булганга, шинель аны ничектер ябыктырып күрсәтә.

Өстәвенә чәче дә кистерелгәч, башы артык зур бүрек кигән бала башына охшап калган. Мин класстан чыкканда ул Ринатка:

— Син хәзер үстең инде, әниеңә булыш, энеңне кара, яме? — дип соңгы әманәтләрен әйтеп тора, Ринат исә аның гозерләп әйткән бу сүзләрен җөпләп башын каккалый иде.

— Менә синең якын дустың да бар, — диде ул һәм мине озын кулы белән үз янынарак тартып китерде. — Сез дуслар бит, әйе бит? — диде ул икебезне дә ике яктан кочып. Мин дә, Ринат та, аның сүзләрен раслагандай, башларыбызны селкеп куйдык. — Тормышта төрле чаклар була, тик, карагыз аны, бер-берегезгә бер вакытта да хыянәт итмәгез. Әнә без, Каюм абыегыз белән, бер төптән чыккан имәннәр кебек булдык. Сез дә шулай куш агач шикелле берегеп, нык булып үсегез!

Без, ярар, үсәрбез дигән кебек, башларыбызны тагын бер кат иеп куйгач, Сирай абый мине янә үзенәрәк тарта төшеп йөземә төбәлеп карап торды. Без малайлар белән күзгә-күз төбәлешеп уйнаганда мин бик тиз җиңеләм, карашымны шундук читкә ала идем. Ә хәзер миңа малайлар гына да карамый, ә зур коңгырт кара күзләре белән мине пешерә язып Сирай абый карап тора иде. Менә аның утлы карашы йомшарып киткәндәй булды, аннан бик җылы иркә нурлар сирпелде, һәм ул, күзләрен йома төшеп, сөякләремне чытырдатты:

— Хәләмгөл!.. — дип, ни өчендер әниемнең исемен әйтеп, мине кочагына кысып торды.

Мин башта йөнтәс шинельле бу кочакта рәхәт кенә кытыкланып басып торган идем. Ләкин кинәт кенә рәхәт бу изрәүгә электр тогы китереп биргәндәй булды да, мин учларым белән этелеп, артка чөйкәлдем.

— Йә, йә, мин шаяртам гына бит, — диде Сирай абый, мине һаман да әле җибәрмичә. — Эштән кайткач, әниеңә сәламемне тапшыр, яме. Минем иң соңгы үтенечем бу, бәхил булсын. Ниса апаң да, әниең дә дус булып яшәсеннәр, араларыннан җил-давыл да үтмәсен...

Шуннан ул мине җибәрде, мин аңа күтәрелеп тә карамыйча, сүзсез генә басып калдым. Ул Ринатны җитәкләп баскыч башына китте. Менә ул борынгы мәктәпнең тимер баскычларыннан акрын гына төшеп бара инде, итек үкчәсендәге дагалары чик-чик килә. Өстәвенә, коридор башындагы су багы кранынннан чиләккә чулт-чулт итеп су тамчылары тама һәм алар, гүяки минем ярама тоз тигезгәндәй, көйдереп-көйдереп алгандай итәләр. Баскычта дагалы итекләр соңгы мәртәбә чыкылдап алдылар да, бервакыт тынып калдылар. Ичмаса өлкәннәр кебек: «исән генә әйләнеп кайт», — дип тә әйтә алмадым бит. Кеше фронтка китә, ә мин... Шуннан мине ниндидер пружина атып биргәндәй итте дә, мин башымны артка ташлап, баскычның тимер идәненә йөгереп килдем.

Баскычның иң соңгы басмасы турысында Сирай абый, аягына ук чүгеп Ринатны аркасыннан сөя-сөя кочаклап тора иде. Ул мине дә күрде, елмаеп кулын изәде, мин дә кулымны селеккәләп аңа җавап бирдем. Шуннан Сирай абый кулын бүрегенә тигезә язып икебезгә дә честь бирде һәм капылт кына борылып, мәктәп ишегеннән чыгып китте.

— Урал ул — илебезнең йөрәге... — дип Агриппина Никитична дәресне йомгаклап килә иде.

Ул үзе сөйләсә дә, аның бәләкәй күзләре — бездә. Минем чигәләрем тагын: «Ил... ил... йөрәге... йөрәге...» дип тибә. Ринат алдагы партада башын игән дә аркасын калтыратып утыра, хәтта парта да дерелдәп-дерелдәп киткәндәй итә. Мин аны тынычландырырга теләп, аркасыннан сыйпап куймакчы булып, аңа таба кулымны сузам һәм нәкъ шул вакыт бөтен мәктәпне янгыратып кыңгырау шалтырый башлый...

Сирай абый әнә шулай фронтка китеп барды. Ул Ринат белән икебезгә истәлеккә дип әле майлары да сөртелеп бетмәгән, тимер чыбыкларны тешләп өзә торган келәшчә белән колагын борып ача-яба торган кул эскәнҗәсе калдырып киткән. Без мона бик шатландык. Безнең элек тә йортыбызга ут керткән монтер Тәлгать кулында карга борынын күргәнебез бар. Борынындагы ярыкларына чыбыкны куйганнан соң кысып йомдырып алсаң, чыбык очы әллә кайларга атыла. Ләкин аның белән эш итүе куркыныч, чыбык очы күзеңә килеп керүе мөмкин. Ә Сирай абый калдырган күгелҗем корычлы келәшчә шундый үткен, ул чыбыкны тавышсыз диярлек керт итеп кенә өзә. Без сынап карый-карый аның белән бик озын бакыр чыбыкны өзгәләп бетердек һәм аның авызыннан коелган бакыр шырпылар белән өстәл тула язды. Бу келәшчә ярдәмендә кадак та суырып була. Без Ринатларның түр якны алгы яктан аерып торган такта бүлентесенә кадак кагып суырып та карадык инде. Келәшчә белән кадакны эшләпәсе турысыннан каптырып каеруга, кадак шундук суырылып чыга. Без әле ишек катындагы стенаның сәндерәгә менгезә торган озынча шакмаклы басмаларыннан да бик зур кадакны суырып карамакчы идек, тик көчебез генә җитмәде. Аннары Ниса апа, күзләрен йомгалап, шундук яныбызга йөгереп килде:

— Баскычны боргач, сәндерәгә ничек менәрсез, — диде.

Йортның күп яклары биек түшәмле булып, Миннегөл апаларда да, Ниса апаларда да ишектән өстәнрәк сәндерә ясалган. Тик Миннегөл апаларның фатирлары тар булу сәбәпле, сәндерәләре дә иркен түгел. Ә менә Ниса апаларның сәндерәләре ындыр табагыдай кин. Анда түшәк-ястыклар, мендәрләр өеп куелган. Без Ринат белән анда котырып уйнаганда юрган һәм мендәрләрнең астын өскә китерәбез. Урын-җирне болай туздыруыбыз өчен Ниса апа безне тиргәп ташлый. Менә хәзер дә ул келәшчәне сынаганда яныбызга бик тиз килеп җиткән иде. Тик бу юлы безне орышмады, фәкать:

— Киемегезне ертыр бит, кул-аякларыгызны да сыдыруы мөмкин, — дип, чыгып торган зур гына кадакны кага төшәргә кушты.

Без аның эшләпәсенә чүкеч белән төеп, кадакны кагып та куйдык. Кул эскәнҗәсе дә ошады. Аның белән тимер кисәкләрен каптырып алып, аларны игәү белән игәргә остарып киттек. Тора-бара кулларыбызның эшкә өйрәнүен сизми дә калдык. Келәшчә белән эскәнҗәдән без бик озак файдаландык. Инде теше үтмәсләнеп бетсә дә, урыны-урыны белән кителгән булса да, ул хәзер дә минем эш кораллары тартмасында кадерле истәлек булып ята. «Кадерле» дип бу сүзне Сирай абыйга төбәп әйтүем түгел. Ул бер дә гөнаһсызга минем сөеп яраткан әнием турында шыксыз хәбәрләр таралуга сәбәпче булды, безнең гаиләбезне тарката язды. Аның бигрәк тә әтине мыскыл итүен күтәрә алмый идем мин. Аның әтидән «йокы чүлмәге» дип көлгән чакларында шырпы кебек тырпая торган идем. Ә шулай да әлеге инструментлар аша Ринат белән икебезгә тормышның иң әйбәт күркәмлеге — ир-ат булу сыйфаты йогып калган безгә һәм аны үзенең кадерле ядкаре итеп әлеге әрсез дә, гадәттән тыш мут та Сирай абый калдырган иде.

Аннары гөнаһ-мазарлары булса да, ник әле кешене гомер буе гел кара яктан гына искә алырга. Ул сугышка киткәндә без әле унбер яшьлек малайлар гына идек. Ә малай чак чишмәдәй саф чак. Аны бернинди кара тамчылар да пычрата алмый. Хәтта бер көнне авыз-борыныңны канатып тукмашсаң да, икенче көнне дустың белән өге-җөге киләсен. Малай чакның әнә шундый риясыз пакьлыгы һәрберебезгә дә гомер юлында маяк булып торса икән, үсемлекләргә төкеректәй җирәнгеч лайласы белән ябышырга торган кабырчыксыз әкәм-төкәм ишедәй вак җанлылыкны, әшәке гайбәтне безнең күңелләрдән һәрвакыт куып торса икән!

Ринатның әтисе сугышка китте. Әле кайчан гына ул бик саран лампа яктысында, ярым-караңгы өебездә үзенең «Ванька-встанька!»лары белән дөньяга безнең күзләребезне ачты. Әле кайчан гына ул, ерак командировкалардан кайтканнан соң, безне аяк араларына алып бик зур сандык өстендә ял итеп ята, безне йонлач аяклары белән әүмәкләп бетерә, безнең һич бирешәсебез килми, икәүләшеп аның аякларын җиңмәкче булабыз, чиныйбыз, котырынабыз. Әле кайчан гына ул... Мин үземнең зиһенемне бик киеренкеләндереп, малайларча маңгаемны җыерып, безне яклап сугышка киткән Сирай абыйның әйбәт якларын искә төшермәкче булам. Тик нишләп соң әле кылт итеп әти белән әнием уема керә?! Әни, кайчан карама, әтине тирги. Һи, аягүрә йоклаган!.. Йокласа соң, әллә кешегә йокларга да ярамыймы? Әнә, кешенең ирләре кылны кырыкка яра. Ярса соң, әти дә әнә оста тегүче ич. Син дә, әнием, бик оста, күрше хатыннарга көлмәкләрне коеп кына куясың. Мехкомбинатның тырыш эшчесенә дә әйләндең. Тик нигә инде әтине гелән-гелән тиргәп торырга?

Мин шунда кинәт үзем турында, киләчәгем турында уйланырга тотынам. Кем булырмын мин? Әни әйтә, кеше ул — кем булса да, җебегән булмасын, баскан җирендә ут чыгарып торсын, ди. Мин үземнең чырадай сыйракларыма карыйм. Ничек чыгармак кирәк инде бу аяклар белән утны? Һәрхәлдә мин кемгә охшарга тиеш, әнигәме, әтигәме? Әни дию белән минем күз алларым яктырып китә, күңелем шатлык белән тула. Ә әти искә төшсә... Нигә үзеңне-үзең шул хәтле түбәнәйтергә, мескенәйтергә икән? Юк, әти күз алдыма килү белән, әнинең исә аны орышкан сүзләре колак төбемдә яңгырагандай булу белән, мин эсселе-суыклы булып китәм. Мин аны кызганам, ләкин шулай да миңа аның кебек булырга ярамас, һәм мин үземнең сөякчел йодрыкларымны төйнәп үземә-үзем ант итәм. Сирай абый кебек хәттин ашкан әрсезгә әйләнмәсәм дә, ичмаса авызыма капканны төшермәслек дәрәҗәсендә генә кыю-тере булырга һәм... һәм инде йокламаска... Аягүрә дә, караватта да йоклап гомерне уздырмаска! Әйе, шулай менә!

Бу рәвешле — балаларча антлар эчүем — ирләрчә еракка карау иде ул... Анысы ирләрнең дә йомшарган чаклары була, аларның да кырыс йөзеннән борчак-борчак яшьләре тәгәрәп төшә. Ләкин ир булырга үз-үземә сүз биргәнмен икән инде, соңгы чиктә дә ачы күз яшьләремне кешегә, бигрәк тә әниемә күрсәтмәячәкмен! Ә инде йокыга килгәндә... Әйе, әнә шул мәлдәге малай вакытымнан соң күпме сулар акты. Минем әле дә булса йоклап туйганым юк. Караңгы таңнан ук торып, исерек кешедәй айкала-чайкала кухняга чыгам. Бер стакан каһвә кайнатып эчәм. Һәм шулай ук, исерек кешедәй кармалана-кармалана, эш өстәлем янына килеп утырам. Минем күп йокларга хакым юк! Авыр сугыш елларындагы дусларымны искә төшерәсем, алар турында, әти-әниләребез хакында хәзерге укучыларга мөмкин кадәр күбрәк сөйләп калдырасым бар. Шуңа күрә дә, караңгыдан ук торсам да: «Хәерле көн!» — дим үземә-үзем. – Әйдә, вакытны уздырма, каләмгә тотын тизрәк!» — дим...

*Тәмам.*

*Нури Арслановның тууына 100 ел*

*Нури Арсланов — үткән гасырның икенче яртысында иҗат иткән күренекле шагыйрьләрнең берсе. Ир-егет һәм гражданин буларак, ул үз чоры вакыйгаларында актив катнашкан кеше. Фин һәм Ватан сугышы солдаты, Урта Азия һәм Ерак Көнчыгыш шәһәрләрендә укытучы һәм рәссам, соңрак шул сыйфатта Казанда чыккан төрле редакцияләрдә рәссам-журналист.*

*Нури Арсланов белән аралашкан һәм аны хәзер дә хәтерли торган кешеләр яхшы беләләр: зур һәм гыйлемле шагыйрь буларак, ул төрки, гомумән, шәрекъ телләрен тирән тоя торган шәхес иде. Шуңа күрә дә, ул шәрекънең дистәләгән бөек шагыйрьләрен татар телендә табигый яңгырата алды. (Гомәр Хәйям, Хафиз Ширази, Мәхтүмколый, Токтогол, Абай һ.б.)*

*Нури Арсланов 1964-72 елларда «Казан утлары» журналында поэзия бүлеге мөдире булып эшләде. Татар шигъриятенең бу яңарыш чорында да, шагыйрь һәм зирәк аксакал булып кала алды: яшьләр иҗатындагы уңай яңалыкларны яклады, кирәк очракта, алардагы дәрт-рухны үз иҗатында да файдалана белде. Аның шигъриятебез тарихында калырлык «Моңсар», «Горур Гайшә», «Романтика», «Майра», «Сак-Сок» кебек поэмалары нәкъ шул елларда язылды да инде.*

*Лаеклы ялга чыккач та, әдип безнең редакциягә еш килә иде, яңа шигырьләрен дә укый, уй-сагышларын да сөйли, кирәк чакта киңәшләрен дә бирә иде.*

*Быел күренекле шагыйрьгә, олпат әдипкә 100 яшь тулган булыр иде. Моннан егерме еллар элек арабыздан китсә дә, аның иҗаты шигърият сөючеләр күңелендә яши бирә. Юбилее уңаеннан шагыйрьнең төрле елларда язылган берничә шигырен укучыларыбызга тәкъдим итәбез.*

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**

# Нури Арсланов

***

**Азат җанлы булып туганмын мин,**
**Карышсам да язмыш кушканга,**
**Бәйгеләрдә чабар ат булсам да,**
**Аякларым булды тышауда.**

**Шул тышауны өзеп ташлар өчен**
**Үз гомеремдә күпме күрәштем!..**
**Җиңалмадым тормыш ваклыкларын,**
**Тик көчемне җилгә өләштем...**

Ахмакларга акыл сатмадым мин,
Сорамадым акыл әҗәткә;
Намус-вөҗдан шартын бозмасам да,
Табынмадым әхлак-әдәпкә.

Акыл белән эш ит диләр миңа...
Ә йөрәкне кая куясы?
Анда һаман әле давыл уйный,
Анда һаман «җеннәр оясы!»

Аның әле амур укларыннан
Һаман килә яра аласы.
Булса булыр икән бу кадәр дә
Тынгы белмәс адәм баласы!..

Типсәң, тимер өзәр чак узса да,
Мин калышмыйм әле ярыштан,
Мәйдан тотсам — исемем генә түгел,
Бөтен рухым, җисмем арыслан!

Нәрсә көтә — әзер барысына да,
Күптер әле алда көрәсе.
Ярышларда егылып үләр идем,
Бер дә килми авырып үләсе.

*1966*

## Үз илем, үз республикам бар

Тусам да киң казакъ даласында,
Үссәм дә мин атта-иярдә,
Гел ашкындым Казан каласына —
Истәлекле, изге җирләргә.
Бу туфракта минем туган илем,
Йорт корганнар монда бабамнар,
Монда минем акчарлаклы Иделем,
Үз халкым, үз республикам бар!

Көзен киткән казлар язын кайта,
Кыйгаклашып, Идел-суларга.
Киек казлар... Без дә төрле якка
Таралганбыз, охшап шуларга.
Бер кайтмаса бер кайталар илгә,
Өмет өзми кайталмаганнар.
Идел-йортта Татарстан дигән
Үз илем, үз республикам бар!

«...Чит җирләрдә йөреп гыйбрәт ал!»лар
Борынгыча яңгырый колакта,
Гадәт булып киткән безгә алар –
Юллар илткән безне еракка.
Гизсәләр дә башлар кайда гына
Күңелдә гел Идел — якты яр,
Йөрәкләрдә мәңге яши торган
Үз илем, үз республикам бар!

*1970*

## Нәсихәт

*Бәйләнчекләр тагын: — Дидактика! — дияр.*
*Дисә дияр, бәлки бер файдасы тияр.*

**Ачулансаң ачулан, тик явызланма,**
**Хөрмәт күрсәт, — яраклашма, сагызланма.**

**Бул булалсаң эре, ләкин эреләнмә,**
**Сүзең якла, — җаһилләрчә киреләнмә.**

**Гайрәт белән усаллыкны бутый күрмә.**
**Горурлансаң горурлан, — мактанып йөрмә.**

**Түбәнчелекле бул, ләкин түбәнләнмә.**
**Ирешсәң данга, — бер дә әллә кемләнмә.**

**Каныкма көнләшеп, — иҗат сөеп көнләш.**
**Мәйдан тотар булсаң, — аяк чалмый көрәш.**

**Тыйнак булу әле — йомшак булу түгел,**
**Һөҗү-калҗыңлы булсаң бул,—чамаңны бел.**

**Тагын кирәк булыр кое, – төкермә син.**
**Көчек булсаң була бир, – айга өрмә син.**

*1971*

## Нигә тургай да...

*Тургай картаямы икән?*
Ибраһим Гази

**Саф җанлы кеше дөньяны**
**Шигырьдә күрә икән...**
**Ә фани дөнья борчылмый,**
**Ул кызганып-нитеп тормый:**
**Анда—тургай да картая,**
**Шагыйрь дә үлә икән...**

**Соңгы тапкыр очрашканда**
**Ап-ак күлмәктән идең.**
**Кул бирдең гадәттәгечә.**
**Әйткәндәй ничәмә-ничә:**
**«Шагыйрь кеше шулай инде, —**
**Ул гел елмая!»—дидең.**

**Күп яши торган кешеләр**
**Елмая, көлә имеш.**
**Аңа вакытың калмагандыр,**
**Ыгы-зыгың алдагандыр...**
**Иҗат гомерең барын бар да, —**
**Хәят бер генә имеш...**

**Чәчәкләр китердем менә...**
**Ә дустым күрә микән?..**
**«Шагыйрь, ник елмаймыйсың?»! — дип,**
**Мөлаем көлә микән?..**
**Нигә тургай да картая,**
**Шагыйрь дә үлә икән?!**

*1972*

# УЛ – ВАЕМЛЫ ДУЛКЫННАН

Өч хикәя... «Оялу»: мәктәптә җыештыручы булып эшләүче әнисеннән оялган Мәдинә; «Илүзәнең туган көне»: сигез яшьлек кызының туган көненә әтисе ни бүләк итә?; «Җиңү бәйрәме»: шахтага киткән җиреннән сугышка, аннары әсирлеккә эләккән, инде хәзер җанына җылы эзләп тилмергән Мәймүнәттәй, аның онигы... Һәркайсы өч-дүрт биттән дә артмаган хикәяләр. Бәгъзе авторларның тынчу су буедай, эчпошыргыч озын, әйтәсе килгәнен дә әйталмыйча, очлый алмыйча азапланып язган «шедебр»ларыннан соң, укый башлаганчы ук, ниндидер өмет уятты. Кысыр өмет кенә була күрмәсен! Кыска хикәяләр дә буш була кайчак...

Үзенә генә хас теле беләнме, авторның дөньяви күзаллавы, яңа табыш-детальләре, көтелмәгән кызык борылышлары беләнме, бу хикәяләр күңелгә кереп калды бит. Әнә, кайчандыр әнисеннән гарьләнгән Мәдинәдән нинди һөнәр сайлата автор?! Илүзәнең туган көнендә кичергән хәл-халәте кемне битараф калдырыр икән?! Ә Мөслимәттәй язмышы?!

Мөслимәттәй, Әминәттәй, Мәймүнәттәй дигәннән, әтәй-әнәй дигәннән, бу хикәяләрне укыганда мин таныш хисләр кичердем. Безнең Мамадыш-Тәкәнеш якларында шулай сөйләшәләр ләбаса! Хәтерлисезме Шәйхи Маннурның күңел кинәндергеч мамык тел белән язылган «Агымсуларга карап» бәянын?!

Бактың исә, Рүзәл Фәиз улы Мөхәммәтшин 1989 елның 25 маенда Кукмара районының читендә урнашкан кечкенә генә Татар Толлысы авылында туган. Табигате искиткеч гүзәл бу авылны бер яктан куе урман уратып алган. Таулардан урманга таба авыл янәшәсеннән көмеш сулы Нократ елгасы агып ята. Кайчандыр Ш.Маннурның Тулбаеннан күчеп килгән шигъри җанлы кешеләр яши биредә – ягымлы, үтемле телле татарлар!

...Рүзәл 2010 елда Татар дәүләт гуманитар педагогика университетының татар филологиясе факультетын тәмамлый. Укыганда университетның Габдулла Тукай исемендәге һәм Татарстан Республикасы Президентының махсус стипендияләренә лаек була. «Илһам» әдәби иҗат берләшмәсенең әйдаманы да – ул.

Рүзәл Мөхәммәтшин соңгы елларда үзенчәлекле шигырь-поэмалары белән, милләт, заман проблемаларын күтәргән әдәби-публицистик язмалары белән танылды. Аның 2011 елда Татарстан китап нәшриятында тәүге шигырьләр җыентыгы («Каралама») дөнья күрде. Ул – Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, бәгъзе әһле каләмнәр тарафыннан «яңа дулкын» дип билгеләнгән әдәби буын вәкиле. СССР дигән илнең җан биреп яткан мәлендә дөньяга килгән буын инде менә үз сүзен, үз фикерен әйтә башлады. Заманага, милләтнең бүгенге хәл-халәтенә аларның, хакмы ул, юкмы, үз бәяләмәсе бар. Иң мөһиме – алар битараф түгел! Әнә шул ваемлы дулкыннан Рүзәл Мөхәммәтшин, Рөстәм Галиуллин һәм Эльвира Һадилар «Идел»гә эшкә килеп, яшьләр журналының милли вә гамьле йөзен тергезделәр. Һәрхәлдә, аларның әдәби-публицистик язмаларын, әсәрләрен шәхсән үзем, элекке «Идел»че, көтеп алып, кызыксынып укыйм.

Безнең редакциядә күңелгә хуш килгән кульязма әсәрләрне кулдан-кулга йөртеп уку гадәте бар. Мин дә Рүзәлнең хикәяләрен хезмәттәш-каләмдәшләремә тәкъдим иттем. Укып чыккач та, Алмаз Хәмзин: «Һы!» – дип куйды, Камил Кәримов дәшмәде, мыек астыннан елмайды, баш мөхәррирebез Равил Фәйзуллин исә, аеруча җентекләп, кызыл-кара каләме белән кат-кат укып чыккач, ниһаять: «Буш түгел...» – диде, ә Рәфикъ Юныс авторның дүртенче хикәясен «Ак җилкән»нең махсус папкасына сөенеп салып куйды.

Хәер, шагыйрьнең хикәяләре сезнең хөкемегездә, хөрмәтле укучылар.

**Марат ЗАКИР**

Рүзәл
Мөхәммәтша

# ӨЧ ХИКӘЯ



**Оялу**

Киләсе тукталыш — Арча...

Шакы-шокы, шакы-шокы, шакы-шокы...

Электричка, графигыннан соңга калмыйча гына, Казанга ыжгыра. Тәрәзә төбеннән ашыгып узган шәрә ботлы җилбәзәк каеннар, өсте-башын җәй-көз-яз-кыш — ел дәвамында! — алыштырырга кирәк санамаган, төз, йөгергәндә дә үрә катып йөгерергә тырышкан хәрби чыршылар, тупас, дорфа усаклар, кәкре-бөкре карт-коры өрәңгеләр — алдын-артын карап тормыйча, без барасы тарафтан ничек тә булса качып котылырга чамалыйлар ахрысы — кабаланып-кабаланып кирегә, артка чабалар иде...

Түм-түгәрәк булып көн туып кына килә, офыкның буеннан-буена таралган шәфәкъ ялкыны карасу-кызыл күкне дөрләтеп, безгә таба якынлаша... Агачларның да шул янгыннан куркып чабулары булмаганмы икән әле?

Юл шактый озын. Тагын сәгатьтән артык «шакылдыйсы». Вакытны мөмкин кадәр тизрәк уздыру максаты үзеннән-үзе әңгәмәгә тарта. Шундый чакта дуслар-танышлар белән бергә баруыңа тагын бер кат куанып куясың. Вагон тулы кеше, ләкин без — үзебезнекеләр — өчәү генә: Фирдәвес, мин, Илнар. Өчебез дә сыйныфташлар, Фирдәвес белән мин — бер авылдан, Илнар исә — күрше авыл егете. Бер мәктәптә укыдык. Яңа гына аттестат алып кем кая — укырга, эшкә, яисә армиягә киткән иде, шул сәбәпле, әңгәмә үзеннән-үзе бәхетле дә, урыны-урыны белән авыр да, әмма, һичшиксез, кадерле һәм сагынычлы мәктәп елларына килеп төртелде.

Ә искә алырлык вакыйгалар — җитәрлек...

— Хәтерлисеңме, — дип сүз башлады Фирдәвес, — бервакытны син үзең укытучыдан икеле куюын үтендең. Куегыз инде, пажалысты, имеш... Вәт кыласс белән рәхәтләнеп көлгән идек, малай!

— Әни куйдыртты бит аны, — дим мин, аклангандай.

— Вәт көлдек без анда!

Шулкадәр мәгънәсез хәл булган иде ул. Әллә шигырь ятламаган идем шунда, әллә әсәр укымаган идем. Көндәлекнең ике шакмагы зурлыгында «койрык» ясап куйды укытучы. Икелене бигрәк ямьсез ясый алар! Шулкадәр шөкәтсез килеп чыга — без, егетләр, аптырап тормыйча гына, урынга утыруга ук затсыз билге белән бозылган атнаны, Аллага тапшырып, умырып ата идек. Минем дә бу гадәткә хилафлык китерәсем килмәде — дәрес

бетүгә көндәлек бер биткә кимегән иде инде. Ярар, бетте-китте, нәрсәсе бар инде аның, диярсез. Шулаен-шулай да үзе... Әмма ул кичне ата-аналар җыелышы булырга тиеш иде. Истән чыккан бит, әй! Кайтып керде әни, малай, күзлек пыялаларын парландыра-парландыра... «Санта-Барбара»ның бер сериясе кадәр вакыт дәвамында и әрләде, и сүкте, и сүкте, и әрләде. «Иртәгә үк көндәлегендә булсын!» — дип тәмамлады аннары. Нишлисең, «Куегыз... пажалысты», — дип, башымны иеп килеп җиттем инде. Ярый укытучысы кеше хәленә керә торган иде — бер куелган икелене тагын бер кабатларга кыенсынмады.

— Берсендә швабраны ишеккә терәтеп тозак корган идек бит әле... Һаман шул Җәмилә Әнвәровнага инде. Чүпрәкле ягын өскә каратып. Ел дәвамында кабинетның һәр пычрагын, һәр шакшысын — чәчләрне, сазны, сагызны үзенә юмарт рәвештә сендереп барган бу чүпрәк ишек ачылуга тегенә төшкән булса, ул көнне дәрес, мөгаен, бер егерме минутка кыскарыр иде. Андый вакытта байтак гомер әлеге «шаяру»ның кем эшләгәнен ачыклап үтә торган иде.

— Ул вакытта Мәдинә коткарды бит аны. Алай ярамый, вы што, имеш...

— Үзе өчен дә курыккандыр инде... Аңа эләксә. Командир бит!

— Югыйсә, беркайчан да тик утыра алмаган Илсур гаепле калыр иде барыбер.

— Кыстати, мәктәпне бетерүгә кияүгә чыкты ул, име...

— Илсурмы?!

— Мәдинә! Әллә кайларга укырга керерлек башы бар иде ләбаса!

— Икесе дә — ире дә, хатыны да — авылда ди бугай.

— Әйе, мәктәптә эшлиләр, — дип җөпләде Илнар, үзе шул авылдан бит. Ул белми әйтмәс, әтисе директор аның. — Берсе — кочегар, берсе — идән юа...

— Мәдинә идән юамы? — дип кычкырып җибәрдем мин.

— Әйе, — диде ул исе китмичә.

Бер карасаң, бернигә дә шаккатырга кирәкми иде кебек. Яхшы бит инде — үз көннәрен үзләре күрә икән. Аннары, эшнең ояты бармыни? Әмма хәтеремдә уелып калган бер хатирә миңа әле дә тынгы бирми иде, инде бу яңалык әлеге хатирәнең эзен тагын да тирәнәйтә төште...

Унынчыда укыгандамы соң, әллә унберенчедә үкме — өлкәннәр идек инде, кыскасы — тәнәфес, коридор шау-гөр килә. Урыс теле кабинеты каршында без, егетләр төркеме, һәм алар — кызлар, ике түгәрәк ясап, гәп сатабыз. Кызлар арасында Мәдинә дә бар. Шул арада, әллә ничек, көтмәгәндә, коридорның бер башында бик гади генә, иске генә киемле апа күренде. Башына яулык япкан, өстенә таушалган халат бөркәнгән, аягына галуш элгән иде ул. Фермадан эштән кайтышлый гына мәктәпкә сугылуы булгандыр, күрәсең. Нигә икән? Бусын белмәдек. Бераздан танып ук алдык үзен, каршыда — Сәвия апа, Мәдинәнең әнисе иде. Барыбыз да ана белән кызның күрешүен өмет иткән арада, сыйныфташыбыз дуслары белән әнисе ягына ишарәли-ишарәли көлеште, «уфф» дип авыр сулады да... бәдрәфкә кереп, күз алдыннан юк булды.

Мин аңламый торган мәлдә егетләр пышылдашты:

— Оялды бу...

Сәвия апа да туктап тормады, бөкрәебрәк кенә яныбыздан узып китте.

— Сәммесез, — дип калдык без.

Ул безне ишетмәде.

Бераздан Мәдинә дә бәдрәфтән чыкты, тирә-юненә каранып кына алды да, кызлар төркеменә кушылды. Гәп, көлешү-бәхәсләшү дәвам итте...

...Арчаны узганбыз икән инде...

Казан белән ике арадагы кайсыдыр платформада туктап торабыз.

Арып башын игән агачлар да исе китмәгән рәвештә — әйтерсең, әле генә дистәләп чакрым чапмаганнар да! — хәл ала иде. Хәер, хәзер бәлки ул кадәр котырынып чапмаслар да инде — офыктагы ялкын сүрелә төшкән. Күк чистарган — ап-ак, мәгърибтән мәшрикъкача ник бер болыт-фәлән әсәре булсын! Үрсәләнеп, иң очка — биеккә, галәмгә үк менеп житәргә теләп янган шәфәкъ сүнгәннән соң, гүя кемдер кат-кат, ышкып-ышкып күкне юганда артыгын тырышып ташлаган — баш өстендә илаһи зәңгәрлекнең эзе дә юк. Бары — аклык, буш вә ваемсыз ап-аклык кына...

Чибәр иде шул Мәдинә. Ул саргылт чәчләре, кыйгач кашлары, алсу иреннәре дисеңме... Ул киенү-ясануы... Кыйммәтле хушбуй исе аңкып тора иде аннан. Күпләрне үзенә гашыйк иткән кызның бар муллыгын йомшак, төгәл бер ритм белән чайкалдырып тактага чыгулары гына да ни тора иде бит! Афродита... Афродита үзе көнләшерлек!

Ә хәзер шул кыз мәктәптә идән юа икән...

Юк, эшнең начары юк!

Һәм аннары — яшьләр бит әле, гомер-бакый болай бармас, киләчәктә — кем белә, дөнья бу! — бәлки, рәтләнер барысы да.

Әллә... әнисе катырак күрсенде микәнни?

## Илүзәнең туган көне

Ул, күзен ачарга теләр-теләмәс кенә керфек каккалап бераз ятканнан соң, тирән итеп сулыш алды, түшәктә килеш киерелде. Мизгелләп-мизгелләп кенә вакытны санап текелдәгән сәгать алтыга якынлашып килә: зур угы — унны, кечкенә угы — алтыны күрсәтә. Тагын ун минут иркәләнеп ятсаң да була әле. Аннары әнисе кереп уятачак. Ул вакытта Илүзә юри күзләрен йома, йоклаганга сабыша. Шулай булмыйни! Әнисе башыннан сөеп, йөзенә төшкән чем-кара чәчләрен колак артына тараячак, аннары, пышылдап кына, күреп яткан төшең белән алсу чынбарлыкны — иртәне сизелер-сизелмәс кенә ялгап жибәреп:

– Күз нурым, тор инде, әйдә, — диячәк бит. Мондый ләззәттән үз акылындагы кеше баш тарта димени инде!

Ләкин бүген Илүзә ул кадәр ялкауланып ятарга теләмәде — тиз генә сикереп торып урынын жыештырды, мендәрне матурлап бастырып куйды, тәрәзәнең пәрдәләрен ачты — май кояшы да инде, Илүзә кебек, уянып килә иде.

Краннан аккан салкынча су нәни кызның онга манылган төсле ап-ак кулларын, ап-ак битен юды.

Йомшак, әллә нинди болын чәчәкләре исе аңкыткан сөлге белән сөртенгәннән соң, ачы сызгырудан сискәнеп, кече якка чыкты ул — плитә өстендә чаж-чож килеп чәй кайнап утыра иде. Илүзәнең кечкенә генә камыр бармаклары плитәне сүндерде. Шулвакыт, ишек ачылып китте дә чиләкләр тоткан Мәрьям апа күренде — мал карап керүе иде булса кирәк. Ул ашыгып кына кулын юды, сөртенде, аннары кызын күтәреп алып түшәмгә чөйде:

– Нәрсә, бәләкәй кыз, тагын бер яшькә үстекме?

Әй! Ничек оныта алды ул моны? Бүген Илүзәнең туган көне ич! Аңа сигез яшь тулды бүген, сигез яшь! Си-гез! Нинди бәләкәй булсын, Илүзә дәү, дә-әү инде хәзер!

– Бәхетле бул, кызым, сәламәт бул, яхшы бул, игелекле бул. Туган көнең белән котлыйм сине!

– Рәхмәт, — дип ярым пышылдады Илүзә. — Ә әти кайда соң?

– Хәзер керә.

Чыннан да, тиз арада әтисе дә керде, аны күрүгә, кабаланып, әнисе чәй хәстәрләргә керешге — эшкә барырга вакыт җитеп килә икән...

– Әти, – диде Илүзә чәйне йотып җибәргәч, келиндер кетердәтеп. – Ә минем бүген туган көнем. Сигез яшь тулды!

– Һай, шулаймыни? – дигән булды әтисе. – Маладис! – Кулы белән тантаналы шәрехләр ясап, кызына тагын бер келиндер тоттырды. – Мә әле... Тугыз кайчан тула соң?

– Икенче елга! Ә син миңа бүләк әзерләдеңме? Нәрсә әзерләдең?

Әтисе дәшмәде. Шуңа күрә, тәвәккәлләп, кыз кабат үзе сүз кузгатты:

– Әти... – диде ул, бераз каушап, кыенсынып кына. – Миңа бернинди бүләк тә кирәкми. Син... бүген эчмә генә инде, яме?

Әтисе кабат дәшмәде. Үзенә ошамаган сүз әйтсәң, дәшми ул. Канәгатьсез генә кашын җыера. Бу юлы да шулай булды. Мәрьямен әйтер идең... Тәки кызын атасына каршы котыртып йөри бит, җен хатын... Илүзәнең һәрдаим аккан күз яшьләре дә, кайтмый калса, төнге авыл буйлап әтисен эзләп йөрүе дә, һәммәсе дә – фәкать хатынының агу сиптерүе, котыртуы нәтиҗәсе. Тирәнгәрәк төшеп карасаң, ирнең салып йөрүенә дә шул хатын гаепледер әле!

Әтисе чәен эчеп бетереп, чынаягын шалт итеп тәлинкәсенә каплады да өстәл яныннан кузгалып китте...

Мәктәптә Илүзә өчен иң бәхетле көннәренең берсе булгандыр бүген: укытучылары да, сыйныфташлары да котлап кына тордылар, ә бер малай – Инсаф – хәтта чәчәк бүләк итте. Ромашка! Кыланчык... Мәктәп бакчасыннан өзеп алгандыр әле.

Барыбер күңелле...

Дүшәмбе дүрт дәрес укый алар – математика, уку, язу, рәсем. Өчесеннән бишле алды-алуын, ә менә рәсемнән – киләсе дәрестә тикшерербез дип калдырдылар. Туган көнендә көндәлекнең һәр графасында кып-кызыл бишле балкырга тиеш иде лә!

Шуңа бераз үпкәләп кайтып баруы әле...

Их, нинди матур көн! Ничек җылы, ничек рәхәт. Ә болытлар... Зәп-зәнгәр! Илүзәнең күзләреннән дә зәнгәррәк төсле алар бүген. Тар гына сукмак бакча артыннан түбән очка сузылган. Шул сукмак тирәсендә – ямь-яшел чирәм, бакчада – алмагач, алмагачларда – кошлар... Карале, ә тегендә, агач төбендә... Нәрсә анда? Илүзә куркып, һушы-аңына килә алмыйча, җирдә аунаган кешегә иелде:

– Әти... Әйдә, тор инде, кайтыйк инде...

Лыгыр исерек бәндә авыз эченнән генә нидер быгырдап, борылып ятты.

– Әти, кайтыйк инде... – Атасы янында кыз азмы-күпме бөтерелгәч, зур гәүдәле, чырае калмаган ир-ат күтәрелде, Илүзәне кулыннан җитәкләп, икәү атлап киттеләр...

– Әти, ник эчтең инде...

Әтисе җавап бирмәде.

– Минем бит туган көн... Хәзер тагын әни кычкырыр, тагын талашырсыз инде...

Алда тыкрык иде, алар, шуннан борылып, урамга төште. Җил куып йөргән малайлар ата белән кызга төртә-төртә көлешеп, яннарыннан уза торды. Урам буе тезелгән карчыкларның әледән-әле авыр уфтанып, җирәнгеч-әче тавышлары белән чәрелдәгәне бер генә минутка да колагыннан китмәде кызның:

– Имансыз...

– Нурсыз...

— Көпә-көндез эчеп җөр инде...

Ата, анын янәшәсеннән кызы атлады. Әтисен житәкләгән көе, әкрен-әкрен, ул тайпылган якка тайпылып, ул абынгандай итсә, аны тотып калырга тырышып атлады бичара... Юк, елыйсы килми иде анын, килми иде! Ләкин йөрәге моны аңларга теләмәде ахры — чык тамчысыдай саф һәм гөнаһсыз яшьләре янагы буйлап тыела алмыйча актылар да актылар...

## Җиңү бәйрәме

Мөслимәттәй парланган тәрәзәне кытыршы кулы белән акрын гына сөртеп алды. Төрле төстәге шарларны, кызыл әләмчекләрне иртәнге дымсу һавага чөеп, патриотик җырлар җырлап узган укучылардан соң бермәл тынып торган авыл кабат һушына килеп бара иде: әнә, Әминәттәйнен кәҗәсе Мәймүнәттәйнең урам бакчасында, чәчәкләр арасында утлап йөри, киртә башына кунган кып-кызыл әтәч хуҗабикәсен кисәтергә теләпме, әледән-әле бер — йортка, бер — кәҗәгә карап, озак итеп, югары нотага үрелеп житәргә теләгән опера җырчысыдай, сузып-сузып «моңлана». Канауга җыелган суда Хафизәттәйнең ике үрдәге чупырдый. Ул арада түбән очта кайсыныңдыр тракторы зәһәр итеп үкереп җибәрде...

Ләкин хикмәт анда түгел.

— Абдул менә, — дип үзалдына әйтеп куйды Мөслимәттәй.

Чыннан да, агач аягын өстерәп кенә, таякка таянып, акрын гына, авыр гына (гүя сау аягына туры килгән басымны да тулысынча таякка күчерергә теләп), авылның бүгенгә исән калган бердәнбер ветераны — түше орден-медальгә тулы Габделхәй карт — югары очка таба титаклый иде.

— Һ-э-е-й, әзмәвер вакыты барые Абдулның... Авылга бер Абдулые ул...

Мөслимәттәй үзе белән үзе сөйләшергә күнегеп китте. Хәер, үзенә бер дә сөйләшәдер кебек тоелмый, ахры, аңа, уйланып кына йөрим дип уйлый кебек ул. Һәрхәлдә, шундый вакытларының берсендә кем дә кем: «Нәстә дисең?» дип сораганга аптырап, бик тә гаҗәпләнеп, күзләрен мөлдерәмә тутырып тик карап тора. Колак ягы да саграк. Үзе яхшы ишетәм, ди тагын, сүзләренең мәгънәсенә төшенеп кенә житмим, аңышып кына бетермим, ди.

Ачык форточка аша урам яктан Габделхәй картның ачулы, тозлы-борычлы сүгенү тавышы ишетелде:

— Аһ, жаппашмайт мал, кая кергән бит сана... Беткәнмени сиңа чемченер урын!

— Майданга менүедер инде монын, ие, — диде Мөслимәттәй. Болай сөйләнеп йөргәндә анын җөмләсенең башы-азагы, кем әйтмешли, атасы-анасы булмый. Әйткән фикере кәлтә койрыгыдай өзелеп-өзелеп кала, җөе сүтелгән дисбе гәрәбәләредәй, тәгәрәп-тәгәрәп китә дә, әллә кай почмакларга кереп югала.

Мөслимәттәй үзе ветераннар исәбендә түгел...

Вакытында андыйлар башка төркемгә карый иде, заманалар үзгәрсә дә, ничектер, Мөслимәттәйнең статусы үзгәреш кичермәде. Шулай да бәйрәмне күрәсе килә анын. Моңарчы калдырмаска тырыша иде, әмма нишләмәк кирәк — үзе дә Габделхәй карт кебек тузды, таушалды. Кан басымы уйный хәзер, башы әйләнеп китә, барган юлда егылырмын да, ни күрчесе, ни күтәреп алучысы булмас, Алла сакласын дип шикләнә. Югыйсә ул да, үзе әйткәндәй, авылга бер иде бит!

Менә шәһәрдән оныгы кайтты әле... Машинасында җилдереп кенә алып менеп тә куяр, бәлки? Кайтышлый Саниягә дә сугылып чыгарлар — сеңелесе ул анын, ничә ел инде түшәк өстендә ята. Мөслимәттәйнен

дә иң курыкканы шул: үләр вакытлар житеп тә үлә алмыйча, кеше кулына калу, үзеңне дә, тәрбияләүчеңне дә җәфалау, интектерү. Килде икән, яхшы итеп, егетләрчә килсен инде ул үлем, мәрхүм ире ярәшергә килгәндәге кебек килсен — култык астына кыстырсын да, кычкыру-фәләнгә карап тормыйча, күтәреп алып та китсен.

— Бик бәхетле тордык, Аллага шөкер. Миннән соң син дә озак тормассың инде, дигәние, умбишенче җыл менә...

Мөслиматтәй ике буралы кечкенә генә йортта яши. Йорты гади, искитәрлек мебель-мазар белән тутырылмаган, әмма чиста, пөхтә. Ишектән килеп керүгә — кече як, аш бүлмәсе. Аннан уңга борылып чыксаң — зал, олы як. Залда — карават, караватның каршы ягында — диван, турыда, тәрәзә кырыенда — телевизор яшниге. Үсмер егет — оныгы — җаны-тәне белән экранга сеңгән. Тегесе исә туктамый сөйли: Мәскәүдә такырбашлар тагын бер үзбәк егетен суеп үтергән...

Мөслиматтәй, авыр ыңгырашып, караватка ятты. Ул әледән-әле нидер уйлана, аннан, телгә килеп, сөйләнә иде. Дөрес, оныгы аны тыңламады.

— Шахтыга киткәнейек бит... Әтәй-әнәй җилкәсендә торганчы, үз көнебезне үзебез күрик, берәр ничек җан асрарбыз әле, дидек. Дамбасс... Ие... — Ул хәл алырга теләгәндәй, дәшми торды. Гүя мизгел эчендә узган туксан ел гомерен ашык-пошык, кабаланып кына исенә төшерә, җыерчыклы куллары белән саксыз рәвештә тәртип-тәртип тезелгән елларны, вакыйгаларны капшый-капшый, җимерә-вата хатирә сандыгында актарына иде. — Бик каты килде шул, бик каты килде... И, җәе бигрәк матурые бит... — Ул тагын беразга тукталды. — Берзаманны куып чыгардылар безнең бөтенебезне дә, әйдәгез, акуп казыгыз, җәнәсе... Пелиндә... Җыен карт-коры, бала-чага, хатын-кыз инде без... Ашамаганнар, талчыкканнар, лум белән туң төябез... Ие... — Карчык торып утырды. Алай-болай чыннан да сөйләнеп утырмыйммы икән, дигән кебек, оныгына күз салды. Егет битараф иде. Мөгаен, эчемнән генә уйланамдыр, дип тынычланды Мөслиматтәй. — Бер сабый и китте жөгереп урманга таба. Өч-дүрт яшьләр тирәсендә бит инде — кая китә алсын инде, җә! Үзе җылый, үзе чаба, бичарам. Мыеклысы тегенең, әфисәр... җылмайды да мылтыкка басты... Тәгәрәде дә китте бала... Артыннан анасы ташланган иде — мылтык башы белән муен артына гына бәрделәр. Калды шунда җатып... Их... — дип уфтанып ук куйды ул. — Андагы күргәннәр, андагы күргәннәр... Тик мин кайттым менә. Үч итеп кайттым... Фашистларга үч итеп, Гитлерга үч итеп, үлемгә үч итеп! Туган җакка... Ие... Матур яшәдек, Аллага шөкер... — Карчык сүзсез калды... Аның белән бергә телевизор сөйли иде... Тәки бәйрәмгә алып менмәсме икәнни инде бу? Көннәр буе шул яшник, татарчаны караса бер хәл әле. Нәрсә яшеренгән микән шул җен тартмасында? Сеңелесе янына да кереп чыгасы килә иде бит...

— Нәрсә күрсәтә, улым?.. Кемнәр бу? — диярргә базды Мөслиматтәй.

— Фашистлар, — диде егет, битараф кына. — Сез җингән фашистлар. Үзбәк егетен суйганнар...

Карчык, болай да кечкенәлегенә карамастан, тагын да кечерәебрәк, шиңебрәк, бөгәрләнебрәк калды, йөзе агарып чыкты. Бераз кымшанмый утырганнан соң, нибары:

— Ие, — дип үзалдына әйтте дә, стенага борылып, яңадан караватка ятты. Аңламады ул оныгының ни әйткәнен. Ишетте дә кебек үзе... Хәер, оныгының җавабы аңа кирәкми дә иде.

Василий
Шукшин

# АНА ЙӨРӘГЕ

ХИКӘЯ

***Василий Макарович Шукшин (1929-1974) егермедән артык фильмда уйнаган, һәр башкарган роле халык күңеленә кереп калган гаять талантлы артист кына түгел, ә гаҗәеп оста хикәяче дә иде. Ул кеше психологиясен бик яхшы белгән, шуларны үз геройлары образларында гаять зур осталык һәм фәлсәфи тирәнлек белән күрсәтә алган олуг шәхес иде.***

***Аның күпкырлы эшчәнлеген күз алдына китерү өчен үз повесте буенча үзе сценарий язып, үзе төшергән һәм үзе үк төп герой ролен уйнаган «Калина красная» фильмын күрсәтү дә җитә.***

***Без укучыларга аның бер хикәясен тәкъдим итәбез.***

Витька Борзенков район шәһәре базарына барып йөз илле сумга дуңгыз мае сатты да (ул өйләнергә җыена, шуна күрә акча бик кирәк иде), бу эшне бер-ике стакан кызыл белән «юып» алырга дип, шәраб сата торган кибеткә юнәлде. Аннан чыккач, тәмәке кабызып җибәрде... Шулчак янына яшь кенә бер кыз килде дә:

— Кабызырга рөхсәт ит, — дип сорады.

Витька аңа үз папиросыннан ут кабыздырды, ә үзе кызыксыып кызның йөзен күзәтергә кереште — кыз яшь, аның йөзе шешенгән, куллары калтырый иде.

— Махмырданмы? — дип сорады ул туп-туры.

— Сон, — дип кыз да, рәхәтләнеп «Беломор» суыра-суыра, гади һәм туры жавап бирде.

— Ә баш төзәтергә сәмән юкмы? — диде авыр чакларында кешеләрне аңлый алуыннан канәгать булган Витька, үзенең уен дәвам итеп.

— Ә синең бармы сон?

(Витька үзе дуңгыз мае сатканда бу кызның аның артыннан читтән генә күзләп, менә хәзер кибет янында аны махсус сагалап торуына беркайчан һәм берничек тә ышанмас иде.)

— Киттек, төзәл әйдә. — Витькага кыз ошады — сөйкемле иде ул, сылу... Ә шешенкеле булуы һәм бигрәк тә үзенең акчасы юклыгы хакында турыдан әйтеп салуы хәтта аны ничектер дулкынландырып та җибәрде.

Кибеткә керделәр... Витька бер шешә кызылны һәм ике стакан алды. Үзе стакан ярымын эчеп җибәрде дә, калганын эчкерсезлек белән кызга

салды. Тагын болдырга чыгып, кабат тәмәке кабыздылар. Витькага рәхәт булып китте, кызга да. Икесенә дә яхшы иде.

— Монда яшисеңме?

— Менә монда, якында гына, — дип ымлады кыз. — Рәхмәт инде сиңа — җиңел булып китте.

— Бәлки, тагын телисеңдер?

— Мөмкин, гомумән алганда... Тик монда түгел.

— Ә кайда соң?

— Миңа барырга була, минем өйдә беркем дә юк...

Витьканың күкрәгендә ниндидер татлы-шома хис койрыгын болгап алды. Әле вакыт иртә, ә авылына автобус белән сәгать ярым гына кайтасы — аңарчы әле күп нәрсәгә өлгерергә була.

— Минем анда иптәш кызым да бар әле, — дип куйды кыз, Витька үзе белән күпме нәрсә алырга кирәклеге турында уйлап маташканда. Шуңа күрә ул бер шешә ак белән ике кызылны алды.

— Кабымлык белән җиңәрбез, — диде ул. — Кабар нәрсә бардыр бит?

— Табарбыз.

Алар базардан күптәнге дуслар кебек чыгып киттеләр.

— Нигә килгән идең?

— Дуңгыз мае саттым... Акча кирәк — өйләнәм.

— Чынмы?

— Өйләнәм. Җитәр бурлак шикелле йөрергә. — Гаҗәп, Витька үзенең ярәшкән кызына карата начар гамәл кылуы — менә хәзер таныш булмаган кыз белән каядыр баруы турында хәтта уйлап та карамады. Хәзер аңа аның белән сөйгән кызыннан да яхшырак, кызыклырак шикелле тоелды.

— Яхшы кызмы соң?

— Ничек дияргә?.. Йорт җанлы. Яхшы хуҗабикә булачак.

— Ә мәхәббәт мәсьәләсендә ничек?

— Ничек дияргә?.. Элеккеге кебек — алай менә монда нәрсәдер кайнарлатып, тынгысызлап торгандагы шикелле түгел, — андые ук юк. Болай... Кайчан булса да өйләнергә кирәк ич.

— Ялгыша күрмә. Йөрерсең аннары... Бәйләмәгән килеш чинарсың.

Гомумән алганда, шундыйрак рухта сөйләшә-сөйләшә кыз йортына да килеп җиттеләр. Аның исеме Рита иде. Витька ниндидер тыкрыклар аша ничек барганнарын да, монда ничек килеп җиткәннәрен дә абайламый калды. Өйләре гадәти генә — иске, караңгы, ләкин әле тагын җитмеш еллап торыр, уйламас та.

Бүлмәдә (алар өчәү иде) чиста, пәрдәләр, өстәлләрдә ашъяулыклар — уңайлы. Хәтта Витьканың күңеле күтәрелеп китте.

«Фырт иткән, ялтырый — тру-ля-ля». — Ул үзенә тормыш шатлык вәгъдә иткән чакларында гел шулай уйлап ала торган иде.

— Ә иптәш кызың кайда соң?

— Хәзер чакырып киләм. Утырып торасыңмы?

— Торам. Тик тизрәк йөр, ярыймы?

— Күңелсез булмасын өчен, әнә радиоланы куй. Мин тиз генә.

Витькага бу кыз белән нишләп шулай җиңел, яхшы соң әле? Үзләре ниндидер биш минут кына танышлар, ә... Әй, тормыш! Кызның күзләре монсу, уйчан, акыллы. Аңа бу кыз йә кинәт ничектер кызганыч булып тоелды, йә аны кочагына алып кысасы килде.

Рита чыгып китте. Витька бүлмәдә йөренергә тотынды — радиоланы куймады: йөрәге ансыз да ниндидер бәхетле мизгелне сизенеп тибә иде.

Ул инде соңыннан гына хәтерләде:Ританың иптәш кызы килде, анысы ямьсезрәк, олырак, таушалган һәм кыланчык. Килеп керүгә үк такылдый башлады, кайчандыр үзенең циркта булуы, анда ниндидер «каучук эшләве» турында сөйли башлады. Аннары эчтеләр... Витька шундук, өстәл янында ук, Ританы үбеп алды, иптәше исә, моны хуплап көлде, ә Рита, карышкан сыман, аны үзеннән этәргәндәй, Витьканың иңбашына суккалаган булды, үзе һаман аңа сылана барды, муеныннан кочаклап алды.

«Менә бу — тормыш! — дигән уй бөтерелде Витьканың кайнар башында. — Менә кайда ул ымсындыргыч чир. Булдырам бит мин!»

Аннары Витька берни дә хәтерләми — кисеп ташлаган шикелле. Кичен соң гына ниндидер койма янында исенә килде... Озак кына үзенең кайда икәнен, аның белән ни булганын хәтеренә төшерергә теләп азапланды. Башы шаулый, авыртудан чигәләре ярылыр сыман. Авызы кипкән, иреннәре ярылып беткән. Көч-хәл белән генә Рита исемле кызны хәтерли алды... Һәм аңлады: нәрсәдер эчертеп мыңгырәүләндергәннәр һәм, әлбәттә, акчасын алганнардыр. Акча турындагы уй аны тетрәндереп җибәрде. Ул авырлык белән генә торып басты да бөтен кесәләрен капшап чыкты: әйе, акчасы юк. Витька, коймага сөялеп, тирә-ягына күз ташлады... Юк, якын-тирәдә Рита өенә охшаган бернинди йорт та юк иде. Монда бар нәрсә дә башка, бөтенләй бүтән йортлар.

Витьканың бер җирендә кирәк-яракка дип базарда ук яшереп куйган ун сумлыгы бар иде. Капшап караса, унлык шунда, урынында. Витька кая барганын да белмичә, берәр кешене очратырга өметләнеп, урыныннан кузгалды. Ниндидер бер карттан автобус станциясенә ничек барырга кирәклеген сорады. Алай ерак түгел икән үзе, турыга барасы да, аннары тыкрык буенча сулга һәм урам буйлап уңга да тагын турыга. Аннары, карт әйтмешли: «Һәм автобус станциясенә үк килеп чыгасың». Витька шунда таба атлады. Автобус станциясенә барып җиткәнче күңелендә шәһәр угрыларына шундый усаллык туплады, аларны, сорыкортларны, шулхәтле күралмады, хәтта аның баш авыртуы да кими төште һәм анда ниндидер явыз ачыклык туды, бик зур үч алырлык көч барлыкка килде.

— Ярар, ярар, — дип мыгырданды ул, — күрсәтермен әле мин сезгә...

Нәрсә эшләргә җыена, ул анысын ачык белми, бары тик моның яхшылык белән бетмәячәген генә чамалый иде.

Автобус станциясе янындагы кибет бик соңга тикле эшли, анда һәрвакыт кеше күп була. Витька бер шешә кызыл шәраб сатып алды һәм, аны күтәреп төбенә хәтле эчеп бетергәч, буш шешәсен скверга томырды. Ә аның яныңдарак кына өч исерек ир-ат басып тора икән.

— Анда кешеләр булуы мөмкин ич, — диде аңа шуларның берсе.

Шунда Витька флот каешын ычкындырды да очын кулына чорнады, аның авыр, җиз тәңкәле башын кистән сыман иректә калдырды. Бу өчәү аңа бик вакытлы килеп чыккан шикелле тоелды.

— Йә?! — диде Витька. — Чыннан да кешеләрме? Бу бетле шәһәрчектә кешеләр дә бармыни әле?

Теге өч ир-ат үзара карашып алды.

— Ә кемнәр соң монда, синеңчә?

— Әнчекләр! Каучук эшлисез, әйеме?

Өчәү аңа таба килә башлады, Витька аларга каршы китте... Берсе, башына җиз тәңкә белән сугуга, шундук егылды, калган икесе Витькага аяклары белән тибәргә яисә куллары белән сугарга маташты, шул ук вакытта башларын сакларга да тырышалар иде.

Аннары алар:

— Безнекеләрне кыйныйлар! — дип акырды.

Шуннан соң тагын бишләп кеше очынып килде. Витьканың үзенә дә эләкте: кайсысыдыр артыннан шешә белән башына китереп сукты, ләкин кыйгачрак эләкте — ул егылмыйча аягында торып калды. Аның хурланган җаны моңа куанып куйды һәм бөтенләй тынычланып калгандай булды.

Һөҗүм итүчеләр сүгенде, мәгънәсез рәвештә өерелешеп бер-берсенә комачаулады, кинәшләр биреште. Витька моннан файдаланып сукты да сукты.

Тиздән милиция килеп җитте... Барысы бергәләп Витьканы почмакка — кибет белән койма арасына кысрыклады. Ул бирешмәскә тырышты. Милиционерларны алга үткәрделәр, һәм Витька, җүләрлеге белән, аларның берсенә җиз тәнкәсе белән китереп сукты. Җиз тәнкәсе тагын шуның белән дә куркыныч — аның эчке ягына, бөгелгән җиренә кургашын эретеп ябыштырылган иде. Милиционер егылды. Барысы да аһ итеп катып калды. Шунда Витька төзәтеп булмаслык нәрсә килеп чыгуын аңлап алды да каешын җиргә ташлады. Аны КПЗга алып барып яптылар.

Витяның әнисе бу бәхетсезлек турында икенче көнне белде. Иртән аны участок милиционеры чакыртты да Витяның шәһәрдә нәрсә-нәрсә эшләп ташлавы турында хәбәр итте.

— Йа Алла! — дип куркуга төште ана. — Нәрсә була инде аңа хәзер моның өчен?

— Төрмә. Чынында төрмә. Милиционер яраланган, хәзер больницада ята, ди. Мондый эшләр өчен — бары төрмә генә. Биш ел бирергә мөмкиннәр. Нәрсә ул, җүләрләнгәнме әллә?

— Атакаем, Ходам фәрештәсе, ничек булса да ярдәм итә күр! — дип ялварды ана.

— Син нәрсә! Мин ничек ярдәм итә алыйм?..

— Эчкән булгандыр ул, эчкәч җүләрләнә шул...

— Берни дә эшли алмыйм мин, аңла шуны! Ул КПЗда хәзер, инде аңа җинаять эше дә ачканнардыр...

— Ә кем булыша алыр иде икән соң?

— Беркем дә. Кем?.. Булмаса, милициягә барып кайт, ничек-ничек булганын белеш. Тик анда да... Алар да нишли алыр икән анда?

Витьканың кибеп беткән, ләкин нык-чыдам, аякка җинел әнисе авылда бөтерелергә кереште. Авыл советы председателе янына йөгереп килде, тик ул да кулларын гына җәеп җибәрде:

— Мин ничек булыша алыйм ди? Ярар, характеристика яза алам... Хәер, анысын барыбер язарга туры килер, мөгаен. Ярар, яхшы итеп язармын.

— Яз, яз, яхшырак итеп яза күр, безнең акыллы башкаебыз бит син. Исерек баштан гына шулай ул, ә аек чагында чебенне дә рәнҗетми, дип яз...

— Анда бит, исерек баштанмы яисә исерек баштан түгелме, дип сорап тормыйлар... Менә нәрсә: теге милиционерга барып кайт әле син, бәлки, ул аны алай ук имгәтмәгәндер дә. Хәер, шулай микән...

— Менә рәхмәт сина, фәрештәбез син безнең, менә рәхмәт...

— Рәхмәт әйтер сәбәбе юк әлегә...

Ана районга чыгып чапты. Ул үз гомерендә биш бала тапты, ирдән иртә калды (42 нче елда әтисенең үлеме турында кара хәбәр килгәндә Витька имчәк баласы гына иде әле), өлкән улы да 45 нче елда һәлак

булды, кызы 46 нчы елда ябыгудан хәлсезләнеп үлде, калган ике улы исән калып, малай килеш үк ФЗУга алындылар һәм хәзер төрле шәһәрләрдә яшиләр. Әнисе Витьканы бөтен көчен куеп саклап кала алды, бар булган нәрсәсен сатса сатты, барыбер кеше итте — ул көчле-нык булып, буйга-сынга матур, мәрхәмәтле булып үсте... Болай барысы да яхшы иде, тик исерек килеш җүләрнең җүләре булып китә. Әтисенә охшаган — анысы, авыр туфрагы җинел булсын — авылда бер сугышуны да калдырмый иде.

Ана милициягә анда нәкъ автобус станциясендәге кичәге хәлне тикшергән вакытта килеп керде. Витька милиционерны ярыйсы ук «сыйлаган» — ул чыннан да больницада ята икән. Тагын ике исерекбаш та больницада ята ди — алар да Витьканың җиз тәнкәсеннән зыян күргән.

Ул җиз тәнкәне бик кызыксынып карап утыралар иде.

— Уйлап тапкан бит, кабахәт! Белеп кара син аны: каеш та каеш. Ә анын монда гер диярлек. Ярый әле кырыны белән эләкмәгән...

Шушы вакытта Витьканың әнисе килеп керде. Ул ишек бусагасын атлап керүгә үк тезләренә егылды да үкереп, такмаклап еларга тотынды:

— Фәрештәләрем сез минем, акыллы башлар!.. Ничек булса да оныта күрсәгез иде инде сез үзегезнең үпкәгезне — гафу итә күрегез ул каһәр сукканны! Исерек булган... Ул аек чакта кешегә соңгы күлмәген салып бирергә әзер, аек килеш гомерендә беркемне рәнҗетмәде...

Өстәл янында кулына Витьканың каешын тотып утырган олырагы сүз башлады. Бик тәфсилләп, тыныч кына, ана кеше аңласын өчен гади генә сөйләде ул.

— Тукта әле син, ана... Тор син, тор — монда чиркәү түгел. Кил, кара менә...

Начальник тавышының ягымлылыгыннан тынычланган ана аягына торып басты.

— Менә кара: синең малаең каешы бу. Ул флотта хезмәт иткән идеме әллә?

— Флотта, флотта, әнә теге корабльләрдә...

— Хәзер кара инде: күрәсеңме? — Начальник җиз тәнкәне әйләндереп кулында үлчәп карады. — Моның белән кеше үтерү — ике җирдә икең шикелле. Кичә ул кемгә булса да шушы нәрсәнең кырыны белән эләктергән булса — беткән иде. Үтереш! Әле болай да өч кешегә шундый итеп сылаган, хәзер врачлар аларның гомерләре өчен көрәшә. Ә син, гафу итәргә, дисең. Ул бит өч кешене больницага салды. Ә берсен хезмәт вазифасын үтәгән чагында. Үзең уйлап кара: чынында шушындый эшләр өчен ничек гафу итеп булсын?

Йөрәге гакыллы булса да, үзенең газиз баласына бәла янаган җирдә ана башкаларның акылын кабул итәргә сәләтсез иде. Монда логиканың берниндн катнашы да юк.

— Улларым-бәгырьләрем сез минем! — дип кычкырып җибәрде ана һәм елый башлады. — Исерек килеш булгаламый торган эшмени соң?! Төрлесе була бит — сугышканнар инде... Кызгана күрегез сез аны!..

Анага караву авыр иде. Анын тавышында шундый сагыш һәм кайгы, шундый өметсезлек чагыла иде ки, хәтта аны тыныч кына тыңлавы да читен. Хәтта моңа гадәттә кызгануга бик һәвәс булмаган милиционерларның да кайберләре түзә алмады — кайсы карашын читкә борды, кайсы тәмәке тарта башлады...

— Берәү генә ул минем янымдагысы: ашатучым да шул, эчертүчем дә. Житмәсә, өйләнергә уйлаган иде, ул чагында ул кыз белән ничек булырга

соң, әгәр аны утырта калсалар? Ул аны күтәп тора димени? Күтми. Ә кыз игелекле, яхшы гаиләдән — кызганыч...

— Ул шәһәргә ни өчен киткән иде? — дип сорады начальник.

— Дуңгыз мае сатарга. Базарга — май сатарга. Инде туй көнен билгеләгәч, акча бик кирәк иде. Башка кайдан аласың аны?

— Аның бернинди акчасы да юк иде.

— Йа Алла! — дип куйды ана, куркынып. — Ә кайда соң алар?!

— Монысын аннан сорарга кирәк.

— Урлаганнардыр, мөгаен! Урлаганнар!.. Соң, улым-бәгърем, ул, күрәсең, шуңа күрә сугышырга тотынгандыр да — урлаганнар аны аннан!.. Караклар урлаган...

— Караклар урлаган, ә безнең хезмәткәрнең монда ни катнашы бар? Ул аны ни өчен кыйнаган?

— Соң, кызган вакытта арага килеп кергәндер, мөгаен.

— Әгәр дә кызган чакта арага кергән өчен менә шулай эләгә башласа, тиздән безнең милициядә эшләр кеше дә калмас. Бигрәк тә кызу канлы инде алар, сезнең малайлар! — Начальник торган саен кырыслана барды. — Моның өчен кичереп булмый, үзенекен алыр — закон буенча.

— Фәрештәләрем сез минем, мәрхәмәтлеләрем! — дип тагын ялварырга тотынды ана. — Мине, карчык кешене булса да кызгана күрегез, мин бит дөньяны да менә хәзер генә күрдем диярлек... Ул бик эшчән егет, өйләнеп тә җибәрсә, бөтенләй хәлле ир-ат булачак. Мин ичмаса оныкларны карар идем...

— Эш бездә дә түгел, ана, аңла син. Прокурор бар бит! Ярар, без аны чыгардык та ди, ә бездән, ни өчен, дип сораячаклар. Без булдыра алмыйбыз. Андый хокукыбыз юк. Чынында аның өчен мин үзем утыра алмыйм бит инде.

— Ә бәлки, ничек тә теге милиционерны җайларгадыр? Минем тукымам бар — мин быел күп итеп тукыдым! Барысын да аларга дип әзерләгән идем...

— Бернәрсә дә алмаячак ул синнән, алмаячак! — дип, начальник инде кычкыруга күчте. — Чынында, кешеләрне көлке хәлгә куйма син. Бу бит сиңа кода белән коданың үзара эләгешеп алуы гына түгел!

— Кая барырга соң миңа хәзер, улларым? Тагын сездән югарырак кем дә булса бармы, әллә юкмы инде?

— Прокурорга барып карасын, — дип киңәш бирде шундагыларның берсе.

— Мельников! Озатып куй аны прокурорга, — диде начальник һәм үзе, тагын анага таба борылып, аның белән тагын чукрак яки аңгыра белән сөйләшкәндәй сөйләшергә кереште: — Прокурорга барып кара, ул бездән югарырак! Бу эш анда инде. Аңлатсын ул сиңа: без берәр нәрсә эшли алабызмы, әллә юкмы? Сине беркем дә алдамый бит, шуны аңла син!

Ана милиционер белән прокурор янына китте. Барышлый юлда ул милиционер белән сөйләшеп алырга тырышты.

— Нәрсә, улым, ул аңа каты сукканмыни?

Нindидер уйга талган милиционер Мельников дәшмәде.

— Күпме бирерләр икән соң аңар, әгәр хөкем итә калсалар?

Милиционер эре адымнар белән атлавын дәвам итте. Дәшмәде.

Ана аның яныннан терек-терек итеп бара һәм, бу озын буйлы кешене сөйләштерергә теләп, аның йөзенә караштыра.

— Син аңлат инде миңа, улым, дәшмичә барма... Синең дә әниең бардыр,

кызганыч бит сез, шундый кызганыч, үзем сөйләшеп барам менә, ә һәр сүзем йөрәгемә кадала. Күпме бирерләр икән?

Бу юлы милиционер Мельников бик томанлы гына җавап бирде:

— Менә каберләрне бизәгәндә, аның өстенә рәшәткә, баганалар куялар, чәчәкләр салалар... Нәрсә, бу үлгәннәргә кирәкмени? Бу — тереләргә кирәк. Үлгәннәргә аларга барыбер инде.

Ананы шундый курку хисе биләп алды, хәтта ул барган җиреннән туктап ук калды.

— Син нигә дип әле моны?

— Киттек. Шуңа мин: әлбәттә, хөкем итәчәкләр. Әлбәттә, кичерә дә алырлар иде: исерек булган, акчасын урлаганнар — кешене рәнҗеткәннәр. Ләкин барыбер хөкем итәчәкләр, башкалар белсен өчен. Шушы мисалда башкаларны өйрәтү мөһим...

— Үзең, исерек булган, дисең бит!

— Хәзер монысы исәпкә алынмый. Аны беркем дә көчләп эчертмәгән, үзе эчкән. Ә бу башкаларга сабак булыр. Аңа хәзер барыбер утырасы инде, ә башкалар уйланыр. Башкача сезне беркайчан да тәрбияләп булмый.

Ана бу озын буйлының да үз улына карата тискәре караштa икәнен аңлап алды да тынып калды.

Прокурор анага беренче караштан ук ошады — игътибарлы. Ананың үз улы Витька турында яхшы, мәрхәмәтле, аек килеш чебенне дә рәнҗетми, хәзер аңа ничек итеп берүзенә генә калырга дип озын һәм буталчык итеп сөйләвенә карамастан, ул аны игътибар белән тыңлады. Янәсе, аның сөйгән кызы Витьканы көтмәс, ә андый унган-булган кызны аягы-кулы белән тартып алачаклар — яхшы кыз. Прокурор боларның барысын да игътибар белән тыңлап торды да бармакларын өстәлдә уйнатып алды. Аннары сүзен ерактан, ничектер сәер башлады:

— Менә син — крестьянка, сез, мөгаен, гаиләдә ишле булып үскәнсездер?

— Уналты, атакай. Ундүрте исән-сау, икесе кечкенә чакта ук үлделәр. Павел үлде, ә аның артыннан туган икенче малайга да Павел дип куштылар...

— Күрәсез, — уналты! Үзе бер кечкенә җәмгыять. Гаилә башында — әтиегез. Шулаймы?

— Шулай, атакай, шулай. Әтине тыңлый идек...

— Менә! — Прокурор ананы үз сүзендә тотты. — «Тыңлый идек!» Ә ни өчен? Берәрсе этлек эшләдеме, әти кеше аны каеш белән! Ә башкалары әтинең аны ничек өйрәтүен карап тора һәм, этлек эшләргәме, әллә юкмы, дип уйлыйлар. Ишле гаиләдә тәртип әнә шулай урнаштырылган. Бары шулай гына. Әти кеше берсен, икенчесен кичерсә, гаиләдә ни килеп чыга? Таркалу! Мин аңлыйм сине, сиңа кызганыч... Беләсең килсә, миңа да кызганыч — анда курорт түгел һәм, барысын да исәпкә алганда, ул анда бер сезонга гына да бармас. Кешеләрчә барысы да аңлашыла, ләкин югарырак төшенчәләр дә бар бит әле, менә анда без көчсез инде... Хөкем итәчәкләр. Күпме бирерләр — белмим, анысын суд билгели.

Ана аңлады: аның улын монысы да яратмый. «Үзләренеке өчен үпкәләделәр», — дип уйлап алды ул.

— Атакай, ә синнән дә югарырак кем дә булса бармы?

— Ничек инде? — Прокурор тиз генә аңлый алмады.

— Син иң зурысымы, әллә синнән дә югарырак кеше бармы?

Гәрчә аннары үзенә дә унайсыз булып китсә дә, прокурор ирексездән көлеп куйды.

— Бар, ана, бар. Күп!

— Кайда соң алар?

— Кайда дип... Өстәге оешмалар бар... Син нәрсә, шунда барырга телисеңме? Киңәш итмим.

— Миңа мәрхәмәтле кешеләр әйтте: хәзер, хөкем иткәнче коткарырга кирәк, аннары авыррак булыр, диделәр...

— Ул кешеләргә әйт, сез мәрхәмәтле түгел, диген. Алар читтән караганда гына мәрхәмәтле кебек... Кем шундый киңәш бирде сиңа?

— Киңәш иттеләр инде...

— Бар, соң. Юлга акчаңны гына тотып бетерерсең, нәтиҗәсе шул ук калыр. Мин сиңа рәсми рәвештә әйтәм: хөкем итәчәкләр. Хөкем итмичә ярамый, хакыбыз юк. Бу судны беркем дә булдырмый кала алмый.

Ананың йөрәге авыртып кысылып куйды. Ләкин ул прокурорга рәнҗүле иде, шуңа күрә, шушында гөрселдәп авып китмәскә һәм үкереп елап җибәрмәскә тырышып, көчкә басып торуын күрсәтмәде. Аның аяклары сыгыла иде.

— Ахырында аның белән күрешергә рөхсәт ит...

— Монысы мөмкин, — дип шундук килеште прокурор. — Аның нәрсә, акчасы күп булган диләрме?

— Булган...

Прокурор кәгазь битенә нәрсәдер язды да анага бирде.

— Шушының белән милициягә бар.

Милициягә юлны ана үзе генә, озын буйлыдан башка гына тапты — ул юк иде инде. Ничек барасын кешеләрдән сораштырды. Ананың күз алдында бөтен нәрсә томанланды һәм йөзде... Ул сүзсез генә елады, яулыгының очы белән яшьләрен сөрткәләде, ләкин, гадәтенчә, тиз-тиз атлады, тик кайчак кына тротуарның чыгып торган такталарына сөртенгәләп алды... Ләкин барды да барды — ашыга иде. Хәзер аңа, — ул моны аңлый иде, — ашыгырга кирәк, алар аны хөкем иткәнче өлгерергә кирәк. Аннан соң коткаруы авыр булыр. Ул моңа ышана иде. Ул бөтен гомере буенча һаман кайгыларын җыңә килде һәм һәрвакыт менә шулай — һаман аяк өстендә, ашыга-ашыга, яулыгының очы белән күз яшьләрен сөртә-сөртә. Анда аңа булышырга тиешле мәрхәмәтле кешеләргә карата чиксез ышаныч яши иде. Болары ярар, болары үзләренеке өчен рәнҗеделәр, ә тегеләре — өстәрәк утыручылары — тегеләре булышыр. Нишләп булышмаслар икән? Ул аларның барысына да сөйләп бирер дә булышырлар. Гаҗәп, ана улы турында, ул җинаять эшләде, дип бер мәртәбә дә уйлап карамады, ул бары тик бер генә нәрсәне белде: малае белән зур бәла килеп чыкты. Әгәр аны шушы бәладән әнисе коткармаса, тагын кем коткарыр? Кем? Хода, ул шул өстәге оешмаларга җәяүләп атлар, кирәксә, көннәр-төннәр буе барыр да барыр... Табар ул шул мәрхәмәтле кешеләрне.

— Йә, ничек? — дип сорады аннан милиция начальнигы.

— Өстәге оешмаларга барырга кушты, — дип ялганлады ана. — Ә менә бу — күрешергә. — Ул аңа кәгазьне бирде.

Начальник, гәрчә моны күрсәтмәскә тырышса да, бераз гаҗәпләнеп калган иде. Язуны укып чыкты. Ана аның гаҗәпләнүен сизде. «Ә-ә», — дип уйлап алды ул эченнән. Аңа бераз җиңел булып китте.

— Озат, Мельников!

Ана озак, еракка барырга туры килер, тимер ишекләр ачылып китәр дә ул улын рәшәткә артында күрер һәм аның белән астан торып, аяк очларына басып сөйләшер дип уйлаган иде. Ә аның малае шушында ук,

аста, подвалда гына утыра икән. Анда, коридорда, чәчләрен алдырган ир-атлар домино уйныйлар... Күзләре белән ана һәм милиционерга төбәлделәр. Алар арасында Витькасы юк иде.

— Нәрсә, ана, син дә унбиш тәүлек эләктерденме әллә? — дип сорады бер табак битлесе.

Көлешеп алдылар.

Милиционер аны коридор буенча өчме, дүртме булган камераларның берсе янына алып килде дә ишеген ачты.

Витька — берүзе генә, ә камера зур һәм нарлары кин. Ул нарда ята иде. Милиционер килеп кергәч, ул урыныннан күтәрелмәде, тик анның артындагы әнисен күрүгә генә сикереп торды.

— Сөйләшергә ун минут вакыт, — дип кисәтте озын буйлы. Һәм чыгып китте.

Ана нарга килеп утырды, яулыгы белән ашыгып яшьләрен сөртеп алды.

— Карале, үзе җир астында, ә коры, җылы, — диде ул.

Кулларын тезендә үзара эләктереп утырган Витькасы дәшмәде. Ишеккә карап тора иде. Төн эчендә ул ябыгып калган, сакал-мыегы җиткән — үч иткәндәй, ничектер кинәт кенә. Ана карарга да авыр. Аны әкрен генә калтырата, ул, әнисе шуны сизмәсен дип, үзен бик киеренке тота иде.

— Акчаларны, күрәсең, урлаганнардыр? — дип сорады ана.

— Урладылар.

— Ярар иде инде акчалары белән, алар аркасында нигә сугыш башларга иде? Акча безне түгел, без аны табабыз.

Үзен ничек талаганнары турында Витька беркайчан беркемгә дә сөйләмәс иде — оят. Ике фәхишә... Сыкранырлык дәрәҗәдә оят! Тагын әнисе кызганыч. Ул анның үзе янына бөтен законнар аша үтеп булса да киләсен белеп торды, моны көтте дә һәм шул ук вакытта моннан курыкты да.

Бу минутта ана күңелендә бөтенләй башка нәрсә: ул кинәт дөньяда милиция, прокурор, суд, төрмә дигән нәрсәләрнең барлыгын анламый башлады. Янында анның баласы утыра, ул гаепле, ярдәмгә мохтаҗ... Хәзер аны аннан — аңа бары ул, башка беркем дә түгел, бары тик ул гына кирәк чагында — кем тартып ала алсын?

— Белмисеңме, мин аны бик каты микән?..

— Юк ла, яссы ягы белән эләккән... Ләкин ята, тормый.

— Әлбәттә, экспертиза үткәргәннәрдер... Бюллетень алыр... — Витька әнисенә карап куйды. — Җиде еллап чәпәрләр.

— Йа Аллам!.. — Ананың йөрәге әрнеп куйды. — Нигә шул хәтле күп алай?

— Җиде ел!.. — Витька нардан сикереп торды да камера буенча йөренергә тотынды. — Барысы да бетте! Барысы да, бөтен тормышның асты өскә килде!

Ана үзенең сизгер йөрәге белән менә хәзер баласының җанын нинди өметсезлек өзгәләвен аңлап алды...

— Инде сине хөкем иткән шикелле сөйләшәсең! — диде ул шелтә белән. — Шундук, тормышның асты өскә килде, имеш.

— Ә нәрсә көтәргә инде монда? Барысы да билгеле...

— Кара син ана, барысы да билгеле, имеш! Син башта сорар идең: мин кайларда булдым, нәрсәләр булдыра алдым?..

— Кайда булдың? — дип, Витька туктап калды.

— Прокурорда булдым...

— Шуннан? Ә ул ничек?

— Менә шулай, башта, ул ничек, дип сора. Шундук, асты өскә килде, имеш! Ниндидер йомшаклар да соң сез... Әле бернәрсә дә булмаган, ә инде... әллә ниткән уйлар.

— Ә прокурор ничек соң?

— Менә шул... Хәзергә, ди, кайгырмасын, башыннан төрле юк-бар уйларын чыгарып ташласын, ди... Ягъни без монда үзебез генә берни дә эшли алмыйбыз, чөнки андый хокукка ия түгел. Ә син, ди, вакытны юкка әрәм итмә, тот та югары оешмаларга бар, ди. Безгә аннан боерыклар да, теләсәк-теләмәсәк тә, без аны чыгарырбыз, ди. Шул чагында безгә үзебезнекеләр алдында да йөз аклыгы булыр, ди, янәсе, хөкем итәргә теләгән идек тә, булдыра алмадык. Анда алар барысын да уйлаганнар инде. Мин үзем дә кызганам аны, ди... Ләкин без кечкенә кешеләр, ди. Югары оешмаларга бар да, анда барысын да җентекләп сөйләп бир, ди. Синең акчаң күпме иде соң?

— Йөз илле.

— Йа Аллам! Җылытканнар икән кулларын.

Ишектән озын милиционер карап алды.

— Тәмамлагыз!

— Хәзер, хәзер, — дип каударланды ана. — Без инде барысын да сөйләшеп бетердек... Димәк, хәзер мин өйгә кайтам да Мишка Бычков сиңа характеристика язып бирә... Яхшы итеп язам, диде.

— Анда ни... чемоданда минем хезмәт иткәндә алган төрле грамоталар ята... аларны да алып бар, бәлки...

— Нинди грамоталар дисең?

— Күрерсең анда. Бәлки, булышыр.

— Алырмын. Аннары конторга барып килермен — аннан да характеристика алам... Буш кул белән бармам. Бәлки, дим, миңа теге тукыманы сатаргадыр? Сергеевна алмакчы иде миннән.

— Нигә?

— Үзем белән акча алырга — бәлки, кемгәдер төртергә кирәк булыр?

— Кирәкмәс, бары тик эшне генә бозарсың.

— Ярар, карармын әле анда.

Милиционер тагын ишектән карап алды.

— Вакыт.

— Киттем, киттем, — дип тагын каударланды ана. Ә ишек ябылгач, куеныннан печенье белән йомырка чыгарды. — Мәле, аша... Алай бик каты уйланма — асты өскә түгел әле. Мәрхәмәтле кешеләр булышыр. Зур начальниклар яхшырак алар, алар курыкмый. Болары курка, ә тегеләренең куркырлыклары юк — үзләренә үзләре хуҗа. Ә алар катына барып керәм дигәч, барыбер барып керәм мин! Ә син ныгы һәм берәр нәрсә турында, теләсәң, әнә Верка турында уйла... Ул да бик кайгыра. Баягынак кереп чыккан иде әле, ишеткән инде...

— Шуннан?

— Көенә.

Сөйгән кызының көенүеннән Витьканың күкрәгендә бернинди җылылык та сизелмәде. Ничектер шунда, җылынып китмәде.

— Менә нәрсә тагын... — дип пышылдады әнисе. — Эчеңнән генә догалар укыштыр. Ярый ул сиңа, син чукындырылган. Төрле яктан килеп карыйк. Ә мин өйдән иртәрәк чыгармын да — поездга хәтле, дим — тиз генә Николай-әүлияга шәм куярмын, аннан да сорармын. Менә шулай итеп, шәфкать күрсәтми калмаслар. Әтиеңнең сугышта үлүе турындагы хәбәрен дә алырмын...

— Син ни... хәзергә ир туганнарыма хәбәр итми тор инде.

— Итмим, итмим. Бары тик җанымны гына борчып торырлар. Мөһиме — син хәзер барысы да асты өскә килде дип уйлама. Бирсәләр, күп булса, бер ел бирерләр, күз буяу өчен генә. Җиде ел түгел лә инде! Ә кемгә бер ел бирәләр, карыйсың — алар ярты елдан чыгалар да. Анда тырышып эшлиләр дә аларны алдан чыгаралар. Ә бәлки бер ел да бирмәсләр әле.

Милиционер камерага килеп керде дә инде башка аннан чыкмады.

— Вакыт, вакыт...

— Киттем. — Ана нардан торды да, милиционерга арты белән борылып, улын тиз генә чукындырып алды һәм иреннәре белән генә:

— Ходай саклый күрсен сине, — дип пышылдады.

Һәм камерадан чыкты да коридор буйлап китте. Күз яшьләреннән берни дә күрмичә атлады. Улы Витька кызганыч, бик кызганыч иде аңа. Алар, балалар, авырганда да бик кызганыч, ләкин монда ниндидер аерым кызганыч: әйтерсең, син кешеләрдән ярдәм сорыйсың, ә алар йөзләрен читкә бора, күзеңә карамый. Менә хәзер дә шуның шикелле кызгану иде. Вакыты-вакыты белән куркыныч булып китә. Ләкин ана хәрәкәттә, эштә иде. Уйлары белән инде ул авылда булып, югары оешмаларга китеп барганчы кемнәрне күреп өлгерергә, нинди кәгазьләр алырга кирәклеге турында уйлана. Мәрхәмәтле кешеләр булышыр, дигән сүнмәс-сүрелмәс ышаныч аны һаман каядыр алга әйди дә әйди, шуңа күрә ул, иркенләп елап җибәрмәс өчен, бер җирдә дә акрын кыймылдамады, туктап тормады, чөнки ул өметсезлеккә бирелүнең үлемгә тиң икәнен белә иде. Ул гел хәрәкәттә булды.

Төштән соң сәгать өченчеләр тирәсендә ул инде тагын авылдан югары оешмаларга дип чыгып китте.

«Тәңрем, булыша күр, Ходаем! — дип кабатлады ул эченнән бертуктаусыз. — Улымны начар уйларга китереп җиткерә күрмә, акыл иңдер аңа. Ул бераз җиңел акыллырак, үзе белән берәр нәрсә эшләп куя күрмәсен тагын».

Ул кичен соң гына поездга утырып китте.

«Зарар юк, мәрхәмәтле кешеләр булышмый калмас».

Ул булышырларына ышана иде.

*1969*

**Әхәт САФИУЛЛИН** *тәрҗемәсе*

# ӘДӘБИ ӘСӘР ҺӘМ ТӘНКЫЙТЬ ЛОГИКАСЫ

Логика төшенчәсе, фикер йөртү белән бәйле термин буларак, һәркемгә таныш һәм без аны төрле өлкәләрдә төрлечәрәк кулланабыз. Беренчесе — тормыш, яшәү логикасы. Ул фикер йөртүченең дөрес нәтиҗәләр ясавы һәм үзен саклау, яклау максатын алга куеп хәрәкәт итүе, эш-гамәлләр кылуы. Шулай тормыш тәҗрибәсе туплана, кеше яшәргә өйрәнә. Шул ук вакытта уртак тәҗрибә, җыелып килгән акылдан һәркем үз мөмкинлекләре, белеме, акылы, холкы һәм рухи сыйфатларыннан чыгып файдалана, эш йөртә. Аның белән килешергә яки килешмәскә мөмкин, ахыр чиктә «үз логикасы инде» дип нәтиҗә ясыйбыз. Яшь үзенчәлекләре, тормышка карашлары белән аерылып торганга, «балалар логикасы», «хатын-кыз логикасы» дип тә аерып карыйбыз. Бу төр фикерләүдә, эзлекле булу, бердәм таләпләргә җавап бирүгә караганда, субъективлык өстенлек итә.

Икенчесе — фәнни логика. Борынгы грек философы Аристотельдән башлап акыл ияләре фикерләү процессын махсус өйрәнгәннәр һәм Логика мөстәкыйль фән булып формалашкан. Нәрсәне дә булса раслау яки кире кагу, фикерне дәлилләү алымнары, юллары табылган, гомуми кагыйдәләргә әйләндерелгән. Сәбәптән нәтиҗәгә бару, эзлекле фикер йөртү, беренче чиратта, фәннәр үсешенең нигезендә ята һәм тормышта да алдан уйлап, дөрес нәтиҗәләргә килергә ярдәм итә. Ә инде фән-техника үсешендә, математика, информатика, лингвистика кебек тармакларда логик фикерләү — бердәнбер дөрес юл. Аңлашылганча, бу — югары дәрәҗәдә объектив фикерләү өлкәсе.

Өченче катламны да аерып карарга мөмкин. Тормыш шартларының, вакыйгалар барышының кешегә бәйле булмаган эчке закончалыклары яши. Бу очракта кешеләрнең фикерләү рәвеше мәсьәләне хәл итми («шарт-ситуация логикасы»). Мисал итеп базар мөнәсәбәтләре урнашу, глобальләшү күренешләрен әйтергә була. Әлбәттә, без читтән торып, алар турында уйланабыз, фикер йөртәбез һәм үзебезнең нәтиҗәләрне дә ясыйбыз. Әмма тормыш үз законнары буенча, үз эзеннән бара.

Әдәби әсәрнең үз сәнгать логикасы бар. Ул әлеге логика төрләре белән бәйлеме? Кайсына охшаган, якын тора яки бөтенләй яңа күренешме? дигән сораулар туа. Билгеле булганча, сәнгатьнең әһәмиятле, мөстәкыйль бер төре буларак, әдәбият тормыш-чынбарлыкны өйрәнә, анализлый, әмма ул аны кабатламый, күчереп алмый — үз дөньясын иҗат итә, реальлекне сүтеп-җыя. Язучы әсәрендә максатлы рәвештә киеренке фикер йөртә, әсәрнең тексты фикер эзлеклелегенә корыла. Мәгънәләр тирәнлегенә, аларның төсмерләренә яшергән төп фикерен автор үзе иҗат иткән тәртиптә, үз алым-чаралары ярдәмендә «адымлап» аңлата бара. Аның сүз сөрешендә әсәрнең фикере дә, көе-моңы һәм тәэсир итү көче, сәнгать дәрәҗәсе дә чагыла. Әсәрне укучы, язучының фикер җебен югалтмыйча, яшерелгән (турыдан-туры атап әйтелмәгән) фикер-нәтиҗәләргә барып житә икән — менә шул юл инде күзгә күренеп тормаган, әмма укучыны «житәкләп барган» сәнгать логикасы була. Укучы үзе дә автор һәм геройлар дөньясында яши, «иҗат итә»: уйлана, кичерә һәм «хәзинә» таба — ачышлар ясый. Шул очракта гына канәгатьлек хисен кичерә.

Әдәби әсәр логикасы алда сүз барган логика төрләренә нигезләнә, әмма автор аларны үз максатына, жанр үзенчәлекләренә ярашлы рәвештә куллана. Хикәяләп язылган, заман картиналарын, тормышның үзен чагылдырган эпик әсәрләр яки сәхнә өчен язылган пьесалар сайланган материаллар мисалында яшәү закончалыклары турында реальлеккә якын итеп сүз йөртәләр. Бу очракта тормыш логикасыннан файдаланмау — тормыш чынлыгын бозу булыр иде. Әмма шул ук вакытта, автор тормыш, яшәү турында ничек бар — шулай тасвирлау белән генә чикләнә алмый, ул нигә тормыш шундый икәнлекнең сәбәпләрен эзли, ничек булырга тиешлеге турында уйлана һәм бәяли, тормыштагы кыйммәтләрне эзли. Бу — иҗатның максаты, шуңа ирешү өчен язучы реаль җирлектән югарырак күтәрелә — нәрсәнедер гадәттән тыш арттыра, көчәйтә, чынлыкта булган белән булмаганны аерып алмаслык итеп кушып,үзара бәйләп куя. Мәсәлән, Т.Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендә тормыш логикасы саклаңган — 91 яшьлек Әлмәндәр картаеп, вакыты җитеп, үз үлеме белән үлә. Тормыш өчен бу табигый хәл, чөнки һәркемнең гомере туу белән башлана, үлем белән тәмамлана. Әмма әсәрдә сүз һәркемгә мәгълүм хакыйкать турында гына бармый бит. Автор нәрсә турында әйтергә тели соң? Әсәрен нинди максат белән яза? Иң башта ничек, нинди алым-чаралар кулланып язуына игътибар итик. Тормышта үлемнең үзен күреп, аның белән сөйләшеп, бәхәсләшеп, үз эшенне аннан эшләтеп һәм качышлы уйнап булмый. Әсәрдә вакыйгалар барышы исә нәкъ шул эшләргә корылган. Ни өчен соң без тормышта алай булмый, автор дөреслекне бозган димибез. Чөнки автор безне инде кызыксындырып, Әлмәндәр белән таныштырып, аңа гашыйк итеп өлгерде. Күңелебез белән авторның «фикер арбасына» күчеп утырдык: без, әлбәттә, Әлмәндәр яклы. Кызыклы көрәш бара: кайсы җиңәр, ничек җиңәр? Бу сорауларны акыл түгел, безнең хыял тудыра. Алай дисәң, без үлемне алдап була, аны җиңеп була дигән сүзләргә дә ышанасы килеп яшибез. Димәк, Т.Миңнуллин укучысының һәм тамашачысының хис-теләкләрен, хыялын «тормышка ашыра», әйтерсең, шулай була ала икәнлеген исбатлый.

Сәнгатьчә фикер юлыннан тагын бер адым атлыйк. Автор Әлмәндәр һәм Әҗәл рольләрен уйнаячак актерларны алдан ук күздә тотып, аларга багышлап язган. Ни өчен кешеләр аңында бары тик кайгы-хәсрәт, югалту төшенчәләре белән генә бәйле һәм бары тик кире, явыз образ гына була алган Әҗәлне татар халкының яраткан артисты булган Р.Шәрәфиев уйный әле? Ни өчен, мәсәлән, Р.Шамкаев түгел? Артистларның уйнау осталыгына, талант үзенчәлекләренә бу урында тукталмыйча, әсәрнең конфликтына игътибар итик. Төп каршылык тормышның матурлыгын күреп, яшәү ямен тоеп яшәгән, үзе дә тормышны матурлап, кешеләрне куандырып торган Әлмәндәр белән аның гомерен өзәргә килгән Әҗәл арасында. Килгән икән Әҗәл, Әлмәндәрне алып китәчәк инде ул. Димәк, бу конфликтта Әҗәл җиңәчәк? Нәкъ шушы урында автор сәнгать хәйләсен куллана — тормышта була алмаганны «тормышка ашыра» — Әҗәл кешечә фикер йөртә, сөйләшә башлый — «яраттым бит мин сине, Әлмәндәр, нигә мин кешеләр кебек булмаганмын», ди. Бу сүзләр кызык өчен генә әйтелми, җинел холыклы, бюрократ Әҗәл җитдиләнә, үзгәрә — кешеләр тормышына кызыга, соклана, үкенә, Әлмәндәр өчен кайгыра. Шуның өчен дә Әҗәлне үз итә һәм аңа ышана башлыйбыз һәм нәкъ менә Р.Шәрәфиев булганга ышанабыз. Аның күзләрендәге моңсулыкка, ялваруына, сөйләменең ихласлыгына битараф калу мөмкин түгел!

Бу ике герой безнең күз алдында, әйтерсең, татулаштылар, берләштеләр, һәм без ачыш ясадык: бу — Әлмәндәрнең үз әҗәле һәм бары тик аныкы гына икән бит! Конфликт ничек чишелде соң? Тормыш логикасы буенча фикер йөртсәк, Әҗәл җиңде — Әлмәндәрне алып китте. Ләкин үз теләге белән түгел, Газраилнең боерыгын үтәп кенә. Кулыннан килсә, Әлмәндәрне мәңге яшәтер иде ул. Димәк Әҗәл, үзе теләп, Әлмәндәр ягына күчте, автор сәнгать чаралары ярдәмендә конфликтның эчтәлеген һәм мәгънәсен үзгәртте — Әҗәл, кеше рухын аңлый торган зат булып, тамашачы күңелендә урнашып калды. Бу үзгәреш шулай булырга тиеш, логик яктан әзерләнгән хәл иде: әсәр дәвамында (спектакль барышында) бик табигый рәвештә геройлар «Әлмәндәр дус» һәм «Әҗәлетдин»гә әйләнделәр. Хәзер инде кем

жинде дигән сорауны куя алмыйбыз, мәсьәләгә икенче — көтелмәгән яктан килеп карыйбыз, уйланабыз: ни өчендер кешеләрне ачык аңлаешлы «үлем» дигән сүз генә канәгатьләндермәгән, Әҗәл һәм Газраил образлары уйлап табылган. «Әҗәле житте, килде, алып китте»дип сөйләшкәндә, күңел белән аерманы тоябыз. Үлем — яшәүдән туктап калу булса, Әҗәл, кеше бу дөньядан икенчесенә күчкәндә, әйтерсең, арадашчы хезмәтен башкара. Өстәвенә, Әҗәл — үлемнеке булса да, фәрештә дә бит әле ул. Шушы мәгънә төсмерләре арасында «Кешеләр! Үлемнән куркып, аны чалгы күтәргән скелет дип күз алдына китереп, тормышның ямен җибәреп яшәмәгез. Сезне алып китәргә Равил Шәрәфиев кебек сөйкемле һәм Газраил каршында сезне яклый торган үз әҗәлегез килер. Әмма аның өчен Әлмәндәр кебек булырга кирәклеген дә онытмагыз !» дигән фикер яши кебек. Финалда Әҗәл тамашачыларга бу уен гына булса да, сез уйланырга тиеш дигәндәй бик җитди карап тора. Жанр исеме «монсу комедия» дип куелу юкка түгел икән.

Фәлсәфи фикер дә безне уйландыра: яшәвең нинди — үлемең дә шундый; үлемгә бирешмәскә тырышуның мәгънәсе — хәрәкәттән, эш- шөгыльдән туктамау, тормышны ярату һәм кешенең рухи көче, егәрлеге икән. Тагын бер сорауга җавап эзлик. Әдәби әсәр тормышның зурлыгы, катлаулы булуы турында гына сөйләп калмый, бездә канәгатьлек хисен уята — шул очракта гына автор белән килешәбез һәм әсәрдәге фикерләр безне рухландыра. Туфан Миңнуллин сәнгатьлелекнең бу максатына ничек ирешә соң? Күз алдына китерик, әсәрдә Әҗәл образы юк, ди. Әлмәндәрнең бөтен уңай сыйфатлары тасвирланса да, аның яшәү көче, рухи бөеклеге һәм халыкчанлыгы ачылмый калыр иде. Автор кеше гомеренең бер мизгелен, соңгы бер көнен генә сәхнәгә чыгара һәм шушы хәлиткеч үлчәмгә, беренчедән, Әлмәндәрнең бөтен гомерен сыйдыра. Икенчедән, Әлмәндәрнең гадәти генә үлеп китүен (тормышта бу хәл нәкъ шулай булса да) безнең күңел кабул итмәс иде. Аның Әҗәле шундый сөйкемле, кешелекле булганга күрә канәгать калабыз һәм мондый үлем белән килешәбез, әйтерсең, үзебезгә дә шундый әҗәлне алдан ук сайлап куеп, өмет белән яши башлыйбыз. Күңелләр сүрелсә, әсәрне кабат укыйбыз, хисләрне янартабыз. Шул рәвешчә, әсәрдә һәм сәхнәдә ике дөнья — үлем белән чикләнә торган матди тормыш һәм әдәбият-сәнгатьтән кешеләр күңеленә күчеп, мәңге яши торган рухи дөнья килеп кушыла.Тормыш логикасын тулыландырып һәм көчәйтеп, аңа тылсымлы сәнгать логикасы килеп кушылганда гына әсәр чын классик, димәк, мәңгелек була. Әлмәндәр белән аны үлемсез иткән Әҗәл образлары да автор һәм актерларның мәңгелек сәнгатьтәге гомерләре ул!

Тагын бер классик әсәр мисалында сәнгать алымнарына игътибар итик, логикалар бәйләнешен күзәтик. Фәнни логика һәм язучы фикерләвенең уртаклыгы — эзлекле, бәйләнешле һәм дәлилле итеп сүз йөртүдә. Ләкин фәнни фикерләүнең көче фактларның реаль һәм тулы булуында, аларның фәнни алымнарга төгәл буйсындырылган тәртибендә булса, әдәби әсәрдә автор бу тәртипне үзгәртә, хәтта җимерә дә. Бергәләп фикер йөртү барыбызга да бик таныш, исемен әйтүгә бербөтен булып күз алдына килә торган әсәрләр мисалында уңайлы булганга, М.Фәйзинең «Галиябану» драмасына мөрәҗәгать итик. Бу әсәр дә тормышта еш очрый торган ситуациягә корылган — бер кызны ике егет ярата. Реаль тормышта кем ягында булу, кемне яклау яки аларга битараф калу — һәркемнең шәхси эше. Автор исә укучыларын үз фикеренә, хисләренә теләктәш итәргә тели һәм ситуация белән идарә итә башлый. Бер-берсен ундүрт яшьтән яраткан Галиябану белән Хәлил һәм тирә-юньдәге беренче чибәр үзенеке булырга тиеш дип ышанган, байлыгы белән масайган Исмәгыйль каршы куела. Әсәр барышында аңлашылмаучылык, төрле мәкер-хәйләләр аркасында конфликт гаять кискенләшә, вакыйгалар Хәлилнең үлеме белән тәмамлана.

1916 елда язылган әсәр инде гасырга якын вакыт искермичә, хисләр кайнарлыгын сүрелдермичә яши. Татарстанда «Галиябану» спектаклен куймаган авыл юктыр. Казаннан чын артистлар килгәнне көтеп утырмыйлар, һәрберсендә үз Галиябануы, Хәлиле дә табылып тора. Берсенә дә Мирхәйдәр Фәйзи куйган таләпне куймыйча, үзебезнекеләр дип яратып, кабат-кабат карыйлар. Иң кызыгы — соңгы күренештә Хәлил «мин син этне атарга хурланам» дип, револьверын

Исмәгыйльнең аяк астына ташлаганда залдан, бу гаделсезлеккә түзә алмыйча, «ташлама револьверынны, юләр, ташлама» дип кычкырмый калмыйлар. Хәтта Т.Миннуллин да, үзе әйтмешли, язучы икәнлеген онытып, Хәлил авыл егете түгел дип, ризасызлыгын белдергән иде. Бөтен хикмәт тә шунда — Хәлил авыл егете, әмма автор ихтыярындагы авыл егете. Чын тормышта бер генә авыл егете дә мондый акылсызлыкны эшләми, өстәвенә, тормыш логикасы «күрсәтеп» торган вариантлар да бар бит. Мәсәлән, кулында револьвер булган хәлдә, Исмәгыйльне атып үтермәсә дә (тамашачы Исмәгыйльне шулай хөкем итеп куйган иде инде!), Галиябануны житәкләп чыгып китә, исән кала ала иде. Бу очракта автор акыллы тормыш логикасын бик үкенечле итеп жимерә һәм үзе теләгән максатка ирешә — ничә буын укучы, тамашачы Хәлилнең үлеме белән килешмичә, күңелләрендә кеше өчен бик әһәмиятле үкенеч хисен һәм гаделлек жинәргә тиеш дигән теләкне саклап яши. Спектакльдән ташып торган хисләр белән таралабыз, нәкъ шул хисләр рухи дөньябызны чистартып, тормыш ваклыклары, түбәнлекләрдән арындырып тора. Шуның кирәклеген тоеп яшәгәнгә, ничек тәмамланасын белгән хәлдә, тамашачы аны караудан туймый, әсәр сәхнәдән төшми.

«Галиябану» драмасын трагедия жанрына якынайткан һәм легендага әверелдергән сәбәп — конфликтның бер үк вакытта кире дә, уңай да чишелүендә. Исмәгыйль Хәлилне атып үтерде, әмма Галиябануны үзенеке итә алмады, ягъни мәкер, явызлык, байлык мәхәббәтне жиңә алмады дигән идея расланды. (Бу әсәр турында сөйләшүне бүгенге яшәеш белән бәйләп, мәсәлән, хәзерге кызлар, телевизор раслап һәм хуплап торганча, нигә байларны сайлыйлар, бүгенге әдәбият куйган проблемалар белән нинди бәйләнеш бар һ.б. сораулар куеп дәвам итәргә була. Жаваплар эзләү махсус сөйләшүне көтә).

Әлеге ике әсәрне анализлау аша әйтергә теләгән фикернең беренчесе — әдәби әсәр турында сөйләргә алынганбыз икән, аны имгәтмичә, канатларын каерып жиргә өстерәп төшермичә, мәсәлән, А.Гыйләжевнең Бибинурын «бөкшәеп беткән мич башы карчыгына»әйләндермичә сөйләшергә тиешбез.(Шул дәрәжәдә ямьсез, мәрхәмәтсез сүзләр каян табылган?) Ягъни, хис-кичерешләр дөньясыннан гыйбарәт булган, үз закон-кагыйдәләре буенча яши торган әдәбиятны «бу әсәр яки герой миңа ошады-ошамады» принцибыннан чыгып түгел, аның хасиятен белеп һәм авторның уй-ниятен аңларга тырышып бәяләргә тиешбез. Бу — «син» яки «мин» дип үзебезне алга куеп сөйләшү хокукы түгел, фәннилек таләбе. Фәннилек дигәннән — әдәбият, сәнгать һәм ижат турында сүз чыкканда, беренче чиратта, язучылар һәм әдәбият белгечләре (шул исәптән тәнкыйтьчеләр) дә, әдәбият теориясен әллә ни кирәксенмичә фикер йөртәләр. Язучылар «мин теория кушканча түгел, күңелем кушканча язам» диләр икән, алар тулысынча хаклы. Чөнки теория ижатка гына түгел, кайсы өлкәгә караса да, практикадан үсеп чыга икәнлеге мәгълүм. Әлбәттә, теория язарга өйрәтми, әмма әсәрне, ижатны һәм әдәби хәрәкәтне анализларга һәм бәяләргә өйрәтә. Бу урында әдәбият теориясенең катлаулы юнәлешләре, проблемалары күздә тотылмый, бары тик фәннең тәнкыйть белән уртаклыгына басым ясарга телим.

Габдулла Тукайның «тәнкыйть кирәкле шәйдер» дигән мәгълүм сүзләрен барыбыз да яратып кабатлап торабыз. Иң кызыгы, аны беренче чиратта язучылар кирәксенә һәм бу мәсьәләгә битараф булмыйча, үзләре үк тәнкыйтьтә катнашалар, әдәби хәрәкәтне күзәтеп, мөнәсәбәтләрен белдереп торалар. Шулай да, язучыларның үзләре янәшәсендә объектив, гадел бәя биреп торучы тәнкыйтьчеләрне ишетәсе килүләре табигый. Шул ук вакытта тәнкыйтьче язганда һәм сөйләгәндә укучыны да күздә тота бит әле. Һәрбер укучы әсәрнең тирәндә яткан фикерләрен, фәлсәфилеген аңлап бетермәскә дә мөмкин. Ана да ярдәм кирәк, югыйсә ул әсәрнең бөтен матурлыгын күреп, танып бетермәячәк, бик тәмле, витаминлы алманы бер тешләп кабып кына ташлап калдырган кебек әсәр яныннан үтеп китәчәк.

Тәнкыйть бик үткен корал, хәзерге демократия заманында ни сөйләсәм, ничек сөйләсәм дә ирек дип тотынсак, икеләтә зыян ясыйбыз: әсәрен дәлилле анализлап бәяләмәгәндә язучыны (аның рухын) рәнжетәбез, күңелен төшерәбез,

талантының тиешле юнәлештә сарыф ителүенә куәт бирмибез. Икенчедән, китап укучыларның чын сәнгать әсәрен танып, аны урта кул һәм кәсепчелеккә генә корылган әсәрләрдән аера белүләре — зәвыклары түбәнәя. Бу урында, фикеремне раслап, мисал китерәсем килә. Университетта укыткан һәм иҗатының иң танылган вакытында Мөхәммәт абый Мәһдиев бер пьеса язды. Авторның бер җөмләсеннән танылa торган сөйләменнән мәхрүм калган әсәрне персонажлар гына коткара алмый иде. Мөхәммәт абыйны вакытын, талантын әрәм итүдән иң якын дуслары һәм иң таләпчән, гадел тәнкыйтьчеләр Т.Галиуллин һәм Ф.Миннуллин коткардылар.(Бу вакыйганы Т.Галиуллин «Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы» әсәрендә үзе дә искә ала.)

Укучылар фикерен бәяләү дип саналган икенче мисал. Ел саен иң күп укылучы әсәр яки китапка конкурс үткәрелә, бу хупланырга лаек эш. Әмма шул конкурста җиңгән әсәрләрнең барысын да елның иң шәп әсәре дип тану белән килешеп булмый. Күп укылуның сәбәпләре рекламага, кемгәдер иярү, башка китап булмау һ.б.икән, бу әсәрне ел вакыйгасы дип бәяләп буламы? Ун кеше берәр тапкыр укып чыгу белән, бер үк кешенең бер әсәрне кат-кат укуы арасында аерма зур. Китап укучылар махсус эзләп, кат-кат укый торган әсәрләр әдәбиятның әһәмиятен дә, укучыларның матурлыкны тою, әсәрне аңлау сәләтен дә дөресрәк билгели, минемчә. Һәр әсәр классик дәрәҗәдә булырга тиеш дигән таләпне кую мөмкин түгел һәм дәрес тә түгел, әлбәттә, сүз бары тик гадел бәяләү — уртак принципларга таяну һәм тәнкыйтьчеләрнең авторны да, китап укучыны да күздә тотып фикер йөртүләре турында бара.

Әйтергә теләгән фикернең икенчесе, сүз сөрешенең нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт. Гомәр Даутов һәм Әлфәт Закирҗанов мәкаләләрендә («Казан утлары».-2012.-№3) бик урынлы искәртеп үтелгәнчә, әдәбият белеме өч төп тармакны берләштерә. Димәк, әдәби әсәр турында сүз барганда, аның үзенчәлекле алымнарына һәм эчке закончалыкларына игътибар итмәү, бәя биргәндә алар белән исәпләшмәү мөмкин түгел, чөнки нәтиҗәләр дөрес, төгәл, тулы булмый. Әдәби тәнкыйть, мәгълүм булганча, берничә мәйданда фикер йөртә: йә җентекләп бер конкрет әсәрне анализлый, йә әсәрләрен өйрәнеп, язучы иҗатының урынын, әһәмиятен билгели яки бүгенге әдәби хәрәкәткә эзлекле күзәтү ясый. Тәнкыйтьче, шуңа күрә, баштан ук максатын ачыклап, гадәттә, бер мәйданны сайлап ала, башка мәйданга күчкәндә дә төп фикер җебен югалтмый. Әдәби тәнкыйть — бәяләүче, хөкем чыгаручы буларак, гаять җаваплы өлкә. Димәк, тәнкыйтьченең иң беренче чиратта кирәк булган шәхси карашлары, мөстәкыйль фикерләвенең гадел һәм объектив булуы зарур. Бу инде — үз фикер-нәтиҗәләренне башкалар фикере белән дә чагыштырып карап, иң әһәмиятлесе, әдәбиятның нәфисләгән җимермичә сөйләшү дигән сүз. (Заманында Н.Исәнбәт тәкъдим иткән «нәфис әдәбият» термины бик урынлы иде.) Берничә мәкалә күләмендә кузгалган фикерләрдән дә әдәбият, аеруча аның хәзерге хәле турында җитди сөйләшүнең кирәклеге аңлашыла кебек.

**Флера ГАНИЕВА,**
*КФУ профессоры*

# «ОЧА ТОРГАН КЕШЕЛӘР» ЯКИ АК ТӨС ТАНТАНАСЫ

Г.Гыйльмановның «Оча торган кешеләр» (2007) романы күләме белән зур түгел, әмма язылышы белән кызыклы булып, укучыны үзенә җәлеп итә. Вакыйгалары һәм геройлары, Г.Гыйльманов каләменә хас булганча, аерым бер күңел җылысы белән ачыла. Каршылыклар геройларның үзара юктан гына үпкәләшүеннән, бер-берсен аңламауларыннан, үз «эго»ларының өстен куелуы сәбәпле барлыкка килә, шушы «су» белән даими сугарыла, үстерелә һәм конфликт дәрәҗәсенә житкерелеп, ахырда чишелә. Бу конфликт эчке каршылык төсен ала, әдәби герой бөтен сурәтләнелеше белән тышкы дөньяга каршы куела. Аның үз дөньясы гына хакыйкый, үз карашлары гына дөрес, үз әдәбе генә әдәп, ягъни бөтен яктан да ул үзе булып кала. Вакыйгалар барысы да аның барлыгын һәм өстенлеген раслау өчен хезмәт итә. Мондый геройлар үзләре шулай ук ак яки кара була алалар. Романда Г.Гыйльманов нәкъ менә шушы ике төсне уңышлы файдалана, чагылдырган тормыш һәм табигать картиналарын да шушы буяулар белән сурәтләп бирә. Моның да уңышлы як булуын искәртергә тиешбез. Вакыты-вакыты белән әдәби картиналарда аерым төсләр дә барлыкка килә, мәсәлән, төп геройның балачак хатирәләреннән калган кояшлы көннәре яки кыр чәчәкләреннән җыйган букеты, шулай ук, авылга кайткач, клевер чабарга барырга ниятләнеп-сөйләшеп йөрүләрендә клеверны күзаллавы, кызыл-бакыр чәч һәм зәңгәр күзләр — болар шушы ак һәм кара төстәге күренешләргә аерым-аерым төртке-ноктала рәвешендә төс биреп алучы тере картиналар.

Г.Гыйльманов бу романында махсус рәвештә ак төсне өстен чыгара. Әсәрнең теле дә моңа хезмәт итә. Автор шушы төсне бирү өчен стилистик модельләрне оста файдалана, бигрәк тә әйтемнәр, мәкальләр, хикмәтле сүзләр әсәрдә еш кулланыла. Укучы мондый хикмәт-аксиомаларның, берсен икенчесе алыштырып килеп, тезмәләргә әверелеп китүләрен дә унай кабул итә. Алар артык та, ким дә түгелләр сыман дигән тойгы кала, чөнки бер мәкальгә икенчесе бәйле, икенчесен өченчесе ачыклый, конкретлаштыра, өченчесенә дүртенчесе мәгънәви яктан берегеп китә. Мондый урыннарны, Д.Заһидуллина термины белән әйтсәк, стильдә җөмләләрнең вакыт-вакыт «җем-җем җемелдәп китүе» очраклары дип атарга тиешбез. Ул «җемелдәүләр»дә автор бик оста рәвештә халык мәкальләрен дә, үзе уйлап чыгарганнарын да, хәтта ярым-хикмәт, ярым-аксиома рәвешендә булуларына да карамастан, уңышлы кертеп җибәргән. Мәсәлән, романның беренче битләрендә үк мондый юллар бар: «Кайсыдыр изге китапта әйтелгән бит: «Алла безгә биргән рухны нык сагына»,— дигән». Шуңа бәйле автор үз фәлсәфәсен тезә башлый. Стильдәге ул «җемелдәүләр» аерым төс алган картиналар белән үзара ярәшеп, романның укучыга тәэсирен көчәйтә. Әсәр үзенә җәлеп итә, бер сулышта диярлек укыла. Артык аклыгы, артык буталчык булуы, артык таркау вакыйгалардан торуы һәм аларның гүяки очраклы рәвештә бергә җыелулары кебек тойгылар уятуы, инде кайдандыр таныш булган римейка элементларының төрле культураларга хас әдәби әсәрләрне һәм кинофильмнарны искә төшерүләре — болары шулай ук үз рольләрен башкара. Романны анализламаган очракта, уку өчен генә укыганда, ул бик тә яхшы хис-тойгылар калдыра. Анализлаганда исә,

анын эчтәлеге көтелмәгән яктан ачыла. Бу ягы белән Г.Гыйльмановның «Оча торган кешеләр»е үзенең үк «Албастылар»ына да, А.Хәлимнең «Өч аяклы ат»ына да, Н.Гыйматдинова, Ф.Бәйрәмова, М.Галиев, З.Хөснияр, З.Хәким әсәрләренә дә тартым. Бу әдипләр һәм аларның иҗаты татар әдәбиятында бердәм көчле әдәби агым барлыгын раслый. Без аларның барысын да «постмодернистлар» дип атыйбыз. Араларында нинди әдип булуы ачык аңлашылып торганы, постмодернизмның һәммә якларын да үз иҗатында раслый, үстерә, милли үзенчәлекләрен тагын да ныгыта алганы Г.Гыйльманов, әлбәттә. Шунысы кызыклы, бу әдип-әдибәләр бер-берсен кабатламыйлар, әдәби дөньяларын үз стихияләрендә, үз карашлары эчендә, үз фәлсәфәләре белән бәйле яшәтә беләләр.

Г.Гыйльмановның «Оча торган кешеләр» романы һәм аның бүгенге укучы өчен иң әһәмиятле ягы — җиңел укылуы белән дә кызыксыну уяту көченә ия булуында. Андагы туктаусыз кабатланучы символлар, символик һәм мистик эчтәлеккә ия әдәби картиналар, уйдырма һәм чыннан да халыкта таралган яки юк мифлар, әкиятләр, дөрес һәм ярым-дөрес сынамышлар, аларга геройларның игътибар итүләре һәм әсәр барышында аларның дөрескә чыгулары яки геройларның боларны хак дип искәртүләре, халыкта булган яки булмаган йолаларны халыкта сакланып кына калмаган, онытылган яисә хәзер дә бар, әмма ана игътибар гына итми торылган дигән фикерләр уздырылу — болар барысы да авторга карата да укучыда соклану тойгыларын уята һәм әсәрнең талантлы язылуын раслап тора.

Төп геройлары да бик кызыклы бирелгән. Романда өч Сәүбән хакында сүз бара. Беренчесе — Сәүбән үзе, авылда туган, ак йөзле, сыек зәңгәр (күк) күзле, бакыр чәчле. Венера планетасы кешеләре шундый, имеш. Аңарда әтисеннән калган гадәт бар: ул — «оча торган кеше», ягъни таудан да сикерә ала, биек йортның балконыннан да төшеп китә, башкача да. Аның арка-сыртында канатлардыр сыман. Автор укучыны шушы характеристика һәм портреты белән тулысынча ышандыра.

Сәүбән мәктәпне тәмамлаган елны, колхозда бригадир булып эшләүче көрәшче егет Рәмис белән каршылыкка кереп, яраткан кызына көнчелеге аркасында сугышып, тәмам кыйналып, икенче көнне авылдан бакча артлатып кына чыгып кача. Казанга килә. Авиация институтына укырга керә. Аның шушы китүеннән 18 ел буе авылга бер генә кайтмавы әсәрдә берничә кат әйтелә. Ә роман поездтан төшеп авылына таба атлаучы, күнеле моңлы булуы йөзенә чыккан, «җыйнак кына мыек җибәргән, тыйнак кына, әмма ыспай итеп чәчен кистергән... кырык биш яшьләр чамасы булыр» Сәүбәннең портретын сурәтләү белән башланып китә. Әгәр дә мәктәпне тәмамлаганда Сәүбәнгә унсигез булса, тагын да унсигез ел авылга кайтмавын искә алсак, аңа бу вакытта 35–36 яшьләр чамасы булыр иде. Әмма автор аны безгә 45 яшьләр тирәсендә дип тәкъдим итә. Дөрес, романда Сәүбәннең авылына бу юлы кайтканындагы яше төрлечәрәк бирелеп барыла. Әмма автор ирнең яшен кырыктан киметми. Моны Г.Гыйльманов махсус рәвештә шулай эшли дип уйларга мәҗбүрбез.

Икенче Сәүбән — ул аның өрәге, бала чагында калган Сәүбәннең җаны дип аңларга кирәк. Әмма аңа нигәдер 12 яшь. Әгәр дә Рәмис белән сугышуына һәм авылыннан Сәүбәннең чыгып качуына бәйләп карасак, бу өрәккә уникe генә яшь була алмый. Романның башында ук бу өрәк белән очрашабыз. Ул авыл капкасы янында Сәүбәнне унсигез ел буена кайтырмы дип көтеп утырган. Аңлашыла, бу — аның тынычлыгын югалткан җаны. Шушы мистик образ романның тәэсир көчен бермә-бер арттыра, укучыда шик һәм уйлану тудыра, күнелендә интригалы тойгылар хасил итәргә этәргеч бирә. Хикмәти мәгънә алып, чынбарлык белән хыял, тышкы дөнья белән эчке дөнья буталышы (яки кушылышы) барлыкка китерелә. Әсәр үзенең реалистик эчтәлеген шушы өрәк килеп күренүдән башлап, ягъни беренче битләрендә үк югалта. Фэнтези дөньясы башланып китә. Ул әлбәттә аклы һәм каралы гына. Монда барысы да йә ак (әйләнә-тирә мохит тә һәм андагы кешеләр дә — Ак әби, Ак бабай һ.б.), йә кара гына (тау эче, болытлы янгырлы төн, кайбер

кешеләр — Зәлифә, Рәмис, хатыны Сәвия һ.б.). Әсәрдә буталчык урыннар берсен икенчесе алыштыра. Монда автор түгел, герой бутала. Вакыйгаларны ул бер логикага салырга тырыша, әмма мантыйкта алар төрлечә килеп чыга. Шул сәбәпле Сәүбәннен сөйгәне Сәвия дә кемәндә баласын кай очракта елдан артык, икенче бер логик тезмәле ачыклауларда хәтта ике ел һәм аннан да артык йөрткән кебек аңлашыла. Баланы табу вакыйгасы да әсәрдә төрлечә сөйләнелә.

Бу бала Сәүбәннен улы булып чыга. Нәкъ анын өрәгенә охшаган әле, житмәсә. Шулай ук 12 яшендә. Әүвәле Сәүбән аны үз баласы итеп танымый, аннары гына, вакыйгаларны исенә төшереп, андагы буталчык урыннарга ачыклык кертә. Бу — шизоанализ юлы, шизакатьлек стихиясе. Шул Сәүбән, Сәүбәннен улы, романдагы өченче Сәүбән буларак, алга таба фэнтези элементын вакыйгага әверелдерү һәм үстерү өчен хезмәт итә башлый.

Әсәрдә ике Сәвия бар. Анын берсе — Сәүбәннен үз хатыны, икенчесе — яшьлегендә яраткан Сәвиясе. Алар авторнын әхлакый карашларын яктырту өчен хезмәт итә. Бу яктан Зәлифә образы да уньшлы файдаланылган. Бер геройларына әсәрдәге вакыйгаларнын сюжет йөген йөкләп, икенчеләренә әхлак-әдәп карашларына бәйле уйлануларын биреп, Г.Гыйльманов, башка әсәрләрендәге кебек үк, «Оча торган кешеләр» романында да әдәби образларны үзенчәлекле бирү системасына ия булуын таныта. Бу анын, әлбәттә, уньшы дип хаклы рәвештә бәяләнергә тиеш. Шулай да «Оча торган кешеләр» (романнын тулы исеме: «Оча торган кешеләр, яки Иясез язмышлар хакында бәян») әсәре кемнәр һәм нәрсә хакында сон? Анда мантыйк та, тормыш дөреслеге дә юк та, бар да сыман тоелса да, ничек һәм нинди бәя бирергә? Бу сорауларнын үзләрендә үк җаваплары бар. Романнын тулысынча ак төс эчендә, ак төс тантанасы белән язылуы, мона язучынын стилистик табышлары да хезмәт итүе, вакыйгаларнын осталык белән сайлап алынуы, ак әби һәм ак бабайларнын күплеге, кешеләрнен күнелләрендә шәфкать хисенен өстен чыгарылуы — болар барысы да хастаханә атмосферасы чагылышы. Сәүбәннен тормыш картиналарында логикасы булмау, вакыйгаларнын «римейка» тәртибендә төзелүе дә төп геройнын шизакатьле (шизофреник) булуын раслый. Романны, шулай итеп, шизоанализ принцибына корылган дип әйтә алабыз. Әсәр татар постмодернизмынын уньшлы үрнәге буларак бәяләнә ала.

**Фәрит ЯХИН,**
*КФУ профессоры*

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге документлар булу мәҗбүри:

1. Паспорт күчерелмәсе (титул, прописка бите).
2. Дәүләт пенсия страховкасынын страховка таныклыгы күчерелмәсе.
3. ИНН күчерелмәсе.
4. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
5. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп).

# ӘСӘРЛӘРЕБЕЗГӘ НИ ҖИТМИ?

Элегрәк, Фатих Хөснуләр заманында, әдәби әсәрләр турында сүз барганда, эстетик ләззәт төшенчәсе еш янгырый иде. Хәзер ул әллә ни ишетелми. Ләкин телдән бөтенләй төшеп калмаган булса кирәк. Күптән түгел Наил Шәрифуллинның «Тугай чәчәге» дигән повестен кызыксынып, канәгатьлек хисләре тоеп укып чыктым. Әсәр мәхәббәт турында. Әмма ул гадәти сюжетлардан шактый аерыла. Персонажларның берсе — Асия — сукыр кыз. Караңгыны яктыдан, ак шәүләне кара шәүләдән аерып, кояшны гына бераз чамалый икән. Әсәр барышында бу кыз укучыларга бик нык якыная, чөнки ул үтә чибәр, бик моңлы итеп җырлый, кешеләр белән аралашучан самими холыклы. «Кайчагында сагышлы, моңлырак тоелса да, дөньяны безнеңчә күрүдән мәхрүм булса да, Аллаһ аңа төшенкелек түгел, ә күңел матурлыгы, хисләр сафлыгы белән бергә тормышны ярату, сөенә-куана белү сыйфаты, шушы тирә-як табигатькә, тереклеккә мәхәббәт тә биргән» (Идел.– 2012.– № 2.– 15 б.).

Хикәянең икенче персонажы — каникул вакытында авылдагы төзелешкә килгән студент Зөлфәт. Асияне чишмә буенда моңлы итеп җырлап утырган чагында очрата. Ул кызга ихлас хөрмәт белән карый, сөйләшеп-серләшеп сүзләре бетми. Егет аның күзенә операция ясату перспективасы турында аңлата, күңелендә өмет уята.

«Зөлфәт! — ди Асия. — Сине очраткач, мин шуны аңладым: юньләп күрмәсәм дә, яктыны караңгыдан гына аера алсам да, баштагы дөньям, синә кадәр булган, синсез дөньям чыннан да дөм караңгы булган бит. Көннәрем дә, төннәр кебек, һичбер яктысыз, нурсыз булганнар. Ә бүген күңел күгемдә кояшым бар минем... Күңелем якты, шатлыклы, балкышлы хәзер. Күзләрем ачылган кебек. Син, бары тик син генә ачтың миңа аларны. Эчкерсез дуслыгың, саф күңелең, керсез ятратуың, шигырьләрең белән». Күрәсез, анарда тойгы-халәтен шагыйранә нәфис шәкелдә белдерү сәләте дә бар икән. Романтик тасвир өчен бу табигый хәл. Икесенең дә күңелләрендә якты хисләр кабына.

Күренекле табиблар, чыннан да, кызның күзенә уңышлы операция ясыйлар, тоныкланып беткән хрустальне күз алмасыннан аерып алып, икенчене, ясалма хрусталь куялар, дөньяга күзен ачалар.

Билгеле инде, укучы моннан соң әсәрнең тагын да яктырак, җылырак төсләр белән балкуын көтә. Ләкин, сәер хәл, нәкъ менә шушы ноктада көтелмәгән борылыш барлыкка килә. Ямьсезлегемне күргәч, Асия мине яратмас дип уйлый Зөлфәт һәм араны өзәргә була. Ләкин бу мотив нигезле түгел, ул ясалма, ышандырмый. Аны күңел кабул итми, чөнки хикәянең моңа кадәрге күркәм рухына каршы килә. Чынлыкта егет кызны судан алып утка сала. Автор монда, күрәсең, соңгы вакытларда шактый киң таралган үкенечле финал модасына ияргән. Ягымлы, чәчәкле стильне салкын, коры сүз куерту алыштырган, нәтиҗәдә әсәр төзелеп килә торган күркәм йортның түбәсен вакытлыча камыш белән ябып торуга охшап киткән.

Шулай да хикәянең бердәм стилен саклап калу мөмкинлеге бар дип уйлыйм мин. Моның өчен, әлеге ясалма борылыштан арынып, сюжетны логик, эстетик эзлеклелеккә салу, сурәт-бизәкләрне баштагыча дәвам иттерү фарыз. Әсәрнең ахырында автор моңа ишарә дә ясап куйган. Ләкин әсәр өчен моны күрсәтеп, тасвирлап бирү мөһим. Наил Шәрифуллинда язучылык сәләте күренә. Ул моны башкарып чыга алыр дип уйлыйм.

* * *

Мәхәббәт гомер-гомергә дөнья әдәбиятының түреннән урын алып килә. Инсан яшәешендәге кадерле мөнәсәбәтләр, керсез, ихлас кичерешләр, ягымлы, кайнар хисләр укучы күнеленә рәхәтлек бирә, бар вөҗүден биләп ала. Шул ук вакытта гашыйклар хәяте гел сөенеч-куанычлардан гына үрелми. Юлларында каршылыклар чыгып тора, психологик, рухи драма хасил була.

Зөлфәт Хәкимнең «Легионер» дигән романы *(Казан утлары.– 2009.– № 10)* бик матур башланып китә. Автор биредә Яббар белән Фатыйманың яшьләрчә самими, саф мәхәббәтен, әле монарчы билгесез булган, ләкин шулай да инде көтелгән, тансык һәм кадерле хис-кичерешләрен бәян итә, ул тойгыларның бөреләнеп чәчәк аткан мәлен тасвирлый. Аларның бу риясыз дуслыгы әсәргә ягымлы җылылык, яктылык бөрки, күнелдә гашыйкларга теләктәшлек, хуплау тойгылары уята. Романда тасвирланганча, егет белән кыз, аз гына күрешми торсалар да, бер-берсен сагына башлыйлар. Фатыйма сөйгәненә: «Мин барыбер синеке инде, Яббар»,– ди.

Әмма сөенеч-куанычлар белән тулы мизгелләр озакка бармый. Сугыш чыга. Унсигез яшьлек үсмер егет фронтка китә. Пленга эләгә. Андагы бөтен михнәт-газапларны башыннан кичерә, ачлыктан, суыктан, чирдән күпләрнең кырылуын күрә. Монда үзенең дә гомере бик чикле икәнен бөтен вөҗүде белән тоя. Исән калуның бердәнбер юлы качу икәнен аңлый. Фронтка җибәрелгәч, үзебезнең якка чыгу нияте белән ул легионга язылa. Легионер буларак Яббар үз иленә энә очы кадәр дә зыян китерми. Тәүге тапкыр фронтка аяк басу белән ул партизаннар ягына чыга, фашистларга каршы сугыша башлый. Шул рәвешле, аның кальбендә аз гына да ялган, алдашу булмый, ниятен тайпылышсыз тормышка ашыра.

Ләкин плен михнәтләреннән котылу, туган җиргә кайту ана шатлык-куаныч китерми. Илендә Яббарны төрмә рәшәткәләре, тагын да аяусызрак җәбер-золымнар көтеп тора. Аны алты елга төрмәгә ябалар. Сөйгән кызы белән кавышу өмете дә чәлпәрәмә килә. Яббар мәхкәмә билгеләгән срокны тулысынча тутырып чыга. Әсәрдә болар һәммәсе дә реаль тасвирланган.

Моннан соң укучы күнелендә якты бер өмет туа: рәсми җәзаны ахырынача алганнан соң Яббарның, ниһаять, яшәеше көйләнер дип фараз кыла ул. Ләкин өмет акланмый. Киресенчә, озакка сузылган, вакыт белән чикләнмәгән психологик һөҗүм башлана. Ул Яббарның соңгы минутына кадәр дәвам итә. Авылдашлары, таныш-белешләре йөзенә бәреп, әле син житәрлек михнәт чикмәдең дигәндәй, җанын әрнетәләр, сатлыкҗан, диләр, аның белән аралашмыйлар, читләшәләр. Мондый мөнәсәбәт егетнең якыннарына, туганнарына күчә, аларның эшләрендә күңелсезлекләр китереп чыгара. Хәтта, легионлыгы йога күрмәсен дигәндәй, Яббарның туган авылыннан китүен таләп итәләр. «Авылда эзең дә булмасын! — дип акырды Әнсар, йодрыкларын төйнәп. — Мин сиңа монда барыбер тормыш күрсәтмәячәкмен!» — дип яный күршесе, райком секретаре. Егетнең абыйсы Сәеткә болай ди: «Син дә энең белән бергә бер бәйдә китмәгәең». Хәтта легионер исемен күтәреп йөргәнче үлемең артык дип тә куялар.

Автор укучыларга егетнең гаепсез икәнлеген ачык күрсәтә. Суд та аны яманлардай бер факт та китерә алмый. Халык исә бер гаепсез төрмәгә утыртмыйлар дип фикер йөртә. Төрмә, шулай итеп, Яббарны алга таба каһәрләү өчен дәлил хезмәтен башкара. Асылда суд аны пленга эләккәне өчен хөкем итә. Ә пленга төшкәннәргә безнең илдә катлы-катлы җәза каралган. Сталинның 1941 елның августында чыккан фәрманы буенча әсир төшкән һәрбер кызылармеец дезертир һәм сатлыкҗан дип санала. Әмма пленсыз сугыш булмый бит. Плен — яуның даими юлдашы. Хәтта Сталинның үз улы да әсирлеккә эләгә. Икенче бөтендөнья сугышында исә, баштагы мәлдә, совет гаскәрләренең хәле катастрофик төс ала. Мәхмүт Әхмәтҗанов «Тормыш мизгелләре» дигән китабында, ышанычлы чыганакларга таянып, мондый мәгълүматлар китерә: «Сугыш башланыр алдыннан Совет Армиясе танклар, хәрби самолетлар белән немец фашистлары гаскәрләреннән ким тәэмин ителмәгән була. Ә артиллерия, минометлар буенча хәтта өстен тора». Әмма бу чорда безнең хәрби көчләр башсыз калган була.

Публицист язганча, «Сугыш алдыннан, Сталин әмере белән, Совет Армиясенең урта һәм югары комсоставының иң зур күпчелеге — 80 мең кеше кулга алына һәм шуларның яртысын атып үтерәләр. Калганнары Себергә, тундрага озатыла». Сугыш чыккач ашыгычлык белән билгеләнгән тәҗрибәсез командирлар оборонаны оештыра алмый, бинһаяә күп югалтулар барлыкка килә, нәтиҗәдә сугышның беренче айларында немецлар безнең берничә миллион солдатны әсирлеккә ала. Гаскәр белән бергә кораллар да дошман кулына күчә. Фашистлар Совет Армиясенә каршы безнең кораллар белән сугыша.

Романда Яббар даими эзәрлекләү, тиргәү объектына әйләнә. Моңа бәйләнешле рәвештә әсәрдә халыкның мораль-рухи сыйфаты мәсьәләсе дә калкып чыга. Әсирлектән котылу юлын, ышанычлы чарасын тапкан һәм шуны тормышка ашырган өчен генә Яббарны туктаусыз гаепләве белән гади кешеләр хакимиятнең әлеге миһербансыз мәсләгенә кушыла түгелме соң? Әмма халыкны шул рәвешчә бәгырьсез итеп күрсәтү әсәрдә ясалма чыккан.

Плен, төрмә михнәтләрен кичергән күпләгән инсаннарның якыннары, нәселләре шәт әле дә исәндер. Яббарга төбәлгән уклар туры алар йөрәгенә дә барып кадалыр дип уйлыйм. Әсәрдә геройның качу чарасын күрүе хупланмый кебек. Герман җирендә калу мәслихәтрәк булыр иде микәнни?

Бу романның үз эчендә сәер бер каршылык сузылып бара. Бер яктан, автор Яббарның саф күңелле адәм икәнлеген раслый. Авылдашлары кулында да аны яманларлык сынар тискәре факт та юк. Шулай булуга да карамастан, төрмәдә утырып чыккач та аңа каныгалар. Моның тора-тора кабатлануы укучыны ялкыта, романның динамикасы сүрелә, баштагы нәфислеге үзенең төсен җуя. Минем сынаганым бар: персонажны нахактан туктаусыз газаплау укучыга да тискәре тәэсир итә, күңеленә авыр басым ясый.

Ахырга таба романга Волжск ГЭСы — Куйбышев су саклагычы темасы килеп керә. Ул Яббарның бәхетсез язмышы белән бәйләп яктыртыла. Шушы төзелештә эшләүче зат буларак Яббар әлеге диңгезнең туган җиргә ни-нәрсәләр китерәчәген башкалардан алдарак сизә һәм, райкомга кереп, авылны су басу ихтималы турында кисәтә. Ләкин моңа колак салмыйлар, киресенчә, коткы таратуда гаепләп, аны кабат дүрт елга төрмәгә ябып куялар.

Әсәрдән күренгәнчә, ачы тормыш сынаулары барышында Яббардан бары тик әнисе Әминә генә йөз чөерми, төпчеген өзелеп ярата, гаепле булуына тамчы да ышанмый. Яббарның кайтуына авылны, зиратны, тирә-юньне су баскан, Кызыл ярны калкурак урынга күчереп куйганнар. Яббарның сөекле әнисе кабере дә су астында калган.

Райком секретаре Әнсар Яббарга «Сиңа ярлыкау беркайчан да булмаячак!» — ди. Яббарның җиңгәсе Нәсимә иренә: «Син энеңнең дә җелеген суырдың. Бөтенесе аны дошман иткәндә син аны аз гына булса да якларга тиеш идең»,– ди.

Әнисе дә үлгәч, Яббар бер таянычсыз кала. Аның халәтен Дәрдемәнд шигыре бик төгәл аңлата:

*Җитәр, җилкенмә, йолкынма, күңел, син,*
*Кияү булсаң да, ул түйга түгел син!*
*Җиһан тормыш туен иткән чагында,*
*Синең урның — үлекләр аймагында.*

Яббар, туган авылы Кызыл яр тарафына, зиратка таба көймә белән йөзеп китеп, юкка чыга.

Роман ахырында Яббарның абыйсы Сәет белән Өлкә комитеты сәркатибе Әнсар арасында мондый диалог булып ала:

– Ул сатлыкҗан түгел иде» — диде Сәет катгый тавыш белән.

– Нинди сатлыкҗан булсын ди ул! — дип җөпләде аның сүзен Әнсар.

Гәрчә бик анык, кистереп әйтелсә дә, бу сүзләр укучыны бераз аптырашта калдыра. Борылыш кинәт ясалды. Караш үзгәрешенә алар ничек килделәр соң? Югыйсә тарихны да актармадылар, яңа документлар да тапмадылар бит. Аларның

кайчангы мөнәсәбәтләре ихлас иде соң? Теге бәндәне гомере буена чукып тору нигә кирәк булды икән? Ул трагик шәхес итеп уйланылган булса кирәк.

Яббар бигрәк тә якташларының бер гаепсезгә җанын талаганнары өчен әрни, каты күңеллегә әйләнгәннәренә аптырый. Бар фаҗига әнә шунда. Биредә шәхеснең бәхетсез язмышы өчен халык гаепләнә кебек. Ләкин нәкъ әнә шуны күңел кабул итә алмый. Сталинның пленга төшкән ватандашларны сатлыкҗан дип бәяләве белән халык бервакытта да килешмәде.

Матбугат хәбәр иткәнчә, немецларда пленда булган Рәсәй кешеләренә яки туганнарына Германия хөкүмәте хәзер, гафу үтенү йөзеннән, пособие җибәрә икән. Безнең әсәрләрдә исә әле һаман да бер гөнаһсыз фронтовикны халык исеменнән каһәрләү дәвам итә. Автор бу романны бүтәннәргә сабак булсын диебрәк язган кебек тоела. Ләкин ул сабактан бигрәк үчләшүгә охшап тора.

Минемчә, әсәрнең «Легионер» дип аталуы да үзен аклап җиткерми. Яббар бит легионер буларак бер гамәл дә кылмады. Аның пленнан качуы гына конкрет күренештә тасвирлана. Биредә гармония табылмаган кебек күренә.

* * *

Кайчак бер үк сүзне күп тапкыр кабатлый башласаң, ул кәлиманең тискәре мәгънәсе дә чыгып куя. «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» әсәрендә М.Хәбибуллин Сөембикәнең кыз табуы турында яза. Ләкин автор шунда ук сабыйны күздән югалту хәстәренә керешә. Җиденче бүлектә Җангали хан бәбине утырмага җибәрү хакында хәбәр итә. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә утырманың мәгънәсе болай аңлатыла: «Утырма. Хатын-кызларның үз кардәшләрендә, туганнарында кул эше белән озаклап кунак булу йоласы». Биредә исә хан кызы тугач ук кул эше белән шөгыльләнә башлый кебек күренә. Сөембикә, автор язуы буенча, баласын төшендә күреп, елап уяна торган була. Ләкин нилектән үз янында тәрбияли алмавы әсәрдә аңлатылмый.

Уникенче бүлектә урыс есаулы Гавриил Җангалигә нарасыйның Кирмәнгә озатылуы турында әйтә. Гавриил баланың әтисеннән күбрәк хәбәрдар булып чыга. Моннан соң, әсәрдә бәян ителгәнчә, Җангали үтерелә. Сөембикә белән бүтән очраша алмый. Әмма егерме алтынчы бүлектә автор кабат кызны озату вариантына әйләнеп кайта. Моннан күренүенчә, Җангали бәбине, Сөембикәгә әйтмичә генә, Кирмәнгә үзе биреп җибәрә, ә Сөембикә алдында «Мин сине тапмадым» дип аклана. Ханлыкта бикәне табу хәл ителмәслек проблема икәнлеге сизелә.

Дүртенче вариантта Җангали кабат сабыйны озату хакында гәп кузгата. «Мин баланы Кирмән каласына озаттым, сиңа бала кирәкми, күрәсең, Сөембикә», — ди. Тик сәнгатьчә мотивлаштыру гына җитми, сәбәп күрсәтелми.

Шулай итеп, әсәрдән беленүенчә, баланы Кирмәнгә әллә ничә кеше озата. Әмма мондый хәлнең булуы мөмкин түгел. Әсәр иҗат иткәндә язучы теге яки бу хәлнең күп төрле вариантларын күздән кичерә. Ләкин романда шуларның тик берсе, аеруча уңышлы, тормышчан, ышандыргыч дип табылганы гына урын ала. Чөнки чынбарлыкта бер үк манзара төрле вариантта кабатланмый. Ул вакыт белән бергә үтеп китә дә югала, икенче мәлдә инде бүтән күренешләр пәйда була. «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный»ны язганда исә автор, күрәсең, алларак нәрсәләр теркәлгәнен хәтереннән чыгарган да, кире кайтып укуны кирәксенмичә, яңа вариантлар өсти биргән. Чынлыкта исә бу рәвешле кабатлаулар бернинди дә озату булмаганлыгын гына исбатлыйлар.

Мотивлаштыру проблемасының актуальлеге бу авторның «Сулар үргә акса да...» китабында да үзен сиздерә. Анда язылганча, милиция майоры Якуб кассалар басучы Сирайны кулга алырга бара, ярдәмгә заманында шулай ук милициядә эшләгән, ләкин вакыйгага барганда инде шактый йончыган пенсионер әтисен һәм милиционер хатын Васиlә Хаковнаны ияртә.

Караклар йортына килеп җиткәч, милиционерлар туп-туры өйгә бәреп кермиләр. Майор Якуб аларга оборона тотарга боерык бирә:

«Васиlә Хаковна, сез әтине прикройте. Әтәй, син этең белән капкага барырсың. Мин арт якка китәм, бакча ягына. –Якуб шоферга карады. — Михалыч, сезгә капка

каршына туктарга туры килер. Үзегез әнә теге күрше өйнең урам бакча буендагы бүрәнәләр артына посасыз. Васил Хаковна, күрәсез әнә теге тупылны, шуның артында булырсыз, чыгарга ашыкмагыз!» Тик ишек төбенә, караклар хозурына гына бирәү дә куелмый. Аңлашылмый, оборонага урнашу нәрсәгә кирәк булды икән? Милиционерларга бирәү дә һөҗүм итәргә җыенмый бит. Аннары майорның әтисен нәрсәдән «прикрывать» итәргә? Алай посып торасы булгач, милиционерлар бергә нигә килгәннәр соң? Өйләрендә генә утыру хәерле булмас иде микән? Әлеге күрсәтмәләр профессиональ офицер боерыгына охшамаганнар. Аларның бандитны кулга төшерү тактикасы белән бертөрле дә уртаклыгы юк. Киресенчә, бурычны үтәүне генә тоткарлыйлар. Билгеле инде, көтеп утыралар дип, угрылар агачлар артына поскан милиционерлар каршына, «тотыгыз мине» дип, үзләре килеп басмый. Моның өчен милиционерлардан активрак гамәл, тәвәккәллек, кыюлык таләп ителә. Бу очракта майор боерыклары әдәби максатка хезмәт итми. Ф.Хөсни, И.Гази, Г.Бәширов, Ә.Еники, Х.Камалов, Ә.Баян, Н.Фәттах, Р.Батуллада без бу рәвешле эстетик тайпылышларны очратмыйбыз.

Әйбәт әсәр ул — талант җимеше, киеренке, шул ук вакытта дәртләнеп, рухланып иҗат итү нәтиҗәсе. Югары максатка ирешү өчен әдип бөтен акыл куәтен, сәнгатьлелекне зирәк тою сәләтен эшкә җигә. Тик шул чакта гына әдәбиятның үсешенә, алга барышына өметләнергә була.

**Фәрит ХАТИПОВ**

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире ияләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

# ВАКЫТСЫЗ СҮНГӘН ЙОЛДЫЗ

Кәрим Тинчурин — татар драматургиясе һәм театры тарихында тирән эз калдырган, үзенең мәктәбен оештырган, аларның үсеш-үзгәрешенә әсәрләре белән генә түгел, бәлки үзенчәлекле артист, оста оештыручы, талантлы режиссер, театр сәнгате белгече буларак һәм күпсанлы тәнкыйть мәкаләләре аша да зур өлеш керткән, яна рух өргән олы шәхес. XX гасырның 10 елларындагы беренче тәҗрибәләреннән башлап, 30 еллар уртасына кадәр дәвам иткән иҗат юлында әдип бай мирас калдыра — утызга якын пьеса, дистәләгән хикәя һәм тәнкыйть мәкаләләре. Күпкырлы әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлек алып барган, әмма «вакытсыз сүнгән йолдыз»ның тормышы сәхнә әдәбиятын, театрны кайгыртып яшәүнең, туган халкы язмышын үз язмышы итүнең символына әверелде. Шуңа да республикабызның иң яхшы театрларыннан берсе булган Татар дәүләт комедия һәм драма театры хаклы рәвештә К.Тинчурин исемен йөртә.



**1**

Кәрим Гали улы Тинчурин 1887 елның 15 сентябрендә татар әдәбиятына Г.Коләхмәтов, Ш.Камал, Һ.Такташ кебек әдипләрне биргән Пенза өлкәсендәге Бедный Демьян районы Таракан (Белоозерка) авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туып-үсә. Әтисе җир эшкәртү, мал асрау белән шөгыльләнгән, шактый кырыс табигатьле булган. Әнисе Мәхмүдә исә йомшак күңеле белән аерылып торган, укый-яза белгән, балаларына еш кына халык батырлары, пәйгамбәрләр турында кызыклы вакыйгалар сөйләгән. Кәрим күрше авыл мәдрәсәсендә белем ала. 1900 елның җәендә ул Казанга килә һәм шул вакыттан башлап булачак әдипнең «тормыш университетлары» башлана. Ул бер чәйханәгә эшкә урнаша. Шул елның көзендә атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә. Җәйләрен төрле эшкә ялланып акча туплый һәм кышка тагын мәдрәсәгә әйләнеп кайта. Беренче рус инкыйлабының (1905-1907) тәэсире мәдрәсә стеналары аша үтеп керә. Шәкертләр демократик матбугат аша төрле социаль-демократик идеяләр белән таныша, бу исә мәдрәсә тәртипләреннән ризасызлык белдерүгә китерә. 1906 елның февралендә, мәдрәсә тәртипләренә каршы чыккан өчен, 87 шәкертне, алар арасында Кәрим Тинчурин да була, «Мөхәммәдия»дән куалар. Ул башта Тамбов якларына китеп урман каравылчысы булып эшли, аннары Түбән Новгород, Саратов якларындагы авылларда балалар укыта.

1910 елны беренче татар профессиональ труппасы «Сәйяр» җитәкчесе Г.Кариев белемле, бай тормыш тәҗрибәсе булган, төскә-биткә матур егетне артист итеп чакыра. Остазы җитәкчелегендә К.Тинчуринның артистлык таланты тиз ачыла. Г.Камал, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, А.Островский, Ф.Шиллер һ.б. драматургларның әсәрләрен сәхнәдә уйнап, ул үзенчәлекле образлар тудыра. Татарлар яшәгән күп

урыннарда тамашачыларның мәхәббәтен яулый. Шул чордагы вакытлы матбугатта ул башкарган рольләргә югары бәя бирелә.

Бу елларда К.Тинчурин актив рәвештә әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлый. Бер-бер артлы «Шомлы адым» (1910-1912), «Беренче чәчәкләр» 1913), «Назлы кияү» (1915), «Ач гашыйк» (1915), «Җилкуарлар» (1916), «Соңгы сәлам» (1917) пьесалары дөнья күрә. Ләкин патша цензурасы драматургның әсәрләрен («Назлы кияү»дән кала) сәхнәгә куярга рөхсәт бирми. К.Тинчурин болар белән генә чикләнмичә, газета-журнал битләрендә күпсанлы хикәяләр бастыра, чорның шактый катлаулы вакыйгаларына үз бәясен биреп бара.

1917 елгы октябрь инкыйлабының гадел җәмгыять төзүгә китерәчәгенә бөтен күңеле белән ышанган Кәрим Тинчурин халыкка хезмәт итүче театр сәнгате тудыруга хезмәт итә башлый. Инкыйлаблардан соң драматургның «Йосыф белән Зөләйха» (1918), «Тутый кош» (1918), «Сакла, шартламасын» (1918) комедияләре языла. Бу елларда аның оештыручы, житәкче буларак таланты тулы ачыла. 1918 елны драматург алдына таркалган «Сәйяр» труппасы артистларын җыю, спектакльләр куюны башлап җибәрү бурычы куела. Әдип бу эшкә җиң сызганып керешә һәм тиз арада яшь драматурглар Ш.Усманов, Ф.Сәйфи-Казанлы, Ф.Борнашлар белән иҗади хезмәттәшлек урнаштыра, рус һәм чит ил авторларының әсәрләрен тәрҗемә итүне оештыра. Күпмедер вакыт Мәскәүдә Үзәк мөселман хәрби коллегиясендә эшләгәннән соң, К.Тинчуринны Самара шәһәренә, Көнчыгыш фронт карамагындагы татар театр студиясенә житәкче итеп җибәрәләр. Драматург кыска гына вакыт эчендә бер төркем артистлар әзерләп чыгара һәм шулар белән Оренбург шәһәрендә труппа оештырып, спектакльләр куюны башлап җибәрә. 1922 елны ул беraз вакыт Ташкентта да эшләп ала.

1920 еллар башында татар профессиональ театры житди кыенлыклар кичерә. «Сәйяр» труппасының таркалуы, аның җитәкчесе Г.Кариевның вафат булуы, күренекле артистларның китүе яки төрле шәһәрләрдәге труппаларда таралып эшләве h.б. сәбәпләр халыкның рухи тормышында зур роль уйнаган театр сәнгатенә житди игътибар бирүне сорый. Шундый шартларда К.Тинчурин 1922 елны Казанга чакырып кайтарыла һәм аңа Татар дәүләт театр труппасы оештыру бурычы куела. Ул яңа театрга төрле шәһәрләрдәге күренекле артистларны һәм яшь композитор Салих Сәйдәшевны чакыра. Аларга хәзерге Н.Островский урамында урнашкан Яшь тамашачылар театры бинасы бирелә.

Яңа татар театрының оештыручы-житәкчесе, баш режиссеры булу белән бергә, К.Тинчурин театр сәнгатенең нигез ташларын теоретик яктан да «салыша». Аның совет чорында язылган «Вак милләтләр театры хакында бер-ике сүз», «Татар театры нинди юл белән барырга тиеш?», «Совет драматургиясенең бүгенге хәле» h.б. мәкаләләрендә яңа җәмгыять төзү шартларында драматургия һәм театр сәнгатенең төп юнәлешен, идея-эстетик концепциясен, шуларга бәйле хәл ителергә тиешле бурыч-максатлар ачыклана.

1920 елларда татар театрының репертуары шактый сай һәм тематика, жанр ягыннан бертөрлерәк булганлыктан, алда жанрны төрләндерү, тамашачы теләгенә җавап бирердәй сурәтләү алымнары табу бурычы тора. К.Тинчуринның татар профессиональ музыка сәнгатенә нигез салучы С.Сәйдәшев белән иҗади дуслыгы, М.Фәйзинең «Галиябану»ы белән башлап җибәрелгән музыкаль драма жанрын үстереп кенә калмый, аның яңа мөмкинлекләрен дә ача. С.Сәйдәшевнең сәхнә законнарын һәм әсәрнең жанр үзенчәлекләрен белеп, халыкчан рухтагы музыкасы, гомумән, ике сәнгать төренең үзара синтетик ярашуы әсәр текстында тирәнгә яшерелгән фикерләрне дә ачарга ярдәм итә. Әнә шул рәвешле «Казан сөлгесе» (1923), «Сүнгән йолдызлар» (1923), «Зәңгәр шәл» (1926), «Ил» (1927), «Кандыр буе» (1931) кебек берничә буын тамашачыны тирән фәлсәфи, әхлакый эчтәлекләре, сихри музыкалары белән сокландырып килгән әсәрләр языла. Музыкаль драма жанрында уңышлы эшләгән авторның тамашачылар тарафыннан яратып кабул ителгән трагедия һәм драма-комедияләре дөнья күрә: «Зар» (1922), «Американ» (1924), «Җилкәнсезләр» (1926), «Ударниклар бәйрәме» (1933),

«Алар өчәү иде» (1935) һ.б. Әдипнең драматургия һәм театр сәнгатен үстерүдәге эшчәнлеге югары бәяләнә — 1926 елны «Татарстанның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелә. Ләкин аның иҗаты, эшчәнлеге каршылыклы фикерләр дә тудыра. Матбугатта үткәнне яклый, ана мәдхия укый дигән мәкаләләр күренә. К.Тинчурин бер төркем артистлар белән Әстерханга күчеп китәргә мәҗбүр була. Анда татар театрында баш режиссер булып эшли, үзенең «Ил» драмасын да беренче тапкыр шунда сәхнәгә куя. Ике елдан аны Казанга чакырып кайтаралар.

К.Тинчурин, театрның баш режиссеры булып эшләү дәверендә, беренче остазы Г.Кариев эшчәнлеген, тәҗрибәсен үстереп кенә калмый, үзе дә бик күпләр өчен укытучы була. Драматурглар Т.Гыйззәт, Р.Ишморат, артистлар Г.Кайбицкая, С.Айдаров һ.б. истәлекләрендә К.Тинчурин мәктәбен хөрмәт белән искә алалар.

Драматург 1934 елда яна оешкан Язучылар берлегенә кабул ителә. Ул СССР язучыларының I Бөтенсоюз съездында татар драматургиясенең үсеше турында доклад белән чыгыш ясый. Әмма чорның каршылыклы сәяси-иҗтимагый мохите К.Тинчуринга да килеп җитә. 50 яше тулган көннәрдә — 1937 елның 17 сентябрендә ул, «халык дошманы» дип нахакка гаепләнеп, кулга алына һәм 1938 елның 14 ноябрендә атып үтерелә. Башка бик күп репрессияләнгән авторлар белән бергә, аның әсәрләре дә кулланылыштан алына. Бары 1955 елны гына әдип тулысынча аклана, бай иҗаты халыкка кире кайтарыла, пьесалары сәхнәгә менә. Данлыклы драматург, режиссер, артист, педагогның исемен мәңгеләштереп, 1989 елны Татар дәүләт драма һәм комедия театрына Кәрим Тинчурин исеме бирелә.

## 2

Кәрим Тинчурин — үзенең мәктәбен булдырган, традицияләренең үзеннән соң да яңадан-яңа буын авторлар тарафыннан дәвам ителеп, укучы-тамашачы күңелен яулап алуга ирешкән драматург. Халыкның рухи дөньясында тирән урын алып торучы әдипнең иҗаты, билгеле, бербөтен күренеш тәшкил итә. Анда халкыбыз яшәешенең тулы бер панорамасы чагылыш таба. Беренче пьесасын 1906 елда («Моназара») язган дигән мәгълүмат бар. Алдагы елларда «Хәләл кәсеп», «Шомлы адым», «Беренче чәчәкләр», «Ач гашыйк», «Назлы кияү», «Җилкуарлар», «Соңгы сәлам» кебек әсәрләре языла, кайберләре сәхнәгә куела.

К.Тинчурин иҗатка килгән чор — татар халкы тормышында, шул исәптән аның рухи яшәеше чагылышы булган әдәбият-сәнгатьтә дә Янарыш дәвере буларак билгеләнә. Заманның иҗтимагый-сәяси шартлары яшь авторның дөньяга карашларында, уйлану-эзләнүләрендә урын ала. Милләт буларак формалашкан татар халкы икътисади һәм сәяси хокуклар өчен көрәш башлый. Татар җәмгыяте эчендә төрле социаль төркемнәр мәнфәгатенә бәйле каршылык шактый тирәнәя. К.Тинчурин шул тормыш эчендә кайный һәм әлеге идеяләр йогынтысында була. Бу елларда рус-Европа әдәби-фәлсәфи фикере дә кызу темплар белән үтеп керә. Гасыр башында Н.В.Гоголь, А.Н.Островский, А.С.Грибоедов, А.П.Чехов, М.Горький һ.б. әсәрләре татарчага тәрҗемә ителә. «Сәйяр» труппасында артист, соңрак режиссер Г.Кариевның ярдәмчесе булып эшләгән К.Тинчурин рус авторларының әсәрләреннән тыш Ф.Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт», Ж.-Б.Мольерның «Саран» һ.б. пьесалар белән яхшы таныш булган. Шулай да К.Тинчурин, иң элек, татар әдәбиятының күпгасырлык традицияләре нигезендә әдип буларак формалаша.

XIX гасырның соңгы чирегендә реализм юлына чыккан татар әдәбияты XX гасыр башында тизләтелгән үсеш юлы үтә. Реализмның мәгърифәтчелек һәм тәнкыйди агымнарын үзләштерү белән бергә, Европа тибындагы романтизм мәйданга чыга. Шул ук вакытта, аерым авторлар иҗатында модернизм юнәлешенең символизм, импрессионизм кебек агымнарына хас билге-сыйфатлар, элементлар урын алу, аларны иҗади кабул итү белән очрашабыз. Бер яктан, Шәрык әдәбиятының

унай йогынтысын тойган хәлдә, гасырлар дәвамында үсеп-үзгәреп килгән татар әдәбиятының үз традицияләренә таянуы, икенче яктан, көчле агым булып килеп кергән рус-Европа әдәби-эстетик фикерен үзләштерү бу чор татар сүз сәнгатендәге эзләнүләрнең күптөрлелегенә китерә. Г.Исхакый, Г.Камал, С.Рәмиев, Ф.Әмирхан, И.Богданов, М.Фәйзи һ.б. иҗатында һәр төр искелек, артталык тәнкыйтьләнә, социаль каршылыклар, сыйнфый көрәш, милләт язмышы, әхлакый һәм фәлсәфи карашлар, яшәешнең төрле мәсьәләләре яктыртыла.

Заманның катлаулы, каршылыклы шартлары йогынтысында формалашкан К.Тинчуринның «Беренче чәчәкләр», «Назлы кияү», «Соңгы сәлам» пьесалары өйрәнчек әсәрләр дип түгел, бәлки тормыш каршылыкларын, проблемаларын ачык күргән, милләт язмышы, аның киләчәге турында тирәнтен уйланган, аны Янарышка, тәрәккыятькә илтү юлларын эзләгән, артист буларак сәхнә закончалыкларын шактый әйбәт үзләштергән, сәнгать чараларының төрле алым-формаларына иркен мөрәҗәгать иткән драматург иҗаты буларак кабул ителә. Риза ага Ишморатта сакланып калган автобиографиясендә К.Тинчурин үзе күрсәткәнчә, «Беренче чәчәкләр» аның Октябрьгә кадәрге иҗатын характерлаучы, билгеле бер дәрәҗәдә программ әсәр булып тора. 1917 елны «Сәйяр» труппасы тарафыннан нәкъ менә әлеге пьеса сәхнәгә куелганнан соң, Г.Кариевның К.Тинчуринга алтын сәгать бүләк итүе дә символик күренеш.



*Алда – Габдулла Кариев, басып торалар (сулдан уңга) – Кәрим Тинчурин, Зәйни Солтанов, Габдрахман Мангушев. Зәйни Солтановның сәхнә хезмәтенә 20 ел тулу уңае белән төшкән рәсем. 1917 ел.*

«Беренче чәчәкләр»дә 1904-1914 еллардагы вакыйгалар сурәтләнә. Автор бу чорда татар дөньясында барган бәхәсләрне бер төркем яшьләрнең хыял-омтылышы, яшәеше-көрәше аша ача. «Беренче чәчәкләр» әнә шуларга символ булып килә һәм шәхес ирекен, милләт язмышын кайгыртып яшәүче, шул максатта билгеле бер эш-гамәлләргә алынучы яшь геройларны аңлата. Үзәктә кеше шәхесе, язмышы һәм шуның белән тыгыз бәйләнештә татар милләтенең бүгенгесе һәм киләчәге турында уйлану тора. Тормыш авырлыкларыннан ничек чыгарга? Үзгәрешләргә кайсы юлдан барырга? Әлеге сорауларга җавап эзләүгә бәйле драматург дүрт төрле карашны, яшәеш фәлсәфәсен, гомумән киләчәккә бару юлын алга куеп, житди бәхәс алып бара. Беренче юл, Хәкимҗан белән бәйле булып, Аллаһы Тәгаләгә сыенып, булганга канәгатьләнеп, тәкъдирдә ни язылган, шул булыр дигәнгә кайтып кала. Хәкимҗанның яшәү максатын, берәр авылда мулла булып, «җан тыныч, өс-баш бөтен, тамак тук» булу белән генә бәйләп каравы хәтта сукыр шәкерт Суфыйда да көлү һәм ачу уята. Икенче юл Кыям образы белән бәйле булып, һәрнәрсәдән ризасызлыкны, бөтен нәрсәне кире кагуны аңлата. Катнашучылар исемлегендә аның «үзен хәяттан тыш хис кылучы» дип бирелүе дә игътибарга лаек. Кыям, бу чор татар шигъриятендә шактый киң урын алган гыйсъянчы геройның драматургиядә чагылышы булып тора. Дөрес, әсәр ахырында ул «факелчылар» ягында торучы буларак сурәтләнә. Өченче юл Хәйдәр образы белән бәйле булып, революцион көрәшне аңлата. Ул җәмгыятьне үзгәртү юлын эшчеләр хәрәкәтендә күрә һәм милли хәрәкәтнең шуларга кушылуын тели. Дүртенче юл Хәмит образы белән бәйле булып, мәгърифәтчеләр-җәдитчеләр яклаган фикерләрне үстерүгә кайтып

кала. Әлеге яшь егет һөнәр-белем үзләштереп, туган жирендә халкына хезмәт итү теләге белән яши. Ул кеше шәхесен алга куя, аның иреклe булуын, башкалар белән тигезлеген яклый, ә инде боларга ирешү өчен «укырга, укырга, русча укырга кирәк», ди. Хәмит тырышлык белән университет студенты булуга ирешсә дә, каты авыру аны аяктан ега. Текстта бу караңгы тормыштан котылу өчен тырышучы бик күпләрнең вафат булуы да искәртелә. Алар — «беренче чәчәкләр». Кыям сүзләре белән әйткәндә, «ләкин аларга явыз кырау төшкән». Явыз кырау тирән мәгънәле символ буларак авыр тормыш шартларын, кешенең хокуксызлыгын, татарларның изелү, кимсетелү шартларында яшәүләрен, гомумән, самодержавиенең сәяси-ижтимагый системасын аңлата. Пьесаның идея эчтәлегеп ачуда тагын бер мөһим символ-деталь бар — «жимерек күпер». Хәмитнең «жимерек күпердән халыкны чыгару түгел, үзең дә чыга алмыйсың икән» дигәненә Хәйдәр болай жавап бирә: «Күперне өр-яңадан кормыйча булмый. Аны өр-яңадан корыр өчен, аның черегән баганаларын төпләре-тамырлары белән куптарып ташларга кирәк». Аңлашылганча, «жимерек күпер» символы халыклар төрмәсенә әверелгән царизмны тамырыннан ук юк итү кирәклеге фикерен тагы да үстерә, тәэсирлерәк итә.

Татар тормышындагы һәр төр житешсезлекләрдән көлеп арынырга теләүнең бер чагылышы буларак К.Тинчуринның «Назлы кияү» комедиясе языла. Пьеса үзәгенә салынган вакыйга бик гади: Рәшит исемле «назлы» егет Төркестаннан Казанга өйләнергә килә, кыз табалмыйча аптырагач, ахырда асравы Гайнигә өйләнеп кайтып, хур була. Әсәр фабуласына салынган күренешләр шактый таныш. Татар драматургиясе һәр төр кияүләргә бик бай — Г.Исхакыйның «Ике гашыйк», «Алдым-бирдем», Г.Камалның «Безнең шәһәрнең серләре», И.Богдановның «Помада мәсьәләсе» һ.б. искә төшерү дә житә. «Назлы кияү»дәге Рәшит шуларның дәвамчысы. Авторның табышлары комедиячел конфликт оештыруда һәм көлкеле типлар ижат итүдә чагыла. Әсәрдәге тартыш ике юнәлештә бара: берсе — Рәшит белән милли каһарман битлеген кигән Ильяс, Зыя кебекләр арасында. Моңа кадәрге пьесаларда уңай герой буларак сурәтләнеп килгән газета мөхәррире, китап нәшире көлү объекты итеп алына. Беркатлы, мәгънәсез Рәшитнең «укымышлы, общество күргән» кызга өйләнергә теләвеннән файдаланып, аларның теләсә нинди юл белән акча суырулырыннан автор ирония белән көлә. Каршылыкның икенчесе Рәшит белән гаиләсе арасында бара. Монда үзенчәлекле образ булып Рәшитнең жизнәсе Рамазан тора. Һәр эпизодта ул ашауны гына кайгырта. Шуның белән үзеннән көлдергән бу бәндә тагын бер вазифа үти: киләчәктә Рәшитнең аның юлыннан китәсен искәртә. Г.Камал, Г.Исхакый һ.б. сәнгати табышларын дәвам итеп, К.Тинчурин көлүнең эстетик асылына тирәнрәк төшенә бара. Әсәрдә бер генә дә уңай герой юк. Драматургның эстетик идеалы әлеге һәртөр әхлаксыз-мәгънәсезлектән көлүдә чагыла.

К.Тинчуринның «Соңгы сәлам» драмасы — әдипнең сәнгати фикерләвендәге эзләнүләрне күрсәтә торган әсәр. Ул XX гасыр башы татар сүз сәнгатендә шактый киң урын алган сызлану (экзистенциализм) фәлсәфәсенә йөз тотып язылган. Вакыйга-күренешләр, беренче чиратта, рус кызы Ольганы яратучы яшь сәүдәгәр Вахит Мансуровның рухи кичерешләрен, эчке каршылыкларын һәм сәбәпләрен ачуны максат итә. Пьесаның беренче күренешләрендә үк аның баласы авыруы искәртелә. Әлеге метафора-символ төп геройның жан «авыруын», күңел халәтен, әрнүле хәлен аңлата. Мәхәббәт утында янучы яшь ир, кызның атасы атаклы миллионер Вахрушев ярдәмендә «зур кул булу» — Идел буендагы сәүдә эшен үз кулына алу теләге белән дә яши. Әмма ул үзен чолгап алган милли яшәешне — карт анасын, хатыны белән кызын, динен ташлап китә алмый. Үз чорында шактый бәхәсләр уяткан мәсьәләләрне хәл итүдә К.Тинчуринга төрле әдәби агымнар йогынтысын күрәбез. Пьесада егетнең рухи кичерешләре шактый тулы бирелә. Әлеге психологик халәтне драматург сентименталь рухта тасвирлый. Ольгадан килгән мәхәббәт хатлары, эчке монологлар, күз яшьләре моны тагы да тирәнәйтә. Күңелендәге каршылыкларны чишә алмаган Вахит ялгызлык, кайгы-хәсрәт алдында кала. Шул рәвешле укучы-тамашачы алдында башкалардан

аерылган, тормыш мәгънәсен югалткан, упкынга килеп терәлгән шәхес калка. Бу халәтеннән чыга алмыйча, ул үлемгә бара. Пьесада авторның икеләнүле, сызланулы карашлары Мөхәммәтша образында урын ала. Акча-байлыкны инкарь итүче, аракыда гына юаныч табучы бу кеше әйләнә-тирәдәгеләрдә теләктәшлек, яклау, җәлләү тапмый. Атасыннан калган малны туздырып бетерүен «Без китап кушканча эшләдек. Дәүләт кайдан килгән булса, шунда озаттык та» дип аңлата ул. Суфыйлар, әйбер колы булудан куркып, дөнья рәхәтлекләреннән баш тарткан кебек, ул да атасыннан калган малны туздырып бетергән һәм шуның белән үзен азат, ирекле саный. Мөхәммәтша — заманының үзенчәлекле тибы.

Драматургның 1920-30 еллардагы әдәби эзләнүләре, нигездә, ике юнәлештә бара. Берсе — үткән тормышка бәйле вакыйгаларны, халкыбызның гореф-гадәтләрен, традицияләрен бүген дә кыйммәтен югалтмаган идея-эстетик яссылыкта сурәтләү булса, икенчесе — үзе яшәгән тарихи чорның сәяси-иҗтимагый, әхлакый-фәлсәфи мәсьәләләрен укучы-тамашачы алдына кую.

К.Тинчуринның сәнгати планда иң уңышлы әсәрләреннән булган «Сүнгән йолдызлар» трагедиясендә шәхес һәм җәмгыять конфликты сурәтләнә. Ул исә аерым кешеләр, кеше белән төркем, кешенең эчке каршылыкларында ачыла. Әлеге конфликт гаять кискен булып, фаҗига белән тәмамлана. Кеше бәхете мәсьәләсенә нисбәтле рәвештә К.Тинчурин житди проблемаларны укучы-тамашачы алдына куя. Драматург кешегә хас булган мәхәббәтне гаять матур, серле хис-кичереш итеп сурәтли. Нәкъ менә мәхәббәт хисе Сәрвәрне кыю, кискен адымнарга этәрә, бәхете өчен көрәшергә өнди. Надирга исә көч, ышаныч, яшәеш матурлыгын күрү мөмкинлеге бирә. Кешенең бәхеткә, мәхәббәткә хокукы яклану, боларга киртә булып торган сугыш афәтенә нәфрәт булып калка.

К.Тинчурин үзенчәлекле, үзләренә генә хас сыйфатлары белән аерылып торган геройлар иҗат итә. Әбисе тәрбиясендә үскән Сәрвәр үзенең горур табигате, ярдәмчел, кешелекле, әдәпле булуы белән җәлеп итә. Ул киләчәгенә, бәхетенә ышанычы белән башкалардан аерылып тора. Аның өчен үтеп чыкмастай киртәләр юк. Кызның сөйгәне Исмәгыйль таза, матур егет, тәрбияле, кешелекле булуы белән ачыла. Күңелендә Сәрвәргә олы мәхәббәт саклаper да, үзен кызга тиң түгел дип саный. Автор аның ихтыярсыз, хәтта мескен булуын күрсәтә. Бу аның ятимлеге, аннан да бигрәк хокуксызлыгы, кешедә ялчы булып хезмәт итүе белән бәйле. «Язмыштан узмыш юк» дигән гыйбарәгә ияреп, ул үз бәхете өчен көрәшүдән дә баш тарта. Ә менә Надир мәхдүм — драматургның иң уңышлы образларыннан берсе. Татар әдәбиятында табигать тарафыннан кимсетелгән кешенең бу кадәр тирән фәлсәфи эчтәлек белән һәм үзенчәлекле олы характер итеп сурәтләнгәне юк иде әле. Башкаларда бары тик кызгану хисе генә уятучы һәм шуңа күрә бөтен дөньяга ачулы мәхдүмнең олы, гөнаһсыз йөрәге бар. Ул да кеше, ул да өзелеп, җаны-тәне белән ярата. «Мин сездән үтенәм, мине кызганмагыз, — ди ул Сәрвәргә. — Мин ялгыз идем. Аңлыйсызмы, егерме биш яшькә кадәр ялгыз идем, сез ул ялгызлыкның авырлыгын белсәгез иде... (...) Менә ике елдан бирле мин шул авыр газаплы ялгызлыктан котылып тора башладым. Сез коткардыгыз, Сәрвәр туташ. (...) Сез миңа җан керттегез». Надир бик горур, үзен кызганучыларны дошман күрә, чөнки башкалар белән тигез буласы килә. Сәрвәрне яратуы аңа яшәү көче бирә, мәхәббәте тормыш мәгънәсенә әйләнә. Ул Исмәгыйльнең хисләрен хөрмәт итә, шуңа да икесе арасында каршылык юк. Надир хыялында туган бәхетен акылдан язган Сәрвәр белән аралашуда таба. Кызны югалткач, яшәү мәгънәсен югалта һәм, үзенә үзе кул салып, бу дөньядан китә. Шул рәвешле, фаҗигале вакыйгаларга бәйле әсәрнең төп идеясе ачыла — якты, матур хыяллар белән яшәүче, бәхеткә тулы хокуклары булган геройларның үлеменә китергән кара көчләргә, сугышка һәм аны башлаучыларга нәфрәт. Автор үзе дә әлеге позициядә тора. Ул тормышның гаделсезлегенә ачына. Әсәрнең «Сүнгән йолдызлар» дип аталуына да әлеге тирән мәгънә салынган.

К.Тинчуринның «Җилкәнсезләр» трагикомедиясендә вакыйгалар 1910-1924 елларда барып, Беренче бөтендөнья сугышы, инкыйлаблар, гражданнар сугышы,



*«Зәңгәр шәл» спектакленнән бер күренеш.*

НЭП елларының үзенчәлекләре геройлар язмышына, эш-гамәленә бәйле укучы-тамашачы күз алдыннан үткәрелә. «Жилкәнсезләр» (пьесаның баштагы исеме «Ишкәксез») символик мәгънәдә килеп, тормышта үз юлын, кыйбласын таба алмыйча, дингездәге жилкәнсез кораб хәлендә калучыларны аңлата. Совет чорында әсәргә бирелгән бәя-аңлатмаларда, мондый фикер үткәрелде: көлү объекты булып милли буржуазия вәкилләре тора, алар милләт исеменнән сөйләнеп тә, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучылар, инкыйлабтан соң дошман лагерена күчеп ярык тагарак алдында калучылар һ.б. Бүген инде автор концепциясен тирәнрәк ачу-аңлату сорала. (Мондый омтылыш белән Г.Мөхәммәдова һәм Ф.Бәширов язмаларында очрашабыз). Билгеле, К.Тинчурин үз заманы рухы, хакимлек иткән идеология йогынтысында иҗат итә. Әмма ул элекке өстен катлауны тәшкил иткән буржуазия яисә интеллигенциянең, офицерларның меңнәрчә вәкиле язмышын көлкеле күренеш буларак кына ачуның артык берьяклы һәм беркатлы булуын да яхшы аңлаган. Яңа хакимиятне кабул итә алмыйча «тормыш төбендә» яшәүчеләрнең, шулай ук йорт-җирләрен, туган илләрен ташлап китүчеләрнең эш-гамәле артында күпләрнең ачы фаҗигасе ята бит. Әлеге адашып калган «жилкәнсезләр»не аңларга теләүче, ярдәм итүче юк. Үз иленең гражданнарын (бәреп төшерелгән сыйныф вәкиле булсалар да) шундый шартларга куйган, бик авыр хәлгә калдырган хакимиятне ничек дип атарга? Пьесаның субъектив эчтәлегендә әнә шулар ачыла. Тексттагы зур булмаган репликалар да житди уйлануларга этәрә. Мисал өчен, 1920 елларның икътисади сәясәте «тудырган» нэпман Зәйнетдин болай ди: «Сез бай чакта сезнең милләтегез булган. Ә без, каенатай, интернациональ, ха-ха-ха!.. Бездә милләт тә, черт та юк». Һәр эш-гамәлендә милләтем дип яшәгән К.Тинчуринның 1926 елда язган әлеге сүзләре артында нинди уй-фикерләр ятуын аңлау кыен түгел.

Беренче тапкыр сәхнәгә куелуыннан башлап укучы-тамашачының күңелен биләп алган «Зәңгәр шәл» мелодрамасы — К.Тинчуринның иҗат биеклеген билгеләүче пьесаларыннан берсе. А.Яхин билгеләгәнчә, «Зәңгәр шәл» тирән мәгънәле символ булып, әсәрнең бөтен эчтәлеген иңләп үтә. Шахтер егет Булат алып кайткан зәңгәр шәл — гади бүләк кенә түгел, бәлки мәхәббәт, бәхет һәм шәхси ирек, азатлык символы. Мәйсәрә Булат кулындагы зәңгәр шәлне жыргабиюгә осталыгы белән яулап ала. Бу да мәхәббәт һәм бәхет өчен көрәшү кирәклеге билгесе. Ә инде кызның туганы — ат карагы Җиһаншаның алар бәхетенә киртә булып төшүенә бәйле зәңгәр шәл дә баштан төшә. Мәйсәрә ишан йортында кайгы-хәсрәт кичереп яшәгәндә зәңгәр шәл ана ышаныч бирә, рухи таянычы, өмете булып тора. Ниһаять, кызны коткарырга Булат «Зәңгәр шәл» жырын жырлап килә һәм максатка ирешү билгесе итеп шәлен бөркәнүне сорый. Шул рәвешле, төп сюжетны тәшкил итүче вакыйгалар «зәңгәр шәл» символы белән үзара бәйләнеп, керешеп китәләр. Безнеңчә, пьесаның популярлыгы түбәндәгеләр белән аңлатыла: беренчедән, әсәр чын татар тормышыннан алып язылган һәм аны халыкчан яшәү рәвеше иңләп үтә; икенчедән, үзәктә халыкның ирекка, азатлыкка

омтылышы идеясе тора һәм ул һәрбер татар кешесе өчен үтә дә кадерле, мөһим; өченчедән, музыкаль жанрда булып, С.Сәйдәшев музыкасы вакыйга-күренешләргә дә, образларның эш-гамәленә дә гаҗәеп бер моңлылык, хисселек, эчке бер аһәң сала һәм укучы-тамашачы өчен кадерле итә; дүртенчедән, мәхәббәт һәм шәхес ирегенең социаль мәсьәләләр белән үрелеп баруы; бишенчедән, һәрберсе үз йөзе, характеры белән аерылып торган образ-характерлар тудырылу. Гомумән, сюжет-композициянең төзеклеге, образ-характерларның сәнгатьчә эшләнеше, үзәккә куелган мәсьәләләрнең гомумкешелек кыйммәтләренә нисбәтле чишелеше белән әсәр бүген дә гаять актуаль.

Аерым бер пьесаларында К.Тинчурин җәмгыятьтә барган үзгәрешләрне, заманның яңа геройларын, аларга хас сыйфат-билгеләрне ачарга омтыла. Шуның нәтиҗәсе буларак «Ил» мелодрамасы, авылдагы күмәк хуҗалык төзелешен данлаучы «Кандыр буе» драмасы һәм кешеләрдәге мин-минлек, көнләшү кебек сыйфатларны тәнкыйтьләгән «Алар өчәү иде» комедиясе һ.б. языла.

## 3

Драматург иҗатына нәтиҗә ясаганда, әсәрләренең жанр ягыннан түбәндәгечә бүленүе күрсәтелә: 12 комедия, 5 драма, 4 музыкаль драма, 1 трагедия һәм 4 әсәре башка авторлар белән берлектә языла. К.Тинчурин үзен, беренче чиратта, комедия остасы итеп таныта. Г.Камал, Г.Исхакый традицияләрен дәвам итеп, әлеге жанрны яңа идея-эстетик биеклеккә күтәрә. Әдипнең көнкүреш материалын сәяси фикерләр белән кушуы, сатирик пафосның фаҗигале пафос белән аралашуы, көлкене арттыручы алым-чараларның күптөсмерле булуы, тел байлыгыннан оста файдалануы, әсәрләрнең композицион төзеклеге белән характерларның психологик ачылышы — болар барысы да К.Тинчурин комедияләренә хас үзенчәлекләр булып тора. Аның әсәрләренә тирән оптимизм, явызлыкка каршы көрәш, шәхес иреге мәсьәләләрен алгы планга куеп тикшерү хас. Күпсанлы пьесаларында халкыбыз тарихының гаять катлаулы, каршылыклы чорларының тулы панорамасы чагылыш таба. Игътибарын әлеге вакыйгалар уртасында калган кеше шәхесенә юнәлтеп, автор бигрәк тә яшь геройларны яратып, үз итеп тасвирлый. Аларның олы тормышка атлавында очраган каршылыкларда рухи дөньялары бөтен тулылыгында ачыла. Шуңа да К.Тинчурин иҗаты үзенең психологизмы белән көчле. Әдип эчке монолог, геройның үз-үзенә бәясе, «җан хәрәкәте» кебек алымнарны уңышлы файдалана.

Киң планда драматург Г.Ильяси, Ф.Халидиләр нигез салган, Г.Камал, Г.Исхакый һ.б. шәхесләребез тормышчанлык белән баеткан драматургиянең сәхнә закончалыкларына нигезләнүенә, заман сорауларына активрак мөрәҗәгать итүенә житди этәргеч бирә. Әлеге заманчалык, сәнгатилек белән кушылып, сәхнә әдәбиятында яңа сүз, яңарышның яңа баскычы буларак яңгыраш ала. Шуңа да әлеге иҗат үз чорында гына түгел, бүген дә укучы-тамашачыны кызыксындыра, әдип күтәргән мәсьәләләр бүген дә бәхәс уята, янадан-яңа уй-фикерләргә этәрә.

М.Фәйзи башлап җибәргән музыкаль драма жанрын К.Тинчурин яңа биеклеккә күтәрә, аның мөмкинлекләрен халыкчанлык рухында үстерә. Татар театрын музыкаль әсәрләрдән башка күз алдына да китереп булмый. Безнең халык нәкъ менә мелодраматик рухлы һәм музыка белән үрелеп барган сюжетларны аеруча үз итә. К.Тинчурин әсәрләрендә халык рухы яши. Әдип иркен рәвештә гореф-гадәтләргә, җыр-биюләргә, төрле уеннарга мөрәҗәгать итә һәм шуның белән эмоциональ яңгырашка, җан-рухка тәэсирлелеккә ирешә.

К.Тинчурин иҗат иткән геройлар — әдәбиятыбыз байлыгы. Ул татар драматургиясен Хәмит, Рәшит, Батырхан, Сәрвәр, Исмәгыйль, Надир, Муса, Габдуллажан, Булат, Мәйсәрә кебек үз чорының яңа типлары белән баета.

Драматург сәнгать чараларының, аерым алганда, көлү алымнарының, образ-символларның, типиклаштыруның янадан-яңа төсмерләрен бирә һәм боларның һәрберсендә диярлек традицияләргә юл сала. Хәзерге татар әдәбиятында К.Тинчурин

традицияләре унышлы дәвам иттерелә. Аның әсәрләрендә чагылыш тапкан кеше белән җәмгыять каршылыгы мәсьәләсе, үзенчәлекле көлү алымнары, мәкаль-әйтемнәрдән файдалану, этнографизм кебек билгеләр А.Гыйләҗев, Р.Хәмид, Ю.Сафиуллин, М.Гыйләҗев, Г.Каюмов һ.б. иҗатында үстерелеп, яңа казанышларга китерә. Драматург әсәрләрендәге жанр һәм стиль төрлелеге, характерлар бөтенлеге, вакыйгаларның эпик характерда булуы чорыбызның күренекле әдипләре Т.Миңнуллин, З.Хәким һ.б. тарафыннан уңышлы үстерелә.

Шулай итеп, киңкырлы иҗаты белән халкыбызның рухи тормышында тирән эз калдырган Кәрим Тинчуринның бай мирасы бүген дә кызыксыну уята. Каршылыклы дәвернең каршылыклы геройлары, алар алып барган диалог-бәхәс кеше шәхесе, аның яшәеш мәгънәсе, әхлакый һәм матди кыйммәтләр турындагы уйлануларга этәрә. Талантлы драматург, олы гуманист, фәлсәфәче әдип әсәрләре безнең белән киләчәккә атлый.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ**

---

## *Кәрим Тинчурин турында*

*«Кәрим Тинчурин исеме телгә алынуга, аны һәркем драматург, режиссер, артист итеп күз алдына китерә. Кәрим ага моннан тыш гаҗәп сөйкемле, саф күңелле, холкы һәм эчке табигате, тышкы кыяфәте, үзен-үзе тотышы белән чын интеллигент иде».*

**Фатыйма ИЛЬСКАЯ**

*«Тирән хисле, сүзгә үткер, үзенең алтын каләме аша тормышның ачысын-төчесен таный алган тугрылыклы, киң күңелле драматургыбыз Кәрим ага Тинчурин безнең остазыбыз да, юлдашыбыз да, артист һәм режиссерыбыз да иде».*

**Галия КАЙБИЦКАЯ**

*«Бүгенге көндә Кәрим Тинчуринны күбесенчә драматург буларак кына өйрәнәләр. Ә аның режиссерлык һәм актерлык эше онытылып бара. Бу дөрес түгел, әлбәттә. Чөнки ул, талантлы режиссер булудан тыш, күп кенә уңышлы образлар тудырган оста артист та булды».*

**Хәким СӘЛИМҖАНОВ**

*«Кариев белән Тинчурин бик күп нәрсәдә бер-берсен тутыралар иде. Характерлары ягыннан алар бер-берсеннән бик аерылалар, күп кенә мәсьәләләрдә капма-каршы фикердә торалар — шуның аркасында еш*

*кына бик нык бәхәсләшәләр, бер-берсенә шактый әче генә сүзләр дә әйтешкәлиләр, әмма үзләренең принципиаль каршылыкларын шәхси мөнәсәбәтләренә, бигрәк тә театр эшенә күчермиләр иде. Театр интересларына каршы баруны алар зур хыянәт, иң ямьсез әшәкелек саныйлар иде».*

**Заһидә ТИНЧУРИНА**

*«Татар рухын күтәрүче әсәр — «Зәңгәр шәл»не мин мелодрама итеп түгел, музыкаль, фаҗигале, халык драмасы итеп куйдым. Заманалар үзгәрсә дә, ирекккә омтылу, гади халыкны кысу-изүгә нәфрәт һаман да актуаль. Безнең халык сабыр, түзә. Әмма азатлыкка, ирекккә омтылу да җанында аның. «Кара урман шаулый, ирек даулый», — дип, юкка җырламый бит Булат. «Зәңгәр шәл» татарны яшәтүче көч бит ул».*

**Марсель СӘЛИМҖАНОВ**

*«Кәрим Тинчуринны еллар сынавын узарлык художник иткән сыйфатларның берсе — драматургның шәхес буларак бөтенлеге. Ил, халык мәнфәгате өчен көрәш барганда, үз өстенә җаваплылык алырга курыкмаган Тукайлар замандашы буларак, аларның фикердәше дә иде ул. Бүген без театрыбызның уңышлары белән горурланганда, Кариев, Тинчуриннарның хезмәтен ачык күрәбез. Милли культураның үсеш юлларын билгеләгәндә, нык позициясе булган шәхесләр һәрвакыт кирәк. Тинчурин — шәхес культы корбаны. Шәхес культының куркынычлылыгы, явызлыгы чын шәхесләрне юлдан алып ташлап, сафларны шәрәләндерүдә булды. Олы шәхесләрнең җитешмәвен, аларга мохтаҗлыкны озак еллар тоеп, сызланып яшәдек без. Менә аларның мирасы кайтты. Һәм алар шундук үз урыннарын алды...»*

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

**P.S.**

*Кәрим Тинчурин турындагы истәлек-альбом һәм «Шәхесләребез» сериясе китаплары файдаланылды.*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Бәйрәкә һәм Бәйрәкә Тамак авыллары

Кама аръягы төбәгенең көнчыгыш районнары бай табигате, жор күнелле, ачык йөзле кешеләре белән дан тота. Бу якларның атамалары да үзенчәлекле. Аларның мәгънәләре ни аңлатканын тиз генә абайлап та булмый. Аерым атамалары гажәп яңгыравыклы һәм жыр кебек ятышлы. Кайберләренә ишетү белән колакны торгыза торган сәерлек хас. Бәйрәкә шундый атамаларга керә.

Бәйрәкә авылы Баулы шәһәреннән — 65, Бәйрәкә Тамак авылы исә 75 чакрым ераклыкта урнашкан.

Бәйрәкә Тамак авылы янында археологлар XIII — XIX йөзгә мөнәсәбәтле каберлек табалар. Мондагы табылдык әйберләр башка жирләрдәге төрки кабиләкавемнәргә (XIX йөздәге) нисбәтле әйберләр белән аваздаш.

1859 елда Бәйрәкә авылындагы 376 хужалыкта 1247 ир-ат һәм 1281 хатын-кыз яшәгән, авылда 3 мәчет булган.

XVIII — XIX гасырларда Бәйрәкә шул тирәдәге авылларның иң зурысы исәпләнгән. Авыл халкы этносоциаль үзенчәлеге белән дә аерылып тора. Монда татар, башкорт, чуаш, калмык һ.б. халыкларның традицияләре һәм гореф-гадәтләре үзара нык береккән.

Бәйрәкәлеләр «Нажар» һәм «Күк Тәкә» жыеннарында катнашкан. XX гасыр башында авылда биш мәчет булган. Авылдагы беренче һәм өченче мәчетләр 1708 елда, икенчесе 1865 елда үзгәртелеп салына, дүртенчесе 1905 елда төзелә. 1909 елның 15 апрелендә төзелеш бүлеге бишенче мәчет проектын раслый. Хәзерге көнгә кадәр менә шушы мәчет сакланып калган.

Бәйрәкә авылында мәдрәсә дә була. Ул XIX гасырның икенче яртысында ачыла. Аны оештыручы булып өченче мәчетнең имамы Гобәйдулла хәзрәт исәпләнә. XX гасыр башында бу мәдрәсә Уфа губернасындагы мәдрәсәләрнең иң күренеклеләре рәтенә керә. Ул — Уфа, Эстәрлетамактагы Гариф Рәмиев, Эстәрлебаш мәдрәсәләре белән бер дәрәжәдә тора. Дини дәресләр белән беррәттән, мәдрәсәдә шәкертләргә татар һәм рус телләре, география, математика, Россия тарихы һ.б. фәннәр укытыла. Анда спектакльләр дә куела. Бу мәдрәсәдәге прогрессив укыту алымнары авылдагы хатын-кыз мәдрәсәсендәге укытуга да зур йогынты ясый. Мәдрәсәнең йогынтысы Баулыдагы жәдид мәктәбенә дә көчле була.

Өченче мәхәллә имамы булып, әтисен алыштырганнан соң, Мөхсин Гобәйдуллин билгеләнә. Бу — 1897 елда була. Биш елдан соң, 1902 елда мәхәлләнең икенче мулласы итеп аның кече энесе Мәсгут Гобәйдуллин куела.

---

*Дәвамы. Башы 2006 елның бнчы санында.*

Агалы-энеле Гобәйдуллиннар мәдрәсәгә, анда укучы балаларны тәрбияләүгә бөтен көчләрен һәм талантларын бирәләр.

Бөтен дөньяга шөһрәте таралган композитор Софья Әсхәт кызы Гобәйдулллина — Мәсгут Гобәйдуллинның оныгы.

Бәйрәкә сүзенең мәгънәсенә килик.

Бәйрәкә сүзе казах телендә «муллык» төшенчәсен белдерә. Алма-Атада «Бәйрәкә», ягъни «Муллык» дип аталган кибет бар. Бәйрәкә атамасы безнең җөмһүриятькә кыпчак кабилә-кавемнәре белән килеп кергән. Кыпчаклар татар, казах һәм башка күп кенә төрки халыклар формалашуга шактый өлеш керткән. Татар теле сөйләшләрендә аерым төрки телләрдән кереп сакланып калган тел берәмлекләре шактый очрый. Бәйрәкә атамасы шундыйларның берсе.

Кәшиф Рәхим язмаларыннан файдаланып, Бәйрәкә авылы тарихы белән бәйләнешле риваятьләрдән өзекләр китерик.

1648 елның хәзерге Бәйрәкә авылы урынына элекке Мамадыш өязе, Кукмара авылыннан барлыгы унбер хуҗалык килеп урнаша. Бу кешеләр унбер генә баба булсалар да, җан хисабы байтакка җыела. Чөнки нәселдәге карт кеше үлми торып, аның балалары бүленмичә яшәгән. Мәсәлән, бишенче бабай — Собханкол карт үзенең дүрт улы белән бергә яшәгән. Аның оныклары да, өйләнеп, күп балалы кешеләр булып беткән булганнар. Шуның белән бергә, алар хуҗалык дип тә аталмаганнар. «Собхый җыены», «Колый җыены», «Калмәт җыены» дип йөртелгәннәр.

Күчеп килүчеләр Кукмарада кысынкылыкка дучар ителгән кешеләр булган яки чукындырудан куркып качканнар. Ул чагында Мамадыш тирәсендә көчләп чукындырулар, чукынмаган кешеләрне бәкегә тереләй тутырып, бала-чагаларны алып китүләр булган, диләр.

Бу унбер кеше килеп утырганда, биредә фәкать Туйкә авылы гына булган. Бәйрәкәнең көнбатышында чирмешләр яшәгән. Чирмешләрнең олылары Рәкә бай, Атнай, Әхмәтша исемле булган. Рәкә бай чирмеш авылының хуҗасы булып саналган һәм, яна күчеп килгән унбер хуҗалык та аның химаясенә кергәнлектән, авылга Бәйрәкә исеме бирелгән. Күчеп килгән кешеләр чирмешләр белән тату-дус яшәгәннәр. Кыз алышып, кыз бирешкәннәр. Чирмешләр үзләре дә, Казан алынганнан соң, Казан тирәсеннән күчеп килгән булганнар. Әйтүләргә караганда, Кукмарадан килүчеләр белән алар арасында электән танышлык булган.

Бәйрәкә Тамак авылында яши торган Ахунҗан абый сөйләвенә караганда, Бәйрәкә авылы халкы дүрткә бүленгән: 1) типтәрләр; 2) вак сәүдә белән шөгыльләнүчеләр; 3) Казан халкы; 4) мадьярлар.

Болар кемнәр соң? Беренчеләре — Мөшһид Иван Казан ханлыгын канга батырганнан соң, Казан ягыннан һәм башка урыннардан күчеп килгән җирсез халык, ягъни типтәрләр. Икенчеләре — вак сәүдә белән шөгыльләнүчеләр, ягъни әлеге һәлакәттән соң туган-үскән җирләреннән тамырларын өзеп килеп утырырга мәҗбүр булган халык. Дүртенче төркем — шушы тирәләрдә яшәгән венгрлар, ягъни монах венгр Юлиан (XIII йөз) килгәндә үк бу тирәләрдә көн иткән халыктан калган төркем. Географик атамаларның язылышына һәм әйтелешенә караганда, Бәйрәкә авылы XVIII гасырда барлыкка килгән.

Бу авылда тагын: «Кәрт тавы» дигән риваять тә язылып алынган: «Кәрт тавы» дигән җирдә хәзинә күмелгән. Хәзинә җир астында йөз илле — ике йөз ел ятса женләнә, аны кемгә атап күмсәләр, ул хәзинә күмелгән урында кешеләргә шул нәрсә күренә башлый, имеш: йә төйнәлеп ташланган бала, йә сарык бәтие, йә сарык үзе. Ул өрәк, жен, бала тавышы чыгарып елый, йә сарык тавышлары чыгарып бәэлди. Шул урында, ягъни хәзинә яткан җирдә күренгән әйберне (әйтик, сарыкны) чалсаң, ул хәзинәгә ия булырга мөмкин, имеш.

Бәйрәкә авылында Кәшиф Рәхимнән 1974 елда Марсель Әхмәтҗанов язып алган «Мөхәммәтшәриф шәкерт» дигән риваятьтә шактый гыйбрәтле юллар бар:

«Мөхәммәтшәриф дигән шәкерт Пугачевка кушыла. Аннан кайткач, мәдрәсә оештырып, үзенә бертөрле тәгълимат тарата. Ул: «Байлар — Алланың дошманы,

жир — Алланыкы» дигән. Үзе яланаяк йөргән. Байлардан, бәддога белән куркытып, ярлылар өчен ярдәм ала торган булган. 1828 елны югала, шуннан соң аны бер арестантлар төркемендә Себергә озатылганда күрәләр. Үргәнеч шәһәрендә Мөхәммәтшәриф шәех Бәйрәкәви төрбәсе бар, бик оста эшләнгән ташы да бар».

Пугачев күтәрелеше белән бәйләнешле тагын бер риваять сөйлиләр. Анысын да Бәйрәкә авылында Кәшиф Рәхимнән Марсель Әхмәтжанов язып алган. «Йосыф Морза, Пугачев хәрәкәте кузгалгач, кешеләрне Пугачевка кушылмаска өндәп йөри икән. Бер авылда, утын әрдәнәсенә басып: «Пугачев — вор, ул патша түгел», — дип сөйләнеп торганда, аңа аталар. Шуннан соң ул: «Абзагызны коршун ала алмый, абзагыз әжүн гыйлеме белә», — дигән. Аның күлмәк астында тимер көбәсе бар икән. Әмма икенче тапкыр аткач, егылып төшкән. Туганнары, Уфадан килеп, яхшы авыл дип, аны Бәйрәкә авылы зиратына күмгәннәр. Ташы әле дә бар».

1909 елда Бәйрәкә авылында ярлы гаиләсендә язучы Мөсәгыйть Мостафин туа. 1941 елның август аенда ул үзе теләп фронтка китә һәм сугыш кырында батырларча һәлак була.

Ватан азатлыгы өчен гомерен биргән язучы-солдат буларак, Мөсәгыйть Мостафинның исеме Татарстан Язучылар берлеге бинасына куелган мемориал тактага язылган.

***

Бәйрәкә Тамак авылы, шул авылда яшәгән Ахунжан абый сөйләвенә караганда, 1919 елда Бәйрәкә авылыннан аерылып утырган. Бу тирәләрдә урман булган. Авыл Бәйрәкә суының Ык елгасына килеп кушылган урынына, ягъни тамагының сул ягына утырган өчен шулай Бәйрәкә Тамак дип аталган. Бу авыл янында археолог-галимнәр таш чыгара торган карьер тирәсендәге иске каберлекне тикшергәннәр. Бу каберлектән алар кеше һәм хайван сөякләре, тимер кайчылар, өзәнгеләр һәм төрле бизәкләр төшерелгән көзгеләр тапканнар. Әлеге табылдыклар XIII — XIV йөзләргә мөнәсәбәтле зур төрки каберлекләрдә очрый торган әйберләр белән тәрдәш.

Авыл халкы күркәм фигыльле һәм эшчән. Бәйрәкә Тамак авылының да урнашкан урыны бик матур, әйләнә-тирәсендә күлләр һәм таулар күп. Монда Якты күл, Бетле күл, Ташлы күл, Мөәзин күле, Торна күле, Ягур (ягъни Егор) күле, Павул (Павел) күле, Заем күле һ.б., Буа тавы, Кылыч тау һ.б. бар.

Ахунжан абый сөйләвенә караганда, Бетле күл җәйнен эссе көннәрендә дә кипми икән. Ташлы күл дип исемләнгән күл янында, чыннан да, әле дә таш күп. Торна күле янындагы әрәмәлектә торналар бала чыгарган. Егор күле Егор исемле алпавыт җирендә булган. Павул күле, Егорның энесе алпавыт Павел җирләрендә булганга шулай аталган. Заем күле янында бөтен авыл халкын мәҗбүри заемга яздырганнар, дип сөйлиләр.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# Н

**НАЗЫЙРӘ** (гарәпчә-фарсыча: өлге, үрнәк, җавап, охшатма), Якын һәм Урта Көнчыгыш, Урта Азия, Идел буе халыклары әдәбиятында киң таралган, бүтән автор әсәренә җавап рәвешендә языла торган шигъри форма. Автор аңа кадәр язган танылган әдипнең билгеле бер сюжетын һәм төп персонажлар образларын ала да, үзенчә ачып биреп, башка әсәр иҗат итә. Кагыйдә буларак, төп теманы, шигъри үлчәмне, рифмага салу тәртибен, әсәрнең троп системасын саклый. Шулай итеп, Н. танылган әсәрнең фабуласы һәм образларына оригиналь үзенчәлекләр кертеп үзгәртеп эшләнгән әсәр формасы булып тора. Бу мәгънәдә Н. – шәрекъ поэзиясенең күчеп килә торган әдәби формасы. Татар әдәбиятында Н.гә Котб, Сәйф Сараи, Мөхәммәдъяр, Ш.Зәки, Г.Тукай (аның «Печән базары, яхут Яңа Кисекбаш» поэмасы урта гасыр дини-дидактик әсәренә «Кисекбаш китабы») Н. булып тора, Ш.Бабич, Г.Камал һ.б. әдипләр мөрәҗәгать итәләр.

Әдәб.: Квятковский А. Поэтический словарь. М., 1966.

**НАМӘ** (иран телендәге борынгы формасы – намак - язу, китап, документ, хат, мөрәҗәгать һ.б.), әдәби әсәр, тарихи-мемуар, сәяси хезмәтләр кушма исемнәре составында килә (мәсәлән, Фирдәүсинең «Шаһнамә»се, Гаттарның «Панднамә»се, Бабурның «Бабурнамә»се). Мондый мисаллар татар әдәбиятында да бар (Харәзминең «Мәхәббәтнамә»се, Г.Чокрый, Г.Утыз Имәни әсәрләре һ.б.).

Әдәб.: Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

**НАРИМАНОВ** Нариман Кербәләй Нәҗаф углы (2.4.1870, Тифлис ш. – 19.3.1925, Мәскәү, Кремль дивары буенда җирләнә), әзәрб. дәүләт эшлеклесе, язучы. Сәүдәгәр гаиләсендә дөньяга килә. Гори шәһәрендә укытучылар семинариясен (1890), Новороссийск ун-тының мед. ф-тетын (Одесса ш., 1908) тәмамлый. Баку, Тифлис шәһәрләрендә укытучы, табиб булып эшли. 1905 елда «Гуммет» («Энергия») с.-д. оешмага керә, матбугатта публицистик мәкаләләр б-н чыгыш ясый, әзәрб. теленә РСДРП Программасын тәрҗемә итә. 1908-14 елларда Астраханьдә сөргендә булганда шәһәрнең мөселманнар җәмгыяте мәдәни тормышында актив катнаша, дини темага багышланган мәкаләләре б-н «Борһане тәрәкъкый» г-тасында мәкаләләр бастыра, 1908 елда казан-кавказ артистлары җәмгыятен төзү эшендә башлап җибәрүчеләрнең берсе була. 1917 елда «Гуммет» к-теты рәисе, РСДРП (б)ның Баку к-теты әгъзасы, «Гуммет» г-тасы мөхәррире. 1918 елның язында Баку ХКСның шәһәр хуҗалыгы комиссары. 1919 елдан соң РСФСР чит илләр халык комиссариатының Якын көнчыгыш бүлеге җитәкчесе, Милләтләр буенча эшләү халык комиссары урынбасары. 1920 елда Әзәрбайҗан рев. к-тетының, Әзәрбайҗан ХКСның рәисе. 1922 елдан СССР ҮБК рәисләренең берсе. Н.ның әдәби әсәрләре 20 йөз башы төрки халыкларның милли-азатлык һәм рев. хәрәкәтен чагылдырдылар. Н. – милли хорафатларны тәнкыйтьләгән «Баһадур вә Сона» (1896) романы, әзәрб. әдәбиятын беренче тарихи пьесасы булган, халык күтәрелешен чагылдырган «Надиршаһ» (1899) һ.б. авторы.

Әсәр.: Собр. соч.: в 2-х т. М.-Л., 1926; Повести и пьесы. М., 1971.

Әдәб.: Казиев М.Н. Нариманов. Баку, 1970; Кочэрли Ф. Нэриман Нэриманов. Баку, 1965.

**НАРЫШКИН** Николай Васильевич (12.6.1938, Ульяновск өлкәсе Карсун р-ны Кадышево а.), икътисад белгече, язучы, публицист, икътисад фән. канд. (1973), проф. (1998), ТАССР, РФның атказ. мәдәният хезмәткәре (1986, 1996). Казан. ун-тын тәмамлаганнан соң (1966) КХТИда икътисад теориясе һәм хокук кафедрасында укыта. Хезмәтләре РФ, ТР аграр мәсьәләләренә карый. Россия авылының киләчәге хакында уйланулар б-н сугарылган хикәя, очерк, новелла, эссе һәм повестьлар авторы. ТР Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Махотин извоз. К., 1998; Мятущаяся Россия, К., 1999; Священная сура.

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынннан басылып килә.*

К., 2000; Кадышевский эпос. К., 2002; Русский дневник, или По Святым местам Русского Духа. К., 2004. Т.1.

Әд.: Паломник Русского Духа. Жизнь, творчество Николая Васильевича Нарышкина (Махотина). К., 2003; Патриот земли Российской. К., 2005.

*Г.Д.Аверьянов.*

**НАСРЫЙ** (Насретдинов) Гамир Гариф улы (3.1.1916, хәзерге Башкортостан Респ. Кызыл Кама р-ны Иске Янҗегет ав. – 27.12.1959, Казан), драматург. Казан театр техникумын тәмамлый (1937). Туган районында колхоз театрын оештырып, аңа житәкчелек итә. Инсценировкалар, драм. этюдлар, бер пәрдәлек пьесалар, скетчлар яза («Колхоз театры», 1934). 1941-49 елларда (бүленеп) ТАССР МС каршындагы радиотапшырулар комитетында музыкаль һәм драматик тапшырулар мөхәррире булып эшли. «Ялкау Бикмөхәммәт» исемле беренче драмасы 1932 елда басылып чыга. Аның күп кенә пьесалары крестьяннар тормышыннан алып язылган, авылда социаль-икътисади үзгәрешләргә бәйле. «Бухгалтер Ашмасов» (1940), «Путёвка» (1941), «Патриотлар семьясы» (1941), «Таныш кешеләр» (1942) пьесаларында колхозлашуга каршы килгән кешеләрне фаш итеп, автор колхоз тормышын мактап сурәтли. Бөек Ватан сугышы елларында совет сугышчыларының батырлыклары турында шигырьләр, җырлар, хикәяләр, очерклар иҗат итеп «Фронтовая правда» г-тасында бастырып килә. 1950 елларда Н. республика театрлары белән актив эшли. Аның «Идел буенда» (1948) музыкаль комедиясе, «Күңел дәфтәре» (1949), «Без капчыкта ятмый» (1950), «Кушнарат» (1952), «Кадерле минутларда» (1953), «Туган авылым» (1955), «Яшел эшләпә» (1956) драма һәм комедияләре Татар опера һәм балет, Татар академия, Татар драма һәм комедия, Минзәлә татар драма, Башкортостан академия театрларында уңыш белән бара. Пьесалары «Комедияләр» (1950), «Пьесалар» (1953), «Кадерле» (1955; рус теленә тәрҗемәдә «Дорогие минуты», М., 1957), «Яшел эшләпә» (1958; русчага тәрҗемәдә «Зелёная шляпа», М., 1959) җыентыкларында урын алган. Кайбер шигырьләре композиторлар З.Хәбибуллин, Җ.Фәйзи, С.Сәйдәшев, Р.Яхин тарафыннан көйгә салынган. Н. совет-фин кампаниясендә, Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнә.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр: Пьесалар, җырлар. К., 1966.

Әд.: Гыйззәт Т. Гамир Насрый турында // Әсәрләр. К., 1978. Т.4.

*Г.М.Габделхакова.*

**НАСЫЙБУЛЛИН** Зиннур Сәгыйдулла улы (12.11. 1937, Башкортстан АССРның Нуриман р-ны Кече Тенкәш ав. – 10.1.1985, (8.1.1986) Казан), шагыйрь. Башкорт ун-тын тәмамлагач (1968) республиканың төрле газета-журнал редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, Башкортстан радиокомитетында мөхәррир булып эшли. 1969 елдан ТАССР МС ның телевидение һәм радиотапшырулар комитетында. Тәүге шигырьләре «Беренче карлыгачлар» (1969) күмәк җыентыгында урын алган. Шагыйрьнең сугыш вакытына туры килгән авыр балачак һәм яшьлек мәхәббәте темаларына багышланган лирик характердагы шигырьләре «Талгәш» (1973), «Гамьнәр илендә» (1987)исемле җыентыкларында тупланган.

Әд.: Әдипләребез: биобиблиографик белешмә. К., 2009. Т.2.

**НАСЫЙБУЛЛИН** Мәгъсүм Нәҗип улы (15.10.1925, Мамадыш кантоны Байлангар ав. – 14.10.2009, Казан), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1986). Свердловск шәһәрендә юридик (1954) һәм пед. (1959) ин-тлар тәмамлый. 1962-64 елларда Урал һәм Казакъстанның Күкчәтау өлкәсе шәһәрләрендә тикшерүче һәм прокурор вазифаларын башкара. 1960 еллардан хокук темасына караган очерк һәм хикәяләрен җирле һәм үзәк матбугатта бастыра башлый. Очерклардан торган беренче китабы «Конец опасной тропы» исеме белән 1968 елда рус телендә нәшер ителә. Башкортстан Респ-касы прокуратурасында (1964-70) һәм ТАССР Прокуратурасында (1970-81) эшләгән елларында бигрәк тә актив иҗат итә. Ул «Без капчыкта ятмый» (1972), «Телсез шаһитләр» (1974; русчасы «Немые свидетели», 1979), «Төнге ату» (1975), «Алтын алка» (1977), «Яшерен касса» (1978; русчасы «Тайная касса», 1982), «Син тикшерүче бит» (1987), «Күктән иңгән дәлил» (1991), «Кайтаваз» (1996), «Елан гадәтен үзгәртми» (2000), «Дулкынга – дулкын» (2005) детектив хикәя һәм повесть җыентыклары авторы буларак укучыларга билгеле. Әсәрләренең нигезендә авторның озак еллар криминаль дөньяны күзәтүе, җинаятькә этәргән сәбәпләр һәм аның социаль тамырлары, хокук саклау органнары хезмәткәрләренең җәмгыять тормышындагы роле турында уйланулары ята. Н.ның күп кенә әсәрләре украин, грузин, удмурт, чуваш телләренә тәрҗемә ителгән. Бөек Ватан сугышында

катнашкан. Медальләр, ТРның Мактау грамотасы белән бүләкләнгән.

Әд.: Миншин М. Детектив // Правосудие в Татарстане. 2002. №1; Галимуллин Ф. Ак теләкне җилкән итеп // Казан утлары. 1995. №10.

*Г.М.Габделхакова.*

**НАСЫЙР** Хөсрәү (псевд., чын исеме Әбү Мөгыйн әл-Кубәдияни әл-Мәрвази) (1004, Әфганстан. Бәлх ш. тирәсендәге Кубәдиян а. – 1072 дән соң, Әфганстан, Бадахшан өлкәсе Йомган а.), фарсы һәм таҗик шагыйре. Исмәгыйлиләр мәзһәбе вәкиле. Шуның өчен Бәлхтән куыла. Гомеренең соңгы елларын Бадахшан тауларында уздыра. Әдәби мирасын 12 мең бәйттән торган диван, «Ровшанайинамә» («Балкыш китабы») һәм Мисырга кылган сәяхәттән (1046-52) алган тәэсирләрен чагылдырган «Сәфәрнамә» поэмалары, берничә дини-фәлсәфи трактатлар тәшкил итә. Әсәрләрендә сарай шагыйрьләренең хакимнәренә ялагайлануларын, фәнни һәм фәлсәфи фикернең үсешенә ирек бирмәгән ортодоксаль дини руханиларны тәнкыйтьли, ярлыларга карата кызгану таләп итә. Җәмгыятьнең чишелмәгән проблемалар сәбәбен «начар дин» таралуында һәм «гаделсез хакимлектә» күрә.

Әсәр.: Сафар-наме. Книга путешествия. М.-Л., 1933.

Әдәб.: Бертельс А.Е. Насир-и Хосров и исмаилизм. М., 1959.

**НАСЫЙРИ** Зыя (1886-1933), язучы. Югары белемне Төркиядә ала. Укып кайтканнан соң Оренбургта укытучылык итә, «Вакыт», «Йолдыз» г-талары б-н хезмәттәшлек итә. 1913 тән сәүдә фирмасында эшли. 1907-09 елларда язылган «Кемнең баласы?», «Ахирәт йорты», «Поездда угрылык» исемле хикәяләр, «Ятимнәр» пьесасы, «Кочләп кияүгә бирмиләр» комедиясе һ.б. авторы.

**НАСЫЙРИ** (Насыров) Имай (Имаметдин) Низаметдин улы (12.10.1898, хәзерге Башк. Респ-касы Стәрлетамак р-ны Түбәнге Усылы а. – 29.3.1942, яки 29.9.1842 ), язучы, җәмәгать эшлеклесе. 1910-14 елларда Эстәрлетамак мәдрәсәсендә укый. 1914-18 елларда авыл китапханәсен җитәкли. Гражданнар сугышында катнаша. 1919 да Урал фронты Башкорт бригадасы политбүлегенең агитаторы итеп куела, Күзәй кантонында милиция җитәкчесе булып эшли (1920); 1921-22 елларда – Башкорт АССР Главмилициясенең политкомиссары. 1923-31 елларда республика басма органнарын оештыруда катнаша, «Белем», «Сәсән», «Керпе» ж-ллары, «Коммуна» (1931-32) г-тасы редакциясендә эшли . 1934 тә Мәгариф халык комиссариатында инспектор, 1934-36 елларда «Башкортстан вышкаһы» г-тасы һәм «Һәнәк» ж-лының мөхәррире. 1920-24 елларда РКП(б)ның Башкорт өлкә к-ты һәм Башкорт Үзәк Башкарма к-ты әгъзасы буларак РКП(б)ның 10 нчы съездына делегат итеп сайлана. Революцион үзгәрешләргә, яңа тормыш төзүгә дан җырлаган тәүге шигырьләре 1920 еллар башында языла. Н. – «Тереләй кабергә» (Өфө, 1926), «Вагонда» (М., 1929), «Гөлдәр» (Өфө, 1930) исемле мажаралы повестьлар авторы. «Сибай» (Өфө, 1936), «Енелгән ятыу» (Өфө, 1937) повестьларында колхозлар төзү, «Күзәй» (Өфө, 1936 ) романында Башкортстанның бер кантонында совет власте урнаштыру вакыйгалары (романда сүз автор үзе шаһит булган реаль тарихи шәхесләр һәм вакыйгалар турында бара) тасвирлана. «Без һул як ярзан» романы тәгәлләнми кала. Н. – башкорт әдәбиятына һәм сәнгатенә багышланган мәкаләләр авторы. 1937 нең февралендә нахакка репрессияләнә; вафатыннан соң аклана.

Әсәр.: Әсәрзәр: 3 томда. Өфө, 1957-68.

Әдәб.: Зарипов Н.Т. Имай Насыйри: Тормошо һәм ижады. Өфө, 1983.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

Фәнзаман
Баттал

# ӘҖӘЛ МИҢА ӨЧ ТАПКЫР ЯНАДЫ

**Беренче каберем еракта калды...**

Әгәр дә мин ул чакта утырган урынымнан тагын бер генә сулыш соңрак кузгалган булсам да, минем гомер 1955 елның җәендә үк өзелергә тиеш иде. Ә каберем Ык елгасының текә яры астындагы җир куенында калган булыр иде...

Үткән гомеремне барлап утырган, күңелем сагышка чумган минутларымда минем күз алдыма талгын гына агып ятучы газиз Ыгым килә... Аның назы, ятим һәм ач вакытларымда тамагымны да туйдыруы, гүзәллеге белән үземне бар иткән табигатькә гашыйк итүе, тирбәлеп торган дулкыннары белән юатуы ничек онытылсын...

Әйе, ач үлемнән дә күп еллар саклады ул мине. Тотсаң — балыгы, тирә-ягындагы җуалары, кузгалаклары, кызыл һәм кара бөрлегәннәре, чәй урынына пешерергә хуш исле мәтрүшкәләре, сусыл кукылары, арырак атласаң, карлыганнары, шомыртлары, хәтта кыргый алмалары да синеке!.. Терекөмештәй тере бала булсаң, эзләнсәң, ул әзерләп куйган җимеш-нигъмәтләрен таный белсәң, шулар белән тукланганда күңелең Ходайга мәдхия дә әйтеп торса, үтерми сине ачтан Ык буендагы табигать, үтерми!

Дистә-дистә еллар аша шул чорларга борылып караган чакларымда сагыш тулы күңелем елмаеп та куя еш кына. Мин үзем дә шул Ыкның бер балыгы булдым бугай! Күз яшедәй чиста, үтә күренмәле суына чумып, төбендәге чуерташларын, алар арасында хәрәкәтләнүче энә күзедәй вак җан ияләренең ничек хәрәкәтләнүен, анда тагын ниләр барлыгын карарга һәм күзәтергә ярата идем. Тагын бер хәл еш искә төшә... Ыкның Тарзанка дигән урыны бар иде. Ял көннәрендә Минзәләнең бөтен халкы шунда су коена, ял итә. Ярда мәгърур бабабабны хәтерләтүче галәмәт биек тә, киң дә булып үскән бик дәү агач бар иде. Шуның өстәге бер ботагына бәйләнгән арканга тотынып, Ыкның уртасына кадәр үк Тарзан кебек очып суга чума идек. Шундый бер көндә, онытылып китеп, күзлегем белән сикергәнмен. Елганың уртасына барып төшкәч һәм күзлегем су төбенә киткәч кенә ялгышымны аңлап алдым. Йөзләрчә кеше кайнаган-коенган су, әлбәттә инде, болгана... Эзләүдән файда юк. Икенче көнне, халык әле йокыда чакта — иртүк елга буена төшеп, әлеге аркан белән тагын сикереп чумдым Ыкка. Төбенә төшеп, күзне киң ачып әрле-бирле йөзгәч, ни күрим, «читтә кунган» күзлегем, колаксаларын тырпайтып, «мин монда» дигәндәй елтырап ята! Һай, чиста да, гүзәл дә, рәхимле дә иде минем газиз Ыгым!

Сизгәнсендер, укучым, беренче җөмләмдә үк сине каләм диган «кармагыма» эләктереп, үземне иркәләп үстергән һәм... бала чагымда ук үз куенына (мәңгелеккә!) ала язган елгам белән таныштырып үттем. Шулай итмәсәм, мин синең күз алдыңа туган табигатенә рәхмәтсез, аннан бары тик куркыныч кына күргән, шул очракны гына хәтереңдә калдырган үпкәчел бәндә булып килер идем.

Ә хәзер инде әлеге 1955 елдагы хәл турында...

Ыкның сулъяк яры һәр елганыкы кебек текә иде. Читтәнрәк карасаң, биек тә, тигез дә стена кебек торган урыннары күп иде ул ярның. Бер көнне, сөзәгрәк ягыннан килеп, шундый «стенаның» төбендә балык тотып утырам. Ә утырган җирем яр астыннан як-якка сузылган тар гына сукмак... Өч кармагым инде суда, казап куелган таяклары, өчесе өч якка сузылып, балык көтә. Калкавычлары да чумгалап ала, эләккән һәм җепкә тезелгән балыкларым күз алдымда — суда уйнаклыйлар. Хәер, тыпырчына дип әйтү дөресрәктер... Ләкин әле карашым ун адым тирәсе читкәрәк кадалган дүртенче кармагыма да төшкәләп ала. Анысы аеруча чыдам җепле, кармагы да өч чатлы, таягы да ныклы. Анысына җәенме шунда, чуртанмы-чуртмы кабарга тиеш. Һич югы зур алабуга йотмый калмаячак андагы өч чатлы кармакка сыртыннан эләктереп салынган бәртәсне! Әнә бит ул, ычкыну дәрте белән тарткаланып, калкавычны тибрәтә-тибрәтә, үзе дә җепне як-якка йөртеп тора. Ыктан кайберәүләр өчәр потлы җәен дә тота икән, минем бәртәскә дә берәр зур балык кызыкмый калмас. Дөрес, җәенгә үк нәфесләнү юк-югын. Ә инде өч-дүрт килолы балыкларны тартып чыгарулар шактый булгалады. Хәтта бер мәртәбә чуртанның үтә саллысын да, сугыша-таркалаша торгач, кем әйтмешли, ярга сузып салдым бервакыт. Саңагын билсәпид руленә кигереп кайттым ул көнне. Саңагы рульдә булса да, койрыгы юлны себереп кайта. Унбиш-уналты яшьлек малайны оста балыкчы итеп танытуга шул да бик җитә!

Бөтен Ыкның бердәнбер хуҗасыдай япа-ялгыз утырам. Гамил Афзал әйтмешли, күктә — кояш, җирдә — мин! Аркам стенадай биек ярга терәлгән, астымда коры печән, өс бөтен, борыннан чыга хуш исле төтен. Тып-тын. Яфрак селкетерлек тә җил юк. Су өсте дә көзгедәй тигез. Оҗмах!..

Шулай да бераздан оҗмахның бер чите кителгән кебек тоела башлады — теге ныклы кармагымның калкавычы да, җебе дә уйнаудан туктады. Әһә, мәйтәм, йә тонган бу бәртәс, йә ычкынып тайган! Тикшерергә, җимен алыштырырга кирәк! Булмас монда кашык хәтле генә балыклар белән юанып вакыт сату...

Әле генә тотылган чабакны эләктердем дә, җәлт кенә сикереп торып, теге кармак янына йөгердем. Таягына тотынып өлгердем микән, артымда кинәт җил үткәне тоелды, дөнья җимерелгәндәй гөрселдәү ишетелде, елганың каршы ярына таба чүмәләдәй дулкыннар ыргылды. Дулкыннары да капкара. Нәрсә бу?! Артыма борылып карасам, ни күрим, мин утырган урында... туфрак-балчык чүмәләсе! Кармаклар да күренми, барысы да җир астында калган. Баксаң, биеклеге 4 метр чамасы ярның калын катламы җимерелеп ауган. Ә ул каплап торган «төп стенадан» бихисап юан һәм нечкә тамырлар асылынган. Җимерелеп төшкәненнән дә тамырлар чыгып тырпайган. Әйтерсең лә мәңге кул тотышып, исәнләшеп яшәгән кешеләргә нинди дер коточкыч афәт килгән дә, куллары өзелеп, төрлесе-төрле якка томырылган. Әнә бит, өзелгән урыннары агарып калган тамырлар да, кабат кавышырга, ялганырга насыйп булыр микән дигәндәй, бер-берсенә сузылып калган Ә инде ярның аумый калганы су читеннән ике-өч адым ерагайган...

Юк, ул чакта курку диган нәрсә кермәде күңелгә. Киресенчә (балалык галәмәтедер): «Дус малайларны гаҗәпкә салып сөйләрлек зур вакыйга булды

бу, ичмасам! » дип сөендем дә сыман әле. Бары тик еллар үтә-үтә генә тирәнтен уйландыра башлады... Әйе, урынымнан бер генә мизгел кузгалмый утырсам да минем каберем әзер булган инде ул көндә... Мина нәрсә булганын да, кая югалганымны да беркем дә белмәс иде. Берничә аймы, елмы шунда: «Качкандыр... Бүре-мазар ашагандыр... Суга баткандыр...» кебегрәк сүзләр йөрер иде дә, тора-бара телгә дә алмаслар иде. Һәр кешенең үз гаме, үз кайгысы болай да хәттин ашкан...

Шактый еллар баргалап йөрдем мин ул урынга. Япа-ялгыз килеш шушы табигатьнең шаян да, моңлы да бер баласы булганлыгымны, иң беренче шигырьләремне һәм уч төбедәй хикәячекләремне дә шунда язганлыгымны да күз алдыма китереп уйлану өчен... Бармаганыма, мөгаен, утыз гына ел түгелдер... Мин яраткан, мине үстергән Ык елгасы бетте инде ул... ГЭС өчен мөмкинлекләр тудырабыз, Ильич утлары белән дөньяны балкытабыз ди-ди суга батырдылар аны. Мин йөргән юллар, сукмаклар да, әлеге мәгърур ярлар да юынтык ләгәннән аккан суны хәтерләтә торган болганчык дәрья астында калды. Бер ярыннан икенче яры күренмәслек киң булса да, анда су коенып кинәнгән кешеләр дә күренми. Кая аның суында ачык күз белән чумып йөрү?!. Сукыр калырсың, юләр...

Су басуга бер-ике ел үткәч, биек таудан карап тордым балачагым Ыгының ярлары кайда булганлыгын чамалау өчен. Бигрәк тә иксез-чиксез пычрак сулыкның уртасында басып калган зур агачларны күргәч тетрәндем. Алар яфраксыз калган, каралган... Озын кулларга охшаган, корыган кин ботакларын өскә күтәргәннәр дә:

— Нишләттегез безне, кешеләр! Ник шулай үзегезне дә үстергән Табигать ананы үтерәсез?! — дип елыйлар сыман. Каргыйлар да кебек...

Шунда басып торганда: «Әгәр дә мин теге вакытта ук җир астында калган булсам, кешеләрнең мондый ук рәхимсезлеген, коточкыч гамәлләрен һәм, гомумән, ямьле дөньяның тәмам ямьсезләнүен күрмәгән булыр идем бит, Ходаем!» кебегрәк уйлар да кереп тулды башыма... Ләкин яшәлле дә яшәлде... Менә җитмеш дүртенче яшем бара... Еш кына мондый фикерләр дә килә: «Ходай мине исән калдыруны кирәк тапканда, бәлки, болай дип уйлагандыр: — Яшәсен әле, дөньяның Минем юлдан читләшүен, шул читләшүдән туган куркыныч вә ямьсез хәлләрне аңласын, аңлаганнарын үз халкына, диндәшләренә язып та, сөйләп тә гомер итсен, кисәтеп тә яшәсен! — дигәндер...» Әйе, яшәвен шулай яшәдем... Ләкин, Тукайчарак әйтсәм, кырлэндем, күп кыйналдым, әмма дөньяның сафлыкка, шәфкатьлелеккә, гамь белән гомер итүгә юл алуын күрү бәхетенә ирешә алмадым...

### «Юләр врач»

Монысы инде армиядә, казарма караватында күргән төштән башланды...

Кыска, әмма көлдергеч, ә соңыннан күп еллар буе уйландырган төш булды бу.

Төшемдә агач төбендәге эскәмиядә (казарма янында шундый урын бар иде) китап укып утырам. Шулвакыт миңа таба ап-ак халатлы, юантык гәүдәле табибның ашыга-ашыга килүен күрдем. Килеп тә житте бу, сулыш та алмастан, кырыс кына бармак янап, шелтәле тавыш белән боерып та куйды:

— Китап укып, вакыт сатып утырма монда! Марш! Тиз генә аракы тап та, исергәнче эч! Акчаң булмаса, үзем бирәм...

Ашыга-ашыга кулын кесәсенә батырды бу, әмма чыгарырга өлгермәде, төшем өзелде — колагыма кырыс сержантның «Подъём!» дигәне ишетелде. Караватның икенче катыннан атылып төштем дә, башкалар кебек үк ашык-

пошык киенә башладым. Үзем физзарядкада йөгерәм, үзем көләм: «Каян килеп керде бу юләр врач минем төшкә. Бүтән врачлар аракының зарары турында жай чыккан саен сөйлиләр, ә бу юләр исергәнче эчәргә куша!.. Хи-хи-хи!..» Бит юганда да, көлеп җибәреп, чак кына кушучыма алган судан тончыкмадым: «Вәйт, юләр врач!..» Ашханәдә утырганда да көлеп-көлеп куйгаладым... Кемгә аракы эчәргә кушуын әйт әле син аның! Дөрес, урта мәктәпне бетергәч, чыгарылыш кичәсенең төнендә, мәктәпнең ат абзары артына алып чыгып, тәвәккәлрәк классташларым ярты стакан аракыдан авыз иттерделәр. Аннан соң армиягә китәр алдыннан күрше егетләре белән башка китәрлек итеп эчтек. Ә бу юләр врач төшкә кергәнче мин инде ике елдан артык аракыны иснәгәнем дә юк. Алай гына да түгел, искә дә алганым юк. Армиядә кыстап карауччылар булмады түгел. Анда да эчмәдем — курыктым. Гауптвахтага-мазарга тыгарлар дип түгел, командирлар әткәм-әнкәмә берәр күнелсез хәбәр җиткермәгәйләре, аларның кәефен кырмагайлары дип курыктым. Ә бу юләр врач миңа — аракы турында уйлап та карамаган егеткә аракы эчәргә боера!

Көннең икенче яртысында дивизионны сафка тезделәр. Нарядка җибәрмәкчеләр. Ә мин инде сафка басканчы ук нарядны кайда үтәчәгемне беләм. Чөнки әле мин өч көн элек кенә отпускыдан килгән идем. Маневрлар вакытында артиллерия наводчигы (төзәүчесе) булсам да, казармадагы тормышымда филнекедәй гәүдәле батарея старшинасы житәкчелек итә минем белән. Мин — писарь-каптенармус. Бер-бер мөлкәт кирәк булса да, кемнәргәдер увольнительный тутырырга туры килсә дә, берәр документ язу кирәге чыкса да, старшина Лапинның бөтен казарманы тетрәтеп мөгрәве ишетелә: «Саитбатталов, ты где?!»

Менә шул старшинама, күчтәнәч итеп, Минзәлә аракы заводыннан чыккан ике «акбаш» һәм ярты түшкә каклаган каз алып килгән идем отпускыдан. Шуларны йоткач, потлы кулын җилкәмә салып: «Хороший ты человек, Саитбатталов. И водка, и гусь хорошими оказались», — дип мактаган һәм шунда ук нарядка кая җибәрәчәген дә әйткән иде: без хезмәт итә торган Жмеринкадан алты-жиде чакрымда гына винтполигон бар — шунда! Аны саклау өчен гадәттә бер сержант белән ике рядовойны унбиш көнгә җибәрәләр. «Оҗмах!» диләр иде андагы нарядта булган солдатлар. Брикет ягып жылытыла торган каравыл өе дә бар анда. Тышта нинди генә салкын яки юеш булмасын, ут чәчеп торган мич каршында кызыналар. Ә инде ике-өч йөз адымда гына Тартак дигән авыл бар. (Чаярак солдатлар аны Бардак дип йөртәләр.) Өченнең берсе телефон төбендә калса, икәвенә шул авыл кызларының кочагында хозурланып төн үткәрергә мөмкин. Бу хакта «Фил» абзый да белми түгел. Шунадыр: «Пользуйся моей добротой!», диде.

Анлашылды: Барда... тфү-тфү... Тартакка сержант Марач һәм ике рядовой барачакбыз. Берсе — Сверлау егете Матвиенко. Сөенештек. Аннан соң, армия уставы кушканча, наряд алдыннан ике сәгать черем итү өчен, казармага юнәлдек.

Ләкин миңа казармага керергә туры килмәде — ишек төбендә Башкортстаннан килеп хезмәт итүче Әхмәт Йосыпов дигән татар егете туктатты.

— Ике сәгать йоклау миенне генә томалый бит ул... Әйдә, койма аркылы чыгып таябыз да, әнә теге йортка керәбез. Ишек төбендәге почмагында бер мичкә виноград ширбәте бар ул хахулның. Стаканын илле тиеннән сата. Ну, тәмле, ну, баллы, малай, ширбәте! Теленне йотарлык! Миндә акча да бар — киттек!

Әйе, һәрвакыт акчалы малай иде бу Әхмәт — армейский спекулянт иде.

Каяндыр иске-москы итекләр, гимнастеркалар, шинельләр юнәтә, шуларны, берничә тиен дә биреп, «салагаларның» яңа киемнәренә алыштыра. Шул яңаларын тирә-якта яшәүче хохолларга сата. Ә аларның инде хәрби киемгә мөкиббән икәнлеген һәркем белә: эшкә дә, кешелеккә дә кияләр солдат киемен.

Әхмәт хәмер эчәргә чакыргач, әле иртән генә күргән төшем дә искә төште тагын! Янә кабат көлдем әлеге юләр врачтан, «ярый инде, синенчә булсын», дип. Аннары Әхмәт артыннан иярдем. Почмактагы мичкәне күргәч, исем китте: үзе юан, үзе биек. Эче тулы виноград. Шуңа колхоз казаны капкачыдай такта капкач та салынган. Капкач өстенә икешәр потлы гер ташлары куелган. Тутырылган виноград шул басым астында әкрен генә кысыла-сыгыла әчи тора, аска җыелганы, чемер-чемер килеп, кодрәт җыя. Бабай чумырып-чумырып сала тора, без чөмерә торабыз. Шулкадәр татлы, тәмле! — корсаклар күпкәне дә онытылып китткән. Бәй, градусы да барлыгы аякка басып, урамга чыга башлагач кына сизелде. Инде шактый исергәнебезне дә сизеп алдык, шуңа күрә казарманың туалетлары, юыну бүлмәләре урнашкан арткы яктан гына йоклап ятучы хезмәттәшләребез янына үтмәк булдык. Казарманың коридорына керә торган ишекне шыпырт кына ачып маташа идем, каршыма ук замполит Лосев килеп басмасынмы!.. Борылмак, чигенмәк булдым — барып чыкмады, замполит гимнастерка итәгемне эләктерде.

— Нишләп йөрисең? Нишләп йокламыйсың? Ба-а, ты же пьян! Куда назначен в наряд? Куда?! Винтполигон!? Ты же винтполигон пропьешь... Старшина! Где старшина?! Старшина, ко мне!!!

...Винтполигон сагына минем урынга бер кыргыз егетен җибәреп, мине, бераз черем итеп алгач, артиллерия паркының каланчасына менгереп бастырдылар... Тәнгә сылана торган дымлы суык... Һәр бөртеге баш бармак башы кадәрле юеш кар төшә, шинель манма су. Төн караңгы. Тән калтырый. Ә тегендә, винтполигондагы мич каршында, минем урында(!) болай да җылы якта яшәп үскән кыргыз малае кызына! Шушы җәфаны теләгән икән миңа төшкә кергән юләр врач!..

Хәер, алай булып чыкмады...

Таң аткач, смена арасында, казармага кердем. Дневальный тумбочкасы янындагы табуретта дивизион командиры Брук утыра. Җилләр-җилләр китереп, телефон «колагын» әйләндерә, ә үзе, сүгенә-сүгенә, трубкага кычкыра:

— Винтполигон! Винтполигон!.. Вашу мать! Куда подевались?! Почему нет ответа? Все разом в Бардак ушли, да?! Алло, алло!.. Винтполигон!..

Кара карчыгадай кырыс подполковник, бинибая үртәлеп чыгырдан чыккач, сикереп торды һәм «вашу мать» кебек кәлимәләргә «сейчас поеду, всех...» кебегрәк янауларын өсти-өсти, ишек алдына ыргылды. Ул кереп утыруга ук, Украина декабрена хас карлы сазны ярып, вездеход урыныннан кузгалды һәм, як-якка пычрак аттыра-аттыра, күздән югалды. Ә инде... кабат ике сәгатьтән... (язарга да авыр, дуслар), хәрби частька кара хәбәр таралды: винтполигон сакларга киткән егетләрнең барысы да үлгән... Кыргыз егетенең сулышы булган әле. Әмма ул да госпиталь юлында җан биргән. Мондый фаҗиганең хикмәте дә тиз ачыкланды: каравыл йортының юшкәсен иртәрәк ябып, йокыга киткәннәр икән. Ис тиеп үлгәннәр...

«Фаҗига» дидем бит әле, әйеме? Дөресен генә әйткәндә, тетрәнмәдем дә, артык кайгырмадым да кебек ул чакта. Подумаешь, өч солдат үлгән... Анда — армиядә сугыш булмаган чорда да солдатлар еш һәлак була: кайсы-берсе үткән сугышта җиргә күмелеп калган минага басып та, урман эчләрендә күгәреп-кызарып беткән снарядларга орынып та күккә

күтәрелеп оча. Әйтик, маневрлар вакытында күрше полкның авыр танкы жирдән күтәрелеп, гусеница дигән чылбырларын өскә күтәреп, сыртына, ягъни башнясына ятты. Баксаң, жир астында унбишләп ел элек «качып калган» бомбаның өстенә менгән булган... Ярый әле, авыр контузия алган булсалар да, экипажындагы егетләр исән калды. Ул гарипләрне ата-аналары госпитальдән алып киттеләр. Тагын бер егетнең үлеме гыйбрәтле дә, кызык та булып истә калды. Әйе-әйе, кызык та булып... Без ул көнне бөтен полкыбыз белән артиллерия паркында эшләдек. Тягач механиклары тягачларын төзәтә, минем кебек пушкарьлар гаубицаларын чистарта, көпшәләрен көзгедәй ялтыратканчы ышкый. Әнә теге аргы башта шоферлар кайнаша. Шуларның кайберләре машиналарының шиннарын кабарту белән мәшгуль. Насос эченнән көчле басым белән чажлап, колак пәрдәсен ертырдай тавыш белән сызгырып чыккан һаваны шинның клапанына терәп алулары була, бушаган шин бер мизгелдә таш кебек катыланып кабарып та чыга.

Кинәт шул яктан кычкырышкан, өтәләнеп жикерешкән тавышлар колакны ярды.

— Ты што наделал, сука!

— Ты ведь человека убил!!!

— Разьве так шутят?!

Барып карагач, аңлашылды: бер солдат бөгелеп, туңкаеп эшләгәндә икенчесе, шаярмакчы булып, моның ашаганын бушата торган «нокта»сына насосны терәп алган икән. Әнә, ята жирдә солдат. Күз ачып йомганчы кабарган да, бүселеп китеп шартлаган...

Анда һәр солдат үлгән яки һәлак булган саен кызгана, кайгыра башласаң, үзеңнең чиргә сабышуың бар. Шунысын да белә идек ул чакта ук: тыныч хезмәттә чакта да солдатларның күпмеседер үлү норма санала. Ягъни ул үлем өчен командирларны жавапка тартмыйлар... Бу юлы да шулай булды — шартлаган солдатны туган ягына илтеп тапшырдылар и вәссәлам! Үлеменең «кызыклыгы»ннан көлдерү өчен генә искә алгаладылар мәрхүмне кайберәүләр...

Бераз гына төп вакыйгадан читкәрәк китүемнең хикмәте шунда гына — солдат гомеренең өзелүе совет чорында да кайгы булмады армия өчен, хәзер дә бер тиен дә тормый ул жан ияләренең бәһасе. Сүз уңаенда әйтеп кенә үтәм: бу темага мин егерме еллар элек «Солдат: кешеме, хайванмы?» дигән күләмле мәкалә язып дөньяга чыгарган идем инде... Шулай. Берәр бозау яки сарык үлсә дә колхоз фермасында, биш алты кешене суд каршына бастырулары ихтимал. Солдат үлеме исә исәпкә дә, санга да кертелми.

... Әйе, Әжәл миңа солдат чагымда да янады. Ләкин, Ходай рәхмәтедер, тагын исән калдым. Шул вакыйга искә төшкән саен болай да уйланам: әгәр мин ул чакта винтполигон сагына жибәрелгән булсам, минем гомерем дә 1960 елның 23 декабрендә өзеләсе булган... Башкача да фараз кылып карыйм: кем белә, ул көнне хәмер эчмәгән һәм шул хәмернең гөнаһ шомлыгы аркасында ул каравылга барудан тыймасалар, старшина Лапин хәл иткәнчә тегеләр белән китсәм, бәлки, кем белә, барыбыз да исән калган булыр идек! «Мичне томаларга иртәрәк әле, егетләр», дип кисәтә алган, тынлата алган булыр идем, бәлки... Хәер, үтәсе үткәч, китәсе киткәч кенә «бәлки»ләп утырудан, кысыр хәсрәтне куертудан ни файда?! Алар бит инде ярты гасырдан артык жир куенында....

Теге күргән төшемне искә төшергән саен елмаям да:

— «Юләр» табип юкка гына кисәтмәгән икән! — дип куям. Әмма шунысын онытмыйм: ул чакта да минем гомерне, ни өчендер, Ходай

саклаган. Теге врачны төшкә кертүче дә, Әхмәт Йосыфовны алдыма чыгарып куючы да Аллаһы Тәгалә Үзедер, дип уйлыйм. Ләкин... шулай уйлавым гөнаһ саналмый микән?...

## Кеше гарьлегеннән гарьләнеп...

Әҗәл белән өченче мәртәбә күзгә-күз очрашуым мизгелен язар алдыннан бик озак уйланып утырдым... Язуын язармын да бит, ләкин дөнья тупасланып, кешеләрнең шактые оялу һәм гарьләнү кебек хисләрдән мәхрүм калган бу заманда анламаучылар да күп булыр кыйссамның монысын... Шуңа күрә төп вакыйгага керер алдыннан укучыма бер сорау бирәсем килә:

— Әгәр дә сина — бер гөнаһсыз бәндәгә кемдер берәү нахакка кап-кара гаеп ташласа һәм бөтен дөньяга таралырлык итеп сөйләсә яки һич югы миллион татар укырлык итеп язып чыкса, нишләр идең? Әгәр дә хурга калдырган кеше үз гаебен танудан һәм гафу үтенүдән дә баш тартса.

Син уйлый тор, укучым, ә мин тәвәккәлләп язуымны башлыйм.

Бу хәлнең 1987 елның апрель ахырында булганлыгын бик яхшы хәтерлим. Санаторийдан кайтышлый Түбән Камадагы энекәшемә кереп чыгуны кирәк таптым. Анда кергәнче юл өстендәге киосктан «Социалистик Татарстан» гәҗитен алдым. (Ул чакта аның тиражы 200.000 чамасы иде. ) Энекәшемнең гаиләсе белән хәл белешкәч, сөйләшеп тә утыргач, балконга чыгып әлеге гәҗитне караштыра башладым. Ягъни үземне кызыксындырырдай язма эзлим. Шундагы язмаларның иң зурысы — кем әйтмешли, сөлге кадәресе бер язучыбызның тәнкыйди мәкаләсе икән. Ху-уш, укый башладым тегене. Әһә, бу тәнкыйтьче үткән гасырның житмешенче елларында шактый уңышлы әсәрләре белән әдәбият сөючеләрнең игътибарын җәлеп иткән, тора-бара «Канатлар талмасын» исемле бик шәп повесте белән сокландырган Хәниф Хәйруллин дигән язучыбызның иҗатына бәя бирүгә керешкән икән. Мондый рухтарак башлаган тәнкыйтьче юлдан-юлга усаллана баручы мәкаләсен: «Син, Хәниф, прозаик буларак, әйбәт кенә әсәрләр яздың, яратып укырлык берничә китап та чыгардың. Ләкин шигырьләрең бик сай, язылышы талымсыз, түбән... Шигырьләрең тупланган җыентыгың бернәрсәгә дә ярарлык түгел...» Шундый бәясен аңлый башлауга ук аптырашка калдым... Нәрсә бу?! Әллә Хәниф шигырьләр дә яза башлаганмы?! Һәм шулчак аның белән бергә эшләгән чорым да күз алдымнан үтте.

...1963 елның мартында мине — Минзәләдә туган-үскән, шундагы район газетасында берничә ел эшләп өлгергән егетне — Сарманда чыга башлаячак «Ленинчы»гәҗитенең редакторы Әслах Гаязов үз янына эшкә чакырган иде. Ягъни яңа гәҗитне оештыруда, аны дөньяга чыгара башлауда булышлык итүемне, бер-ике ел булса да шунда бүлек мөдире булып эшләвемне теләгән иде Әслах абый... Бардым, эшли башладым. Баксаң, Сарманның үзендә дә Илгизәр Кушаев, Равил Гыймадиев кебек шәп кенә каләмчеләр бар икән. Дуслык, сердәшлек өчен дә менә дигән! Бер-ике айдан Буада редактор булып эшләүче якташлары Хәниф Хәйруллин дигән ир кайтып төште. Әллә Буаны яратмаган, әллә Буа аны үз итмәгән — анысын белгән юк, ләкин шунысы ачыкланды, Сарманына бөтенләй кайткан бу, эш сорый редакция хуҗасыннан. Аңа җаваплы сәркәтип вазифасын бирделәр. Һавалырак икәнен дә чамаладым каракучкыл йөзле, бөдрә чәчле чибәр бу ирнең. Бигрәк тә шигырьчеләрне өнәп бетерми иде Хәниф. Хәтта, шигырь белән мавыгучылар белән сөйләшкәндә, борынын чөя төшеп, шул ук вакытта йөзен дә читкә борып, эре кыяфәт белән:

— Йөрисез инде кычытмаган җирегезне кашып, буталчык сүзләрегездән куплетлар әвәләп... Акыллырак мәкалә язсагыз шәбрәк булыр иде, ичмасам, кирәге чыгар иде, — дигәннәре дә истә.

Дөрес, ул вакытта әле язучы исемен күтәрерлек әсәрләре сизелми иде.

Иллә дә мәгәр район гәжитен матурларлык очеркларны бер утыруда язып та бетерә иде. Язганда каләменнән җил күтәрелгәндәй була иде: җинел яза, белеп яза!.

Әйе, бер генә мәртәбә дә шигырь язганын күрмәдем. Ул жанрдагы әсәрләрен матбугаттан да укыганым булмады...

Ә бу Тәнкыйтьче агай (исемен, фамилиясен әйтмим, гүрендә тыныч йокласын) исә кемлеген, иҗатын биш бармагымдай яхшы белгән Хәниф Хәйруллинның (дип уйлыйк хәзергә) шигъри җыентыгыннан аерым строфаларын тезә-тезә, үзен әйләндерә-әйләндерә типкәли. Имеш, шушындый иҗатны шигырь дип буламы? Ник мондый рисвай нәрсәләр язып, аерым җыентык та чыгарып, әдәбиятның бәясен төшерәсең?!

Бәй, әлеге строфаларның кайберләре таныш булып тоела башлады бу рәхимсез тәнкыйтьне укый торгач... Хәниф Хөснуллин дигән шагыйребезнең шигырьләре түгелме соң болар?! Ул бит еш кына яңа язган шигырьләрен миңа да укып күрсәтә иде. Төгәлрәк әйтсәм, күп еллар буе укып, колагыма тукып яшәде аларны. Монысының да тарихын берничә җөмлә белән сөйләп үтим инде... Мин Хәниф Хөснуллин белән алтмышынчы еллар башында яшь язучылар семинарында танышкан һәм дуслаша башлаган идем. Тәбәнәк буйлы, җирән чәчле, юантык гәүдәле бу егет үзенең эчкерсезлеге, кешелекле, ярдәмчел булуы белән җәлеп итте. Минзәләмдәге эш телефоныма да хәл-әхвәл белешеп шалтыраткалады. Берничә елдан үзе дә килеп чыкты редакциягә. Гәҗиттә эшлисе килә икән дә, урын таба алмыйчарак йөргә икән. Нәкъ шул көннәрдә район радиосының эшен, сыйфатын яхшырту, тапшыруларның вакытын да арттыру кирәклеге турында райкомнан фәрман булган иде. Оештыру эшләрен редакциягә йөкләделәр. Радионы редакциянең бер бүлеге буларак таныячакларын да редакторның колагына кат-кат киртләделәр. Әйе, нәкъ шул көннәрдә редакторым:

— Яраклы кадр тапканчы син оештырырсың, син алып барырсың радиотапшыруларны, — дигән иде. Без көткән кешенең үзе килеп керүе сыман булды Хәниф Хөснуллинның Минзәләдә пәйда булуы. Сүз озайтып тормастан, шуны гына әйтәм: Хөснуллин күп еллар буе бездә эшләде, иҗатының сагышы да, барышы да күз алдымда булды. Яши-яши төрле шәһәрләргә күчсәк тә, аралашуыбыз өзлексез иде.

Шулай итеп, әлеге биек йортның иң югары балконында утырганда ук ачыклап бетердем: баксаң-күрсәң, йа Хода, теге Тәнкыйтьче агай Хәниф Хөснуллинның шигырьләрен Хәниф Хәйруллинныкы дип белеп язган икән әлеге чыбыркылы тәнкыйть мәкаләсен!.. Әле бит үзенең язучы булуына ныклап инанган, күп меңнәрчә, хәтта миллионнарча татар алдында үзен җаваплы итеп тойган каләм иясе бер генә фактны ялгыштырса да ояла, хурлана, гарьләнә, эчендә үкенү ялкыны яна. Ә бу очракта зур форматлы гәҗит битен тутыра язган зур мәкалә бары тик ялганнан, гөнаһсыз каләм ияләрен пычратудан, мыскыл итүдән гыйбарәт!

Шул мизгелдә, бер-берсен тыгынлый-тыгынлый кырыкмаса-кырык сорау тула башлады башыма:

— Ничек бу Тәнкыйтьче агай китаплар тышлыгына ук ап-ачык итеп басылган әдипләрнең фамилияләрен дә укый алмаслык хәлгә килгән?!

— Үзенең ни-нәрсә язганын да аңлый алмаслык дәрәҗәгә җиткән, үзе кебек үк танылган ике язучыны шакшыга батырган бу кеше бүгеннән соң дөнья күзенә ничек күренергә тиеш?!

— Бу мәкаләне укыганда теге әдипләр нинди хисләр кичерер икән?!

— Язганының пасквиль икәнлеген тәмам аңлагач, бу агай хурлыгыннан-гарьлегеннән бауга менмәс микән?!

Бу очракта укучыбыз шунысын да белергә тиеш: әсәрләрен иҗат

иткән чакта чын язучылар үзләрен фәкыйрьләр яки патшалар итеп тә, фаҗигагә юлыккан адәм итеп тә, мескен кол һәм җәллад итеп тә тоярга сәләтлеләр. Ягъни әдәби геройлары кичергән хисләрне, максатларны, кайгы-хәсрәтләрне бөтен тулылыгы белән үз йөрәге аша кичерә беләләр. Бу — Ходай биргән үзенчәлек. Менә мин дә биек балконда шундый халәткә килдем. Ә сорауларым һаман үрчи торды:

— Әгәр дә мин шундый ялган гыйбрәт язган булсам, нишләр идем?!

Каным кайный, башым әйләнә башлады, хәтта шундый мәсхәрәгә үзем юлыкканмындыр, бөтен милләт алдында гафу ителмәслек рисвайга калганмындыр сыман тоелды һәм... искә төшерү дә куркыныч хәзер... тугызынчы каттан аска карадым. Анда асфальт. Машиналар кайный. Шунда кинәт әллә нәрсә булды — тәмам хәлсезләндем. Биеклек мине аска суыра башлады. Һәм ул мине сөйрәп тә төшерәчәк иде. Ләкин шул мәлдә артымда салмак, тыныч кына тавыш ишетелде:

— Әйдә, абый, кер. Өстәл әзер. Тамак ялгап алыйк.

...Әйе, шөкер, акылым сафланып, дөньям яктырып китте. Ашап-эчеп алгач, энекәш белән яшелләнүе сизелә башлаган бакчага чыктык. Шушындый да матур табигатьтән — һәр үләне, һәр бөҗәге, агачларда ачылып килүче һәр бөре күзенә мөлдерәп караган якты дөньядан ничекләр итеп үз теләгең белән китмәк, кап-караңгы җир астына ничекләр күчмәк кирәк?!

Шулай... Ул чакта да исән калдым. Анысына да 24 ел үткән... Әлегә яшәп ятам, иҗат итәм. Гомер бик кыска ул. Үлем барыбер килә! Әгәр дә Әҗәл тагын да килсә, мөгаен, соңгысы булыр... Житмештән дә нык узган карт белән сатулашып тормас ул...

Әнә, яраткан, хөрмәт иткән каләмдәшләрем булган ике Хәнифнең мәңгелеккә күчүләренә дә күп еллар үтте инде. Теге тәнкыйтьче яманласа да, әйтеп бетерим: үзеннән соң әдәби мирасы күп калмаса да, Хәниф Хөснуллин да сәләтле шагыйрь иде, мәрхүм. Ләкин аның сәләтен күрмәделәр яки күрсәтмәскә тырыштылар.

Ә-ә-ә!.. Теге Тәнкыйтьче агайны әйтәсезме? Казанга кайткач очраштым мин аның белән. Гарьлекле мәкаләсен дә исенә төшердем.

— Ничауа, андый хәлләр булгалый ла ул... Үтәр әле, онытылыр...— диде дә, елмаеп та куйгач, берни булмагандай үз юлы белән китеп тә барды...

**Редакциядән.**

*Кадерле авторларыбыз һәм укучыларыбыз. Яңа сәхифәне дәвам итеп үз язмаларыгызны да җибәрегез әле. Мондый очраклыклар һич тә кызык-мызык, «шаккатризм»нар гына түгел, ә бәлки күп-күп адәм затларының һәм тулаем кешелекнең дә киләчәгенә тәэсир итә ала торган серле төеннәр булса кирәк...*

# КАРУРМАН ҖАНЛЫ КЕШЕ

Казан мәчетләре турындагы тапшыруларны телевидениедән кабатлап күрсәткән саен Хәйдәр Гайнетдин искә төшә. Ул әзерләгән тапшырулар... Аның дулкынландыргыч тавышы... Сүзнең тәмен белеп ашыкмыйча гына иске мәчетләр турында сөйли. Үзе дә шушында янәшәдә генә кебек. Менә-менә ишек кыңгыравы чылтырар да, кабарынкы күзләрен каплаган калын пыялалы күзлеген рәтләп, ул килеп керер төсле. Гадәттәгечә коридорда тәмәке кабызырбыз һәм ул телевидениегә кагылышлы яңа идеяләре белән уртаклашыр, мине берәр тапшыруга чакырыр. Кичләрен аның башына әллә нинди идеяләр килә торган иде...



Вакытның күз ачып йомган арада узуына хәйран калырлык. Аның дөньядан китүенә дә шактый вакыт үткән. Тапталган сүз булса да әйтим инде — үлеменә әле дә һич ышанасы килми. Бигрәк фаҗигале китте шул... Һәлак булды.

Мин Казанга килгәндә ул «Ялкын» журналында эшли иде. Гел аралашып торсак та, без аның белән алай тиз якынаеп китә алмадык. Ул чакта Хәйдәр Рөстәм Мингалим, Марсель Галиләр белән бик якын дус иде.

Кайчагында алар Кутуй урамындагы студентлар тулай торагына килеп керәләр, мин, тагын бер-ике шәкерт Казан урамнарына чыгып китәбез. Иске аэропортка кадәр барып җитәбез... Андагы ресторан тәүлек дәвамында эшли иде... Янәшәдән кечкенә очкычлар һавага күтәрелә. Аларның җиле безнең чәчләргә орынгандай була. Кайтканда исә без инде урамны тутырып кайтабыз. Хәйдәр мәһабәт тавыш белән «Карурман»ны сузып җибәрә. Автономиянең тар кысаларында да, урыс Казанында да үзебезне азат, хөр итеп хис иткән мизгелләр булгалап тора иде.

Шәп җырлый иде ул. Җырлау сәләте дә нәселдән килә шул. Әнисе — Илһам Шакирның бертуган апасы бит. Кайчагында Марсель Гали Илһам агайга юри бәйләнеп тә маташа иде: «Нигә син, янәсе, Хәйдәрчә җырлыйсың? Подражаешь...»

Ләкин ничаклы аралашып йөрсәк тә, мин аның «Карурман»нан бүтән җыр башкарганын ишетмәдем. Дөрес, ул аны да бик нык кәефләнгәндә генә җырлый иде. Кайчагында шулай төн уртасында өйгә килеп керә, бераз утыргач, коридорда аның тавышы стеналарга бәрелеп тышка ыргыла. «Кара да гынай урман, караңгы төн...» Диварлардан акшар коела, түбә бераз күтәрелеп ыңгыраша да кире үз урынына утыра. Икенче көнне йорттан чыккан кешеләр аңгыраебрак атлый башлый.

Кайчагында ул Аккош күлендәге язучылар дачасына килеп тә җырлап китә. Концертларга йөрми торган әһле каләмгә бу чыгыш берничә елга җитә иде. Хәер, хәзерге концертларда андый тавышны ишетеп буламыни?.. Шул Илһам агай үзе чыгып җырласа гына инде...

*Килмәс идем Аккош күлләренә,*
*Йөрмәс идем җырлап «Карурман»ны, —*
*Түгеләсе килә бушанганчы,*
*Тыеп буламыни моңлы җанны?!*

*Мөлдерәмә моңдыр күңелемдә,*
*гомер буе җырлап йөрү язган.*
*Кая барыйм инде түгелергә, —*
*Бердәнбер бит җирдә — шәһре Казан.*

Аралашыр өчен җайлы кеше түгел иде ул. Берәр ялгышыңны күрсә, каһкаһәләп көләргә дә күп сорамый. Минем үземә дә аның белән берничә тапкыр чәкәләшеп алырга туры килде. Хәер, гаеп күбрәк үземдә иде, ахрысы... Артыграк кызу идем яшьлегемдә. Һәрхәлдә, тыштан төртмәле, чәнечкеле булып күренсә дә, аның бик нечкә күнелле, тиз рәнҗүчән кеше икәнен мин беләидем. Ләкин күпләргә аның җаны нигә? Шуңа күрә аны өнәмәүчеләр, хәтта дошман күрүчеләр җитәрлек булды.

Студент чакта «Ялкын»га китергән шигырьләрне аның кулына тапшыра идек. Бераз чатаклык күрсә, ул алагаем авызын җәеп көлә, пөхтә хәрефләр белән төзәтеп куйгандай итә. Йә, ничек яратасың, якын күрәсең бу кешене? Әмма тулай торакка кайтып аугач, уйлана-уйлана, аның хаклы булуына төшенәсең... Төрле кеше төрлечә мөдәррислек итә шул...

Ул гаҗәеп бер стилист иде. Шигырьләренә генә күз салыгыз — анда һәр сүз үз урынында, һәр юл чарланган. Әмма моның кире яклары да бар — аның шактый гына шигыренә ниндидер тилелек, очыш җитми, шигырь «ат уйнагандай уйнамый...» Хәер, мондый кимчелек атказанган байтак шагыйрьләргә хас. Уйласаң, ул кимчелек тумыштан килә бит. Тумыштан кешегә шигырь очкыны күчмәгән. Ә ул көн саен утырып, гадәт буенча, шигырь язып азаплана. Хәйдәрнең шигырьләре аз. Ул аларның күбесен студент чакларында язган, мөгаен. Соңгы ун-унбиш елда ул инде шигърияттән бөтенләйгә киткән иде. Тик алардан, бер килгәч, бөтенләйгә китеп буламыни?! Бөтенләйгә — аннары...

Никадәр генә яшерергә тырышса да, иҗатчының асылы әсәрләренә күчә... Ул тормышта да пөхтәлекне, ыспайлыкны ярата иде. Көзге пычрак көннәрдә караңгы Казан урамнарын гизгәннән соң безнең киемнәрне юмыйча икенче көнне рәешкә чыга алмыйсың, ә аның чалбарында ник бер тап булсын...

Рухының да пакь калуын теләде ул. Әлбәттә, монысы авыррак иде. Хәтта Тукаебыз да гомеренең ахырында көрсенеп куйган бит: «Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым...»

Менә минем алдымда Хәйдәрнең «Ут теле» дигән бердәнбер шигырь китабы ята. 1982 елда нәшер ителгән... Кайберәүләр хәтерлидер әле, совет елларында күпләрнең китабы берничә «кызыл» шигырь белән башланып китә иде. Аларны шагыйрьләр «паровоз» дип атый. Янәсе, шуның белән үяу цензураны алдыйлар да, берниндиидеологиясез лирика яисә мәгънәсен беркем дә аңламаслык «крамола» шул «паровозга» тагылып укучыларга барып ирешә. Һи, гүзәл наивлык... Бу инде бер үзгәрмәс гадәт-йолага әверелгән. Шуңа да шигърияткә әлеге нәни генә хыянәт табигый да тоела иде. Әйтерсең, хыянәтнең нәние була... Ә Хәйдәрнең шигырь китабы чәчмә эпиграф белән башланып китә: «Безнең халыкта шундый ырым бар: имеш, болында сары чәчәк җыйсаң, йортында янгын чыга. Аннары тагын шундый ышану да яши: имеш, янгынны сүндерү өчен һәм утка пешкән урынны дәвалау өчен ут телен белергә кирәк».

*Ут төрттем мин төнгә!*
*Тау башына*
*яктым учак,*
*ялкын дөрләде.*
*Үрләде ул караңгылык буйлап,*
*Кабатларга теләп көннәрне.*

Һәр шагыйрь шулай бер тапкыр гына булса да караңгылыкка ут төртеп карарга тиештер.

Үз иманына каршы бармау өчен эчке җегәр, рухи көч кирәк. Совет матбугатында

эшләп тә, шул идеологиягә хезмәт итмәскә тырышучылар күп түгел иде. Хәйдәр сөйләгән бер вакыйгага искә төшә. Пионер гәҗитендә эшләгәндә бугай, аны редактор үз бүлмәсенә чакыра. Кайсыдыр бер авылда янгын чыккан да, мәктәптә укучы бер кыз шунда янып үлгән икән. Ул, пионер галстугының янган өйдә онытылып калганын искә төшереп, кире кереп киткән... Галстукны озаграк эзләгәнме, чыгарга өлгермәгән. Редактор ханым, әлбәттә, бу кызны «каһарман пионер» ясап мәкалә яздырыр өчен Хәйдәрне шул авылга юлламакчы икән. Ул анда бардымы, хәтерләмим, тик каһарман кыз турында мәкалә язылмады, билгеле. Хәйдәр бу турыда бик тетрәнеп сөйләгән иде. Бу бичара кыз коточкыч мәрхәмәтсез идеологиянең корбаны ләбаса! Мескен баланы бер гади чүпрәк хакына утка ташланырлык кимәлгә җиткерер өчен кемнәр шулкадәрле тырышты икән... Ут телен, ут телен өйрәтергә иде аңа! Әлеге вакыйганы ул үзенең бер чәчмә әсәренә дә кертте бугай.

Соңгы елларында Хәйдәр проза әсәрләре язды. Алары да аның шагыйранә иде. Бер-бер артлы «Су кызы», «Яшел алма» кебек бәян-хикәяләр тупланган китаплары чыкты. Дөрес, аның иҗаты күләм ягыннан әлләни мактанырлык түгел. Матбугатта, телевидениедә эшләгән кеше бик җәелеп тә китә алмый. Хәер, сәбәп монда гына да түгелдер...

Иң мөһиме, ул безгә тыгыз җәсәдле, нәфис тел белән язылган әсәрләр калдырды.

Ә күпме язган булыр иде. Яза алган булыр иде. Әдәбиятның бөтен нечкәлекләрен тойган, телнең бөтен хасиятен үзләштергән кешеләр бездә күп түгел бит...

Әдәбиятта нидер казаныр өчен талант кына җитми. Мәгълүм булганча, талантсыз килеш тә анда зур уңышка ирешкәннәр бар. Мөгаен, күпмедер кимәлдә иҗатны спорт белән чагыштырырга мөмкин. Озак вакытлар язмый торсаң — ягъни кул китсә! — үзенне формада тотмасаң, иртәме-соңмы арадан төшеп каласың. Әллә нинди саллы сәбәпләрең булсын, төрле сылтаулар тап — әдәбият берсен дә кабул итми. Әдәбият даими көрәш ул. Иң беренче нәүбәттә — үз-үзең белән көрәшү.

Һай-һулап өндәп торучы, кирәксә, камчылап алучы җайдак иярләргә тиеш йөрәгенне. Бәлки, нәкъ менә шул җайдак талант дип аталадыр? Алайса, талантсызларны нинди җен куалый?

Милләтенең демографик һәлакәтен жаның белән тойган килеш, яңа буынның үз телебездән бизә баруын күрә торып, бер-бер артлы әдәби әсәрләр тәгәрәтеп тору өчен яхшы мәгънәдә графоман булу кирәк. Хәйдәр графоман түгел иде. Һәртөрле мәгънәдә...

Аның йөрәге, җайдагын чөеп, мәңгелеккә томырылды.

Кул сузымы арада гына дөньядан фаҗигале киткән каләмдәшләр күз алдыннан үтә. Фәннур Сафин, Эдуард Мостафин, Мөхәммәт Шәйхи, Илгизәр Солтан... Бу әле кинәт телгә килгәннәре генә. Саный китсәң, бик күп икән алар... Бу хәлгә инде күнегеп тә киләбез, ахрысы. Без үз талантларыбызны саклый белмибез, үз-үзебезне саклый белмибез... Нигә ул мәгълүм упкын һәмишә тарта безне жан сорап?.. Татар киләчәгенә карата өметсезлекме, чарасызлыкмы?

Югыйсә, авыру бит күптәннән, күптәннән килә. Татар нәфис прозасының атасы Заһир Биги язмышын ирексездән хәтерләрсең. Хәйдәрнеке белән аның тәкъдире арасында охшашлык бар... Кайбер истәлекләргә караганда, Заһир Бигинең үлеменә дә хатыны сәбәпче булган. Ләкин әлеге фаҗигага ун ел элгәре үк ул болай дип язып куйган: «Гаять көчле авырулы бер хәлгә төштем. Башлануы кайгыдан юану өчен бер кәеф-сафа кору сымаграк булып күренсә дә, ахыры соң дәрәҗәдә һәлакәтле булды. Кулыма каләм тотмас бер хәлгә килдем. Тормыш ләззәтләреннән өмид өздем. Моннан соң яшәвемдә файда булмас дидем дә, әҗәл сәгатен... көтә башладым...»

Хәер, Биги заманыннан бирле нәрсә үзгәргән соң? Милләтнең кыяфәте дә шул ук, кайгы да шул, татар әдәбиятында да һәммә нәрсә кабатлана...

**Ркаил ЗӘЙДУЛЛА**

# СӘЙДӘШ, ЕНИКИ ҺӘМ... ЗӘҢГӘР КОСТЮМ КЫЙССАСЫ

...Ул көнне мин соңгарак калдым. Асия апаның йөзендәге канәгатьсезлеге ишекне ачкан мәлендә үк сүзләренә күчте:

— Баланны, дөньяңны онытып йөрерсең икән!.. Әйттем бит мин сезнең икегезгә дә: «Вакытында алырлык булсагыз гына балагызны карыймын», — дидем. Ирең командировкага киткәч, бөтенләй азындың. Әнә, сәгатьне күр!..

Хуҗа ханымның «әмере»нә буйсынгандай, стена сәгатенең оясыннан сикереп чыккан күккүк тә «күк-кү, күк-кү» диеп сигез тапкыр кычкырды.

Аягымны кочаклаган улымны кулыма күтәреп, мин һаман ишек төбендә таптанам, ашыга-ашыга акланырга тырышам.

— Ачуланмагыз инде, Асия апа! Алты җиткәнен сизмәгәнмен бит...

Телевидениенең музыкаль тапшыруына Заһид абый Хәбибуллин килгән ие. Тапшыру тәмамлану белән без аны эш бүлмәбезгә чакырдык.

Скрипкасында «Тәфтиләү», «Гөлҗамал», «Әллүки»ләрне уйнап, ул безне тәмам әсир итте. Дөньямны бөтенләй онытканмын шул...

— И-и, Заһидның скрипкасына шулай һушың киткән, ә Салих Сәйдәшне тыңласаң нишләр идең микән син?!

Ошбу мәшһүр ике исемме, Асия апаның катырак сөйләшүеме — эштән кайтып ял итәргә яткан Исмәгыйль абыйны да йокы бүлмәсеннән чыгарды. Җан тартмаса кан тарта дигәндәй (Исмәгыйль абыйның һәм каенанамның бабалары бертуган), ул хатынына коры гына:

— Нишләп кешене ишек төбендә тотасың?! Бар, чәенне куй! Алай бик мактанасың килсә, Сәйдәш белән танышлыгыңны да табын янында сөйләрсең, — диде. Ә үзе, гаепкә алма инде дигәндәй кыенсынып, мине чишендерә башлады.

...Алдымдагы чәемнең суынуына да игътибар итмичә, каршымдагы ханымны тыңлый-тыңлый, мин янә дөньямны онытам.

— Гомерем буена мин бер генә урында — Бауман урамындагы кием кибетендә генә эшләдем. Ирләр киеме бүлегенең мөдире идем. Мөдир дигәч тә, үзем үк товар кабул итәм, үзем үк сатам да инде.

«Сез мине бала караучы гына итеп күргәч тә» дигәндәй, сөйләвеннән туктап-туктап, Асия апа кинаяле карашын бер Исмәгыйль абыйга, бер минем тарафка ыргыткалап ала.

— Мин эшләгән елларда кибетне әле «Универмаг» дип, әле «Кием магазины» дип атап йөрттеләр. Хәер, исемдәмени хикмәт. Хикмәт аның Казаныбызның нәкъ йөрәгенә урнашкан булуында. Каршыбызда гына маңгай-түбәсенә «Дом печати» диеп язылган мәһабәт Матбугат

йорты. Аның аскы катында китап кибете, ә өске катларында гәзит-журналлар, китап нәшрияты редакцияләре, Язучылар союзы, Язучылар клубы. Менә шушы илаһи йортка йөрүче шәһәребез интеллигенциясе безнең кибетебезне дә бик тә-бик тә үз итә иде шул. Гәзит-журнал редакцияләренә килүчеләр дә безгә кагыла, Союзга, Язучылар янына йөрүчеләр дә сугылып чыга. Кыскасы, кибетебездән бер дә кеше өзелеп тормый. Үзенә кирәк товарны да шәһәрнең бөтен «каймагы» бездән генә ала. «Фирма магазины»на инде, хәзергечә әйтсәк. Сугыштан соңгы ул илленче еллар — кибетләрнең ярлы чагы, кибетләрнең генәме соң, ил үзе дә яна тернәкләнеп аякланып килә бит. Аның каравы, кешеләрнең рухы бай, өметләре якты, күнелләре дә киләчәккә ышаныч белән мөлдерәмә. И-и, ул елларда кемнәр генә килми иде безнең кибетебезгә!.. Нидер алу өчен түгел, болай гына, карау, күрү, берочтан хәлебезне дә белү өчен генә керүчеләр дә бар иде. Әйе, әйе, андыйлар да байтак иде. Мирсәй Әмир, Нәкый Исәнбәт, Габдрахман Әпсәләмов, Фатих Хөсни, Салих Сәйдәшләр белән мин якыннан әнә шул кибеттә эшләгән елларымда таныштым.

Бермәлне шулай, язга табарак инде бу, зур гына партия яңа товар алдык. Ирләр костюмы гына да дүрт-бишләп булгандыр, мөгаен. Аларны элеп-урнаштырып кына бетерүебез булды, гадәттәгечә, көләч йөзе белән ихлас сәламнәрен өләшә-өләшә, Салих абый килеп керде. Керү белән күзе әлеге костюмнарга төште. Костюмнарга диюем дөрес үк булмас, күзенең җылысы шундук аларның берсендә — зәңгәр төслесендә тукталды.

— Әллә ошаттыгыз инде, Салих абый, — дидем дә, әлеге костюмны элгече-ние белән кулыма алып, әйләндерә-әйләндерә күрсәттем. Һәм шундук: «Күзегез-йөзегезгә дә килешеп тора, киеп тә карамыйсызмы соң?» — дип өстәдем.

— Карыйк әле, бәгырь, таман да булса... Күз күрер аннары.

Шулай сөйләнә-сөйләнә пальтосын салып, костюмның пиджагын гына киде дә, көзге каршына килде Салих абый. Мин дә көзгегә карадым һәм хәйраннар калдым. И ул көзгедәге йөз!.. Мин күреп күнеккән, иллесен узган йөз-кыяфәтнең эзе дә юк. Көзгедән шундый да бәхетле егерме биш яшьләрдәге егет томырылып карап тора инде менә — соклануымнан «һай!» дип әйтүемне сизми дә калдым.

— Минем костюм бит бу. Тәгаен — минеке! Син ничек уйлыйсың, бәгырь?

Мин исә:

— Тач сезнеке инде, Салих абый, тач сезнеке! Бу кадәр дә килешер икән үзегезгә: йөзегезгә дә, гәүдәгезгә дә!.. Салып та тормагыз сез аны, кигән килеш кенә кайтыгыз — өегездәгеләр дә шаккатсыннар, — дип такылдадым.

Әле генә бәхеттән балкыган йөзгә күләгә ятуын күреп, аптыраплар калдым.

— Без, булмаса, Асия бәгырь, болай килешик: син минем костюмны бер өч-дүрт көн генә сатмыйчарак тот инде. Бер урында миңа гонорар акчасы тиешле. Аны бирүләре белән килеп алырмын.

Мин шундук аны тынычландырырга ашыктым.

— Бер дә борчылмагыз, Салих абый, беркемгә дә сатмыйбыз. Сезнеке инде бу костюм, сезнеке!

— Вәгъдәме, бәгырь? — диде ул монсу гына елмаеп, һәм миңа кулын сузды.

...Куллар кысышып, ансат кына вәгъдә бирсәм дә, костюмны саклау бер дә җиңел булмады. Ул замандагы сәүдә законы буенча саклау хокукыбыз — ике сәгать кенә. Складта гына тотар идең, ревизия килсә, башыңны бетерәчәк. Һәм мин, Салих абый китү белән, костюм кесәсенә 10-12 сәгатькә хәтле сатылмый дигән «законлы» язу кададым.

Төш җиткәнче үк башка костюмнарыбыз сатылып та бетте. Инде кергәне берсе зәңгәр костюм тирәсендә бөтерелә башлады. Мин исә ике сәгатьтән ике сәгатькә теге язуны яңасына алыштыра торам.

...Һәр көнне, гадәттәгечә, нәкъ сәгать 10да Салих абый килеп керә дә:

— Йә, бәгырь, ничек, көтәме мине костюмым, — диеп, көзге каршына юнәлә.

Киеп караган минутларында илаһи бер бәхеттә коенып, кибетебезне ак шатлык белән тутырып, чыгып та китә — каршыдагы китаплы йортка, язучылар янына ашыга.

Әмма җәйгә таба Салих абыйның килүләре сирәкләнде — атнасына йә ун көнгә бер күренү белән чикләнә башлады.

Җәй айларында бездә практика үтү өчен сәүдә техникумыннан бер кыз җибәрделәр. Бер иртәдә директорыбыз шул кыз белән яныма килде дә, син кайтканчы бу бүлектә эшли торыр диеп, үзе белән мине дә базага, товар сайлап алырга чакырды. Ә кайтуыбызга ... Кайтуыбызга практикант кызыбыз, кояштай балкып, шатлыгын уртаклашты:

— Биш ай буе алучысыз яткан зәңгәр костюмны сатып җибәрдем. «Яңа товар кайткан саен хәбәр итсәгез, даими покупателегез булырмын» диеп, ул абый әле миңа телефон номерын да бирде!..

Кызыбызның бу хәбәре мине өнсез калдырды. Хәер, ул чактагы хәл-халәтемне сөйләп тормасам да була. Үзем гаепле бит, үзем юньсез: «Ике сәгать дәвамында сатылмый» дигән теге кәгазьне костюм кесәсенә кадап китәргә онытканмын, хәерсез...

Ходаның рәхмәте, ярый әле сатып алучы телефонын калдырган. Һәм мин аны әлеге телефон буенча бик ансат эзләп таптым. Ә инде: «Салих абый Сәйдәшевкә вәгъдә ителгән иде ул!» — дигәнем булды, костюм шундук минем кочагыма күчте. Алай гына да түгел, мехкомбинатта эшләүче, Шамил исемле япь-яшь кенә бу инженер егет: «Миннән Салих абыйга бүләк булсын, ә?» дия-дия, костюм өчен түләгән акчасын да алмый маташты. «Рәхмәт изге ниятеңә! Тик... Салих абый мондый бүләкне кабул итмәячәк. Мондый бүләк бүләк булмаячак, аны кимсетәчәк, рәнҗетәчәк кенә. Ә инде чыннан да аңа ярдәм итәсең, йә бүләк бирәсең килә икән, тап чарасын: коллективыгызның берәр мероприятиесенә, йә берәр кичәгә чакырыгыз үзен...» диеп, бәйнә-бәйнә аңлатуым исә күңеленә хуш килде булса кирәк, ул миңа рәхмәтләр әйтеп озатып калды.

Бу вакыйгадан соң тынычланырга да өлгермәдем, кибетнең ярты еллык эшен тикшерергә өч кешедән торган ревизия килеп төште. Бер дүрт көн тикшергәннән соң, мине ревизиянең җитәкчесе янына, директорыбыз бүлмәсенә чакырдылар.

— Виктор Иванович булам мин, ә син — Асия Абдулловна Усманова икәнсең, дөресме? — дип каршылады ревизор агай үземне, һәм алдында яткан бер катыргы папкага ымлады: — «Дело»ның карап утыра идем әле.

Миңа монда югары профессионал белемле һәм дә мактаулы сатучы булуың турында белешмәләр бар. Сәүдә кагыйдәләре белән нык таныш икәнсең. Димәк, син саботажлык юлына да аңлы рәвештә баскансың. Кем өчен яшереп яткыздың ул киемне? — диде дә, кинәт кенә урыныннан кубып, шифоньерда эленеп торган зәңгәр костюмның түш кесәсенә бармакларын

батырды. Һәм бармаклары арасына кысылган кәгазь кисәген — теге, «ике сәгать дәвамында сатылмый» дигән «законлы» язуны — минем тарафка очырды.

«Корткычлык», «саботажлык» кебек сүзләр белән газета битләре чуарланудан туктамаган еллар бит әле бу; минем чын-чынлап котым алынды, тез буыннарым йомшарды. Егылып китүдән куркып, мин тизрәк урындыкка утырдым.

— Яшермәдем. Менә ич, язуы да бар. Ике сәгатькә калдыруны сораганнар иде, килеп алмадылар бит. Бүтән кызыксынучы булмады, — дия алдым, ниһаять, мине үтәдән-үтә күрүче күзләренә карамаска тырышып.

— Алдашма! Мондый сыйфатлы костюм биш ай дәвамында сатылмыймы?! Сатылмаган очракта, квартал тәмамлангач, ник бәясен төшермәдегез? Башка товарларның хакы киметелгән ләбаса. Дөресен сөйләсәң генә мин актта саботажлык кылуыңны «үз вазифасына салкын карау» кебегрәк төшенчәгә алыштырып, штраф түләү белән генә дә чикләнү мөмкинлеген тудыра алам. Төшенденме: дөресен сөйләгән очракта гына! Юкса...

Шушы мәлдә миңа әллә ни булды. Сикереп тордым да, күз яшьләремә буыла-буыла:

— Сезнең Петр Чайковскиегыз булган кебек, безнең дә Салих Сәйдәшевебез бар! — дип кычкырдым.

— О-о, Салих Сәйдәшнекемени бу костюм?!

Ревизор агайдан бу сүзләрне ишетү мине айнытып җибәрде. Айнытып кынамы сон?! Миңа җан керде. Мин тормышка янәдән кайттым. Ниндәен җылы итеп әйтте бит ошбу урыс агае безнең Сәйдәшебез турында. Ниндәен җылы итеп, ярабби!..

Үкси башлавымны тыярга маташкан арада, «тынычлан» дигәндәй, беләгемә йомшак кына кагылып, Виктор Иванович үз урынына үтте. Мин ишеккә юнәлдем.

...Ревизиянең киткәненә ярты айлап үткәч, без дә тынычланып эшли башлагач кына Салих абыебыз пәйда булды. Гаҗизанә хәлдә бер миңа, бер зәңгәр костюмга караган килеш кибет бусагасында ук тукталып калуына пошынып, мин аңа каршы атладым.

— Беләсеңме, бәгырь, бу юлы инде мин костюмымны күрергә өметләнмәгән дә идем. Күрче, көткән бит, бахыр. Табибымны тыңлап, калага бераз вакыт кайтмыйчарак тордым. Менә бит: гонорарым да, костюмым да көтә икән бит...

Без киемнәр янына үттек.

Костюмын киеп көзгедәге сурәтенә бер елмаеп алгач та Салих абый миңа борылды:

— Һай, Асия бәгырь, мине бәхетле иттең бит, җаный! Ә хәзер... төрик инде без аны.

Мин костюмны төреп үзенә тоттырдым. Салих абыйның саубуллашырга сузылган кулы кинәт кенә өскә күтәрелде:

— Нинди кайтаваз бу?

— Түрдән ишетелгән тавышны әйтәсезме? Кибеткә рояль кайтканые. Шуны урнаштырып маташалар бугай. Кыллары чыңлап киткәндер.

Төргәкне шундук кочагыма төртеп, Салих абый түргә узды. Ә бераздан мин анын директорыбыз белән бергә бик тә ашыгып чыгып баруын шәйләдем. Артымда кемдер: «Рояльләр көйләүчене апкилергә киттеләр», дип куйды.

Таныш булмаган агайны да ияртеп, алар төш авышкач кына кайтып керделәр. Һәм шундук рояль янында мәш килә башладылар.

Кибетебезнен түре әйтерсен лә тылсым көченә ия урынга әйләнде — юк сәбәпне бар итеп мин һаман-һаман шул турыдан урап килергә җай эзлим. Салих абый бит анда, Салих абый!..

Инде менә эш көнебез тәмамланыр вакыт якынлашты: сәгать теле җидене күрсәтә. Ачкычлар бәйләме божрасын бармагымда әйләндерә-әйләндерә, мин янә түргә узып, директорыбызга кибетне бикләргә кирәклеген искәрттем. Кульяулыгына кулын сөртеп торучы Салих абый безгә таба борылды һәм:

— Өйләрегезгә ашыкмыйсызмы? Сезнең игелегегез әҗерен кайтару мөмкинлеге туып тора бит әле менә, — дип, рояльгә ымлады.

Мөмкин хәлме бу?! Ышанырга да, ышанмаска да белми без сүзсез калдык.

...И ул Салих абыйның уйнаулары! «Ай, былбылым», «Җаным җәл түгел сиңа» кебек көнелләрне җилкендереп алучы җинелрәкләреннән башлап, «Һаваларда йолдыз», «Сәгать чылбыры», «Кызыл төлке», «Ишкәкче карт» кебек халкыбызның озын-озын көйләрен уйнады ул. Шуннан соң гына үзе язган, үзе тудырган музыкага күчте.

Ай ул рояльдән аккан җаннарны айкаучы музыка! Иделебез дулкыннары шавын да, урманнарыбыз аһәнен дә, чишмәләребез челтерәвен дә, ата-бабаларыбыз калдырган олы дөньяның ләззәтле газап-сагышын да сыйдырган моң!..

Талгын искән җилдәй назлап иркәләүче ул моңны сүз белән сөйләп буламы соң, йә Хода?!

...Без урамга чыкканда сәгать 9 тулып киткән, эңгер-меңгер ингән иде инде. Ә Бауман урамы кибетебез тирәли халык дингезенә күмелгән. Салих абыйны шундук алкышлый башладылар. «Рәхмәт, туган!», «Браво, Сәйдәш!», «Афәрин!» кебек сүзләр яңгырады.

Халык диңгезе эчендә ул кичне хезмәттәшләрем белән бергә Салих абыйны өенә хәтле озата бардык. Саубуллашканда гына зәңгәр костюмлы төргәкне мин аның үз кулына тоттырдым.

...Көннәр үтә торды. Көннәр генә түгел, атналар, айлар да үтеп китте. Ни кызганыч, Салих абый белән хушлашырга бара алмадым. Ул көнне кибет өчен мин җаваплы идем. Аны соңгы юлга озатып кайткан директорыбыз исә, күз яшьләрен тыярга тырышып, әледән-әле: «Сәйдәш зәңгәр костюмнан иде», — дип кабатлады.

...1969 елның җепшек җилле көзенең бу кичендә Асия апалардан ничек чыгып китүемне, коммунал фатирыбызга кайчан кайтып керүемне хәтерләмим. Бөек Сәйдәшнең костюм алырлык та акчасы булмауны аңлап, аклап буламыни, ярабби. Үкси-үкси елаудан да күкрәгемә кысқан өч яшьлек улым булу гына тыйгандыр, мөгаен.

Ә икенче көнне Әмирхан Еники хозурында идем инде мин.

— Әмирхан ага, сез ничек уйлыйсыз: Салих Сәйдәш бәхетле идеме? — дидем мин аңа, Асия ападан ишеткәннәремне бәйнә-бәйнә сөйләгәч тә. Һәм мәшһүр композитор турында телевидение аша чыгыш ясавын үтендем.

Ул гадәтенчә ашыкмый гына:

— Хәтәр йөк белән килгәнсез икән, — дип куйды. Ә бераздан: — Мин каләм белән генә эш итәм, ораторлык сәләтем юк шул алай, — дип өстәде.

— Моны сез, фәкать сез генә булдыра аласыз, Әмирхан ага. Сез бит «Әйтелмәгән васыять»не язган кеше! Антон Чехов кебек үк нечкә хисле язучы!..

— Мин үземне кемгәдер тиңләүләрен, кем беләндер чагыштыруларын теләмәс идем, — диде ул, хәтере калгандай, читкәрәк карап. — Булдыру мәсьәләсендә дә сезнең белән килешмәс идем. Сәйдәш — тирәнтен өйрәнүне сорый торган шәхес. Кичерәсез, аның турында төпле фикер әйтергә мин әзер түгел.

— Сез хаклы, Әмирхан ага, чагыштыру кирәкми. Кая инде ул татар язучысына Чехов, Толстой, Достоевский, Шолоховлар дәрәҗәсенә күтәрелү! Куркак бит ул татар язучысы — куркак!.. Музыкабыз даһие Сәйдәш турында гадел сүз әйтергә сез дә курыктыгыз менә. Ә мин... Мин сезнең янга бик тә ышанып килгән идем, — дидем дә, моңарчы тыелып торган күз яшьләремә буылып, китәргә ашыктым.

...Дистә елдан (ягъни 1979 елның көзе инде бу), Салих Сәйдәшнең тууына 80 ел якынлашкан бер мәлдә, мин теге сөйләшүне Әмирхан аганың янә исенә төшердем. Һәм үзем сәнгать, мәдәният, әхлакый тәрбия, рухи мирас бүлекләре редакторы булган «Азат хатын» журналы өчен «Салих Сәйдәш бәхетле идеме?» дигән сорауга җавап язуын үтендем.

Бу юлы ул язарга ризалыгын белдерде. Алай гына да түгел, рәхмәт әйтә башлавымны да бүлдерде.

— Ул рәхмәтне мин әйтергә тиешмен. Әгәр теге чакта сез мине куркаклыкта гаепләмәсәгез, Сәйдәш турында сүз әйтүне мин белгечләр эше итебрәк караган булыр идем. Ә сез мине бу шәхес турында кат-кат уйланырга, ныклап эзләнергә мәҗбүр иттегез. Нәтиҗәдә 1975 елда «Гөләндәм туташ хатирәсе» дигән, күпмедер дәрәҗәдә Сәйдәшнең егет чорын чагылдырган әсәрем дә туды. Инде менә сезнең гозерне үтәрлек тәҗрибә дә тупланды шикелле... Илтифатыгызга рәхмәт, — диде ул, бик тә үз итеп, бик тә җылы итеп.

Ә 1980 елның август башларында исә язманы минем кулыма тапшырды.

— Бу әйберне мин төгәл ун ай яздым. Кайбер көннәрне кәгазьгә бер җөмлә төште. Ә кайсыбер җөмләләрне язу өчен атналар кирәк булды.

Җитәкчеләрегез кул тыкмас, шәт. Минем нокта-өтерләрем дә, мотлак, үйламыйча гына куелмый, — дип, ошбу язманың үзе өчен бик кадерле булуын да искәртте.

...Әмирхан Еникинең мине сөендергән «Бәхет мәсьәләсе» исемле ошбу очеркы «Азат хатын» журналында 1980 елның ноябрь санында басылды.

**Рәйсә ЮСУПОВА**



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнен сәхифә!

## Мин калам көзләрдә...

**Мең дә бер гөлләрнең**
**Кыюсыз ал чагы...**
**Күңелнең бәхеттән**
**Ал чагы,бал чагы.**
**Канатлар, әй, җиңел!..**
**Ә җаннар тагын да.**
**Хисләрем нечкәреп**
**Күкләргә кагына.**
**Сәвами моң белән**
**Уралган көннәрем.**
**Хәтерли һәр йолдыз**
**Төшләрем, өннәрем...**
**Бу күк—ашъяулыкта**
**Йолдызлар кабына.**
**Ә күңел талпына**
**Сак кына,тын гына...**

***

**Соры шәһәр**
**Инде күптән йоклый.**
**Төссез шәһәр...**
**Урамнары буйлап төн атлый.**
**Төне исә кара...**
**Тик син күккә кара:**
**Анда**
**мең дә ике йолдыз балкый.**
**Бу шәһәрдән бәхет эзләмиләр.**
**Җансыз шәһәр...**
**Күңел яралы.**
**Шәһәр күгендәге йолдызлардай**
**Җанны җылытып бер ян әле!**

## Теләк

**Икәүләшеп йөрдек бүген**
**бер төн буе.**
**Куллар — кулда,**
**синең уйлар — минем уем.**
**Йолдызларга орынырга**
**буй җитмәде.**

Йолдыз булып янды ал таң –
үз итмәдең.
Теләгеңә ирешмәгәч,
моңсуландың,
Яндың, талдың...
Бу мизгелдә
Мин янымда булуыңнан
Ләззәт алдым.
Киләсе төн алып бирәм
йолдыз диеп.
Бүген тагын янда калдың.
...Түбәнәя күрмәсен
Йолдызлы күк кенә...

***

Чык булып гөлләргә тамам да,
Йолдызлы тынлыкта эримен.
Кулларым кояшка сузылды —
Җирне күк итәргә телимен.
Кысалар ят минем күңелгә,
Ашкынам хыялга җитәргә.
Офыкка кулымны сузам да,
Телимен күкне җир итәргә.
Сагышлар болытка сарылды...
Белделәр,ахрысы, теләгем.
Сагышлар аңлады, ахрысы –
Көзне яз итәргә теләдем.

## Язга дәшү

Күзләреңдә — зәңгәр чәчәк җыры,
Күзләреңдә — өзелгән моң эзе.
Сагышка табынган күңлеңдә
Эрегән, ахрысы, көз үзе.
Яфрак–яфрак көннәр коелганда
Өер булып очты галәм көле.
Көзләреңә ияргән болытлар да,
Бүген яңгыр көне — синең көнең.
Ә мин менә язга гашыйк булдым,
Һәм җанымда никтер гел яз мае.
Бу көзләрдән урлармын да сине,
Дәшәрмен мин язга елмаеп.

***

Сөю җырлары — күбәләк,
Алып менә күкләргә.
Дәшә гел бәхет мәленә,
Йолдыз–сәйлән чүпләргә.
Йолдызларга дәшкән саен
Сиңа дәшкәндәй булам.
Җавабыңны ишетмәгәч,
Җиргә төшкәндәй булам.
Хәтердәге сөю җырын
Йөрәгем отты инде.
Тик язда калган хәтерне
Күкләр онытты инде...

## Күзләрдә калам

**Буш йөзләрдән торган рәсем ясыйм,**
**Буш сүзләрдән торган җыр язам.**
**Язларыма юллар ерак әле...**
**Мин күзләрдә калам, күздә калам.**
**Кыскартылган вакыт йомгакларым**
**Сүтәмен дә, кире җыямын.**
**Җәйләр үтте. Бары сурәт булып**
**Мин күзләрдә калам, каламын.**
**Кыш күңеле ак ди. Ак кар ятар**
**Безнең уртак сурәт-эзләргә.**
**Мизгелләр елларга әйләнде –**
**Мин калдым күзләрдә, күзләрдә.**

## Ә шулай да...

**Күктә йөзгән ай да һаман шул ук,**
**Йолдызлар да сәйлән сыманнар.**
**Ә шулай да вакыт үткән инде,**
**Далаларда йөгерә кылганнар...**
**Йөрәгенә галәм сыендырган**
**Төн ярасы сыкрый һаман да.**
**Ә шулай да вакыт үткән инде, –**
**Узган инде үткән заманнар...**
**Җылытырга иде күңелемне,**
**Хакыйкатькә атлап бер адым.**
**Вакыт чоңгылында җилләр исә,**
**Агып бара еллар тагын-тагын...**

Ләйсән ИСХАКОВА,
*КФУ студенты*

---

# САРЫ ЯУЛЫК

ХИКӘЯ

*Исеңдәме, яшьтәш, дисәләр,*
*Күзләр зәңгәрләнә төшәләр...*
И.Юзеев.

Ике зур сумка тотырып эштән кайтып килүче Наилә подъезд төбендәге утыргычта аңа карап елмаеп торган ир-атка игътибар итмәде. Үзенең олы юбилей кичәсенә әзерләнеп, мәшәкатьләнеп йөргән чагы. Илле бише тула. Күзенә ак-кара күренми. Кунаклар күп булачак, бергә эшләгән хезмәттәшләре, дуслары, туганнары җыела. Борчыла, болай зурдан кубып кунак төшергәне булмады шул. Туган көн бәйрәмен гомумән яратмый, төче сүзләр, чәчәкләр...

Туган көне дә кайсысы микән әле аның? Илле икенче елның җиденче апрелеме, әллә сиксәненче елның унынчы октябреме?... Әфганстанда узган биш ел, анда үткәргән көннәр... Ул көннәрдә, ул төннәрдәме? Наиләнең чем-кара чәче көмеш төсенә кереп кайтты, исәнлеге дә ташка үлчим генә. Яшь хирург кыз солдатларның

яраларын бәйләп кенә калмады, операциясен дә ясады, бик күпләрне үлемнән дә алып калды. 33нче частьтагы коточкыч хәлне искә төшергәндә әле дә чәче үрә тора, тәннәре чымырдап китә.

Бер кичне егерме жиде солдат китерделәр, ярым үле, ярым тере иде алар. Кычкырып кына түгел, улый-улый елады Наилә. Үзенең аларны үлем тырнагыннан йолып кала алмау көчсезлегеннән дә, сөлек кебек сылу ир-атның – кемнәрнендер газиз баласы, ире, якыны, сөйгәненең — яшәүгә өмете юклыгына кайгырып та елады... Ыңгырашып, саташып кычкыруларга ямьсез сүгенүләр кушылып, ярдәмгә ашыккан шәфкать туташларын аяктан екты. Иртәгә авыр яралыларны калага алып китәргә тиешләр. Ял итеп алырга дип башларын мендәргә тидергәндә таң яктырып килә иде инде.

...Подвалда ярдәм көтеп алты тәүлек ятты Наиләләр. Бәхеткә каршымы, исән калуларына бер сәбәп булдымы, медикаментлар саклана торган кечкенә бүлмәгә, идән астына бераз гына ял итәргә төшкән кызлар «үлем йокысы»на чумып, өстәге хәлләрне сизми калдылар.

Янгын күз ачып йомганчы лазаретны чолгап алган. Беркем белми калган, беркем ярдәм итә алмаган, яралылар ярдәм сорап акыра-кычкыра тереләй янганнар.

Наиләләр ябылып калган бүлмәнең чыгу люгын ачып булмаганлыктан, бөтен өметләре Бөек көчнең үз кодрәтендә иде. Аларның исән икәнлеген бишенче көнне, торба шакылдаткан тавыштан гына белгәннәр. Өчесен дә аңсыз килеш табып алганнар. Наиләнең чәче дә шунда агарды. Үлеп терелделәр бит!

...Подъезд ишегеннән кереп, икенче катка күтәрелгәч, кемдер жиңеннән тартты кебек, Наилә, үзе дә сизмәстән, почта әржәсе янында басып калды. Юкка гына тукталмаган икән, ниндидер  конверт бар! Почта ачкычы кайда соң? Ул ашыга-кабалана сумкасын капшарга кереште. Һаман-һаман югалып торганга гәжит-журналларны почтадан барып ала иде, ә бүген? Бүген аны ниндидер сәер бер көч туктатты!

Нинди хат бу?...

Кайчан килгән?...

Бер кулы белән азаплана торгач, Наилә сумка төбеннән ачкычын табып алды. Тимер капкачны ачып жибәрүе булды, хат, дулкын өстендә йөзгән йомычка кебек як-якка чайкалып, таш идәнгә килеп төште. Конверт тышына зур итеп «Наиләгә!» диеп язылган. Иелеп алмакчы иде дә, хатның мөһере дә, кире адресы да юк икәнен искәрде. Әфганда үткән еллар үзенекен итте. Һәр адымны, һәр хәрәкәтне сак кына кылырга күнегелгән. Шикләнде, конвертны алмады.

Нәрсә бу? Кемнән?

Наилә аптырады, нишләргә белмәде. Урлаганда тотылган кеше сыман, як-ягына каранды. Тугыз катлы йорт, лифты дөбер-шатыр эшләп тора, кем кермәс тә, кем чыкмас. Дустан дошман күп дигәндәй, конверт кына димә! Әнә, почта белән килмәдемени кеше үтерә торган порошоклар?

Хат, яшен вакытында аяк астына килеп төшкән утлы шар кебек, Наиләнең котын алып таш идәндә ята бирде.

Чү, лифт ачылды!

— И, Марат, син икәнсең, сумкаларымны подъезд идәненә куясым килмәгән иде, шушы конвертны гына алып бирче, зинһар?

— Шәһәргә киләләр дә кеше булалар, кем икәнлекләрен оныталар, — дип мыгырданды соңгы айларда бик сирәк айнык күренгән Марат, идәндә яткан хатны алып Наиләгә сузганда. Аннары ул, тагын нидер сөйләнә-сөйләнә, калтыраган куллары белән ачкыч тишеген көчкә табып, фатирына кереп китте.

— Рәхмәт, зур үс! — диде хатын, шаяру катыш, күршесенең тупаслыгына исе китмичә. Белә бит ул аның бар дөньяга нигә ачулы икәнен... Юк, усал да, явыз да түгел Марат. Беркөнне, һич уйламаганда, ике яшьлек малаен ияртеп хатыны ташлап китте аны. Монысы барып алмый, тегесе кайтмый хәзер. Яхшы ук салгалап йөри торгач, гел айнымаска әйләнде... Менә шулай бала ятим кала, ә ир-ат? Ир-ат... әрәм була. Кулындагы конвертны да онытып, әнә шулай әрнеп калды Наилә күршесе Марат артыннан.

Хат тышында кечкенә хәрефләр белән «Наилдән» дип тә язылган икән.

«Наил!? Ничек?.. Каян?..» Наилә сискәнеп китте! «Ни гомер бит!..»

Яшен тизлегедәй күз алдыннан мәктәп еллары, яшьлеге йөгереп узды. Бу шул чаклы тиз булды ки, аның кан тамырлары буйлап кайнар кан таралды да, аның яктыртып, Наиләнең уйларын балачакка алып китте.

...Әнә алсу күлмәк кигән Наилә ялантәпи яшел чирәмнән атлый. Янәшәдә сыйныфташы Наил аның туфлиләрен тоткан... Алар сөйләшә-сөйләшә, соңгы кыңгырау кичәсеннән кайталар...

Ачкыч тота алмаслык булып калтыранган куллары Наиләгә янә күршесе Маратны искә төшерде. «Мин... айнык бит! Ә нигә кулым калтырый? Нишлим мин? Наил? Кайда син? Үзең китерденме әллә хатынны? Нигә адрессыз ул?»

Ишеген ачып өй эченә узган Наилә сумкаларын урнаштырып та, өстен салып та тормады, хатны ачарга кереште. Ерак балачакка алып киткән ап-ак конверт, очкыннар чәчеп торган утлы күмер кебек, кулны өтә иде... Аның эчендә хат түгел, ә ниндидер кабарынкы әйбер икәне кулга сизелеп тора. Наилә, кипкән иреннәре белән: «Наил, Наил!?» ди-ди, аптырый-каушый конвертны ачып җибәрде. «Чү, җил дә исмәде ич!». Наиләнең күзләре тагын да зуррак булып ачылдылар, ул:

— Ә-ә!?, — дип кычкырып җибәрде.

Кояш төсле җете сарыга әфлисун төсендәге көзге яфраклар төшкән... капрон яулык! Ул конверт эченнән шуып кына төште дә, «Ниһаять, күрештек!» дип кочаклап алган сыман, Наиләнең аяк битенә сузылып ятты. Наилә иелеп ефәк яулыкны алды да, хәле китеп ишек катына чүкте.

...Җиденче март көне иде. Җиде чакрым араны күрше авылга йөреп укыйлар Наиләләр. Иртәнге автобус соңарып килгәнгә, дәресләр әллә кайчан башланган, мәктәптә тынлык хөкем сөрә. Йөгерүдән сулулары капкан кызлар-малайлар шыбыр-шыбыр килеп сыйныфларга таралыштылар. 10 «Б»да усаллыгы белән бөтен мәктәптә дан тоткан тарих укытучысы Мәрьям апалары икән.

— Керегез, әйдә, керегез әле! Шыбырдашмый гына утырышыгыз! — диде, «мыш-мыш» борын тарткан укучыларга сөзеп карап, Мәрьям Соруровна. — Сорап карыйм әле мин сездә-әә-ән! Вакыт бик бар, — дип тә өстәде. Өсләрендәге салкын да сүрелеп өлгермәгән укучыларның башлары парта астына ук сеңде.

— Фәхриева, әйдә, син сөйлә!

«Бетте баш!» — яшен тизлегендәге уй миен ярып узды Наиләнең. — «Нәрсә үттек соң әле без кичә, кичтән нәрсә укыдым соң мин?..»

Укымыйча дәрескә килгәне юк та үзе, ләкин фикерләре таралган чак бит! Ишектән килеп кергәч тә Наилнең матур карашын күреп югалып калды ул. Сыйныфка бер булган бу чибәр егеткә кызлар сыланырга гына тора, ә Наиләнең, аны әлегә кадәр ошатып йөрсә дә, керфек астындагы шомырт күзләрен тутырып Наилгә карарга батырчылык иткәне юк. Егетнең карашы кызның аякларын — халсез, үзен аңсыз итте ләса! Ул Наиләгә текәлеп карап елмайды да, нәрсәдер әйтергә теләгәндәй ниндидер ишарә дә ясаган булды бит әле.

Мәрьям апа Наиләнең фикерләрен җыеп сөйли башлаганны көтеп тә, сөйлә инде дип ялынып та тормады, кискен итеп:

— Ишектән кергәндә үк күзеңне тутырып Хәмәдъяровка карадың. Онытылырсың да шул! Кая, нәрсә ымлады ул, нәрсә качырасыз сез анда? — диде.

Укытучы ашыга-ашыга кыз янына килде дә, Наиләне этеп диярлек парта астына тыгылды. Һәм... Аннан дүрткә бөкләнгән «Социалистик Татарстан» гәҗитен тартып чыгарды.

— Ә-ә-ә, һм-м-м! — диде Мәрьям Соруровна сузып кына. — Молодец, Хәмәдъяров! Менә ничек икә-ән! Үзең бер авыз сүз сөйли алмадың, Наиләгә соңгы хәбәрләрне гәҗите белән үк алып килгәнсең. Гыйшык-мыйшык дисез инде, алайса?

Укучылар шым булдылар.

Әйе шул! Мәрьям апалары гәҗиттә басылган соңгы хәбәрләрне туплап, аларны укып килергә кушкан иде...

Укытучы, олы бер ачыш ясагандай, эре-эре атлап такта янына килде дә, кулындагы гәҗитен селки-селки:

— Аны укып килергә иде... — диде.

Шулчак озак көттергән кыңгырау шалтырады, ләкин берәү дә урыныннан торып китәргә базмады, барсының да күзе гәҗит эченнән җилфердәп төшеп идәндә яткан сары яулыкта иде... Сыйныф беравык тын торды да, кинәт шыбырдаша, чыш-пыш сөйләшә башлады.

— Тынычланыгыз! Утырыгыз барыгыз да, беркем беркая китми! Йә, Наилә, чыгып ал яулыгыңны! Ал, ал! Бүләк ич, әнә нинди матур, кояш үзе бүлмәгә төште диярсең!

Иренмәде укытучы апа, яулыкны бөгелеп идәннән алды да, бар зурлыгына туздырып, сыйныф алдына селкеде. Оятыннан помидор кебек кызарган Наилә ни дияргә дә белмәде. Нәрсә бу? Кемнеке? Бер сыйныфташларына, бер укытучыга карап аптырады. Укучыларның бу хәлгә бик исләре китмәде, чөнки Наилнең күрше партадагы кыздан дәресләр буе күзен алмавын күптән беләләр инде, ә менә «дәрес хуҗасы» бөтен сыйныфны «пленга» алды. Дәвамы ничек булыр иде, әмма Наил барысын да үз урынына утыртты.

— Мәрьям апа! Сез дөрес аңламадыгыз. Ул минем гәҗит, тик яулыкны мин... әнигә дип алган идем, бәйрәм бүләге ул.

Наилне бөтен сыйныф яклап чыкты.

— Мәрьям апа! Хәзер кызлар яулык бәйләми инде.

— Иртәгә 8 март бит, әнисенә алды ул аны...

«Социалистик Татарстан» гәҗитенә кыстырылган сары кояш-яулыкны ул көннән соң искә төшерүче булмады. Оялчан Наил күрше авылның зифа буйлы, озын керфекләре арасыннан серле төймәләр булып күренеп торган шомырт кара күзле, икегә бүлеп үргән озын толымлы чая кызы Наиләгә бер авыз сүз дәшә алмый мәктәпне тәмамлады.

...Наилә сары-кояш яулыкны алып битләренә, иреннәренә тидерде. Ерак балачакка, мәктәп елларына әйләнде дә кайтты, әйләнде дә кайтты. Күз алдына туткыллы йөзле, кара бөдрә чәчле, төз гәүдәле һәм һәрвакыт моңлы карашлы Наил килеп басты.

«И, Наил! Белмәдең, белми калдың шул син ул чакта ук инде чая кызның сине ничек яратканын! Гомер буе саф, бөредә килеш саклады бит ул сиңа булган тәүге мәхәббәтен. Һәрвакыт синең турында хәбәрдар булды. Армиядән өйләнеп кайтканыңны, аннан аерылышканыгызны ишеткәч тә өметен өзмәде. Менә, марҗа белән тора дип ишеткәч кенә, күңеленнән сызып ташлаган иде. Ни булды соң? Син кайда, Наил!? Ничә ел бит!

...Аз сүзле Наил, дәресләр буе Наиләне күзәтеп утыра, әмма тәнәфестә ләм-мим сүз дәшми. Кышкы буран, ачы суыкларда Наилә апаларында куна калса, сүзсез генә яныннан сумкасын тотып озата бара. Башка берәүдән дә озаттырмый. Менә шушы йомыкый «аю Наиле»н яратты Наилә. Биш ел институтта укыганда да сүз кушучыларга егетем бар дип кенә әйтте. Чибәр дә, тәкәббер дә син диючеләргә дә җавабы бер булды: тәкәббер түгелне эзләгез! Ә Әфганда, ут эчендә ир-ат затына булган мәхәббәте көчле дуслыкка әверелеп кенә калды... Искиткеч кырыс холыклы, каты куллы ир-атлар янәшәсендә үзе дә шул төркем кешесенә әйләнде бугай ул. «Якын дус»тан ары бара алмый үтте гомере.

Менә ичмаса Наил!? Наил дус кына түгел шул. Наилә аны гомере буе яратты, көтте. Ир-ат сыйфатларын үзенә сеңдерып, түзәргә, еламаска да өйрәнде, тормышның ачысы-төчесен дә байтак күргәнгә, сабыр була да белде. Бүген, менә әле хәзер ни булды соң аңа?

Кулына ак конверт кочкан Наилә кабат яшьлегенә, мәктәп елларына кайтты.

...Чыгарылыш кичәсенә дип әнисе аңа, бер казга алмаштырып, каладан алсу күлмәк алып кайтты. Сылу тәненә сыланып торган өрфия күлмәкне кигән Наилә бу кичәдә яңа сусылланып пешкән җиләкне хәтерләтте. Аның күлмәге башкаларның күз явын алса, үзен тагын да чибәрләтте. Әлегә кадәр бер сүз кушарга оялган Наилгә ни булгандыр, ул Наилә янынан бер адым да китмәде, күзеннән күзен алмады. Алар гел икәү биеделәр. Атлап түгел, очып йөрде Наилә. Таң каршыларга авыл башына чыккач, «сиңа суык бит», дип, Наил пинжәген кызның иннәренә салды. Шул минутта куллар кулга тиде, күзләр очрашты. Нинди суык булсын ди,

утлы учакта көйде Наилә, янды, пеште. Бу халәтне алар икесе генә белделәр. Тан кызыллыгында Наилнен каратутлы бите дә кызарып тулышты хәтта.

Биш ел саен шушы җирдә очрашып торырбыз дип сүз куешып таралыштылар. Җитәкләшеп өйгә кайтып җиткәч, «ин кайнары» капка төбендә булды. Наил саубуллашырга дип кулын сузган кызны эх дигәнче кочагына алды да... Үбү булдымы ул, гомерендә бер тапкыр да әнисенен пәп итүеннән кала башканы белмәгән кыз анлый алмый калды. Наилдән җилләр исте. Уку йортларына таралышканчы күрешергә куешкан сүзләр тормышка ашмады. Әтисез үскән малайнын ике авыл арасында йөрергә матае булмадымы, әллә авыл егетләре туктатып кисәттеләрме, күрешә алмадылар. Наилә әзерлек курсына Казанга китеп барды, аннан институтка укырга керде. Хатлар аша да табыша алмадылар.

«Наил! Кайда син! Ничек сакладын син бу яулыкны?..»

Наиләнең ерак үткәнгә киткән уйларын бүлеп, ишектә кынгырау шалтырады. Сары яулыгын тоткан килеш, дулкынланудан кем икәнен сорарга да онытып ишекне ачып җибәрүе булды, тагын аһ итте Наилә. Бер кочак сары розалар тотып күрше Марат басып тора иде.

— Да! «Святыня» да уянды бугай, ахыр заман җитә диләр, шулдыр, шулдыр, — дип мыгырданды ул, кулындагы чәчкәләрне аптыраган Наиләгә сузып. — Менә, мадам! Сезгә бирергә куштылар! Әллә ашыга, әллә ояла. Һм-м! — Марат тамагын кырып куйды.

— Кем иде ул, Марат?

Наилә баскычтан аска йөгерде. Менә хәзер, менә шушы минутта чыкмый калса, бик үкенер, гомер буе үзен гафу итә алмас, бик якын кешесен җуяр сыман тоелды аңа. Бер кулына сары яулык, икенчесенә сары чәчкәләр тотып, Наилә подъезд ишегеннән урамга атылып чыкты. Чыгып та басты, баскан урынында катып та калды. Ишек алдында аңа карап, елмаеп чал чәчле Наил басып тора иде...

**Миңзифа ӘХМӘТШИНА**

---

## Оят белән оятсызлык чиге кайда?

Аптыраганнан, гаҗизлектән язуым ла бу минем. Ялгызлыктан сорар кеше булмаганлыктан. Ялгыз дип, әти-әнием дә, апам белән сенлем дә бар үзе. Укыган җиремдә дә кызлар белән сөйләшкәлим болай. Ләкин артык бер сүз ычкындырудан да куркып торам инде, ачылып сөйләшүне әйткән дә юк. Хатын-кызлыкка караган бер соравымнан бүлмәдәге кызлар атна буе көлделәр әнә.

Миңа укуы читен түгел, эштән дә курыкмыйм, мина яшәве читен. Бигрәк тә кыз бала булып. Кызлар ничек яшәргә тиеш хәзер? Бу турыда сөйләшкәндә хәтта әти белән әни дә бәхәсләшеп китәләр. Муллалар да бер төсле генә анлатмыйдыр шикелле. Ә укытучылар бөтенләй берни сөйләми. Общежитиедәге кызларны тыңласам, кызарып бетәм. Егетләр дә гел бериш, әйткән сүзләре колакны тырный, әйтеп җиткермәгәннәре чырайларына чыга... Телевизорны ачсам, янә аптырашка калам.

Минем өчен итәкнең кай җирдән булырга тиешлеге генә дә бик авыр, газаплы мәсьәлә.

Әхлак, әхлак дип сөйлиләр, тик кайда соң ул оят белән оятсызлыкның чиге?

Миңа да яшәргә кирәктер бит. Күнелем дә ымсынгалап куя, йокламый чыккан төннәрем дә була. Картаеп бетәм бит инде, быел 22 тулды менә...

**Сания Г.**
**Чаллы.**


## Юраганнары юш килгән



*Б.Кустодиев*

Мәшһүр рәссам Б.Кустодиев театр өчен декорацияләр ясау белән дан казанган шәхес иде. И.Репинның талантлы шәкерте, башта портрет остасы буларак танылса да, соңыннан ул бу жанрга сирәк алына торган булган. Алынса да, үзенә якыннар, абруйлы, күренекле шәхесләрнең генә портретларын ясаган. Әлбәттә, аның иҗат җимешләре бик югары бәяләнгән, акчаны бик юмарт түләгәннәр аңа.

1922 елда берчак аның янына беркемгә дә билгеле булмаган ике яшь егет килә. Алар үзләрен ярлы, күп акча түли алмаячак студентлар дип таныталар. «Сез һәрчак мәшһүр кешеләрнең генә портретларын ясыйсыз. Менә безнең, берninди исемебез булмаган кешеләрнең парлы портретын ясагыз әле. Кем белә, бер заман безнең исемнәребезнең дә дөньяга танылуы ихтимал бит», — дип шаярткан болар. Чын зыялы һәм бик гади кеше булган Кустодиев шунда ук эшкә тотынган.



*П.Капица*

Шаккатмалы хәл: егетләрнең икесе дә соңыннан дөньякүләм танылган олы галимнәр булып чыга бит. Берсе, Капица Петр Леонидович, физиканың ике яңа юнәлешен иҗат итүдә актив катнашкан академик ул, Англиядә ундүрт ел буена фәнни командировкада булып, кайткач СССР Фәннәр Академиясендә Физика проблемалары институтын оештыра, аның беренче директоры булып эшли. Ике кабат СССР дәүләт бүләгенә, 1978 елда дөньядагы иң абруйлы Нобель бүләгенә, ике кабат Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек дип табыла. Мәшһүр галим, искиткеч фән эшлеклесе булу белән бергә, техника үсешенә дә саллы өлеш керткән иде ул, аның кварцтан нечкә җеп булдыру ысулы турында бер язган идем инде.



*Н.Семёнов*


Семёнов Николай Николаевич та, фәнни тикшеренүләре белән дөньякүләм танылган академик булып үсте, химик физика дигән яңа фәнне иҗат итеп үстерүдә зур роль уйнады. Ул да, дусты Капица шикелле, ике кабат Социалистик Хезмәт Герое исеменә, ике кабат СССР дәүләт бүләгенә һәм Нобель бүләгенә лаек дип табылды. Өстәвенә Ленин премиясе дә аның бүләкләр җәдвалын бизәп куйды. Чылбырлы реакцияләр тәгълиматен бу галимнең казанышлары арасында иң күркәме дип атарга була.

Шунысы да игътибарга лаек: бу галимнең икесе дә озын гомерле булдылар, туксан яшьләренә тиклем актив, киеренке иҗат мохитендә яшәделәр. Яраткан эшең белән мавыгып яшәү гомерне озайта дип психологлар күптән раслаганнар иде. Бу ике галимнең тормыш юлы шундый фикер өчен менә дигән мисал булып тора.

Рәссам, егетләрнең парлы портретын язганда, менә, беркемгә дә билгеле булмаган кешеләрнең дә рәсемнәрен тарихка калдырам бит әле дип уйлагандыр, мөгаен. Рәссамга язмыш, ни дисәң дә, бик күркәм шәхесләрнең генә портретларын язарга насыйп булган шикелле. Егетләрнең шаярып юраганнары юш килгән.

**Ким ШАКИРОВ**

**Ребусны чишсәгез, француз язучысы Эдмон Гонкурның канатлы сүзләрен укырсыз.**




Зөфәр ХИСАМОВ *төзеде,*
*Буа.*

***Узган сандагы ребусның җавабы:***

«Хатын-кыз мәхәббәтен кырык ел саклар, сөймәгәнен сәгатендә үк әйтеп бирер».

---

*«Ак җилкән»гә хат язу өчен адрес:*
*420066, Казан, Декабристлар ур., 2, «Казан утлары», «Ак җилкән».*
*E-mail: kazanutlari@yandex.ru*

## Печән Базары

Мөнир
Абдуллин

# БАШЛЫК КИЛГӘЧ

«Аккаен» агрофирмасы директоры Сәетҗан Исламов гадәттәгечә иртүк тиз генә терлекчелек фермаларын, техника паркын әйләнеп кайтты да чакырылган кешеләрнең барысын да үз бүлмәсенә дәшеп алды.

— Иртәгә терлекчеләр җыелышы, — диде ул. Җыелышка Самат Шәйдуллович үзе килә. Доклад укылып, башлык чыгыш ясагач, алдынгыларга бүләкләр тапшырылгач, ашханәгә бергәләп чәй эчәргә керәбез. Сезне чакыруымның сәбәбе шул: җыелышта күп сөйләп вакыт үткәрмәбез, әйтәсе сүзегезне табын янында әйтерсез. Авызыгызны йомып утырмагыз, башлык безгә бик еш килми. Инде килгән икән, мине уңайсыз хәлдә калдырмагыз, сүзегезне өздереп әйтегез. Самат Шәйдулловичның йөрәгенә акмай булып ятарлык булсын. Мин үзем тостымны терлекчелектә ирешкән уңышларыбызны яңа башлыкның эшкә яңача тотынуы, бу тармакка моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә игътибар бирелүе белән бәйләрмен. Аның исәнлегенә бер стакан, юк, бер рүмкә тотып куям диярмен. Гафият, рүмкәләр бик кечкенә булмасын. Ашханәдә табылмаса, берәрсеннән алып торырсың. Самат Шәйдулловичның рүмкәсенә тидереп алуга чыңлап китәрлек булсын. Колагың ишетсен, сиңа кат-кат әйтеп тә таманга туры килә!

Икенче көнне җыелыш билгеләнгән вакытта башланып, доклад укылып, башлык сөйләгәч, алдынгылар бүләкләнгәч, берничә хезмәт алдынгысы чыгыш ясагач, халыкның бер өлеше хуҗалыкның ашханәсенә җыелды. Сәетҗан Исламов тост әйтеп, бераз ризыктан авыз иткәч, сүзне агрофирманың баш зоотехнигы Садри Рәхимовка бирде. Садри теләр-теләмәс кенә торып басты:

— Нәрсә генә әйтим икән инде, авылдашлар. Бер генә рүмкәдән соң сөйләве авыр булыр. Хатын да, башка вакытта авызыңнан сүзең чыкмый, кызмача кайтсаң, үрдәк ите ашаган дип белерсең, лыкы-лыкы сүзең бетми, ди. Самат Шәйдулловичның безгә килүе әле беренче тапкыр гына.

Сез киләсе дип бөтен ферма территориясен чистартып куйдык. Сыер имчәкләрен импортный сабын белән икешәр кат юдык. Сез килә дигәч, сыер башына көнлек савым да өч литрга артты. Ярты ел түләнмәгән хезмәт

хакын да бирделәр. Сезнен безгә олы башыгызны кече итеп килгәнегез хөрмәтенә тост күтәрәм. Минем үземә күп эчәргә ярамый, кан басымы арта. Шулай да тотмыйча булмый. Кан басымы күтәрелсә күтәрелер, бер төшәр әле...

Директор баш зоотехникнын сөйләп бетергәнен дә көтмәде, сүзне иртәдән үк яхшы гына төшереп алган ферма мөдиренә бирде. Мөдир Дамир Хөсәенов торып басканчы ук сөйләргә тотынды:

— Безнен ферма иске булса да, шөкер, жимерелмичә, ишелмичә тора әле. Итен дә, сөтен дә башкалардан ким тапшырмыйбыз. Быел Ходай кушып сыерлар бозауласа, баш саны да артыр. Тик менә ясалма орлыкландыру белән эшләр бераз хөртиләнеп китте. Бөтен сыерларга да сперма житәр-житмәс. Орлыкландыру техникы Ярулла салган баштан сперма тутырылган пыяла банканы төшереп ваткан. Сүземне жыр белән тәмамлыйсым килә: әйт әле, күбәләк, бу кадәр күп эчеп армыйсын син ничек?!

— Эчеп түгел, очып, шуны да рәтләп жырлап бирә белмәден, — дип, ачуы чыккан директор сүзне тизрәк баш инженер Фәләх Закировка бирде.

Болай да күп сөйләшми торган инженер егет бер кулына рюмкә, икенчесенә чәнечке белән эләктереп алган колбаса кисәген тотып сөйләп китте:

— Без техниканы урып-жыюга елдагыдан яхшырак әзерләдек. Запчастьләр артыннан йөреп, быел мунчамны да салып бетерә алмам, ахрысы. Хатын көн дә йөрәк итен ашый. Өйгә кайтып керүгә мазут, бензин исе тарала. Өйдән куып чыгармаган хатынга рәхмәт. Бензин житкерер хәл юк. Налог түләмисез дип үткән атнада мастерскойда утны өзделәр. Аптыраган, Самат Шәйдуллович. Үземнен дә бу араларда кәефем юк, эчем китеп тора, нәрсә ярамагандыр. Кулдан килгәннен барысын да эшләрбез сезнен хөрмәткә!

Шактый гына төшереп алгач, ишек янында утырган баш агроном Сәлихжаннын да теле ачылып китте. Ул, рюмкәсен югары күтәреп, сүз сорады:

— Авылдашлар, хөрмәтле Самат Шәйдуллович, иптәш Исламов, берике генә сүз әйтим әле. Үзегез беләсез, бу елларда колорадо конгызы тәмам үзәккә үтте бит. Инде төшкә кереп аптырата. Агу сибеп тә тончыктырып булмый бит шул зәхмәтне. Мина алар шулкадәр ияләшеп китте, берсе ияреп өйгә кайткан. Ишегалдында да шул хәшәрәтләр йөри. Бер коршкорт, бер тавык, бер үрдәк ашамый аларны. Шулай да узган ел бәрәнгенен гектарыннан 90 центнер уныш жыеп алган идек. Без аны, башкалардан калышмыйк дип, 100 итеп түгәрәкләп куйдык. Ну быел колорадо конгызына каршы бөтен авылны күтәрдек. Муеннары сынгыры...

Директорнын түземлеге житмәде:

— Сәлихжан, син бик тирәнгә кереп киттен, утыр...

— Юк, әле мин әйтеп бетермәдем...

Сәетжан Исламов тиз генә сүзне түрдәрәк утыручы сыер савучы Зөбәржәткә бирде. Зөбәржәт сүзен кыска тотарга теләп. «Мин сезнен кебек матур итеп сөйли белмим инде. Эчкәнем дә юк», — дип тост әйтүдән котылырга теләсә дә, барып чыкмады. Директор үзенекен итте. Терлекче апабыз янәдән торып басты да сөйли башлады:

— Ярар инде алайса, гаеп итмәссез, бу як колагым ишетеп бетерми. Утыз сигез ел сыер савам бит инде. Бүлнискә барырмын дигән идем. Директорыбыз районнан башлык килә, беркая да бармыйсын дигәч, бармадым инде, монда килдем. Безнен күршебез Рәхимжан абый,

жыелышка хакимият башлыгы килсә, әйт әле, диде: ике авыл арасында кайчан күпер булыр икән, интегәбез дә инде, ни җәяүләп, ни машина белән, ни трактор белән үтәрлек түгел. Җимерелеп харап кына булмасак ярарые инде, Ходаем...

Директор, сүзнең бик озынга китәсен абайлап:

— Зөбәрҗәт апай, аңлашылды, сөйлисе кешеләр син генә түгел монда, утыр, — диде.

Зөбәрҗәт директорның ни әйткәнен ишетеп бетермәде. Сөйләвен белде:

— Үзебезнең авыздан өзеп тә дәүләткә сөт тапшырабыз, ник тапшырмаска, агрофирмабыз зарплат бирми, инде ничә айга алган юк. Пай өчен биргән ике капчык он белән генә яшәп булмый ич. — Зөбәрҗәт янында утырган иренә карады. — Ә син чамалап эч, күзләрең йомылып беткән инде! — диде.

Кемдер Зөбәрҗәтнең күлмәк итәгеннән тартты. Ул дәшми-тынмый гына урынына утырды.

Мәҗлесне алып баручы агрофирма директоры башка беркем дә сөйләмәс инде дип йомгак ясап куярга теләсә дә, эше барып чыкмады, яхшы ук мәлҗерәгән ветеринария табибы Камил Сираев кулларын болгый-болгый урыныннан торып басты:

— Мина тост әйтергә кушучы булмаса да, Самат Шәйдуллович килүеннән файдаланып, бер-ике сүз әйтергә рөхсәт итегез. Безнең терлекчеләр хәлләреннән килгәнчә тырышалар инде. Сөтне тагын да арттыру өчен мөмкинлекләребез зур. Әмма минем бар курыкканым шул: дуңгыз гриппы гына килә күрмәсен. Югары очның Төхфәт тагын чит илгә китеп барган. Авыру-мазар эләктереп кайта күрмәсен диюем...

Директорның җен ачуы чыкса да, Сираевка каты бәрелмәскә тырышып, җайлап кына әйтеп куйды:

— Камил, түгәрәклә, вакыт аз калды, Самат Шәйдулловичның китәсе бар.

— Мин болай да бик түгәрәк, Сәетҗан Кадыйрович, ни ашасаң, шул бар.

Аннары директор башлыкка сүз бирде. Башлык бер-ике сүз әйтте дә, торып ишеккә таба атлады. Аның артыннан ук директор кузгалды. Ул арада рүмкәләр, стаканнар тагын чынлап алды. Мәҗлес хуҗалык җитәкчесеннән башка гына дәвам итте. Анда катнашучыларның кайсы алпан-тилпән үз аяты белән китеп барды, кайсыларын машинага утыртып озаттылар. Ашханәдә табын әзерләүчеләр генә калды.

Халидин
Әхәтов

# НИГЕЗ КӨЧЕ

НӘСЕР

Череп җимерелеп барган койма артындагы каенга эленгән сыерчык оясы җиргә мәтәлеп төште. Вакыт галиҗәнапләренең мәрхәмәтсез һөҗүменә түзә алмыйча бетәшкән, ныклыгын югалткан карт оя көзге усал җилнең йолкуына түзә алмады — калтыранып-калтыранып торды да, үзе кебек үк күпне күргән каен ботакларына бәрелә-бәрелә түбәнгә очты. Җиргә төшеп җиткәнче берничә кисәккә таралды.

— И-и-х! — дип ыңгырашты карт каен, бергә гомер иткән дустын югалтканын аңлап — миңа да күп калмагандыр.

Оядан чыккан кош йоннары, мүк-үләннәр күптәннән көрәк кермәгән бакчага таралды. Кайсылары корыган тигәнәк, кычыткан сабакларына сарылды, җиңелрәкләре бөтерелә-бөтерелә өйнең тәрәзәләренә бәрелде. Әйтерсең йорт хуҗасын чакырып тәрәзә кагалар.

И-и-х! — дип чытырдады койма да — Шакымагыз, файдасыз. Мина терәү салырлык та адәм калмады нигездә.

Гөрләп торган чаклар бар иде бит, — дип моңсу гына шыгырдап әңгәмәгә кушылды ачылып калган өйалды ишеге. — Ишегалды чирәмендә балаларның чыр-чу килеп уйнаулары, каз бәбкәләре көтүләре, кояш күргән бозауның ишегалдын тутырып чабып йөрүе, тавыкларның дөнья бетереп кыткаклавы... Хуҗалар гүр иясе булгач читкә таралган балаларының кайтып күренгәне юк. Безнең беркемгә дә кирәгебез калмады микәнни?! Җир кадере, нигез кадере бетте микәнни?!

— Җир кадере, нигез кадере... Онытттылар инде адәмнәр ул сүзләрне. Суган фәлсәфәсе сатмагыз! — Өй түбәсенә килеп кунган карга сүзләре иде бу. Күкрәген киереп горур утырган әлеге фәлсәфәченең түшендәге каурыйлары җилдә тырпаеп-тырпаеп ала. Ул пыскып яуган янгыр тамчыларын калтыранып өстеннән коеп төшерде дә бик белдекле кыяфәттә дөньяви теманы дәвам итте: — Без һәрвакыт кешеләр янында яшибез. Алар булган җирдә без бар. Аларсыз яши алмыйбыз. Игътибар иткәнсездер, соңгы вакытта авылдагы тал-тирәкләрдә оялар бушады. Шәһәргә агыла халык. Халык артыннан безнекеләр калмый. Заманалар үзгәрде, заманалар белән адәм балалары да үзгәрде.

— Ахырзаман... — дип чыгырдады койма җилдә калтыранып.

Карга башын алга ташлады да, канатларын җәеп моңаеп утырган карт каен яныннан очып үтеп бер якка янтайган лапас түбәсенә килеп кунды.

— Менә бу җимерелеп барган лапасны төзәтергә, әнә ул череп барган нигезне ныгытырга кайтырлар дип уйлыйсызмы? Көтмәгез. Шәһәрдә яшәү шартлары башкача, анда тормыш яхшырак, цивилизация, — диде карга үзенең күп белүе белән горурланып. Өйалды ишеге ныграк шыгырдап куйды, карганың шомлы фәлсәфәсеннән аның саруы кайный башлады бугай, түзмәде:

— Нигез — адәм баласының кендек каны тамган изге җире, — диде. — Аны онытсалар ата-бабаларының рухлары рәнҗер.

— Тездән саз ерып, узарга юлы, атлап чыгарга төзек күпере булмаган караңгы авылга кайттылар ди, көт, — диде карга, һаман үзенекен тукып.

Кинәт ишегалдына капка астыннан аклы-каралы мәче килеп керде. Әңгәмәдәшләр тынып калдылар. Мәче иң элек туктап бөтен җирне беркат карап-күзәтеп чыкты, аннан соң эре генә өйалды ишегенә таба юнәлде. — Кәтән ич бу! — диде ишек шатланып.

— Йортны ташлап чыгып киткән йолкыш кайтып килә. Тьфү! — дип төкеренде карга.

Ләкин Кәтән бернигә игътибар итмичә ачык ишектән өйгә кереп китте.

Мәчеләрнең йортка кире әйләнеп кайтуларын яхшыга юрыйлар. — Әле генә моңаеп торган коймада өмет чаткылары кабынды.

— Бәрәкалла! — диде каен.

Шыгырдап капка ачылып китте. Әле генә «джип»тан төшкән гаилә күтәренеп ишек алдына керде. Зур сумкалар күтәргән әти кеше алдан атлаучы улына эндәште:

— Менә улым, мин шушы йортта туып үстем. Бабалардан калган изге җир бу. Без монда яшәячәкбез!

— Җүлә-ә-р-р! — дип акырынды карга һавага күтәрелеп.

— Җүләр-р-р!

Тик аның тавышын җирдәгеләр ишетмәде. Ямьсез аваз яңгыр болытларына ияреп юкка чыкты. Болытлар таралды. Тәрәзәләрдә биегән кояш нурлары белән бар җирдә яшәү рухы, тормыш чаткылары кабынды.

---

## Электрон почта да төпсез түгел

**Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кульъязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының электрон варианты да булу улай.**

**Хатлар исә, жинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.**

**Редакциянең электрон адресына фәкать кечкенә күләмдәге язмалар (хатлар, документлар, фикерләр һ.б.) гына кабул ителә.**

**Электрон адреска күләме 5 биттән арткан язмалар җибәрелгән очракта, почта аша аның оригиналын (кәгазьгә басылган вариантын) алгач кына әсәр кабул ителгән санала.**

# ЖУРНАЛЫГЫЗ ШӘП РУПОР, ӘММА...

Гафу итегез, әйтер сүзләрем бик күп, ләкин кәгазьгә шәпләп төшерерлек рәтем юк. Ләкин моны зарланып әйтүем түгел. Аллага шөкер, 87 яшемне тутырып йөрим. Отставкадагы подполковник, 1945 елгы Җиңү парадында катнашкан сугыш ветераны мин. Һәм – 1965 елдан бирле «Казан утлары» журналы укучысы. Ягъни инде «Совет әдәбияты» чагыннан ук укый башладым. Ул чагында Камчаткада хезмәт итә идем әле.

47 ел стажлы укучы буларак, шуны әйтергә телим: соңгы чорда (90нчы еллардан соң) кайсыбер саннарда журналның сыегая баруы сизелә иде. Шуңа эчем пошып йөри иде. Шөкер, сезгә кайсы җил үзгәрешләр алып килгәндер, кеше кызыгырлык язмалар күренә башлады, соңгы елларда. Афәрин. Минем күңелгә бигрәк тә әдәбият-сәнгать әһелләре, үз халкын үз иткән, аның өчен җиң сызганып көрәшкән затлар турындагы матур-матур язмалар һуш килде. Нигә эч поша иде? Урысчадан кирәкмәгән тәрҗемәләр, тормыш әдәпсезләре турында кызык итеп язылган романнар басыла башлауга. Шөкер, сезнең өслүбегез алышынды. Туфан Миңнуллин үзе белән, Тәлгат Галиуллин – каләмдәшләре Мөхәммәт Мәһдиев, Гомәр Бәширов, Гариф Ахунов белән бик матур итеп таныштырдылар. Соңгы документаль әсәрнең Фәрваз Миңнуллин турындагы өлеше аеруча ошады. Аның кебек тәнкыйтьчеләр нигә юк хәзер? Өметле яшьләр бар бит. Нигә үстермибез? Язучылар берлеге ни карый, дәүләт нигә ярдәм итми? Телевидениедәге шайтан туйларын туктатырга вакыт түгелме? Монда да беренче булып Фәрваз кебек кыю һәм абруйлы тәнкыйтьче сүз әйтергә тиештер, мөгаен.

Журналыгыз шәп рупор. Әмма сезгә булдыклы ярдәмчеләр дә кирәк дип уйлыйм.

Әхмәт **КАДЫЙРОВ**.
*Казан*



*Язучы Бруно Зернит, шагыйрь Әхмәт Ерикәй, журналистлар Юрий Арди, Александр Жаров Бөтенсоюз радиосында чыгыш ясар алдыннан. Мәскәү. 1957 ел.*



*Татарстанның халык артисткасы Асия Галиева. 70нче елларда алынган рәсем.*



*«Шәһри Казан» газетасының беренче баш мөхәррире Хәлим Габдулла улы Гайнуллин (1951). 1990 елда чыга башлаган шәһәр газетасын ул 5 ел җитәкләде.*



*Шагыйрь Мостай Кәрим белән Тукай клубында очрашу. Фотоны игътибар белән карагандa бик күп язучыларны һәм сәнгать эшлеклеләрен танып була. Казан. 1977 ел.*



*Бер төркем язучылар Язучылар берлегендә. Утырганнар (сулдан уңга): Лирон Хәмидуллин, Әхсән Баян, Мәгъсум Хуҗин, Туфан Миңнуллин, Салисә Гәрәева; басып торалар – Галимҗан Гыйльманов, Зиннур Мансуров, Разил Вәлиев, Ләбиб Лерон, Гәрәй Рәхим, Шаһинур Мостафин, Рәдиф Сәгъди, Данил Салихов. Казан. 2005 ел.*

### ХУШ ОЛИМПИАДА! ИСӘНМЕ УНИВЕРСИАДА!

Лондонда XXX җәйге Олимпиада 27 июльдә башланып, 12 августта тәгәлләнде. 24 — алтын, 26 — көмеш, 32 бронза медальле Россия командасы, АКШ, Кытай һәм Бөекбритания спортчыларыннан калышып, дүртенче урынга лаек булды.

Мәгълүм булганча, Олимпия уеннарында Татарстаннан 22 спортчы катнашты. Аларның 11е медаль алды. Шул исәптән, «Зенит-Казан» командасының алты волейболчысы, йөгерешче Юлия Зарипова һәм йөзүче Эльвира Хәсәнова чемпион булды. Рапирачы Камилла Гафуржановага — көмеш, мәргән Василий Мосинга һәм тхэквондо көрәшчесе Алексей Денисенкога бронза медаль бирелде.

Татарстанның яшьләр эшләре, спорт министры Рафис Борһанов фикеренчә, әлеге казаныш 2013 елда Казанда узачак Бөтендөнья җәйге Универсиадасында катнашучы якташларыбыз өчен матур үрнәк булып тора.

Август ахырында Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов Указы нигезендә бер төркем спортчылар һәм тренерлар Республикабызның югары бүләкләренә лаек булды.

### ШӘҺӘРЛӘРНЕҢ ЕВРАЗИЯ ФОРУМЫ

Казан ратушасында шәһәрләрнең Евразия форумы булып узды. Анда Россия шәһәрләре һәм төбәкләре башлыклары, ЮНЕСКО Бөтендөнья мирас комитетының Казанда узган Яшьләр моделе вәкилләре катнашты.

Кунакларны Казан мэры Илсур Метшин сәламләде. Ул 2012 елның Татарстанда Тарихи-мәдәни мирас елы дип игълан ителүен хәбәр итте. «Бу республика җитәкчелегенең мәдәни һәйкәлләрне саклауга зур игътибар бирүен күрсәтә. Барлык шәһәр җәмәгатьчелеге әлеге эшкә җәлеп ителгән», — диде Казан башлыгы.

Чарада катнашкан Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев республикада киң масштабта Болгарны һәм Зөяне төзекләндерү эшләре баруын әйтте. «Бу тарихи һәйкәлләрне дөнья стандартлары нигезендә төзекләндереп, Татарстанның һәм Россиянең мәдәни һәм музей үзәкләренә әверелдерергә телибез», — дип белдерде ул.

Бөтендөнья мирасы шәһәрләре оешмасы генераль секретаре Дени Рикар үз чыгышында: «Казан халыкара кинлектә мөһим урын алып тора башлады. Бөтендөнья мирасын саклау элементларының иң әһәмиятлеләреннән берсе — яшьләр. Казан бу яктан да үрнәк булып тора, монда бик күп яшьләр проектлары гамәлгә ашырыла», — дип билгеләп үтте.

Шәһәрләрнең Евразия форумының темасы «Мирас һәм инновацияләр» дип атала иде. Форумда катнашучылар Казан һәм башка шәһәрләр мисалында мирасны саклау, туристларны җәлеп итү, шәһәрне халыкара мәйданда таныту, шәһәрдә яшәү шартларын яхшыртырдай яңа технологияләрне кулланышка кертү турында сөйләште.

### ТАРИХИ МИРАСНЫ КАЙГЫРТЫП

Казан Кремлендә Бөтендөнья «Мәдәни һәм табигый мирасны саклау» турындагы 1972 ел конвенциясен камилләштерү һәм яшьләрнең тарихи объектларны саклау һәм популярлаштыруда ролен арттыру җәһәтеннән сөйләшү булып узды. Анда Санкт-Петербургтан рәсми вәкилләр — ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасын саклау комитеты әгъзалары да килгән иде.

Утырышта Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасын саклау комитеты рәисе Элеонора Митрофанова, ЮНЕСКО эшләре буенча Россия комитетының җаваплы сәркәтибе Григорий Орджоникидзе да катнашты. Минтимер Шәймиев үз чыгышында әлеге очрашуларның зур әһәмияткә ия булуын ассызыклап әйтте. «Безнең халыкның тормышында авыр чорлар бик күп булган, — диде ул. — Әмма хәзер бергәләп матди һәм матди булмаган мирасны киләчәк буыннарга лаеклы рәвештә тапшырып калдырырлык итеп кире торгызырга вакыт җитте».

«Бу очрашуның Татарстанда үткәрелүе юкка гына түгел, — диде Элеонора Митрофанова. — Чөнки сездә төрле мәдәниятләр һәм диннәр үзара килешеп яши. Бу яктан Татарстан башкаларга үрнәк булып тора».

Мәдәни мирасны саклау һәм реставрацияләү буенча халыкара тикшеренү үзәге генераль директоры Стефано де Каро һәм аның киңәшчесе Мөнир Бушенаки бу очрашуның төрле ил-җир кешеләренә тәҗрибә

урткаклашу мөмкинлеге бирүен әйтте. Борынгы Болгар һәм Зөя утрау-шәһәрчегенә сәфәр кунакларнын күңеленә аеруча хуш килде.

### «ТАТМЕДИА»ДА ҮЗГӘРЕШЛӘР

ТР Президенты Указы нигезендә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасын камилләштерү максатыннан, «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы бетерелде. Марат Моратов, «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе вазыйфасыннан азат ителеп, ТР Президенты Аппараты җитәкчесенең беренче урынбасары итеп билгеләнде. Агентлыкның матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә дәүләт идарәсе мәсьәләләре буенча вазыйфалары ТР Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына тапшырылды.

Шулай ук үзгәрешләр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенә дә кагылды. Генераль директор итеп Ирек Җәүдәт улы Миннәхмәтов билгеләнде.

Ирек Миннәхмәтов 1980 елның 25 декабрендә Казанда туган. 2003 елда Казан дәүләт финанс-икътисад институтын, 2008 елда Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының юридик факультетын тәмамлый. 2010 елның 10 августыннан «Татспиртпром» ААҖ генераль директорының коммерция мәсьәләләре буенча урынбасары. Моннан тыш, шәхси эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнә һәм «Чингисхан» ҖЧҖнең генераль директоры булып тора. 2008 елдан алып 2010 елга кадәр — Казан шәһәре Думасы депутаты. Өйләнгән, кыз үстерә.

### ПОЛЬША КУНАКЛАРЫ КАЗАНДА

Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов Казанда Польша Республикасының маршал Мечислав Струк җитәкчелегендәге Помор воеводалыгы делегациясе белән очрашты.

Татарстан Президенты, очрашуны ачып, күптән түгел генә Польшаның футбол буенча Европа чемпионатын кабул итүен, уеннарның Помор воеводалыгы башкаласы Гданьскида да үтүен искә төшерде. «Әлеге вакыйга югары дәрәҗәдә үтте, мондый зур чараларны үткәрү тәҗрибәсе Татарстан өчен дә кызыклы», — дип ассызыклады Рөстәм Миннеханов. Ул воеводалык маршалына татар диаспорасына ярдәме өчен дә рәхмәт белдерде. Республика башлыгы Татарстанда инде менә 14 ел дәвамында Польшаның «Ак бөркет» җәмгыяте, католик чиркәү эшләп килүен, Казан мәктәпләренең берсендә балаларның поляк телен өйрәнүен хәбәр итте.

ТР Президенты, нефть-газ-химия өлкәсеннән тыш, машина төзелеше, мәгариф, мәдәният өлкәләрендә дә Татарстан белән Польша арасындагы бәйләнешләрне киңәйтергә кирәклеген искәртте.

Мечислав Струк, үз чиратында, шушы сәфәр барышында делегация әгъзаларының инде Казан федераль университеты белән элемтәләрне җайга салырга өлгерүен дә билгеләп үтте. Ул шулай ук ТР Президентына, илләренә кайтуга ук, делегациянең Татарстан компанияләре белән хезмәттәшлек итә алырдай фирмалар эзли башлаячагын әйтте. Маршал сүзләренә караганда, биохимия, медицина, IT үзара хезмәттәшлек итү өлкәләренә әйләнергә мөмкин.

### ИНГЛИЗЧӘ ДӘ ЯХШЫ БЕЛ

Казан федераль университетының филология һәм сәнгать институтында өстәмә һөнәри белем бирү курсларын тәмамлаучыларга дипломнар тапшырылды. Әлеге укулар 3 ел дәвамында алып барыла һәм анда Казанның төрле югары уку йортларында белем алучылар инглиз телен тирәнтен өйрәнә. КФУның филология һәм сәнгать институты директоры, профессор Рәдиф Җамалетдинов диплом тапшыру тантанасында искәртеп узганча, соңгы елларда республикада ике дәүләт теле белән беррәттән, чит телне өйрәнергә теләүчеләр дә арткаңнан-арта бара. «Алар — мәктәп укучылары, студентлар гына түгел, ә төрле тармакта эшләүчеләр дә. Әйтик, быел, Татарстан Министрлар Кабинеты ярдәмендә оештырылган татар телен өйрәнү курсларында 1 меңнән артык кеше белем алды. Башка телләр буенча да шундый эзлекле эш алып барыла», — диде институт директоры.

КФУның филология һәм сәнгать институты оештырган әлеге курсны 56 кеше тәмамлады һәм мондый укулар алга таба да дәвам иттереләчәк.

### ГАВРИИЛ ДЕРЖАВИНГА — ЯКТАШЛАРЫННАН

Санкт-Петербургта Гавриил Державин музей-утары вестибюлендә бөек шагыйрьгә һәйкәл куелды. Тантаналы мәрасимдә Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов катнашты. Бронза һәйкәл «Татнефть» акчасына коелган. Рөстәм Миннеханов мәрасимдә катнашучыларны сәламләү сүзендә Гавриил Державинның Казаннан ерак түгел — Казан өязе Сокуры (Покровское) авылында тууын искә төшерде. Бөек шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесенең Россияне данлавын, туган җирләренә мәдхия җырлавын ассызыклады. «Без үз якташыбыз белән горурланабыз», — диде Рөстәм Миннеханов.

Татарстан җитәкчесе Державинның музей-утарын реставрацияләү һәм яңартып төзү эшләренә югары бәя бирде. Кунаклар өчен утар буйлап кыскача экскурсия үткәрелде, аларны аеруча кадерле экспонатлар белән таныштырдылар. Соңыннан Татарстан Президенты бөек шагыйрь һәй-

каленә чәчәкләр куйды. Чарада Санкт-Петербург татар милли-мәдәнияте мохтарияте вәкилләре дә катнашты.

### БОЛГАРДА ЯҢА ХӘЗИНӘ

Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы директоры Рафаил Мәхмүтов әйтүенчә, Мәскәү археологлары хәзинә тулы сандык тапкан. Археологик эзләнүләр вакытында белгечләр төрбә нигезенә юлыккан. Анда кабер ташы һәм көмеш бизәнү әйберләре салынган сандык та булган. Табыш XIV гасырга караган 12 берәмлектән тора. Хәзер аларны тикшерү, чистарту эшләре бара. Соңыннан әлеге беләзек, алкалар Болгар музеена тапшырылачак.

### КОРЪӘН — ИРАН СӘНГАТЕ КӨЗГЕСЕНДӘ

Казанның Ислам мәдәнияте музеенда «Коръән — Иран сәнгате көзгесендә» дигән күргәзмә ачылды. Казанлылар һәм башкала кунаклары мөселманнарның изге Китабын бизәү буенча киңкырлы сәнгать белән таныша ала. Коръән аятьләре Иранның бүгенге заман рәссамнары интерпретациясендә күрсәтелә. Күргәзмәдә Иран рәссамнарының 50дән артык әсәре тәкъдим ителә.

### МОНА ЛИЗА КАЗАНГА КИЛӘ

14 сентябрьдә республиканың дәүләт Сынлы сәнгать музее галереясында даһи шәхес Леонардо да Винчиның бар иҗатын колачлаган үзенчәлекле күргәзмә ачыла.

Җир шары буйлап сәяхәт кылучы күргәзмәдә рәссам, архитектор, скульптор, галим, инженерның гомере буе ясаган, уйлап табылган әйберләренең макетлары урын ала. Экспонатлар арасында дөньяның рәсем сәнгатендә иң танылган «Мона Лиза» әсәре дә бар.

Заманында мульти-спектраль фотокамера уйлап тапкан француз инженеры Паскаль Коттега үзе ясаган сканер кулланып атаклы картинаны рамсыз, пыяласыз гына төшерү мөмкинлеге биргәннәр. Өч сәгать дәвамында Паскаль 13 фото эшләгән. Әлеге уникаль фотолар белгечләргә картинаның егерме биш серен ачарга ярдәм итә.

Проектны оештыручылар раслаганча, дөнья буйлап сәяхәт кылучы «Даһи да Винчи» күргәзмәсе Җир шарының унлап илендә булган. Аның иҗаты белән якыннан Мәскәү, Санкт-Петербург тамашачысы да танышкан инде.

### ДИВАРЛАР СӘНГАТЬ ӘСӘРЕНӘ ӘЙЛӘНӘ

Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов башкалабызда Like it Art фестивалендә катнашучылар — граффити осталары эшләре белән танышты. Республика башлыгы фестиваль мәйданчыкларының берсендә булып, урам рәссамнары белән аралашты.

Әлеге фестиваль Казанда шәһәр мэриясенең рәсми ярдәме белән уздырыла. Анда Россия, Италия, Болгария, Польша, Германия кебек илләрнең рәссамнары катнаша. Фестивальдә катнашучылар өчен шәһәрнең зур объектлары билгеләнгән, аларда граффити сурәтләре урын алачак. Фестивальгә чакырылган рәссамнар Казанның 27 мәйданчыгында эшли. Яңа Савин районындагы күпкатлы йортлар диварларында аеруча киң колачлы рәсемнәр пәйда булды.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткәне өчен язучы **Хәбибуллин Габделәхәт Габделхәй улына** «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татар халкының мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклап калуга һәм үстерүгә, милләтара татулыкны ныгытуга зур өлеш керткәне өчен Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары — Россия Федерациясе төбәкләренең татар җәмәгать оешмалары белән эшләү бүлеге башлыгы **Тукаев Марс Рифкат улына** «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Быелның 24 августында Мәскәүдә Муса Җәлилгә һәйкәл ачылды.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Әхәт Хәбибуллин**.

# Яңа китаплар




**XX гасыр татар әдәбияты тарихы: ике китаптан торган дәреслек/ Төзүчеләре: Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. - Казан: Казан университеты, 2011.**

Китапларда XX гасыр татар әдәби барышындагы төп тенденцияләр һәм закончалыклар күзәтелә, милли иҗади үзаннын хәрәкәте, юнәлешләре традицияләр ачыклана. XX йөз татар әдәбияты тарихын тикшерү билгеле бер этапларга күзәтү (обзор) һәм чор әдәбиятында күренекле әдипләр иҗатын монографик анализлау рәвешендә алып барыла. Һәр этапның үзенчәлекләре белән янәшә гомуми әдәби барышка хас сыйфатлар билгеләнә.

Беренче китапта Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал, Дәрдмәнд, Г.Ибраһимов, Ш.Камал, Һ.Такташ, Гали Рәхим, К.Тинчурин, М.Галәү, Х.Туфан, М.Җәлил иҗатлары анализлана.

Дәреслекнен икенче китабында XX гасырнын икенче яртысы татар әдәбиятына күзәтү ясала (1956 - 2000) (И.Юзеев, А.Гыйләжев, Т.Миңнуллин, Р.Фәйзуллин, Ф Садриев, З.Хәким, Ф.Бәйрәмова).

Дәреслек югары уку йортларында «Филология» белгечлеге буенча белем алучы студентларга һәм татар әдәбияты тарихы мәсьәләләре белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә.



Әхәт Хәбибуллин

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)